ТӘҮФИКЪ КӘРИМОВ

ПУБЛИЦИСТИК ЯЗМАЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2009

УДК 821-512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4
К95

Тәрҗемәчесе *Флёра Тарханова*
**Кәримов, Т.Ә.**

Төсләр балкышы : публицистик язмалар / Т.Ә.Кәримов ; тәрҗ. Ф.Тарханова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 272 б.
ISBN 978-5-298-01879-1

Бу – бер караганда, бергә бәйләү мөмкин булмаган өлкәләрне: бала һәм үсмер чак, Ватан турында җирсү һәм юксынусагынуга корылган шигъри проза, кешене шәхес буларак бәйләүче җылы эссе, серле дөньяга кереп китә торган «сюрралар», җитди тарихи хезмәтне һәм башка темаларны берләштергән китап.
Гаять төрле һәм кызыклы, үткәнебез турында тарихи чыганакларга нигезләнгән җитди әсәрләр һәм лирик истәлекләр киң даирә укучыларга шактый бай мәгълүмат бирер, дип ышанабыз.

УДК 821-512.145-4
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01879-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Кәримов Т.Ә., 2009

СҮЗ БАШЫ УРЫНЫНА

«Һәр кеше мәсләк, фикерләр ирегенә һәм аларны ирекле рәвештә белдерүгә, чагылдыруга хокуклы; бу хокук бернинди каршылыкларсыз үз фикереңдә нык тору ireген һәм теләсә нинди чара, юл белән, хәтта, дәүләт чикләренә дә карамыйча, мәгълүмат, идеяләр эзләү, табу һәм тарату ireген үз эченә ала».

*Кеше хокукларының гомуми*
*декларациясе, 19 нчы маддә*

*** * ***

Бу китапта язылганнарның барысы да – минем тормышымның, уй-хисләремнең, эчке кичерешләремнең бер кисәге, бер өлеше.

Аны ашыгып, кабаланып укыма – уйлан, күзалла: анда син үзеңне дә, хисләреңне, борчу-кичерешләреңне дә күрерсең, тоярсың.

Чөнки безнең барчабызның да тамырларыбыз, килеп чыгышыбыз – бер нигездән, безнең һәммәбезне дә дөньяга яраткан, барлыкка китергән, барыбыз өчен дә Бер булган Хода – Бер Югары Аң; Ул – безнең янәшәдә, бөтен җирдә, безнең һәрберебездә.

Бу очракта безнең аерма бары тик шунда: мин – бу китапның язучысы, син – аның укучысы.
*Автор*

**ЕВРАЗИЯЛЕ –**
**МЕҢЬЕЛЛЫКЛАР КИСЕШЕНДӘ**

Сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган бу китап гомеренең иң матур һәм хисләрне инде акылына төреп эш итү чорына кереп баручы мөлаем казахстанлы, Европача белем алган һәм нәсел тамырлары белән Казан җиренә килеп тоташкан булуын йөрәк түрендә нык саклаучы, аны беркайчан да хәтереннән чыгармаучы автор дусларының шактый киң даирәсендә генә түгел, ә бәлки, төрле катлау укучыларында да зур кызыксыну уятыр.

Бер караганда, бер-беренә һич бәйләнеше булмаган балачак һәм Ватан турындагы сагышлы шигъри прозасы, бетмәс-төкәнмәс гаҗәеп матур төш кебек, бөтереп ала, әсәрләндерә торган әдәби һәм бер үк вакытта гап-гади кеше – Высоцкий турындагы эссе, сюрралары, җитди тарихи хезмәте, профессиональ дәүләт хезмәткәренең сәясәткә кагылышлы һәм башка бик күп язмалар тупланган бу китап эклектикадан һәм бар нәрсәне дилетантларча колачлаудан ерак тора, дип ышандыра алабыз.

Әйе, сүз дә юк, сездә Тәүфикъ Кәримов белән бәхәскә керү теләге дә туарга мөмкин. Аның сәнгати иҗаты югары интеллектуаль һәм жанрларга бүленми; әдәбият законнарына караганда күбрәк музыка законнарына нигезләнә, буйсына. Билгеле, болай итеп язу бар кешенең дә хәленнән килми.

Белгәнебезчә, мондый аралаш иҗат күпләрнең күңеленә тия, ачуын кабарта. Кәримовның гомумхалык байлыгы булып тоелган Высоцкий җырлары, рок һәм футбол турындагы эсселарының гадәти, традицион булмаган шәхси стиле безне тагын да ныграк ярсытырга мөмкин.

Тик бу эсселар авторы белән бәхәсләшү, дәгъвалашу җиңел булмас. Ясаган барлык нәтиҗәләрен, фикри йомгакларын ул аргументлар белән генә түгел, ә бәлки, саллы фактура (библиография, хронология) белән дә ныгытып куя.

Безнең карашка, китапның иҗтимагый әһәмиятле һәм бер үк вакытта бәхәсле өлеше – Тәүфикъ Кәримовның үз этносы тарихына – бүгенге көндә Казан татарлары булып йөргән болгарлар һәм үзенең нәсел тарихына багышланган «Хәтер сандыгыннан» дип аталган дүртенче темасы.

Хәзерге вакытта барлык нәшриятлар да, редакцияләр дә шыплап тулган үзбелдек тарихчыларның бихисап «иҗат җимешләре»ннән аермалы буларак, бу – иң кыргый теорияләрне дәраслаучы (әмма дәлилли белмәүче) Ходай илһамландырган экстатик сүз чәчмәсе, шулай ук шаман камланиясе дә түгел, ә чын-чынлап зур хезмәт.

Авторның кайбер аргументлары яки нәтиҗәләре белән ризалашмыйча, аларга каршы килергә дә мөмкин, әмма бәхәскә керүчеләргә җиңел булмаячак, чөнки аның белән тигез дәрәҗәдә көрәшү өчен һәр мәсьәләдә аннан да күбрәк һәм тирәнрәк белергә кирәк.

Тәүфикъ Кәримов бу китабы белән Татарстан Республикасының төп халкы һәм башка төрки халыклар этногенезы турындагы әдәбиятка үз өлешен кертер, дип уйлыйбыз.

Китапның тулаем субъектив, шәхси характерда булуы – аның төп сыйфаты, дәрәҗәсе, чөнки чор да, төбәкләр дә, кеше дә бер-береннән башка яши алмый, алар бәйләнеше бәхәссез.

Узган меңьеллыкның икенче яртысында Европа белән Азия чиге үтә торган шәһәрдә дөньяга килгән Тәүфикъ Кәримов – яңа, дөресрәге, яңарыш кичергән Казахстан дәүләтчелеге төзелешенең гади шаһиты гына булмыйча, ә бәлки, аны төзүдә актив катнашучы да. Ул – сәясәт белгече, шуңа да Халыкара бердәмлек аңа 1996 елда Россия Федерациясе Президентын сайлауларда күзәтче булуны ышанып тапшырды.

Энциклопедик белемле, талантлы, күзәтүчән – нәкъ менә шул сыйфатлар автор иҗатын Евразия континентында үзгәрешләр чорының саллы, игътибарны җәлеп итә торган документы итә дә инде.

Бу документның төп өстенлеге шунда: сез аны зур кызыксыну белән бер утыруда укып чыгачаксыз.

Чөнки без барыбыз да евразиялеләр, Кәримов үзе дөрес күрсәткәнчә: «...бу очракта безнең аерма бары тик шунда: мин – бу китапның язучысы, син – аның укучысы».

## ТӨСЛӘР БАЛКЫШЫ

*Күңелемне сагыну –*
*сагыш басты –*
*Хәлләремне ала талкышы.*
*Яшьлегемнең гүзәл мизгеленә*
*Алып китте төсләр балкышы.*
*(Ф.Тарханова, 2008)*

## ТӨСЛӘР БАЛКЫШЫ

Мюнхен. Туксан өченче елның көзге киче. Күңелдә давыл.
Сагыш белән әрнү йөрәкне телә.
Посткоммунистик һәм демократик дәүләтләрдә яшәү дәрәҗәсе нык аерыла.
Яхшыруга бернинди өмет юк.
Һәрхәлдә, алдагы ун елда бу аерма әле күбрәк булмаса...

Ирексездән В.Высоцкий җырларының сүзләре искә төшә: күңелләрне айкап ташлый, әйтерсең лә яшәеш юкка чыккан, шулкадәр авыр, җан өзгеч композицияләр Jefferson Airplane, Black Sabbath, Led Zeppelin, Shocking Blue, Pink Floyd...

Өйгә кайтасы килә... Гаиләмә, хатыным һәм балаларым янына.

Уйларым мине тагын да ераккарак – мәктәп елларына, бала чакка алып китә...

Чәчкәләрнең бөтен төсләре балкыган, кояш нурлары уйнаган, кырмыскалар, чикерткәләр яшәгән, ышаныч булган җиргә...

...Кая китте бер шук малай –
Кайчандыр мин булган малай?..
Әйтегез, картлык – җәннәтме,
Әллә җан кыйгыч җәлладмы?

Кошлар кая китеп үлә,
Беләмсең сентябрь яшен?
Зур дәрьялар аңлый микән
Әйткән сүземнең мәгънәсен?

Яшь яфраклар язгы җилгә
Ниләр диеп җырлый икән?
Үлемне кайсы җибәрә –
Күкләрме, әллә Җир микән?

Төннәрне ярып кем үкси –
Кеше яки берәр кошмы?
Төнендә күргән Йолдызның
Исемен ничек дип куштың?..

...Чынлап та, бала чакта дөнья нинди булган?

Дөресрәге, дөнья бала чакта ничек кабул ителгән?

Якты, кояшлы, шәфкатьле, төсле, чиста, кызыклы һәм күңелле булып.

Киләчәк көн тагын да әйбәтрәк, тагын да кызыклырак булыр. Аннан соң да – тагын да, тагын да, тагын да...

Көн үзе озын булып тоела, ә Тормыш исә, сүз дә юк, чиксезлеккә омтыла.

Шулай итеп, дөньяда, тирәлегеңдәге бар нәрсә – үз урынында: син – бу дөньяда, әйтерсең лә синең өчен генә билгеләнгән һәм урнаштырылган тәртиптә иң мөһиме.

Җиһанда ата-анаңнан да яхшырак, миһербанлырак һәм матуррак беркем дә юк...

Боларның барысында да, нигездә, Синдә – һичшиксез, ышаныч.

Ул, туган вакытында ук кешегә кереп, бала чагында ныгып кала, әйләнә-тирә мохитне кабул итәргә булыша, холкын формалаштыручы, калыплаучы, башкаларныкыннан аерылып торучы сыйфатлар ала да аннан соң гомер буе синең белән бергә, синең җаныңда яши...

Менә шулай итеп, кеше аны – үзенең эчке ышанычын, өметен, «бәлки, соңгысы чынга ашар» дигән ышанычын – үзе сүнгәнче күңелендә йөртә.

Бернигә дә карамастан, аның ышанасы килә, һәм ул ышана да – гомере буе, һәрвакыт.

Шуңа күрә дә ул иң соңгы булып, җан тәслим кылганда гына, соңгы уй белән бергә китеп бара, сүнә...

Ә бала чакта бар җиһан, чынлап та, бары тик төсләр аша гына күренә.

Хәтта төссез сорысы һәм пычрагы да...

Өлкәннәрдә исә соры инде төс түгел. Саналмый төс булып.

Ул бөтенләй икенче мәгънәгә, төсмергә ия.

Төсле буяулар бала чакта күптөрле булып күренсә, үсә барган саен алар саны сизелмичә генә кими башлый.

Дөнья тарая – кысаларга керә, төсләр, чикләр, мөмкинлекләр азая...

Һәм сиңа дөньяны танып белү авырлаша, нәтиҗәдә салават күперенең барлык төсен дә хәтерләп һәм санап чыгып булмый башлый.

Һәм дөнья, ахыр чиктә, бары тик аклы-каралы булып кына кала, башкалар бернинди игътибарны да җәлеп итми...

Моннан соң инде Чәчәкнең бөтен матурлыгын, аның таҗ яфракларында, сабагында «кайнаган» тормышны, эчтә йөргән Камканы, шунда ук очып килеп кунган һәм, сине күрмәгәндәй, сиңа бөтенләй игътибар итмәгән Төклетураны элеккечә күрү мөмкинлеге беркайчан да тумас.

Ә бәлки, күрә дә торгандыр, әмма ул сине барыбер бала дип кенә кабул итә.

Шуңа күрә ул куркытмыйча гына, йомшак итеп кенә бызылдый, әйтерсең лә үзе өчен генә, үзенең күңеле булсын өчен генә...

* * *

*...Кайчан да булса мондый манзараны тагын бер мәртәбә күрергә, үземнең әбием утырткан чәчкәләрнең һәр төсен, зәңгәрсу һәм сары таҗлары төсмерләрен тоярга, бөҗәкләрнең кеп-кечкенә дөньясын гаҗәеп зур итеп күрергә мөмкин булыр микән? Әйтерсең лә бу – без яшәгән дөньяда иң әһәмиятле, иң мөһим бернәрсә...*

*Мюнхен, ноябрь, 1993*

## «МАКАБКА БАБАЙ»

...Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары туп-туры битемә килеп кагылды. Аның иркәләвен, җылысын тоеп, уянып киттем.

Торасым килми.

Әмма кояш нуры мине тынычлыкта калдырасы итмәде булса кирәк – күзләремне камаштырырга кереште. Мин, аннан качарга теләгәндәй, күзләремне кыстым, һәм, еш-еш бер ачып, бер йомып караганда, үземнең сирпелеп-сирпелеп киткән озын керфекләремне тойдым.

Өйдә беркем дә юк. Бары тик стенадагы сәгатьнең келт-келт йөрүе генә ишетелә.

Бүлмәдә рәхәт, чиста һәм салкынча.

Балаларны, гадәттә, көндез йоклатып алалар бит, мин дә көпә-көндез йоклап яткан җиремнән уянып киттем.

Урынымнан тордым да урамга чыгар өчен ишеккә таба атладым. Ишекне ачкан гына идем, шундук, уяныр-уянмас халәттә, йокымнан айнып җитмәгән килеш, яңадан күзләремне кыстым, һәм мин чын-чынлап кояшлы, җылы җәйгә, бала чакның гаҗәеп серле һәм кабатланмас дөньясына килеп кердем.

Июнь башының гадәти бер көне иде.

Эссе көннәр һәм чиллә башланмаган әле. Полкан, кояш нурларыннан качып, үзенең өе артына кергән дә күләгәдә йоклап ята. Табагыннан аз-азлап тиз йотымнар белән су эчеп торучы чыпчыкларда аның эше юк.

Башымны күтәреп карасам, өебез кыегында миңа текәлеп карап торучы ике соры чыпчыкны күреп алдым. Моңарчы ни турындадыр чыркылдашкан бу ике чыпчык, мине күрүгә, шып булды.

Шул мизгелдә баш очымнан ук төклетура бызылдап очып үтте.

*«Кая юл тотты?»*

Карашым веранда каршына әбием утырткан аксыл-зәңгәр чәчкәләрнең әллә ни зур булмаган куагына төште.

Акрын гына килеп чүгәләдем дә аларны күзәтә башладым.

Менә шул кечкенә генә җир һәм үлән кисәгендә тормыш кайнавын күрдем.

Яшел сабаклар буйлап дымлы җирдә көрән кырмыскалар чабыша, һәрберсе үзеннән зур йөк күтәргән: саламы да, чебен белән озынборын да бар анда.

Камка Тутай, кызыл канатларындагы ак таплары белән мактанып, яфракка ябышкан да нәрсәдер яки кемнедер көтә...

*«Теге төклетура кайда соң?»*

Уйлап куюым булды, куркудан кинәт читкә сикердем: чәчәкләр арасыннан, усал бызылдап, берьюлы берничә төклетура очып чыкты.

*«Кызык, алар анда нишли икән?»* дигән уй кызыксынуымны арттырды.

Кулыма салам алып, яңадан чәчәкләр янәшәсенә чүгәләдем.

Төклетуралар, минем үзләре янында булуыма ризалашып, эшкә кереште. Җиһандагы барлык бөҗәкләр кебек үк.

Алар, зәңгәрсу чәчкәләр эченә берәм-берәм кереп, үзләренең хортумчыклары белән шифалы сут җыялар.

Төсләре – сары. Үзләре юан булсалар да, чәчәк эчендә җиңел генә, ашыкмыйча гына, бызылдаша-бызылдаша хәрәкәтләнәләр, вакыт-вакыт бер чәчәктән икенчесенә күчеп китәләр...

Кинәт ерактан, хәзер сарай булып кына калган иске йорт ягыннан, әбиемнең тавышын ишеттем. Ул, көлә-көлә, кемгәдер татарча нидер сөйли иде.

Мин, ашыкмыйча гына, аның янына киттем.

Яшелчә, җиләк-җимеш бакчасы аша эти түшәгән такта сукмактан.

Уң якта – яшь йөзем агачлары, сулда – әле яңа гына ныклап үсеп киткән помидорлар, кыярлар.

Әбием җиргә җәймә белән клеенка җәйгән дә самавырдан агызып тәмләп кенә чәй эчә. Үзе үрмә гөлләр белән уралган кетәклектә мәтәлә-мәтәлә йөгерешеп йөргән кечкенә йомшак кошчыклар – чебешләрне елмаеп күзәтә...

Мин анының янәшәсенә килеп утырдым, һәм без хәзер икәүләп чәй эчәбез. Шакмак шикәр һәм җәймә белән. Үз телебездә шаян сүзләр әйтешеп. Кетәклек буенча аңгыраеп һәм чыелдашып куышып йөргән бәхетле сары чебиләрне, котырынган үз токымын тимер челтәр аша аптырашып карап торган инде җитлеккән тавыкларны әллә кызыксынып, әллә кызгану белән күзлибез.

Инде үсеп җиткәннәр өчен моның ни аңлатканын төшенгән сыман...

...Шунда ук самавыр янәшәсендә Урал елгасына коенырга чапкан абыемнар калдырган ике китап ята.

Инде күптән укылган әлифбаның төсле битләрен тиз генә актарып чыккач, кулыма кызыклы һәм исеме аңлашылмый торган «Минем беренче китапларым» сериясеннән «Макабка бабай» («Дед Макабка») дигән юка гына китапны алдым.

Һәм ашыкмый гына, иҗекләп укый башладым. Анда да җәй, каникуллар, әби һәм онык...

Әйе, быел көзгә миңа да мәктәпкә, беренче сыйныфка...

*** * ***

*Бу китап миндә әле дә саклана.*
*Документлар һәм башка кыйммәтле кәгазьләр белән шкафта ята.*
*Бала чакның мәрхәмәтле китабы.*
*Тик бераз саргайган гына. Минем беренче китабым – минем яшьтәшем.*
*«Детгиз», бер мең тугыз йөз илле сигезенче ел...*

*Мюнхен, ноябрь, 1993*

## ӨРӘҢГЕ ЯФРАГЫНЫҢ КӨЗГЕ РЕГТАЙМЫ, ЯКИ ГАДИ ГЕНӘ ӘЙТКӘНДӘ – ЯФРАК

...Җәй көзгә авышты.

Көзнең якынаюы бөтен нәрсәдән сизелә – суытты, дымлы һава, салкын җилләр еш исә, кояш та инде элеккечә җылытмый.

Агач яфраклары әле күптән түгел генә ачылып киткән кебек иде, шул арада кинәт олыгаеп, картаерга да өлгерде: сары төскә кереп, корый да башлады.

Шуңа күрә аларның да күңеле боек: агачларның үзләрен дымлы, салкын җиргә коярга теләвен сизенәләр кебек...

Әйе, бәлки, шулайдыр да.

Кайчандыр яфраклары белән шаулашып утырган агачлар хәзер, бәлки, чынлап та алардан арынырга, тынычлыкта калырга телидер.

Ә яфраклар исә, бөрешеп, агач ботакларына ябышкан хәлдә, өзелеп төшкәндә түзә алмаслык авыртуны көтеп җилферди...

Менә шундый киеренкелектә алар эленеп тордылар да, кинәт кенә җиңелчә исеп киткән җил аларны агачларыннан бернинди авыртусыз өзеп алып, һавага очыртып җибәргәнен сизми дә калдылар.

Бу гаҗәеп бер күренеш иде: яшел төсен югалтып корышкан, сарыларга «сабышкан» яфрак, берни дә аңларга өлгермичә, нәкъ төштәге кебек, үзенең соңгы очышында тирбәлә, һәм шулай тирбәлә-тирбәлә, бөтен җәй буе бер горурлык һәм ышаныч белән, яшьләрчә дәртләнеп шаулап утырганын гына исенә төшергәндер...

Шул вакыт кечерәк кенә бер өермә безнең бу яфракны әйләндерә-әйләндерә һавага күтәрде, һәм ул үз агачыннан гына түгел, хәтта урманның үзеннән дә биектәрәк оча башлады.

Әүвәл аңа куркыныч булып китте, аннан, инде кипкән булса да, үзенең барысыннан да югары булуына горурлык хисе тойды.

Әйтерсең лә менә шуның өчен генә булса да үз агачыңнан өзелергә һәм күкләргә очарга җәл түгел дип уйлап куйды...

Әмма анының үз-үзенә соклануы озакка бармады, һава агымында әле уңга, әле сулга чайкала-чайкала, кырдырып түбәнгә оча-оча туп-туры суга килеп төште.

Һәм йөзеп тә китте...

Елга агымы аны ашыкмыйча гына үзе белән агызып алып китте.

Яр буйларында кырлар, урманнар күренеп калды, һәм яфрак, зур кызыксыну белән, нindидер яңаны танып белә иде кебек...

Аңа кабат бер уй килеп төште: үзе белән агачын бизәп, матурлап, ямьләп күпме вакытын әрәмгә үткәргән, баксаң, әле анының барысы да алда икән бит...

Тик бу юлы да бик тиз исенә килде: юешләнеп һәм авыраеп, ул бата башлады.

Һәм шул мизгелдә яфрак үзеннән алда ярга килеп терәлгән бүрәнәгә ябышты, ул аны коткарып калды.

...Суның сай урынында, елга яры буенда шулай икәүләшеп озак яттылар: берсе – кайчандыр агач булып үскән бүрәнә, икенчесе – үз агачыннан ташланган, инде корып төсен югалткан, аздан гына суга батмыйча калган яфрак...

Яфрак, сагышка чумып, шундый ук нык, биек, көчле һәм мәрхәмәтле, яз көне аңа яшәү биргән, үзенең нык тамырлары белән туфрактан дым тарткан, кечкенә генә бөрене саклап һәм үстереп гаҗәеп матур яшел яфракка әйләндергән үз агачын исенә төшерде.

Әле күптән түгел генә үз агачы турында әллә ни матур уйда булмавы өчен аңа оят булып китте, аны тудырган агачын, үзенең бердәнбер һәм соңгы җәен уйлый-уйлый, үзен коткарып калган бүрәнәгә ныграк сыенды...

*Мюнхен, 14 гыйнвар, 1994*

## БАЛА ЧАК РӘСЕМНӘРЕ

Алтмышынчының икенче яртысы.

Көз ахырына якынлаша.

Эңгер-меңгер.

Күк йөзе өскә ишелергә торган сорылы-каралы яшен болытларына уралган.

Мин (ул чакта миңа сигез-тугыз яшь иде) өйдә, тәрәзә каршындагы өстәл янында утырам һәм күкне күзәтәм: кинәт кайдандыр өстән, җир белән күкне аерып торган караңгы һәм серле бушлыктан салмак кына һәм тавышсыз гына ап-ак юеш кар бөртекләре төшә башлады.

Алар, очып төшә-төшә, безнең өйгә керә торган баскыч өстендә берүзе эленеп торган һәм Урал елгасы ярында урнашкан өебезнең караңгы, буш ишегалдын яктыртып торучы лампочка яктысына килеп җиткәч, җемелдиләр һәм ялтырыйлар.

Бу вакытта инде бакчабызны әти күптән казып чыккан; йөзем куаклары томаланган һәм узган елгы күмер шлагы белән капланган иде.

Этебез Полкан гына, дымлы һавадан бөрешеп, оясыннан боегып карап тора...

...Караңгы төшеп килә.

Әллә кайдан гына сиздермичә, улый-улый салкын җил килеп чыкты.

Бу көчле җилдән һәм дулап яуган кардан капка, өй каршындагы бакчада үскән агачлар шыгырдап һәм шакылдап тора башлады.

Төшкән мәлдә үк яңгыр тамчыларына әверелгән кар бөртекләре, үзләренең тизлеген арттырып, ниндидер бер буталыш, хаос тудырды.

Мин, дүртенче сыйныф өчен казах теле дәреслеген актара-актара, һаман да өстәл янында утыра бирәм һәм тәрәзә аша урамдагы манзараны күзәтәм.

Кар бөртекләре, ак черкиләрдәй, юеш җиргә төшеп ятарга һәм пычрак күлләвекләргә әверелергә теләмәгән кебек, лампочка тирәсендә озаграк бөтерелә төсле иде...

...Ул да булмады, суыта башлады, һәм кар, чиләкләп койган кебек, ишеп яварга кереште.

Җил ничек кинәт килеп чыккан булса, шулай тиз тынды, үзеннән соң гадәти булмаган сәер тынлык һәм җылы бүлмәбездә дә сизелерлек өшеткеч суык һава калдырды.

Кар инде яңгырга әверелми, күптән корышкан сирәк яфраклар каплаган юеш җир өстен күз ачып йомганчы күмеп китте.

Хәзер тыныч кына, тоташ ак пәрдә булып яуган һәм акрынлап баскычларны, сукмакларны, Полкан оясын күмеп барган ак кардан ишегалды тагын да яктырып китте. Полкан, шулай күп итеп кар яуганга шатлангандай уйный-уйный, әйләнә-әйләнә төшеп килүче кар бөртекләрен тәпиләре белән тотарга һәм төшкән уңайга кабып йотарга азаплана иде...

Башта чиста, аннан тиз арада урамда көчәеп киткән суыктан бераз тирләп чыккан ике катлы тәрәзәләрдә юка боз кыйпылчыкларыннан нәфис һәм үтә күренмәле бизәкләр пәйда булды.

Күлләвекләр белән дә шул ук хәл: әүвәл юка боз белән капланып, шундук туктаусыз яуган карга күмелде.

Суык никадәр тиз үз көченә керсә, явып торган кар да, күзгә күренеп, шул ук тизлектә каты һәм коры була башлады.

Көтмәгәндә килгән үзәккә үтәрлек суыкның җитдилеген һәм кырыслыгын шактый тиз аңлап алган Полкан да яңадан оясына кереп качкан һәм, борынын да күрсәтмичә, эчтән генә бу хәлләрне күзәтеп тора...

...Әйе, бу искиткеч күренеш иде, аннан калган тәэсирләр дә мәңгегә күңелгә кереп калды. Әйтерсең тылсымлы бер әкиятнең гаҗәеп матур бер күренеше иде бу.

Әле бер сәгать чамасы элек кенә тышта Гурьевның инде ничәнче тәүлек күңелләргә сагыш һәм чарасызлык салган коточкыч пычрак һәм лыҗырдыклы төссез, салкын яңгырлы һавасы шул арада үзгәрде дә куйды: бөтен җирне ап-ак кар юрганы каплады.

Безнең ишегалды да танып булмаслык хәлгә килде: яп-якты, чиста, ниндидер тантана, бәйрәм көтелгән ишегалдына әйләнде.

Табигатьнең нәкъ менә минем күз алдымда барган искиткеч матур бу күренешеннән, бер сәгать эчендә ел фасылының үзгәрүеннән, көзнең кышка күчүеннән күңелгә аңлатып бетерә алмаслык тынычлык, җылылык һәм бер үк вакытта соклану кереп урнашты.

Хәтта Мерси исемле песи баласы да (аңа бу сәер исемне әбием кушкан иде), ниндидер сәерлек сизеп, тәрәзә төбенә сикереп менде дә зур бер кызыксыну белән тыштагы хәлләрне күзәтә башлады.

Ә бераздан, күргән-белгәннәреннән канәгать калып, идәнгә сикереп төште һәм ашыкмыйча гына үзенең җылы урынына – ул чакта әле өйнең урта бер җирендә торган мич янына барып ятты.

...Шулчак капка шапылдап куйды һәм, әле генә туып, бөтен җиргә сибелгән беренче кар япмасын шыгырдатып кемнеңдер кереп килгәне ишетелде.

Тәрәзә буеннан икенче сменада укучы һәм яңа гына тәмамланган дәресләреннән соң кайтып килүче абыем узып китте.

Бер минут та үтмәгәндер, бүлмәгә аның белән бергә аңкып суык һәм карның саф, чиста исе килеп керде. Бу истән өйдә тагын да рәхәтрәк, тагын да җылырак булып китте...

Бизәкләре дә аклы-каралы гына булган бер иске дәреслек битләрен актарып утырганда, әле генә чынбарлыкта күреп торган манзарага ике тамчы су кебек охшаган рәсемне күреп алдым!

*Караңгы кич. Кар төшә. Кыска пальто кигән һәм баганадагы ялгыз фонарь яктылыгында яктырып күренгән бер үсмер егет, култык астына портфелен кыстырып, мәктәптән өенә кайтып килә.*

Ул чакта бу күренеш мине таң калдырган иде, шуңа күрә ул минем күңелемдә мәңгегә уелып калды да.

*Мюнхен, 2 октябрь, 1993*

## ТӨНГЕ СЫЗГЫРУ

*Гурьев шәһәренең В.И.Ленин исемендәге 4 нче урта мәктәбе директоры һәм укытучылары – А.А.Плешковка, А.М.Афанасьевага, В.И.Крутькога, А.С. һәм Л.А.Плетневларга, Н.А.Кәримовага, А.С.Гейга, Н.Н.Руковишниковка, Л.П.Масленниковага, Л.А.Борисовага, А.В.Акутинага, А.Н.Мартиросьянцка, Ж.Б.Умирбековага һәм җитмешенче еллар башында физика дәресләренең берсендә үз тормышыннан шушы кечкенә вакыйганы сөйләгән (шактый еллар үткәч, бөтенләй чит дәүләттә һәм дөньяда мин аны түбәндәгечә күргән) Г.А.Скворцовка...*

...Илленче еллар ахыры – алтымышынчы еллар башы.

Казахстанның көнбатышында урнашкан Гурьев өлкәсенең Кульсары бистәсе.

Ярымчүл зонасы, кискен, коры климат, үсемлекләр дөньясы бик ярлы: бары тик дөя чәнечкесе һәм саксаул; ел әйләнәсе диярлек дала җиле исә.

Җәй айларында – өтеп ала торган кайнар, кызу җилләр, өстәвенә ком белән катыш; кышын исә – үзәккә үтә торган салкын җилләр, шулай ук комлы.

Республиканың төп нефть төбәгендәге район үзәге.

Төссез пычрак йортлар, балчык һәм саман өйләр.

Һәр ишегалдын камыш белән саксаулдан үрелгән читән аерып тора.

Бөтен җирдә хәерчелек һәм фәкыйрьлек.

Бары тик бөтен халык өчен һәм якын көннәрдә туачак якты киләчәкне символлаштырган сыман, әле яңа гына төзелгән ике катлы һәм колонналы КПСС райкомы бинасы гына әлеге балчык корылмалардан югары күтәрелеп горур калкып тора...

Әмма, хәерчелеккә дә карамастан, ул чакларда һәр хуҗалыкта, һәр йортта мал-туар асрыйлар иде. Кемгә кермә сарыклар, сыер, ат яисә дөя була торган иде.

Һәр кеше үз гаиләсен нигездә үзе ашатырга тырыша иде.

Тик күп тә үтми, Кремльдәге юлбашчыларыбызның моңа эче поша башлады: алай ярамый, дөрес хәл түгел бу, социалистик дәүләт үз халкын үзе туйдыра, киендерә ала, дип карар да чыгарып куйдылар.

Һәм өй борынча мал-туарны, кош-кортны исәпкә алучылар йөри башлады: кемдә күпме һәм рөхсәт ителгәннән артмыймы һәм башкалар?

Шуннан соң инде терлек тоту файдасызга, заман таләпләренә туры килмәгән бернәрсәгә, алай гына да түгел, законга каршы килә торган нәрсәгә әйләнде. Шулай итеп, совет халкы, үз хакимнәреннән аермалы буларак, ярымач яшәвен дәвам итте.

Башкача мөмкин түгел. «Халык дошманы» булырга инде беркем дә теләмәде.

Ишегаллары, абзар-куралар бушап калды.

Мал-туар урынына ишегалларында җилләр генә киләп сарып йөри башлады...

*** * ***

Уку елы башында шәһәрдән килгән яшь укытучыны бистә кырыендагы йортларның берсенә урнаштырдылар.

Ул чакларда кунакханәләр юк, ә гомуми тулай торакларда барлык килгән кеше өчен урын җитми иде.

Казах гаиләсе, яңа мәшәкатьләр тудырса да, укытучыны дустанә кабул итте.

Әмма ул елларда бу турыда сөйләп йөрү гадәте юк иде.

Шуның өстенә ул чакта мөгаллим җәмгыять өчен иң хөрмәтле һәм кирәкле кеше иде; чөнки ул халыкка белем, тәрбиялелек, әдәплелек, кемнәр өчендер хәтта цивилизация үрнәкләре алып килде.

Әлеге мөгаллим-укытучы эш тәҗрибәсен барак рәвешендәге мәктәпләрнең берсендә өйрәтүгә кереште.

Акрынлап җирле гадәтләргә һәм йолаларга да ияләнде, аларга кушылды.

Зур кызыксыну һәм теләк белән эшләде, яшәде.

Чөнки һәр яшь кешенең, бигрәк тә институтны әле яңа гына тәмамлаган белгечнең, күңелендә һәрвакыт бернәрсәгә дә бәйләнеше булмаган, үзенә генә хас, үзенчәлекле ышанычы һәм өмете була һәм бар да ул.

Ышаныч – сайлап алган юлның дөреслеге, ә өмет – бөтен эшләреңдә һәм җәмгыять эшләрендә уңышлы башлангыч һәм уңышлы нәтиҗә...

*** * ***

Озак та үтми, кара көзләр килеп җитте.

Көннәр кыскарды, кичләрен тагын да караңгырак, ә төннәр озынрак була башлады.

Менә шундый караңгы, күзгә төртсәң дә берни күренмәслек төннәрнең берсендә, ни йолдызлар, ни ай калыкмаган төннәрнең берсендә аны кемнеңдер ачы итеп сызгыруы уятты.

Тәрәзәдән килеп караса, беркем юк. Хуҗалар гадәттәгечә йоклап ята.

Ачы сызгыру тагын кабатланды.

Җитмәсә, ниндидер бер сәер үкерү һәм тавышның төрлечә үзгәрүе белән. Укытучының, бу хәлдән коты алынып, күңеленә шом төште.

Сызгыру, берничә мәртәбә туктап торып, таңга кадәр дәвам итте.

Укытучы бу мәхшәр төндә ниләр генә уйламады!..

Көндез, эшен төшенке күңел белән генә башкарганнан соң, өенә кайтты; укучыларга, күршеләренә, хуҗаларына сынап карады, ни дә булса белеп булмасмы дип уйлады.

Алдагы төннәре тыныч узганга, ул әлеге вакыйганы оныта да башлаган иде инде.

Әмма бераз вакыттан соң бу хәл яңадан кабатланды.

Аңа бу төндәге сызгыру тагын да ярсурак, тагын да көчлерәк булып тоелды. Таң атканда гына тынды.

Бу турыда ул хуҗаларына берни әйтмәде, шулай да төн уртасында ишегалдына берүзе чыгарга җөрьәт итмәде, чөнки, җирле халык сөйләгәнчә, бистә кырыена еш кына даладан ач бүреләр килә икән.

Тик моны болай гына калдырып булмый бит инде, нидер эшләргә кирәк, һәм ул барын да үзе ачыкларга булды.

Алдагы төндә ул инде көтә иде.

Аны йокысыннан мәхрүм иткән бу кыргый, бәлале сызгыруны көтә иде.

Һәм барысы да элеккечә үк башланып китте: шулай ук зәһәр итеп, улап сызгыру яңгырады.

Игътибар белән тыңлаганнан соң бер фикергә килде: кеше болай сызгырмый, тик кем?

Шунысы кызык: ни өчендер сызгыру төнлә генә яңгырый.

Ә бәлки, көндез мөмкинлеге юктыр, аннары көндез гадәти булып тоелган һәрнәрсә төнлә бөтенләй башка төсмергә һәм мәгънәгә ия бит...

*** * ***

...Мәктәптән кайткач, ул ишегалдын тикшерергә кереште.

Камыш белән саксаулдан үрелгән читәнне игътибар белән карап чыкканнан соң, кулдан ясалган агач сыбызгы табып алды. Кайчандыр аның ярдәмендә далада хайваннарны чакырып җыя торган булганнардыр, күрәсең.

Сыбызгы, читәнгә җиңелчә генә кыстырып куелганга, җилнең тәэсире белән үзенең торышын да үзгәртеп торган.

Эш менә нәрсәдә булган икән!..

Берәр бала онытып калдырган бу сыбызгы, җилнең һәр юнәлешенә буйсынып, йомшак кына искән җилдә дә сызгырып торган булып чыкты.

*** * ***

*...Кайчакларда дөньяда сүз белән әйтеп бирә алмаслык көчкә һәм сагышка ия булган менә шундый хәлләр дә булгалый.*

*Инде күптән онытылган һәм беркемгә дә кирәге калмаган көтүче сыбызгысы, төннәр буе коточыргыч сызгыруы белән үзенең дөньяда барлыгын кешеләрнең исенә төшерергә тырышса да, чынбарлыкта исә ирексездән үзен тыңлаучыларга бары тик курку гына салган әлеге вакыйга сыман...*

*Мюнхен, 17 ноябрь, 1993*

*P.S. Игътибар итегез: мәктәп укытучылары арасында җиде милләт вәкиле: рус, украин, латыш, яһүд, казах, татар һәм әрмән.*

*Безнең сыйныфта гына да сигез милләт баласы укыды: казах, рус, болгар, немец, татар, украин, ингуш һәм грек. Ул елларда шәһәрнең иң яхшы футбол командасындагы шул ук казах, рус, немец, чечен һәм татарлардан җыелган 11 уенчы җиңү өчен тигез дәрәҗәдә көрәште.*

*Ул вакытта без, партия – совет дөньясында хакимлек иткән өлкән агалардан аермалы буларак, кешенең милләтенә әллә ни игътибар бирми идек. Бүгенге көндә генә ул, узган елларны искә төшергәндә, йөзләр һәм фамилияләр төрлелеген көтмәгәндә-уйламаганда күрә башладык.*

*Менә бит нинди чаклар бар иде...*

*Бүген исә, бер-беребездән аерылып, бәйсезлектән котылгач, кинәт кенә барысы да шикле бәндәләргә әйләнгәнгә һәм һәркемнең милли йөзен бик тиз ачып салганга, кемнең кая сиздермичә генә китеп барганын абайламый да калдык...*

## ИСӘНМЕ, ГАЗИЗ ЙОРТЫМ!..

*1986 елның 12 декабрендә әтием эшкә дип чыгып китте һәм әйләнеп кайтмады. Ул слесарь-сантехник булып эшли иде һәм карлы-яңгырлы сүрән бу көнне эшеннән бакыйга күчеп китте.*

*Өйдә ул чакта телефон юк иде. Мин караңгыга кадәр эштә булдым: партиянең шәһәр комитеты беренче секретареның конференциядә ясарга тиешле чыгышын әзерләдем. Әтинең вафатын төн җитеп өйгә кайткач кына белдем...*

Әти-әни йорты...

Әтиең салган йорт...

Үзең туган йорт...

Бала чагың, яшьлегең үтеп киткән, үсеп буй җиткән йорт.

Кайчандыр зур гаиләнең үз мәшәкатьләреннән, шатлык, хәсрәтләреннән шау килеп торган газиз йорт...

Синең бөтен гомерең бәйле йорт.

Язмышыңа әйләнгән бердәнбереңне алып кайткан һәм инде биредә үз гаиләң тормышы башланган йорт...

Аннан беркайчан да чыгып китмәс булып тоелган йорт.

Кайчандыр моны күз алдына да китереп булмас иде, бу турыда уйларга да ярамый иде...

Шулай да син чыгып киттең...

...Бүгенге көндә бу йортта бары әнием генә яши. Берьялгызы.

Безнең балалар, оныклар өчен ул дәү әни. Елга бер мәртәбә ул аннан китеп бара. Уралга яки Актүбәгә.

Еллар хәзер нык үзгәрде, һәм без йортны караштырып торабыз.

Менә хәзер дә ул өйдә юк.

Һәм мин, ачкычларны алып, өебезгә кайтып киттем...

Гурьевның гадәти җәйге көне. Эссе, коры һәм гадәттәгечә тузанлы һава.

Бер болыт әсәре дә юк, кыздырып торган кояш нурлары күзләрне камаштыра. Бу эсселеккә түзә алмыйча, сирәк агачларның, карагачларның яфраклары төссезләнә, саргая.

Бар да һәрвакыттагыча.

Мин күптән ияләнгән юлдан атлыйм – дөя чәнечкеләре, мәктәп ишегалды аша йортыбызга якынаям.

Менә ул да күренде. Минем туган йортым – түрбакча, агачлар; өч тәрәзә, төсе уңган, әмма кайчандыр әтием буяган чарлакның кызгылт кашагасы – мине бар да шатланып һәм сагыш белән ерактан ук каршы ала.

Исәнме, газиз йортым!..

Капканы ачып керәм...

Көтелмәгән хәлдән баскан урынымда катып калам – каршыма салмак кына атлап, хәлсез елмаю белән әбием килә...

Каушап калам, ни эшләргә белмим, дәшмичә генә аңа карап торам.

Ә ул, тыныч кына яныма килеп, мине кочып ала, җанга якын җылысы белән шул ук мизгелдә мине тынычландыра.

Һәм элеккечә аның кечкенә, нәфис һәм арган гәүдәсен тоям...

Кадерле әбиебез!..

Ул сүзсез генә мине алга үткәрә. Һәм мин, нәкъ төштәге кебек, ишегалды буйлап барам. Элеккечә үк себерелгән, чистарган ишегалды буенча.

Бары тик кояш нурларыннан төшкән һәм бөтен йортны яктырткан бер яктылык белән гаҗәеп тынлык, сиздермичә генә, мине бер сихри хәлгә китерә. Һәм мин кайчандыр монда хөкем сөргән дөньябызга китеп барам.

Йөзем куаклары ямь-яшь. Тигез түтәлләр. Краннан су агып тора. Полкан табагы тирәсендә чыпчыклар җыелышкан. Ата мәче, иренеп кенә иснәп, бусага төбендә утыра.

Бар да элеккечә.

...Сарай янына киләбез. Мин шул ук кетәклекне һәм мине күргәч сагаеп калган тавыкларны күзлим.

Сарайга керә торган ишектән бер читтәрәк кечкенә кетәклек, анысы чебиләр өчен. Әнә үзләре дә. Сап-сарылар, йомшак түгәрәкләр. Чи-чи килеп йөгерешеп йөриләр...

Әбием, дәшми-тынмый гына, үз хуҗалыгына елмаеп карап тора. Искереп беткән төссез озын күлмәктән. Күлмәк өстеннән алъяпкыч япкан, куллары артта. Бераз бөкрәя төшкән. Күз тирәләрендә җыерчыклар. Ә күзләре – мәрхәмәтле, сагышлы. Бераз кысыбрак карый.

Үземне белгәннән бирле карт инде әби. Кечкенә вакытымда ук шундый иде. Әйтерсең лә вакыт аңа тимәгән. Ул һәрвакыт бертөсле, һәрвакыт карт, әмма тынгысыз һәм җитез...

Үз гомерендә ниләр генә күрмәгән безнең әбиебез...

Язмыш талкуын зур сабырлык, түземлек белән үткәреп җибәргән, аларны булырга тиеш нәрсә дип кабул иткән. Һәрвакыт Коръән укып, тормышы бәйле булган кешеләрне исендә тотып. Бер-бер артлы килүче һәм бер-берсен алыштыручы буыннарны бәйләп...

*...Казан губернасының Кушлавыч авылы. Зур гаилә. Габдулла Тукай. Николай патша. Казан, Кәримов Мифтахетдин.*

*Нинди булган ул безнең бабабыз? Без аны беркайчан да, хәтта фотосын да күрмәдек...*

*Каспий диңгезе. Жилая Коса. Сәүдәгәр йорты, инкыйлаб, балалар, ачлык еллары. Бабаебыз вафаты.*

*Аннан соң – тагын сугыш, диңгез кешеләрдән китә, Гурьевка күчеп килү. Фронтта өлкән улы Әдһәм һәлак була. Әбием үзе госпитальдә санитарка булып эшли, шәһәрне тупка тотканда чукраклана.*

*Бер карасаң, гади бер тормыш. Татарча һәм гарәпчә генә белгән әби...*

*Ә аннары – үзенең әйтүенчә, күкләрне тишеп үткән ракеталар, соңрак телевизор...*

*Һәм менә без – аның оныклары...*

...Шул мизгелдә сагыштан йөрәгемне түзә алмаслык авырту кисеп үтте – мин әтиемне тойдым.

Тойдым гына түгел, күрдем дә мин аны. Әтием!!!

Әйе, күрдем мин әтиемне.

Ә ул, һәрвакыттагыча, нәрсәгәдер борчулы иде...

Бары тик күзләре белән генә елмаеп, нидер эшләвен дәвам итте.

Йөрәгем, бөтен җаным әрнү-сызлаудан сыкрады, газапларга чумды... Әтием өчен кисеп-кисеп авыртудан. Бездән бик иртә китеп барганга, ә минем аны алып калыр өчен берни дә эшли алмаганыма. Кичер мине, кадерле әтием...

Балалар әти-әниләренә һәрвакыт бурычлы булып кала.

Кызганыч, моны алар бик соң, әти-әнисе бакыйга күчкәч кенә аңлый...

...Әтием, хәлемне аңлап, сүзсез генә тагын миңа карап куйды, эшеннән туктамады. Ул бик сирәк елмая иде, ничектер үзенә генә хас елмаю белән, шатлыгын да, хәсрәтен дә бергә кушып. Мин аның ни эшләгәнен дә, нинди борчуы барын да аңламадым, аны бары тик күзләрем белән, җаным белән күрдем, күңелдәге сагыш, авырту турында сөйләштем. Сүзсез генә...

Һәм без бер-беребезне аңладык. Бөтен уйларыбызны һәм хисләребезне уртаклаштык...

*...«Алтын куллы» диләр иде аның турында күршеләр. Эшендә дә мактаулы, абруйлы иде ул. Гомере буе слесарь булып эшләде. Мәгърифәтле, заманында танылган һәм көчле нәселдән чыккан кешенең улы... Кайчандыр шактый зур һәм иркен булган, су белән җылытыла торган менә бу өйне ул безнең өчен берүзе салды. Һәрвакыт чиста, каралган һәм яшел ишегалды. Һәрвакыт эштә, хәрәкәттә – бер генә минут та буш тормый, ял итүнең ни икәнен дә белми. Кирәк булганда, ул итекче дә, мич ягучы да, электрик та, каравылчы да, тегүче дә, балта остасы да һәм агач эше остасы да... Аңа көн дими, төн дими ярдәм сорап күршеләр дә, эшеннән дә киләләр иде – монда нидер булган, тегендә ниндидер авария – бөтен гомере шулай үтте. Мәңгелеккә безне ташлап киткәндә дә эшенең иң кызу чагы, кемнеңдер*

*заказын үтәгән вакыты булган. Ә бит аңа нибары илле алты яшь иде, моңа җитмештер инде дип уйласалар да. Менә шулай яшәде ул, кешеләр өчен тырышып, барысының да күңелен күреп...*

...Тамагыма төер утырды. Ишегалды уртасында аптырап басып торам. Сызланудан, сагыштан арыган, бушап калган хәлдә... Аның каравы, алар белән, минем кадерлеләрем белән яңадан бергә...

Вакыт туктап калгандай булды.

Бу чиксез сызлануда бар нәрсә хәрәкәтсез катып калды...

...Бары шуннан соң гына күзләремнән акрын гына яшь тәгәрәп төште. Кинәт кенә әллә кайдан килеп чыккан тузанлы җил мине чынбарлыкка кайтарды.

Әллә яшьтән, әллә тузан белән җилдән тирә-юнем томанланды, кояш нурларының шәүләсе күзләремне чагылдырып үтте...

Бер мизгелгә генә башым әйләнеп китте, күзләрем ихтыярсыз йомылды, шул ук мизгелдә аларны ачсам, телсез катып калдым – мин ишегалды уртасында ничек басып торган булсам, шул ук урындамын, тик – берүзем... Ишегалды буш, каралмаган, ташландык хәлдә. Сарай – җимерек. Шаккаттым. Кычкырасым, җиргә ятып үкереп елыйсым килде.

*«Кайда соң сез?! Кая киттегез?! Китмәгез, зинһар өчен, китмәгез!..»*

Мин атылып өйгә кереп киттем. Бүлмәләрдән йөгереп үттем – беркем юк!.. Яңадан ишегалдына йөгереп чыктым – анда да беркем юк... Сызлануым мине күмеп китте. Башымны тотып һәм ыңгырашып, җиргә аудым...

*** * ***

*...Моның белән генә бетмәде әле.*

*Алар минем төшләремдә яши.*

*Андый чакта төштән аерыласым, уянасым килми минем.*

*Үзең дә сизмичә, вакытны сузасың – төш бетмәсен, төштәгеләр китмәсен, шул халәттә булса да, төшемдә генә булса да әтием яшәсен иде!..*

*Ул да моны сизә һәм аңлый. Мин аның улы лабаса.*

*Шуңа күрә, кайда гына булсам да, ул минем белән.*

*Минем аңа бер генә үтенечем бар: беркайчан да, беркайчан да миннән китмә син, кадерле әтием... Миндә, төшемдә генә булса да яшә, тик яшә генә...*

*...Еш кына метрода яки автобуста барганда, тәрәзә пыяласында чагылган йөземдә мин аның карашын тоям – арыган, уйчан, текәлгән һәм борчулы карашы...*

*Мюнхен, декабрь, 1993*

## НИМФЕНБУРГЕР КАНАЛЫНДА

Туксан өченең ноябре. Мюнхен.

Нимфенбург Сарае. Бавария герцоглары һәм корольләренең борынгы резиденциясе.

Бу Сарай шактый кызыклы: бинаның уң ягы белән сул ягы игезәкләр кебек. Гаҗәп төгәл кабатланган.

Уңда ни булса, сулда да шул...

Ә уртада – шул ук исемдәге канал. Аның ике яры ике урында асылмалы күперчекләр белән тоташтырылган һәм, бер яктан – зур шарлавык, ә икенче яктан – чатыр, аның эчендә хәрәкәттә катып калган нәфис болан сыны.

Тиз арада туңып һәм боз белән капланып өлгергән каналда исәпсез-хисапсыз кеше: яшьләр, өлкәннәр һәм, билгеле инде, балалар, хәтта нәниләр дә килгән. Төрлечә киенгәннәр, куртка, пальто, джинсы, хәтта махсус спорт киемен дә күрергә була. Һәркем елмая, көлә...

Бар да гадәти. Шугалакта шулай булырга тиештер дә инде.

Һәм мин, бу гомумхалык бәйрәмен күздән кичергәч, ирексездән уйлап куйдым: «Мондый бәйрәм кайчандыр булган иде түгелме соң? Ник күңелле булса да монда нидер җитми төсле».

Уйлый торгач, кайчандыр булган шундый бәйрәм кинәт кенә ап-ачык итеп минем күз алдыма килеп басты, ә бәлки, исемә генә төшергәнмендер...

*...Паркта ярымтүгәрәк корылмада тынлы оркестр уйный.*

*«На сопках Манчжурии», аннары – «Солдатский вальс».*

*Кеше әллә ни күп булмаган шугалакта кулга-кул тотынып, салмак кына, йөзеп киләләрмени, озын пальто һәм итәкләрдән яшь парлар шуа. Ә өлкәнрәкләре кар каплаган сукмакта җыелышып басканнар да, әсәрләнеп, аларга сокланып карап торалар...*

*...Һәм шулчак әйтерсең кемдер телевидение каналын күчереп куйды, хәтергә йолдызларсыз дөм караңгы төн бәреп керде: Уралны һәм колакны ярырлык көчле, үтә тиз әйләнгән җыр – «А люди в городе гуляют по льду...»*

*Шугалак. Тиз генә әмәлләп куелган, кыйшайган биек такта койма, кереп йөрер өчен берничә тишек урыны да бар. Ике почмакта – җилдә чайкалып торган ике лампочка, ә уртада – репродуктор яки «чаң». Бер генә кеше дә юк.*

*Бер мин. Суыктан һәм җилдән шакырдап каткан унике яшьлек үсмер. Караңгыда тигезсез боз өстендә абына-сөртенә шуып йөрим. «По переулкам бродит лето...» колагыма кереп, әллә ниләрне күз алдыма китерә...*

*** * ***

Бүген иртән, инде декабрь кергәч, Вайнах-Фест, ягъни Раштуа бәйрәме алдыннан, гадәттәгечә сиксән өченче автобуста Нимфенбургер каналы яныннан узып киткәндә, мин, уйламаганда-көтмәгәндә, инде боздан чистарган суда (!) гаҗәеп матур ике аккошның бер горурлык белән йөзеп йөргәнен күреп калдым...

*Мюнхен, 17 декабрь, 1993*

## БАШЛАНУ

*Сүрүемнән башым*
*күренү белән,*
*Күзем ачтым ошбу дөньяга.*
*Еллар үтте –*
*язмыш шактый җикте:*
*Холкым – корыч, күңел – пыяла,*
*Баскан җирем – биек кыяда.*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

## БАШЛАНУ. БУ НИЧЕК БУЛДЫ?

*Туксанынчы елда Алма-Атаның кышкы төннәренең берсендә әйтерсең бу дөньяга килүемнең беренче мизгелләрендә булып үткән вакыйгаларның аңымда кабат торгызылуы үзенең кинәтлеге һәм төгәллеге белән мине таң калдырды.*

*Һәм мин, төн уртасында сикереп тордым да каләм-кәгазь алып, караватымда утырган килеш, иртәнгә кадәр кайбер нәрсәләр хәтеремнән очып бетәр дип куркудан, барын да рәттән яза башладым. Һәм мин шулай язып киттем. Хикәя арты хикәя, бу китап та менә шулай туды...*

...Кинәт караңгы булып китте.

Шул караңгылыкны тою барлыкка килде.

Караңгылык бөтен җирне биләп алды.

Әмма бу дөньядагы иң якты Кояш кебек иде.

Чөнки мин яши башладым. Һәм бар дөнья бу караңгылыктан тора иде. Бу хәл күпмегә сузылгандыр, әйтә алмыйм.

Тик бар да Мәңгелеккә чумды...

...Кинәт якты дөньяның нурлары, түгәрәкләр, сызыклар һәм таплар пәйда булды. Дөнья үзгәрә, яктыра башлады.

Бу нурланыш мине ни өчендер куркыта, тынычлык, караңгылык миңа якын иде, кире шуңа кайтасым килде. Куркуга салган яңалык миңа ят иде.

Яңа күренешләр бер калыкты, бер батты – бу караңгылыкта инде бертөрлелек юк иде.

Алар белән бергә Вакыт төшенчәсе дә туа башлады.

...Тирә-юнемдә бары тик ак белән кара.

Һәм мин йә алга, йә югарыга гына карый идем – бөтен дөньям бары тик минем алдымда гына иде...

...Очышны тою, көнкүрешне тою белән бергә, башлангыч чорда туды.

Минем аңым бу караңгылыкта очып йөри, ак балкышлар тугач, мин дә алар белән очып йөрдем, тик эчке карашым белән әлегә минем өчен караңгы булган, әмма мин инде анда булган, ул да миндә булган бу дөньяга шактый еш һәм гадәти итеп карадым, тик – әлегә...

...Мине беркем дә аңламый, ә мин, сөйләшә белмәсәм дә, барысын да аңлыйм.

Нинди телдә (татар, рус яки казах телендәме) сөйләшүләренә карамастан, барысы да – фразалар да, сүзләр дә аңлашыла.

Үземнең сөйләшә башлавымны миңа бик озак, чиксез озак көтәргә туры килде.

Көттем һәм аннан курка да идем.

Мин дә башкалар кебек булырмынмы икән?..

Аңлатып бирә алмаслык хис: горурлык һәм курку, ни өчен Мин тудым әле, әйләнә тирәмдә кем? һәм нәрсә? – барысы да мине киеренкелектә тота...

Бу дөнья – кайдан?..

Мин – кайдан?..

Боларның барысы да минем эчке дөньямда һәм тышкы дөньямда.

Ә аннан соң кайчакларда чәч төбеннән алып аяк табанына кадәр бөтен тәнемә үтеп кергән курку акрынлап тынычлануга күчә барды. Шулай кирәк, бу дөнья минеке һәм әйләнә-тирәдәге бар нәрсә минем өчен генә...

...Вакытны – булган барлык хәлләрнең алмашынып торуын, үзгәрүчән булуын аңлый башладым.

Тик Вакыт үлчәве генә юк иде әле.

Ул – вакытны белдерүче ниндидер вакыйгалар, билгеләр һәм хәрәкәтләр белән генә үсте...

...Тирә-як миңа таныш булып, кайчандыр күргән кебек тоелды.

Мин алга таба ни булачагын да беләм кебек.

Алдагы тормыш баскычында мине ни көтә?..

Бу турыда уйламасаң, җиңел, уйласаң, яшәешнең һәм көнкүрешнең котылгысызлыгы һәм ваклыгы, түбәнлеге яңадан баштанаяк салкын тиргә төшерә...

Бөтен аңны хәвеф биләп ала.

Бары тик уйларны үзгәртү, башка нәрсәгә күчерү генә акылның зәгыйфьләнүеннән коткарып кала...

...Бервакыт минем температурам күтәрелде. Һәм мин, бу дөньядан аерылып, урынга калдым. Бары тик минем аңымда гына кайдандыр килеп чыккан җемелдәп торучы һәм лампочка спиральләрен хәтерләтүче, әмма яктыртучы һәм «Г» хәрефенә охшаган якты нокталар пәйда булды.

Һәм бу җемелдәвекләр мине эзәрлекли башлады: аңымның бер почмагына куып кертмәкчеләр. Мин качам, әмма алар, кайдадыр бер почмакта тагын да ишәеп, мине кабат эзәрлеклиләр.

Җан авазы бөтен бу мәхшәрне шәрехләп торды, һәм ул чиксез дәвам итте. Чынлап та бу куышу шулкадәр озак дәвам итте ки, йөрәк белән нервыларым өзелер дәрәҗәгә җитте.

Ә алар, сул почмактан килеп чыгып, мине һаман эзәрлекли. Әгәр мине тоткан булсалар, кемдер әйткәнчә, үлгән булыр идем. Моннан котылу өчен миңа икенче, түбән почмакка күчәргә кирәк иде, тик әлеге җемелдәвек нокталарның саны янә артты.

Аннары мин аларны ничектер юкка чыгарган кебек булдым, әмма кайдадыр тирәндә, сулъякта, бу коточкыч билге яңадан җемелдәп тора башлады...

Мин, аннан качарга теләп, очып киттемме шунда, ниндидер чокырга, әллә упкынга, әллә очы-кырые булмаган торбага төштемме – анык кына хәтерләмим.

Боларның барысы да ниндидер бер йомык, төгәл билгеләнгән пространствода булды.

Иң мөһиме шунда: моның мәгънәсе бар иде – барысы да миңа һәм әлеге җемелдәвекләргә билгеле булган ниндидер бер кагыйдә яки закон буенча барды.

Җемелдәвекләр санының артуында һәм кимүендә, шахмат тәртибендә, ниндидер арифметик прогрессия туды.

Бу җемелдәвек әле чиксезлеккә китеп, әле, шул ук мизгелдә артып яки кимеп, миңа якыная иде.

Җемелдәвекнең бер көчәеп, бер кимеп торуы йөрәк тибешемә туры килә иде...

Бертуктаусыз эзәрлекләүдән арыган һәм гаҗиз булган мин нишләптер урамда уянып киттем – кояш нурлары күзләрне чагылдыра, янымда кулларымнан тотып кочагына алган әбием басып тора. Салкын тиргә чумып саташып ятканда, урынымнан сикереп торганмын да, өйне һәм ишегалдын тиз-тиз үтеп, кояш нурларына күмелгән урамга чыкканмын һәм шунда аңыма килгәнмен.

Тиздән авырудан арына башладым...

...Иң матур һәм рәхәт төшләр – очып йөргәнеңне күргән төшләр.

Шулкадәр җиңел очасың, гәүдәң, тәнең авырлыгын да тоясың үзе, җирдән яки идәннән җиңел генә этеләсең дә өскә, югарыга очып менеп китәсең.

Күп очракта бүлмә буйлап кына очырта.

Ә кайчакта, имеш, сине кемдер эзәрлекләп куып килә, ә син тиз генә этеләсең дә югарыга очып китәсең, куып килүче сикереп тотмакчы, тик аның буе җитми. Мондый вакытта үзеңне җиңүче итеп сизәсең.

Очкан чакта гаҗәеп җиңеллек, рәхәтлек тоясың, хәтта җиңелчә генә башың да әйләнә...

...Миңа биш яшь. Яки шул тирә.

Кич белән урамнан безнең өй турыннан чәчләре агарган, сакаллы бер бабай узып китте.

Аны күргәч, зиһенемне күптән онытылган дип йөргән бер уй кисеп үтте – әйләнә-тирәм һәм мин үзем бу дөньяда вакытлыча гына, кунак кына икән бит...

Курку белән өметсезлекне кабат тойдым мин ул чакта.

Тик мин моны әле беренче мәртәбә генә тоям диеп уйладым.

Нәкъ менә шул мизгелдә «үлем» дигән сүзнең мәгънәсенә төшендем мин. Коточкыч бер курку белән. Болар бар да минем җанымда, минем аңымда иде.

Мин менә шулай итеп өлкәнәйдем. Үзгәрә башладым. Бу дөньяны аңлый башладым.

*Алма-Ата, декабрь, 1990*

## СИҢА ҺАМАН ВАКЫТ ҖИТМИ

Сиңа һаман вакыт җитми инде,
Һаман ашыгасың, чабасың.
Эшең күп шул, башта – дөнья гаме,
Яшәү ямен шуннан табасың.

Туктау түгел,
хәтта уйларга да
Вакытың юк синең,
җаең юк.
Кайдан, ничек,
нинди максатларга
Килдең бу дөньяга
Һәм яшисең ничек? Нигә янда
Ни Кояшың, төндә Аең юк?..

Көтмәгәндә абынып киткән чакта
Килеп чыкса әгәр яман хәл,
Син шунда да
«артык кыланасың»:
Бер секундка гына уйланасың,
Аннан янә эшкә
юл аласың –
Бушка киткән вакыт
һаман жәл.

Кая? Нигә? Кайчан? – күпме сорау.
Җавапларга төшкән
күзге кырау.
Чөнки синең
һаман вакытың юк,
Бәлки, шуңадыр да
Сарыгың да исән,
бүрең дә тук.

*ICE экспресс поездда Мюнхеннан Гамбургка һәм кире кайтканда В.Высоцкийның «Бегство мистера Мак-Килли» кинофильмындагы: «Тебе всегда некогда, ты спешишь на учебу или работу...*
*...Вот твой билет, вот твой вагон – все в лучшем виде одному тебе дано...*
*И если встретишь там ты Бога – то передай ему привет», – дигән җыры белән өртелгән уйлар.*

*23 декабрь, 1993*

## КИЛӘЧӘКНЕ ИСКӘ АЛЫП,
## ЯКИ «ХӘТЕРЛИСЕҢМЕ СИН,
## БУ НИЧЕК БУЛАЧАК?»

*«Хәтерлисеңме син, бу ничек булачак?..»*
*Чынлап та, хәтерлисеңме син моның*
*Ничек булачагын?..*
*Сөйлимме?..*
*Әллә кирәкмиме?..*
*Бик гади бит ул.*
*Уйлап карарга гына кирәк,*
*Шундук исеңә төшерәчәксең...*
*Уйла әле – Син дә Аны хәтерләрсең...*

...Әйтерсең сине кемдер каядыр
Ерак-еракка алып китәдер...
Тирәндә булган абсолют нәрсә
Башка халәткә,
үлчәү – киңлеккә,
Чиксез бушлыкка
һәм дә юклыкка
Күчеп бетәдер,
күчеп бетәдер.

Кирәксез булгач,
сүнгәләп торгач,
Яшәешеңнең тирән мәгънәсе
Юкка чыккандыр.
Кем икән соң син,
Кайда, кайчандыр
Сиңа кагылган
Һәртөрле хәлләр
Нигә булгандыр?
Ниләр кыргандыр?

...Җиңеләясең, авырту килә,
Ул авыртудан котылыр өчен
Очарга иде ерак-еракка.
Кайчандыр төштә
очып йөргәндәй –
Җаның омтыла
рәхәт бер якка.

Шушы уйлардан тынычланасың,
Иркенәя тын,
очына җаның.
Инде берни дә
борчымый сине,
Авыртуны да
тоймыйсың инде –
Әйтерсең күкне гизәсең тагын...

...Бернинди аваз, чәчәк, яктылык –
Бар да каядыр үз юлын алган.
Вакыт та беткән,
юк караңгылык –
Алар һавага эленеп калган.
Тик кайчакларда
ике арада –
Яшәү – Мәңгелек аралыгында...
Очып йөргәндә
һәммәсенең дә,
Көн һәм Төннең дә

«канаты» талган.

Хисләр, хәрәкәт туктап калганнар,
Бары уй гына
тибә җанында.
Бары уй гына,
башка берни дә
Калмаган инде,
хәтта каның да.

Фанида да ул беренче иде,
Бакыйда да ул
соңгысы булды.
Бары шул Уйда Яшәешеңнең
Бөтен барлыгы бергә тупланды...

Бик теләсәң дә,
күрә алмассың,
Берни ишетеп,
сорап та булмас.
Хәтта хәрәкәт сиңа бирешмәс,
Тырышып кара,
бәлки, нык тормас.

Кинәт бу Уйдан
сискәнеп куйдың!
Шушы мизгелдә бөтен тәнеңнән,
Үзең һәм җаның,
бәгырең аша
Көчле ток узды.
Бар тормышыңны искә төшереп,
Соңгы авырту,
көчле авырту
Үтәли тишеп,
гомереңне сызды.

Кап-кара бушлык, терәксезлекнең
Киң итеп ачкан
бу кочагыннан,
Түзә алмаслык авырту салган,
Телгәләп кискән
ут-пычагыннан
Котылыйм диеп күпме талпынма,
Бар да өзелә.
Яшәвең белән соңгы элемтә
Өзелгән чакта ничек түзелә,
Ничек түзелә?

Соңгы көрәштә барыбер җиңәсең –
Капкын – кочактан
котылып китәсең.
Тик Мәңгелеккә,
чиксез Бушлыкка
Барып төшәсең, килеп җитәсең...

Әйтерсең лә син
Бер дә тумаган,
Фани дөньяда

гомумән булмаган.
Кеше булып син
Тормыш кормаган,
Җиһан, галәм дә,
Җир һәм кешеләр,
Ай һәм йолдызлар
Яшәмәгән дә,
балкып тормаган.

Аерым алганда, сәясәтчеләр,
Җыен җирбитләр һәм гайбәтчеләр,
Билгеле инде, химаячеләр,
Мәрхәмәтле җан, ил сөючеләр...
Бер дә булмаган,
монда тормаган.
Булмаячак та,
Тормаячак та
Тик синең өчен.
Кире кайтырга
юк синең көчең,
калыр фанида
Өн белән төшең!

*Бу турыда син беркайчан да онытма!*
*Үзең исән чакта.*
*Минем бу сүзләремне син хәзер, бүгенге көндә укыйсың.*
*Синең белән минем үткән тормышыбыз һәм киләчәгебез турында ул...*
*Мюнхен, ноябрь, 1993*

**ДЕРЕЛДЕК**

...Әллә нинди бер тышчага төрелгән күңел кайтаргыч канлы-сулы дерелдек ниндидер максат белән миңа таба шуыша иде.

Бугазыннан сәер авазлар чыгарып, яныма килеп җитте дә терәлеп үк каршымда торып басты.

Күзем күргән бу галәмәттән шундук укшый башладым.

Нәкъ менә шушы мизгелдә, бу җанөшеткеч-чирканчык һәм тулаем диярлек канлы судан торган хәшәрәттән шундый ук җирәнгеч, канлы җепселле бер нәрсә аерылып, миңа ышанычын белдергәндәй, уң кулымнан тотып алды.

Җирәнеп һәм котым очып, мин чигенеп куйдым. Бу сәер дерелдекне җентекләбрәк күзәтә башладым һәм гаҗәп нәрсәләр күрдем: беренче мәлдә хәшәрәт булып күренгән бу җан иясе, ныклап карагач, төгәл планлаштырылган һәм укмаштырылган, әйтерсең лә кем тарафыннандыр программаланган, нигездә, пычрак сулы-итле сыекчаны болгатып ясалган организм булып чыкты.

Әмма ул, күбесенчә судан торса да, агып китмәде, тышчасыннан кубып төшмәде, киресенчә, тиешенчә йомылган һәм тәгаен билгеләнгән бер пространствода, киңлектә җыелып тора, шуның өстенә аңлатып булмый торган ниндидер бер көч хисабына иркен күчеп йөри ала иде.

Нидер сизенеп, артыма борылып карасам, миңа әллә ни игътибар итмәгән тагын берничә хәшәрәтне күреп алдым.

Димәк, бу берүзе генә түгел.

Янымда торган дерелдеккә кабат әйләнеп карадым. Күргәнем шаккатырды: аның эчендәге бар нәрсә әйләнештә, хәрәкәттә, кайнауда. Күрәсең, һәрдаим аның тормышы өчен мөһим булган ниндидер процесслар бара. Башыма уй килде: болай булгач, аңа эндәшер, аны чакырыр өчен берәр төрле сигналы (позывное) яки хисап-теркәү номеры кебегрәк исеме йә кушаматы да булырга тиеш бит инде, чөнки алар күбәү, барысы да бериш – укмаштырылулары да, көйләнүләре дә бертөсле.

Ниндидер сәер торбалар, шланглар, җепселләр белән дыңгычланган һәм төрле яклап каплаган лайласыннан каядыр эчкә агып төшүче елгачыклардан торган бу лайлалы һәм тотрыксыз шома хәшәрәт белән япа-ялгыз күзгә-күз очрашу һушны алырлык иде.

Шуның өстенә аның эчендәге бар нәрсә хәрәкәтләнеп, селкенеп, дерелдәп кенә калмыйча, кызгылт төскә кергән бу җан иясе (шулай дип әйтеп булса) үзе дә бер урында тыныч кына тормый – үзеннән

чыккан симметрияле тармаклары даими тартышып, колак тондыргыч һәм аңны ярып үтәрлек җирәнгеч, күңел кайтаргыч авазларын бертуктаусыз яңгыратып тора иде.

Ниндидер аң җитмәс рәвештә, берсүзсез, кемдер билгеле бер вакытка дип кенә ясаган бу катнашманы күргәч, кинәт мин аңарда үзенең мәңгелегенә һәм бу дөньяда һичшиксез кирәклегенә инану ташып торуына таң калдым.

Боларны бер-беренә берничек тә бәйләп булмый, югыйсә бөтен барлыгыннан чиксез җирәнү, курку, кызгану һәм шыксызлык чәчрәп торган бу хәшәрәт үзен шул ук вакытта Тудыручысының даһи һәм камил иҗат җимеше дип саныйдыр, мөгаен.

Чынлап та, әлеге сәер җан ияләре арасында калгач, мин бу дөньяга, әйләнә-тирә мохиткә ниндидер бер эчке кызыксыну һәм тынычлык, сабырлык белән карый башладым. Ул гына да түгел, миңа бу хәшәрәттә бернинди дә артык һәм файдасыз нәрсә булмаска тиеш дигән уй килде...

Мин күзәтүемне дәвам иттем. Кинәт ул менә-менә агып китәр йә эреп җебер дә шөкәтсез бер измә күченә шуышып җыелыр кебек тоелды, шуңа күрә мин кабат бераз артка чигендем – аңа урын бушаттым.

Әмма бу җан иясе, минем янә чигенеп куюыма кимсенгәндәй, тагын да якынрак килеп басты һәм мин, теләсәм-теләмәсәм дә, аның шундый ук лайлалы һәм аскы өлеше кебек үк хәшәрәт, ян-яклап янчелгән шарны хәтерләткән баш өлешен җирәнә-җирәнә күзәтергә мәҗбүр булдым.

Канга баткан сеңерле-кимерчәкле бу дерелдеккә бераз тыгызрак органик материалдан кыса кидерелгән һәм ул нык сыланып тора иде. Әлеге күренеш мине тагын да ныграк тетрәндерде...

Бу җанөшеткеч күренештән һәм хәшәрәтләрдән, бөтен барлыгым актарылып, бугазыма укшу гына түгел, тышка бәреп чыгарга теләгәндәй, косык килеп тыгылды, әмма шул ук мизгелдә минем аңымда нидер ярып чыккандай булды һәм мин, шаккатып, аннан чыккан һәр авазны көтмәгәндә төгәл аңлый башладым, ә аннары, бөтенләй катып калып һәм текәлеп карап, инде нәрсә булганына гомумән төшенмичә, әле генә мин күргән сулы-канлы хәшәрәттә кешене танып алдым!!!

Ышанырлык та түгел, бу чыннан да кеше иде!!

Тирә-юньдәгеләр шулай ук кешеләр иде!

Минем кебек...

Хәрәкәтләнү, сөйләү, ишетү сәләтен бөтенләй югалтып, ахыр килеп, күргәннәремнән тетрәнеп, мин дәшми-тынмый гына басып һәм кемнеңдер минем белән кул бирешеп күрешкәнен, миннән нидер белергә теләп тырыша-тырыша сораштырганын карап тора бирдем...

*Әйе, башка сыймаслык хәл иде бу. Югыйсә гадәттәгечә җәйге бер иртә, һәм мин, шулай ук гадәттәгечә, Мәскәү янындагы Опалиха дигән станциядә электричка көтеп тора идем.*

*Атырау, 29 октябрь, 1995*

## МИН – ?..

...Мин.
Билгесез, кайдандыр алган гомер белән,
Билгесез, кайдандыр яралган бу дөньяда...
Билгесез,
Кинәт кенә кайдандыр барлыкка килгән
«Мин» дигәнем – кем соң ул?..
Шулай да кем соң «Мин»?..
Кайдан,
Ни өчен,
Нинди максатта,
Нигә,
Көтмәгәндә,
Кинәт кенә,
Монда барлыкка килгән
нәкъ менә – Мин?..
...Мөгаен, шулай китәрмен дә –
Минем кем икәнемне
Белмичә,
Аңламыйча,
Төшенмичә,
Танып җиткермичә.
Барыбер дә

Ул – «Мин» һәм мин
Монда булдым...

*Мюнхен, 5 гыйнвар, 1994*

## Katnarsis (чистарыну)

*Менеп киттем галәм киңлегенә,*
*Яктысында күрдем йөземне...*
*Чистарынып калдым*
*бар зәхмәттән,*
*Пакь сафлыкка төрдем үземне.*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

*Шәхси һәм шәхестән тыш, объектив һәм субъектив, «Мин» һәм «Мин түгел» арасындагы чикләрне юкка чыгаручы шомлы, шифрланган сюрреалистик саташуларны һәм күзгә күренгән шәүлә-өрәкләрне өсте-өстенә, кирәгеннән артык өю һәм шул ук вакытта җанны вакытлыча булган һәм кирәксез барлык нәрсәләрдән арындыру акрынлап үзенең югары ноктасына җитеп килә – чиктән узган чынбарлык кичерешләрнең, куркыныч фильмдагы кебек, инде узып китүенә ышаныч калмаган хәсрәт-сагыш һәм кеше гомеренең һәлакәткә дучар ителүе белән беррәттән, үз аңының психологик тирәнлегенә алга таба үтеп керүе хәзер инде туктатып булмаслык дәрәҗәгә җитеп килүче бөтендөнья һәлакәте һәм чоңгылы фантазмы алдыннан өзек-өзек кадрлар һәм сюжетлар белән соңгы мәхшәрне демонстрацияләүгә, күрсәтүгә күчте...*

## I. ҮЗ АҢЫҢ ТИРӘНЛЕГЕНӘ ҮТЕП КЕРҮ

### КАДАКЛАР

...Мин ниндидер ярым йокылы, җебек халәттә идем.

Әллә кәнәфигә, әллә урындыкка кадаклап куелганмын...

Бу турыда уйлап алуым булды, ни өчен аңыма килүемне аңладым – кемдер егерме сантиметрлы ике тимер кадакны минем башыма кагып кертә иде...

Бары тик секундның бер өлеше кадәр вакытка гына сузылды бу тетрәнү, каушау, чөнки чынбарлыктагы гамәлгә караганда бу турыдагы уй үзе куркынычрак иде – авырту бар, әмма «мине нишләтәләр» дип уйлап көткәндәгечә көчле түгел.

Сәер, моны күрү тоюга караганда куркынычрак иде.

Кадаклар акрын-акрын, берничә миллиметрлап кына, ниндидер тыгыз, үзле нәрсәгә кереп бара.

Сугу артыннан сугу, әмма тавышы юк...

Авырту да бөтенләй юкка чыккан кебек...

Һәм шунда тагын да көчлерәк тетрәнү белән мин шуны аңлап алдым: үзем белән бара торган хәлгә читтән карап торам икән!!

Бу башта күргәннәргә караганда күпкә көчле күренеш иде.

Мин, аңга килү белән, әлеге кадакларга һәм үз-үземә читтән карап тора башладым.

Ни булганын аңлап өлгермичә, мин пространствода күчеп куйдым, үземнән читкәрәк киттем.

Бу бик сәер, башка сыймаслык һәм шул ук вакытта шаккатарлык гамәл иде...

*«Җитәр, чыгарырга кирәк кадакларны...»*

Бу турыда янә уйлап та өлгермәдем, кемдер, ә бәлки, мин үземдер, тыныч кына, салкын кан белән бу кадакларны берәм-берәм башымнан тартып чыгара башлады...

Шул ук вакытта үземнең бу эшемне читтән күзәтеп тордым...

Хәзер инде авырту көчәйде. Ул шулкадәр озакка сузылды – түзеп булмый башлады.

Башымда нәрсәгәдер ябышкан булып, кадакларның кергәнгә караганда чыгуы авыррак иде. Чыккан чагында үзенә ниндидер резин кебек тыгыз – үзле нәрсәне ябыштырып чыгара, шуңа күрә сизгерлек арта, авырту көчәя, нервылар түзми...

Беренче кадак икенчесе белән чагыштырганда җиңелрәк чыкты...

Шулчак башка уй төште: «Кадаклар баштан чыккач, алардан соң калган тишекләрне томалар өчен ни дә булса табарга кирәгер...»

Эшемне туктатып торып, без, ягъни мәсәлән мин, нәрсә дә булса табып булмасмы дип, як-ягыма карандым...

Бер мизгел эчендә өчебез дә – башымнан тартып чыгарган кадаклар белән бу мәхшәрне читтән күзәтеп торучы мин бергә кушылдык, һәм мин уянып киттем.

**УЯНДЫМ**

Әле төн иде.

Ни өчендер: «Әле төн икән», – дип уйлап куйдым.

Бүлмәдә тынлык.

Тирә-юньгә колак салдым. Гаҗәп бернәрсәне ачыкладым – тынлык гадәти түгел икән бит, әллә нинди, тонык. Бөкедәге кебек.

*«Йоклап китәргә кирәк. Таңга кадәр ерак әле. Кызык, сәгать ничә икән?»*

Караватт өстендә эленеп торган төнге лампаны кабыздым.

Сәгать туктаган. Төнге унбер тирәсендә. Әмма циферблаттагы көн исеме икенче.

*«Сәер, беркайчан да болай булганы юк иде. Ярар әйдә, иртән бар да ачыкланыр».*

Мендәремне рәтләдем дә лампаны сүндердем. Тып-тын.

Кинәт тәнем буйлап ниндидер калтырау йөгереп үтте. Монда нәрсәдер бар!

Тиз генә утны кабыздым – тынлык, берни юк.

Бернинди аваз ишетелми. Хәтта урамнан да.

Киеренкелек белән тынлыкка колак салдым. Әйтерсең колакка мамык тыкканнар – тыңладың ни, тыңламадың ни.

*«Ут яндырып йоклыйм. Әгәр йоклап китеп булса».*

Уйлап куюым булды, идәнгә нидер шапылдап төште.

Идәнгә килеп төшкән предметның бәрелгән тавышы мине караватка беркетеп куя язды. Мин инде йокымнан тәмам уяндым. Әйтерсең бөтенләй йокламаган. Йөрәк, бәреп чыгардай булып, котырынып тибә. Бернәрсә аңламыйча, тавыш килгән кебек тоелган якка озак итеп карап тордым. Тик берни дә күренми, берни ишетелми. Бөтен дөньясында бары тик бер минем йөрәкнең котырынып типкән тавышы гына яңгырыйдыр төсле.

*«Нәрсә инде бу?»*

Кинәт күңелгә шом керде: бүлмә буйлап кемдер йөри кебек тоелды. Акрын гына башымны борып карадым: әллә тойдым, әллә күрдем – чынлап та, бүлмәдә миннән башка тагын кемдер бар... Бер генә мизгелгә йөрәгем туктап калгандай булды, бөтенләй югалды. Тәнемә салкын тир бәреп чыкты. Баштанаяк. Маңгаемнан тир тамчылары агып төште.

*«Мөмкин хәл түгел бу! Ут янып тора лабаса! Нәрсә соң инде бу?!»* – дигән уй яшен тизлеге белән башымнан йөгереп үтте.

Әйтерсең мин башка дөньяга күчкәнмен. Үз бүлмәмдә булсам да. Япа-ялгыз. Бернигә дә карамастан, моның шулай икәненә иманым камил.

*«Нәрсә соң бу яки кем булыр бу?»*

Шул ук мизгелдә мин янә кемнеңдер бүлмә буйлап йөргәнен, ниндидер кыштырдау, предметларның күчүен ишеттем.

Котым очып, күзләремне ярымкараңгыга текәдем: шулчак үтә күренмәле кешенең җиңелчә сызымын (контурын), ягъни өрфә образын күреп алдым.

Ул, борчулы бер уйга чумып, минем бүлмәмдә ни беләндер мәшгуль иде кебек тоелды миңа...

Мин катып калдым, аны өркетмим дип үзем куркып, дөресрәге, минем барлыгымны сизмәсен дип, хәтта тын да алмыйча утырам, әйтерсең мин бүлмәдә юк, булмаган да.

Боларның барысы да сәер генә түгел, ә бәлки, мөмкин булмаган хәл иде – бу шәүлә ут яктысына туры килгәндә юкка чыга иде...

Аннары, минем өстәлем янына килеп утырды да кабат уйга чумды кебек күренде.

Йөрешенә, хәрәкәтенә, гәүдәсен тотышына карап торганнан соң, кинәт аның үземә охшаганлыгын күрдем һәм шулчак мин, моның мөмкин түгеллеген белсәм дә, гаҗәпләнеп уйлап куйдым: *«Бу мин микәнни? Минем образ? Тик кайдан килгән соң ул?!»*

Чарасызлыктан, өметсезлектән минем шәрран ярып кычкырасым килде, әмма, тамагым күптән кипкәнгә, тавышым чыкмады...

...Мин урамда гына аңыма килдем. Берни аңламыйм, берни хәтерләмим...

**ТӨН. ТРАМВАЙДА**

Урамда төн.

Һәрвакыттагыча фонарьлар юк, бары тик күзгә төртсәң күренмәслек караңгы.

Бер генә адәми зат та юк.

Кинәт әллә кайдан бу караңгы шәһәрдә рельслар буйлап әкрен генә миңа таба шалтыр-шолтыр килүче трамвай күренде.

*«Кайдан килеп чыкты ул монда? Аларның бу шәһәрдә булганы да юк бит һәм беркайчан да булмас та инде».*

Үзем дә сизмичә калдым, бара торган бу трамвайга ни өчендер сикереп тә мендем.

Салонда шулай ук беркем юк. Бер генә пассажир да күренми.

Бары тик сукыр лампалар һәм буш утыргычлар...

Шулчак мин тәрәзәгә карадым, тәрәзә пыяласында миңа гаҗәп таныш йөзне күреп алдым.

*«Кем булыр бу? Кайдан килеп чыкты? Трамвайда миннән башка кеше булмагач, буш трамвай тәрәзәсендә аның йөзе ничек чагыла соң?*

*Күзләре дә таныш үзенең. Карашы да.*

*Һәр көн диярлек мин аны күрәм кебек. Тик кайда?*

*Минем күзләремә шундый уйчан карыйлар... Тукта!!! Әллә инде... Әллә инде бу да минме?!*

*Булмас ла!*

*Мин бит әле яшь, ә аны инде җыерчык баскан, үзе бөкрәйгән, картайган!..»*

Бер төн эчендә, мәхшәрле төн эчендә хәлсезләнеп калган тәнем калтыранып куйды.

*«Бу трамвайдан төшеп калырга кирәк».*

Тик нәкъ менә шул минутта трамвай, тизлеген арттыра барып, инде бернинди тукталышсыз, караңгылыкка очты.

Әйе, әйе, тукталышсыз, хәтта рельсларсыз! Моны әле генә аңладым.

Аның тизлеге дә коточкыч иде, чынбарлыктагыдан чиктән тыш артык.

Тәрәзәдән сирәк утлар күренеп калды, күбесенчә – караңгы, туннельдәге кебек караңгы...

Җан-фәрманга барган бу трамвай мине әле бер якка, әле икенче якка ташласа да, мин трамвай йөртүче янына, дөресрәге, ул утырган кабина янына килеп җиттем. Кая баруыбызны сорамакчы идем.

Карасам, котым очты – анда да беркем юк...

Каядыр, билгесезлеккә «очучы» бу йомык пространствода мин берүзем икән бит.

*«Нишләргә? Кая бара бу трамвай, мин үзем кая һәм ни өчен барам?..»*

Ниндидер ярдәм өмет итеп, артыма борылып карадым һәм салонның арт тәрәзәсеннән караңгы урамда трамвайны күргәч кемнеңдер кулын күтәргәнен, ә ул туктамыйча узып киткәннән соң артыннан йөгергәнен күрдем.

*«Ниһаять, хет бер кеше пәйда булды...»*

Мин аңа җентекләбрәк карадым.

Гаҗәпләнүемнән сүзсез калдым: караңгы урамда трамвай артыннан йөгерүче кешенең мин икәнен танып алдым. Яшь чагымдагы мин.

Йөгерә, ә бит файдасызга йөгерә. Чөнки аның белән трамвай арасы һәр мизгелдә ерагайганнан-ерагая бара. Берничә секундтан бер-беребезне күрми идек инде...

Вакыт белән Пространствода эреп таралдык, бер-беребез өчен юк булдык...

Каядыр билгесезлеккә «очып баручы» трамвай һәм Мин. Ә бит әлеге шәһәрдә трамвайларның беркайчан да булганы юк, шулай ук цивилизациянең дә. Югыйсә монда бөтен нәрсә дә бар кебек, ә шул ук вакытта берни дә юк...

Шулчак көтелмәгән хәл булды – трамвай артыннан йөгергән һәм кинәт юкка чыккан теге адәм, берни булмагандай, җиңел һәм тиз адымнар белән трамвай ишеге янында пәйда булды. Ишек ачылып та китте һәм ул бер сикерүдә трамвайда иде инде...

Тик ул мине күрмәде кебек. Мине, ягъни үзен күрмәде.

Мин, бу хәлгә ышанырга да белмичә, селкенергә дә куркып торам.

*«Мөмкин түгел!..»* Каушаудан башка шул уй гына килде.

Аннары: *«Бәлки, ул минем игезәмдер?»* – дигәне өстәлде.

Ниндидер өмет салып уйладым мин моны. Шулчак пыялада үземнең бүтән чагылышымны күреп, сискәнеп киттем...

Сәгатемә карап алдым – уклары шул ук урында, бер минутка да күчмәгән. Колагыма куеп тыңлап карадым, үзе текелди, гадәттәгечә... Берни булмагандай...

Төн буе чабып йөрүдән бөтен тәнем авырайды, шулай да бу авырлык аякларыма төште бугай – аякларым арыды.

Әүвәлгечә зур тизлек белән барган трамвай артыннан тыны бетеп йөгергән кешенең нәкъ менә мин үзем икәнен тойган кебек булдым...

Әмма шул ук мин тыныч кына трамвайда утыра.

Бер мизгелдән тәрәзә пыяласындагы минем шәүлә җәелә башлады. Мин янә сискәнеп куйдым.

*«Нидер эшләргә кирәк, югыйсә юкка чыгуың бар»,* – дигән дуамал уй төште.

Эскәмиядән сикереп тордым да трамвай йөртүче кәнәфие янына ташландым һәм тиз генә тормозларга бастым. Кинәт туктаудан бөтен тәнем белән рульгә һәм алгы тәрәзәгә килеп сыландым.

Көчле бәрелүдән мин күпмедер вакытка аңымны югалтырга тиеш идем югыйсә, әмма мондый хәл булмый калды.

Минем организмым бербөтен булып тупланган, барлык мускулларым бер мизгелдә тыгыз резин массага әйләнгән иде...

Тәрәзәдән аерылып аякларыма бастым. Артыма борылып караган идем, тагын вакытның икенче үлчәнешендә булып чыктым: теге адәми зат, югары тизлектә кинәт кенә бернинди тукталыш булмагандай, сабыр гына торып басты, ишек янына килде, ишек тә берсүзсез буйсынып ачылып китте һәм ул трамвайдан төшеп тә калды...

Бу хәлләргә берни аңламыйча карап торганнан соң, тагын да ныграк аптырашта калдым: тәрәзәдәге йөзем ап-ачык булып, инде монысы бер канәгатьләнү белән миңа карап елмайды да чыгу исәбе белән ишеккә таба китте. Тик тәрәзә пыяласы буйлап!!! Шулай ук тыныч кына трамвайдан төште һәм, чакыргандай итеп, миңа борылып карады.

Мин әкрен генә башымны ишек ягына бордым һәм яңадан тәрәзәгә карадым. Анда янә үземне күрдем, хәзерге үземне...

Бу – яңадан миңа китереп бәрде. Искиткеч нык арыганлыкны, хәлсезлекне, йончыганлыкны сиздем...

Бернинди егәр дә, теләк тә юк иде. Тик бер генә нәрсә – тегеләр артыннан миңа да тизрәк чыгып таярга. Шулай эшләдем дә. Инде берни дә тоймый башлаган идем.

...Баш әйләнә. Мин бу караңгы шәһәр урамнарының берсендә басып торам. Кайда, кайсы төшендә – берни аңламыйм.

Хәзер инде моның әһәмияте дә юк иде. Иң мөһиме – мин трамвайдан котылдым. Күңелемә тынычлык керде, йөрәгемнең шашып тибүе басылды...

Тынычланырга иртә булган икән: әле генә трамвай торган якка борылып карасам, минем күз алдымда ул һавада эреп юкка чыкты – әйтерсең лә бөтенләй булмаган да, мин утырып та йөрмәгән!

...Ә бәлки, вакыт эчендә сәяхәт кылып, башка җирләргә китеп баргандыр...

**ШЫКСЫЗ ШӘҺӘРДӘ**

...Мин беренче адымымны кай якка – сулгамы, уңгамы ясарга белми басып торам.

Аптырап бераз торганнан соң, әле яңа гына теге трамвай кузгалып киткән җир аша ныклы адымнар белән туп-туры, ягъни үзәккә китеп бардым.

Әкияти рельсларны үткәч (алар инде юк иде), хәйран калып тордым. Имештер, теге трамвайга утырып киткән урында торам икән...

Күңелемнән эчке бер соклану хисе, әллә инде көлү ташып чыкты. Бу инде бернинди кысаларга, *әлеге реаль, сюрреаль һәм реаль бергәлектәге дөньяда объектив һәм субъектив катнашу һәм булу төшенчәсен аңлауның нормаль кеше мөмкинлекләренә сыймый торган көч иде*.

Акылдан язар хәлгә җиттем.

Шуны аңладым: алга таба гаҗәпләнерлек, шаккатарлык берни булмаячак. Һәм, уңга-сулга китмичә, туп-туры, караңгылыкта утырган шөкәтсез йортларга таба атладым...

Хәтта берни сизмичә, берни тоймыйча һәм бернәрсәгә дә гаҗәпләнмичә йорт аша уздым.

Үтәли.

Монда бернинди дә гайре табигыйлек юк икән.

Тик бернәрсәгә генә игътибар ителде, төгәлрәге – тойдым: бу йортлар чынбарлыкта, табигатьтә гомумән юк икән.

Бу – фикция, уйдырма гына. Һавада очып йөргәне дә түгел әле.

Ул бары тик минем хыялымда, күзаллавымда гына иде.

Ә хәзер ул инде юк.

Бу шыксыз шәһәр дә булмаган кебек.

Бер генә нәрсә дә юк. Бу дөнья да юк.

Шулай булгач, бирегә кайдандыр кинәт килеп чыккан минем тормышым да юк...

## II. МӘҢГЕЛЕК ҺӘМ ЧИКСЕЗЛЕКНЕҢ АКЫЛГА СЫЙМАСЛЫГЫ

### КАЙТУ

...Әйтерсең бөтен планета буш.

Бары тик караңгылык, күктәге сирәк йолдызлар гына – һәм башка берни дә юк.

Караңгылыктан кала бу шыксыз планетада берни юк.

Кайчандыр ни өчендер яшел-зәңгәр төстә дип аталган бу планетада.

Элекке исеме ниндидер бер кимсетү кебек яңгырый.

Һич башкача түгел. Мыскыл итү кебек...

Теге трамвайны гына булса да күрү һәм, шул трамвайга утырып, шыксыз булса да кайчандыр булган шәһәр утларын карап йөрү теләге уянды.

Тагын бер мизгелдән мөмкин булмавы белән мине әсәрләндергән уй төште: *«Мин – бу планетада берүзем икән бит.»*

Һәм мин күзләремне алга, караңгы пространствога текәп, аның иң биек ноктасында торам кебек, алдымда – бары тик минем галәмем генә...

Миңа җиңел булып китте – мин үземне йолдызларга якын итеп тойдым, пространство белән минем ара әйтерсең ачыла бара, шуның белән серле, кайчандыр миңа гаҗәп якын булган, ә хәзерге вакытта ни өчендер минем тарафтан онытылган дөнья якыная бара иде...

Минем яннан ниндидер бер тантана белән астероидларның биниһая зур кантарлары акрын гына йөзеп үтте, метеоритлар балкып-балкып китте. Аларның барысы да бик кечкенә, уенчык кебек кенә иде яки киресенчә. Мин генә ул гаять зур, чиксез гигант, ә уйларым һәм җаным бу космик киңлекнең үзе иде...

Шулчак мин әлеге чиксез киңлекне үтәли күрүемне аңлап алдым, ул бер үк вакытта чиксез дә, сүз белән әйтеп бирә алмаслык чикле дә иде.

Үзе бар, икенче караганда, юк та кебек.

Әмма бөтен күргәнемнең аңлатып бирә алмастай фантастик һәм гадәттән тыш булуы космосның җыенкыланып, җыйнакланып, кечерәеп калуында гына түгел иде. Мин аның матурлыгын, бөеклеген күрдем – бу планетада яши-яши онытып бетергән төсләрне, буяуларны күрдем. Монда бар да чиста, ачык һәм күзгә күренмәле; караңгылыкның, хәтта яктылыкның әсәре дә юк...

Балкышларның, шартлау, аҗаганнарның матур булып, төрле төсләргә кереп үзгәреп торуы артык якты да түгел, күзләрне дә чагылдырмый...

Астероидлар, планеталар, йолдызлар, кара упкыннар (чокырлар), кометалар, минем кайтуымны сәламләгәндәй, янымнан очып-очып узды...

### ТАНЫП-БЕЛҮ

Мин, шул парадны кабул иткәндә, ниһаять, әлеге пространствоның бер кисәге булып кына түгел, хәтта бу пространствоның үзе булып калдым.

Шулчак мин бернәрсәне аңлап алдым: боларның барысы да зур һәм әһәмиятле генә түгел, ә искиткеч бөек һәм акылга сыймаслык нәрсә (бөтен бу дөнья һәм андагы кешенең кайдан, ни өчен, кем тарафыннан, нәрсәгә һәм кайчан барлыкка килүен танып-белү безнең өчен беркайчан да мөмкин булмаячак, чөнки ул чакта без уйлап тапкан бу дөньяда гармония белән тәртип бозылачак. Димәк, биредә безнең вакытлыча булуыбызның иң кечкенә мәгънәсе дә юкка чыгачак...

Бәлки, шуның өчендер дә (яки ни өчендер) минем аша, аңым аша, уйларым һәм хисләрем аша акрын гына, ашыкмыйча очып узган минем бу галәмем өчен борчылу уе тугандыр.

Боларның барысы да миндә генә түгел, минем янәшәмдә дә: каршымда, өстә һәм аста, сулымда һәм уңымда – бөтен җирдә...

Хәзер инде мин шуны аңладым: ялгыз булсам да, берүзем генә түгел идем, ягъни янәшәмдә башка дөнья да бар, бу – минем галәмем, бу – минем эчке дөньям, эчке минем.

Гадәти «Мин»гә караганда, тагын да зуррак һәм бөегрәк булган нәкъ менә бу «Мин» мәһабәт һәм мәңгелек, шул ук вакытта гади һәм яклаучысыз ул дөньяның бер өлешен тәшкил итә.

Бу «Мин» – шул ук «башка» инде...

Алар – минем Галәмдәге башка дөньялар, үлчәмнәр, төшенчәләр, зурлыклар, вакытлар, күләмнәр – күп булды һәм бар.

Чиксез күп.

Аларны чагыштырырга да, янәшә куярга да ярамый.

Очсыз-кырыйсыз, чагыштыргысыз һәм бер үлчәүгә дә сыймый торган (үлчәүсез) бу нәрсәләр һәрвакыт булды һәм бар.

Аларның барысы да миндә һәм минем белән.

Һәм алар бары «Мин».

Шуның өчен икенче бернәрсәгә кучә торганы да шулай ук миңа кучә...

## III. ВАКЫЙГАЛАРНЫҢ (ХӘЛЛӘРНЕҢ) ВАКЫТЛЫЧА ГЫНА БУЛУЫ

### УЯНУ

...Көтмәгәндә караңгыда, искәрмәстән, әйтерсең очраклы рәвештә, әүвәл ыгы-зыгы, ә аннары, офыкның ярымәйләнәсен һәм сызымтасын сызып, яктылык нурлары таралды.

Һәм бераздан, әле ярым караңгылыкта, кояшның беренче нурлары сибелдe, аннан соң әле яңа гына беленгән офык артыннан күк йөзенә акрын гына, хозурланып һәм тантаналы рәвештә, кызган кызгылт-сары дискка охшаган гаять зур түгәрәк алсу шәфәкъ күтәрелә башлады. Минем планетам өстенә кояш чыкты.

Беренче көн иртәсе туды...

...Дөнья уянып килә. Бу җирдә һәм бу төндә ни булганын да белмичә, хәтта бу турыда бернинди шөбһәсез һәм хәбәрсез.

Дөнья бу хакта белә алмый иде, чөнки ул бөтенләй башка кагыйдәләр буенча яши.

Билгеле, ул мине дә белми. Аның өчен мин әллә бар, әллә юк.

Әмма бу дөнья үзенең яңа Вакытын исәпли башлаган иде инде.

Минем белән бергә барлыкка килгәнгә, минем белән бергә китәргә дә тиеш, һаман шул – бары тик миндә, минем эчке дөньямда...

### БЕРЕНЧЕ КӨН ИРТӘСЕ

Мин бу планета офыгын төгәл кояш боҗрасының ничек итеп яктыртканын күрдем.

Бу таң калырлык һәм илаһи бер күренеш иде: беренче көн иртәсендә ярымтүгәрәктән әлеге дә баягы хәйран зур кояш түгәрәге (дискы) тулысынча йөзеп чыкты...

Минем игътибарым һәм аңым бербөтен булып, үзем дә сизмәстән, табигатьнең – кошлар һәм хайваннарның, елга-күлләрнең, диңгез-дәрьяларның акрынлап уянып, кояш нурларына күмелә баруына күчте.

Миннән аста, миндә һәм минем аша аңгырайган кошлар сыман йөзеп баручы болытларга карадым.

Әйтерсең лә беренче мәртәбә. Чиксез гаҗәпләнү белән урманнарны һәм чүлләрне күзәттем, аларда хайваннарны йә булмаса кешеләрне эзләдем.

Табигатьнең уянуын күзәтү белән мәшгуль булып, дөньяда кешеләр арасында яшәү өчен тагын да яраклырак була бардым һәм, шундук хәрәкәткә килгән бу өзлексез әйләнештә тәмам югалып калып һәм бу төндә үзем белән ни булганын да онытып, әлеге планетада яшәүчеләрнең барысы кебек үк гадәти һәм төссез, берни белән аерылып тормаган җан иясенә әверелдем.

Дөнья бу төндә ни булганын күрмәде дә, белмәде дә, аңламады да. Ул хәтта планетаның әле яшел булуын да күрмәде, һәм, билгеле ки, биредә кабат, тагын бер мәртәбә булган мине дә белмәде һәм аңламады.

Әйе, дөнья үзенең яңа кешесен белми иде һәм белергә дә теләмәде, шуның белән ул үзен дә белми иде.

Тик моны инде мин үзем дә белми идем бугай...

### КӨН

...Ә халык ни өчендер (элеккечә) каядыр ашыга.

Аларны никтер (гадәттәгечә) берни кызыксындырмый – вакытлары юк.

Шулчак зиһенем таралгандай булды. Алардан күреп, баскан җиремнән кузгалдым да аларга кушылып мин дә каядыр йөгереп киттем.

Алар кебек үк, беркемне дә, бернәрсәне дә, хәтта үземне дә сизмичә, күрмичә.

Нәрсә булганын, ни буласын – барысын да онытып.

Бу сәер дөньяда Билгесезлеккә ашкынган бөтен кеше кебек.

Әйләнә-тирәмдә бар да күренеп-күренеп кенә кала...

Үзләрен читтән күрми, бары тик үзләре турында гына уйлый һәм кая, ни өчен йөгергәннәрен дә белми. Шуңа күрә бик тиз юкка чыга торган кешеләр үз дөньяларында шулай яшәде һәм яшиләр. Табигатьтән аерылмыйча, аның белән бер булып...

Бөтенләй көтмәгәндә-уйламаганда, йөгереп барышлый диярлек, югарыдан бу дөнья өстенә ялгызы гына сагыш белән карап торган кояшка күзем төште.

Ни өчендер ул икенче төрлегә әйләнгән, таң атканда чыгып килүчегә бөтенләй охшамаган. Аларның бу дөньясында кечерәеп калган һәм әһәмиятен югалткан.

Башка дөньядан, галәмнән килгән бу кояш биредә, әлеге планетада. Мин тәмам айныдым, зиһенем кайтты, чөнки мин кинәт кенә шуны искәрдем: тиздән без кешеләрнең берәрсе, үзен иң бөек дип исәпләп, моны да – минем кояшымны, минем дөньямдагы, минем галәмемдәге кояшны үзләштерер дә калганнардан, үзе кебек үк бернигә дә яраксыз, вак җанлы кешеләрдән ясак, салым җыяр.

Бу кояш бар кешенеке булса да, очраклы рәвештә генә монда, әлеге планетага килеп чыккан булса да...

Боларның барысын да – әлеге кешеләрне, аларның кимчелеген һәм бозыклыгын, түбәнлеген һәм саранлыгын, фәкыйрьлеген һәм мескенлеген күрү минем күңелгә тирән яра салды, түзеп булмаслык авырту биләп алды. Әйе, бу дөнья ахырына таба бара һәм аны туктату инде мөмкин түгел иде...

Минем уйлар шундый озын яки алар тормышы шундый кыска – мизгелгә тиң булдымы, талчыккан, беркемгә дә кирәге булмаган һәм беркем дә күрмәгән бу кояш дискы акрын гына офыкка, үзенең баешына төшеп китте, планетаның ярымтүгәрәге артына кереп югалды, әйтерсең ул безне дә шунда – - караңгылыкка, йолдызларга чакыра, шуның белән безгә һәммәбезгә дә үткәнебез турында, кайдан килүебез һәм киләчәгебезнең кайдалыгы турында искәртә кебек иде.

Ул барыбызны да туктап калырга, хәл алырга һәм уйланырга чакыра, өнди.

Тик галәмнән, космостан килгән бу билгене беркем дә күрмәде һәм беркем дә аңларга теләмәде.

Әле үзем дә көн башланганда бу турыда онытым...

Ә халык, инде нәрсәдәндер канәгать булып (әйтерсең бу аларның биредәге алдан билгеләнгән язмышы), кирегә, ягъни бу иртәдә кайдан йөгерешеп киткән булсалар, шуңа таба юл алды.

Минем әлеге яшел планетамдагы беренче көнем менә шулай үтеп китте.

**ТӨН**

...Төн җитте.

Мин, җиңел сулап, өметләр, ышаныч белән, баштанаяк төнгә чумдым – ял иттем, дәрман җыйдым, үз аңым, үз минем чоңгылларына, үз эчемдә сокланудан һәм тетрәнүләрдән нишләргә белмичә, ерак һәм акыл ирешмәслек дөньяларга һәм киңлекләргә очып киттем.

Бу миңа гаҗәп якын, әмма инде күптән булган дөньяны искә төшерде – һаман да шул, бары тик миндәгене.

Чынлап та, төнлә белән безгә нинди генә төшләр, уйлар һәм хисләр килми...

**ТӨНГЕ ЮЛАУЧЫЛАР**

...Караңгыда җимерелеп, ватылып беткән юлдан ялгыз эт бара.

Мөгаен, хуҗасыз эттер.

Мондый этләр нык күбәйде, этләр генә түгел, йортсыз-җирсез кешеләр дә бик күп хәзер.

Ашыкмыйча гына, җиңелчә йөгереп, бик еш туктый-туктый, шундый өзек-өзек ритм белән ул алга – билгесезлеккә атлый.

*Мин, янында булмасам да, аны күрдем.*

Чүп тутырган ниндидер тартма янында туктап, ул аны тәпиләре, танавы белән актара башлады...

Шулчак кайдандыр кеше килеп чыкты һәм эт, куркып, читкәрәк барып басты.

Хәзер инде кеше чүп савыты иясе булды.

Әмма ул бик тиз тынычланды һәм, ачуы килеп, тартмага тибеп куйды. Димәк, кызыксындырырлык берни юк...

*Минем игътибарым инде аңа юнәлде.*

...Кеше шул ук юлдан ары таба китте. Сагыш белән, бөкрәя төшеп, бернинди максатсыз. Тишек аяк киемендә, ертылып беткән чүпрәк-чапракта. Ниндидер торак яныннан үткәндә ул, сыерчык оясына охшаган гаять зур өйнең тәрәзәләренә текәлеп, туктап калды.

*Мин сагышлы һәм моңлы, теге дөньядан яңгыраган төсле гаҗәп таныш музыка ишетелгән тәрәзәләрнең берсенә карап тора башладым.*

Мизгелнең санаулы өлешләре эчендә мин квартирда идем инде. Өстәлдә CD ята, туктаусыз музыка яңгырый, тик беркем дә юк.

Җентекләбрәк карый башласам, имәнеп киттем – мин үз квартирымда икән бит, дискны да үзем куеп чыгып киткәнмен!..

Каушап калганга, уйларым буталды. Әмма теге кешене исемә төшерү белән мин урамда идем инде.

Тик ул юкка чыккан.

Барлык подъездлардан, тирә-юнемнән, янәшәмнән аны эзли башладым.

Әллә ул бөтенләй булмаганмы? Миңа шулай тоелды.

Мин ары таба китәргә батырчылык итмәдем, тик шул вакыт юлда теге эт пәйда булды.

Ашыкмыйча гына килә бирде, инде бу йорт янына да якынлашты.

Нигәдер: *«Эткә ияргә кирәк, ул теге кеше артыннан, аның юлыннан бара. Аларның юлы да, маршруты да бер...»* – дип уйлап куйдым.

Шулай булып чыкты да.

Хәрәкәтемне, әллә очуымны шунда, бераз тизләтеп, мин аны кабат күреп алдым: ул, башын кая куярга белмәгәнгәме, аягүрә йоклап бара.

*...Кинәт чигәләрем, коточкыч кисеп, кысып авырта башлады һәм мин, эт булып арып, авыртудан һәм картларча бөрешеп, өстемдәге киемемне тарткалап куйдым да, кире борылып, тиз-тиз, әллә инде йөгереп, өйгә таба киттем.*

*Караңгы төндә мин йөгергән юл өстеннән ялгыз шәүләмнең артымнан куып килгәнен күрдем...*

*Каршыга ниндидер бер эт килеп чыкты.*

*Без, бер-беребездән куркып, караңгыда читкә тайпылыштык.*

*...Минә өйгә дә җиттем.*

*Тәрәзәдәге утны күргәч, йөрәк түремдә гитара кылларының тибрәнүен һәм җырчының (Грейс Сликмы, Марешка Верешмы шунда) ямансу моңлы тавышының интенсив яңгыравын тоеп, мин караңгы подъезд баскычларыннан тиз генә квартирыма килеп кердем...*

...Төнге ялгыз юлаучылар исә үз юлларын таңга, иртәнгә кадәр дәвам иттеләр.

Әгәр алар чынлап та булган булса...

**ТӨНГЕ САГЫШ**

Шулчак мин шуны аңладым: бүген, бу төндә бөтен кеше алмашынды, аларның саны һәм сурәтләре шул килеш калса да, җаннары алмашынды, ә бит аларның берсе дә көн дәвамында үз миненә кереп карамады, үзенә хәтта читтән дә күз төшермәде. Бары тик бу көнне ничек уздырырга, ничек яшәп чыгарга дип кенә уйлады. Һичшиксез, башкалар хисабына – әйләнә-тирә мохит, табигать, кешеләр, ягъни бары тик киләчәк хисабына яшәү иде исәпләре...

Мин ниндидер бер сагыш белән төнге күккә, бер мәгънәсезгә түгел, ә бәлки кайдадыр еракта – чиста, якты, ачык, чикләрсез, тыюларсыз, ирекле тегендә – дөнья барын искә төшереп җем-җем килеп торучы йолдызларга карадым...

Миемне авырттырып, яңадан шул ук уй йөгереп үтте: мин – бу планетада берьялгызым икән бит...

**КЕШЕЛӘР**

Кызганыч, алда торган һәр көн узган көнгә охшаш.

Бер-берен сүзсез генә алыштыручы кешеләр бер-берсеннән берни белән дә аерылмый – һәрберсе ни өчендер нәрсәдер расларга (үзенә түгел, башкаларга) тырыша, ахыр килеп, шуның белән ул үзе кебекләрне кимсетә, рәнҗетә һәм юкка чыгара.

Аларның бу планетада очраклы рәвештә генә булуларының бөтен мәгънәсе шунда кебек тоелды.

Минем уйланулар үзләреннән-үзләре бер фикергә китерде: тиздән кешеләр бер-берсенә суларга да ирек бирмәячәкләр, һаваны хәтта үзләреннән дә алачаклар һәм тончыгачаклар. Беришләре – һавадан башка, икенчеләре – артыклыктан.

Беркемгә дә кирәкмәгән борчулардан, кичерешләрдән арып, мин йоклап алырга уйладым, тик кешеләр дөньясының һәм бу планетаның һәлакәттән котылгысызлыгыннан бәреп чыккан салкын тир һәм калтырау мине кузгала алмаслык хәлгә китерде.

Аларның һәлакәткә дучар булганлыгы, шул исәптән минем дә, җанга тынгы бирмәде.

Бит аларның барысы да миндә, минем эчке дөньямда...

**МУЗЫКА**

...Әйтеп бетергесез арыганга күзләремне япсам, кинәт беренче мәртәбә үз Музыкамны күрдем.

Авыртудан йөрәгем кысылды. Вокал никадәр югары, моңлы булса, кыл булып тартылган нервыларым күтәрә алмаслык авырлыктан әллә шартлап өзелде, әллә, киресенчә, тынычланып калды...

Тормышны, яшәешне искә төшергән бу композиция моңсурак булган саен, теге төнне һәм үз галәмемне ачыграк күрдем мин, һәм, эчтән күзгә күренмәслек ноктага кадәр кысылып, бөрешеп, үз эчемдә чиксезлеккә кадәр киттем.

Мин шундый биеклеккә яки тирәнгә киттем ки, хәтта кечкенә һәм җем-җем килеп торучы йолдызларга кадәр җиттем. Эчке дөньямда, үз чиксезлегемә...

Һәм үземнең иң соңгы ноктама җитүгә, мин бу упкыннан яктылык тизлеге белән, мизгелләрнең бер мизгеле эчендә яңадан үземнең чиксез «Мин»емә әйләнеп һәм шуның белән сакланып калып, кире кайта идем...

Эчке дөньямдагы бу авырту һәм борчылулар мине тагын да сизгеррәк итте, һәм мин бу дөньяны үтәли генә түгел, берьюлы берничә халәттә һәм үлчәмдә күрдем.

Алар, үзем кебек үк, реаль булмаса да, тәнсез булса да, алар аша үткәндә, аларны тойганда һәм аңлаганда мин аларга ярдәм итәргә теләдем, әмма алар, бу йолдызлар, мине кабул итмәделәр, янәсе, тормыш-яшәешкә ия булгач, мин алар өчен чит-ятка әйләндем.

Әмма музыка барыбер бар иде, ул миңа уй-фикерләрне һәм хисләрне генә түгел, теге – минем дөньямнан килгән бу мәгълүматларны тапшыра ала иде...

## IV. КОТЫЛГЫСЫЗЛЫКНЫ ҺӘМ ҺӘЛАКӘТКӘ ТАБА БАРУНЫ АҢЛАУ

### ЧЕЛЛӘ

...Бер генә болыт әсәре дә юк.
Бар да хәрәкәтсез калган.
Көйдереп торучы кызу кояшта хәлсез калудан...
...Бернинди селкенү.
...Бернинди хәрәкәт.
Турыдан-туры төшеп, бар нәрсәне үтәли яндырып торучы кояш нурланышы һәм радиация.
Ут кебек кызган, гаҗәп нык кызган, күзләрне кисеп үтә торган көйдергеч һәм тузанлы һава.
...Сусызлыктан арыган,
яргаланган, корып каткан
һәм бар нәрсәгә битараф җир.
Көеп янган дөя чәнечкесе,
дүңгәләк (өермә үлән) һәм
карагач...
...Җилдә яргаланып кипкән тире.
Тешләрдә, авызда ком.
Бернинди тавыш юк.
Бары тик
даими тибрәнеп торучы,
кайдадыр биеккә элен гән
һәм колакларда тынып калган чың.
Өметсезлек,
Котылгысызлык,
Сагыш
Һәм һәлакәткә дучар ителү –
Җирнең,
Табигатьнең,
Кешеләрнең...

### «Ч» ВАКЫТЫ

...Мин кайчандыр берәү утырган трамвайда булдым, һәм аннан чыгу бәхетенә ирештем, ә хәзер кешеләр арасында яши башладым.

Әмма яшәү, аларда кабул ителгәнчә, кояш астында, бигрәк тә минем кояшым астында һәм минем планетамда иң яхшы урын өчен көрәшү генә түгел әле. Бездән моны беркем дә беркайчан да тартып алмаячак.

Чөнки ул – мәңгелек, шул ук вакытта минем «мин» кебек үк – вакытлыча.

Шулай булса да, алар, акча һәм хакимлек өчен көрәштә күзләре томаланып, цивилизациянең үз планетасын, аның белән бергә үзен дә эзлекле рәвештә йотып барганын күрергә дә, аңларга да теләмәделәр. Шуңа күрә шартлауга һәм һәлакәткә якынаялар да...

Боларның барысы да һәлакәтнең башы.

Алга таба кайчан нәрсә буласын, планета белән, кешеләр белән, димәк, минем белән дә, ягъни минем эчке дөньям белән дә ни буласын беркем, хәтта галәм дә белми иде. Белгән булса да, чишелешне көтеп, дәшми торды, бары тик янәшәбездән цикл саен очып узучы гаять зур кометаларны, безнең акылыбызга сыймаслык UFO кебек нәрсәләрне җибәреп кисәтә генә иде.

Шуңа күрә «Ч» вакыты безнең дөнья өчен, димәк, минем өчен дә әле килмәгән дип ышанасы килә...

Әмма йолдызлар дөньясы яки йолдызлы дөнья биредә, Җир йөзендә без тудырган, кешеләр тудырган ыгы-зыгыны, ялганны яратмый, кабул итми.

Без бөтенебез дә – планетабыз һәм кояш – исәпсез күп башка йолдызлар һәм галактикалар кебек үк, бербөтеннең аерылмас, бер-беренә тулысынча бәйле өлешләре...

Һәм менә көннәрдән бер көнне әллә төштә, әллә өндә күргәннәрнең кирәгеннән артык өеме үзенең югары ноктасына җитте. Мин инде безгә якынаеп килүче бөтендөнья һәлакәте һәм суырып алырга әзер чоңгылы алдыннан соңгы дәһшәтне күрдем һәм үземнең бөтен барлыгым белән тойдым – озон катламы саклавыннан мәхрүм калган планетабызны зур булмаган һәм гаять зур астероидлар чын-чынлап бомбага тотты; алар, гадәти ташлар сыман, өстән явып кына тордылар, ә кешеләр, дәһшәт китергән куктән күзләрен алмыйча, качып котылырга теләп төрле якка сибелделәр, барыбер файдасы тимәде, чөнки бу таш ташкыныннан исән калган тере организмнар шундук кояшның бөтен нәрсәне яндырып, көйдереп юк итүче ультрафиолет нурланышы белән юкка чыкты, көл булды. Бары тик яңача, дөрес яши башлау гына кешеләрне һәм планетаны һәлакәттән коткарып кала алачак иде, әмма яңарыш та, акылга килү дә булмый калды...

Әйтерсең бу дөньяда берни булмаган.

Ни кешеләр, ни бу дөнья, ни бу йолдызлар белән – бернәрсә дә булмаган.

Шуңа күрә мин үзем дә булмаган.

*Бары тик миңа гына, минем йөрәк клапанының бу дөм караңгылыкта һәм тынлыкта барысын да миңгерәүләтерлек, һуштан яздырырлык әүвәл салмак, аннан торган саен ешая барган, киеренке, тигезле-тигезсез һәм йотлыга-йотлыга тибеше генә ишетелә кебек тоелды...*

**ТЫНЫЧЛАНУ**

...Нык итеп ябылган ишек яңагы астыннан идәннәрне, дивар, түшәмне яктылык сибеп торучы тыгыз пәрдә белән томалап, агып торган коры бозны хәтерләткән зәңгәрсу төтен акрын гына шуышып чыга һәм бөтерелеп күтәрелә башлады...

Ишек сизелмичә генә ачылып киттеме, әллә юкка чыктымы, бусагада күз алдыма да китерә алмаслык гаҗәеп бер күренеш ачылды: ишегалды мәйданчыгы юк, бары тик ялтырап торган яшькелт төсмерле җете кызыл-зәңгәрсу яктылык кына бар иде. Бу яктылыктан нык рәхәтлек бирә, тынычландыра һәм үзенә тарта торган нурланыш сибелә иде.

Бүлмә балкып китте – барлык предметлар әллә кая китеп юк булды – тирә-юньдә бары тик шушы нурландырып-йотып торучы яктылык кына хөкем сөрә иде...

*Һәм минем җаным, әлеге җем-җем килгән яктылык бормалары буйлап очып китеп, биеккә-биеккә күтәрелде һәм шул ук мизгелдә, җиңелчә генә җил исеп куйгандай, бу зәңгәрсу караңгылыкта эреп югалды, әйтерсең ул биредә беркайчан да булмаган...*

*Мюнхен, декабрь, 1994*

## Хәтер сандыгыннан

*Тарихларга кереп басамын да*
*Хәтер сандыкларын ачамын.*
*Кайчакларда дошман явын күреп,*
*Уйларыма кереп качамын.*
*Хәнҗәрләре киссә йөрәгемне,*
*Хакыйкатьне күмсә, нишләрмен?*
*Без болай да күпме газап чиктек,*

*Нәтиҗәсен күреп мең ялганның,*
*Ярылып яткан кыңгыр эшләрнең.*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

## КЕРЕШ СҮЗ УРЫНЫНА

Үз тарихыңны белми һәм аңа билгеле бер мөнәсәбәт булмый торып, мәдәниятне берничек тә үстереп булмый.
*Л.Н.Гумилев*

*Һәр кешенең башка кеше хакыйкатеннән аерылып торган үз хакыйкате бар, шулай ук һәр халыкның башка халык хакыйкатенә охшамаган үз хакыйкате бар.*

*Таләп ителгән нәрсә шул: әүвәл аны әйтү, бары тик шуннан соң гына үзенеке белән чагыштыру мөмкинлеген бирү.*

*Нәкъ шуның кебек үк, җәмгыятьтә һәр кешенең үз урыны бар. Бу дөньяда һәр халыкның да үз урыны бар, шуңа күрә үзе турында бары тик ул гына сөйләргә тиеш һәм сөйли ала.*

*Юкса чит кеше сөйләгән тарих бөтенләй икенче халык тарихы булачак.*

Соңгы елларда тереклек эшчәнлегебезнең барлык өлкәләрендә дә бара торган өстенлекләрне һәм кыйммәтләрне кабат бәяләү, җәмгыятьнең сәяси-социаль-икътисади нигезен тамырдан үзгәртеп, безнең барыбызны да нык үзгәртә. Асылда барысын да үз даирәсенә кайтара.

Катлаулы һәм шуның өстенә авыртуларсыз, борчуларсыз үтми торган әлеге процесс, чынбарлыктагы хәлләргә карашларны һәм мөнәсәбәтне үзгәртә барып, бүгенгенең генә түгел, узган көннең дә шактый күп мәсьәләсен ачты һәм ача тора.

Иң әүвәл дәүләт тарихыннан, дөресрәге, әле күптән түгел генә без яшәгән, кайберәүләр исә бүген дә яшәп ята торган империя тарихыннан.

Яңа мәгълүматлар ташкынында еш кына элек без белгәннәргә бөтенләй капма-каршы фикерләр һәм бәяләмәләр өстенлек итә башлавы да закончалыклы. Төгәлрәк итеп әйткәндә, без элек күп нәрсәне белмәдек. Беленми калды.

Мәсәлән, хәзерге Атырау (Гурьев) өлкәсе территориясендә соңгы меңьеллык дәвамында күптөрле милләт һәм халык вәкиле яшәде, әле хәзер дә яши. Биредә төрле дәүләт берләшмәләре гамәлдә булды. Аларның идарә итүләре һәм юкка чыгулары турындагы тарих җентекләп өйрәнүне, бер үк вакытта ихтирамны да таләп итә.

Бүгенге көндә генә дә монда алтмыштан артык милләт вәкиле исәпләнә...

Без әлеге казах җирендә безгә кадәр яшәгән халыкның, һич булмаса, үз халкыңның, үз гаиләңнең язмышын, чын тарихын (үз генеалогияң турында әйтмим дә инде) беләбезме соң?..

Җавап бер генә – күбебез белми.

Моңа аңлатма да бер генә – бүгенге көндә гасырлар тирәнлегенә төшеп, объектив, җентекле эш итүне, теге яки бу тарихи фактка яки вакыйгага дөрес бәя бирүне рөхсәт итмәгән, мөмкинлек бирмәгән хакимлек итүче режимнарга ярарга тырышкан күпгасырлы фальсификация, бар нәрсәне бозып, ялган юлга кертеп күрсәтү.

Бастырып чыгарылган материаллар, беренче чиратта идеология һәм хакимияткә бәйсез тарихчылар идеологиясе, шуны раслый: Россиядә бөтен гасырларга кагылышлы рәсми тарихи фән, Иван Грозныйдан башлап әле күптән түгел генә гамәлдә булган ялган социализм дәверен дә исәпкә алып, асылда, тулаем ялган булмаса да, шактый бозылган, үзгәртелгән.

Бу әле йомшак итеп әйткәндә.

Ул бары тик әлеге бөек державачыл дәүләт мәнфәгатьләрен ныгытуга һәм раслауга хезмәт итте.

Калганнарның барысы да бер үҗәтлек белән һәм даими рәвештә халыклар хәтереннән юып алынды һәм вакыт узган саен тигезләнде, аермалар бетерелде.

Нәкъ менә шул мәнфәгатьләрдә чагыштырмача күптән түгел генә халыклар күчереп утыртылды, җирләр һәм территорияләр үзара һәм үзирек бүленде, миллионлаган кеше юк ителде, нәтиҗәдә бары ГУЛАГта гына да әлеге империя хакимлегендә булган халыкларның интеллектуаль генофонды туры мәгънәсендә җиргә күмелде.

Ул гына да түгел, бу хәлләр гомер-гомергә Кремль хуҗалары каһәренә тарган халыкларның газаплары һәм каны белән кушылып барды.

Бу канлы сәясәт бүгенге көндә дә дәвам итә.

1994–1996 елларда уйлап чыгарылган агрессия һәм чечен халкын чираттагы кырып бетерү сәясәте – моңа дәлил...

Ә бу хәлләрдән шактый алда, XVI гасырда, шул ук мәнфәгатьләрдә тулы бер халыкның мөстәкыйль рухи мәдәниятен һәм тарихын юк итү процессы башланды: аның бер өлеше көчләп башка дингә

күчерелде, ә халык берникадәр вакыттан соң үзенең чын этнонимыннан, ягъни исеменнән дә мәхрүм ителде.

Сүзем – бүгенге Казан татарларының элгәрләре – Идел буе болгарлары турында.

## I. «ТАТАР-БОЛГАР – БЕРТӨРЛЕ»

*Россия империясе – биредә яшәүче башка халыклардан аермалы буларак, бөтен бәласе гасырлар буе аның исеменнән хакимлек һәм шул ук вакытта бары бер генә нәрсәгә – урысларга изге булып тоелган, шуңа күрә аларга илаһи көчтәй тәэсир итүче иң мөкатдәс сүзгә – Россия дигән сүзгә һәрдаим басым ясап сылтау итүчеләр тотыгы һәм үз хакимнәренең (патшамы ул, генсек яки президентмы – барыбер) барлык канлы гамәлләрен аклау булган урыс халкы гына түгел, әлбәттә...*

«Татар-болгар – бертөрле», – дияләр иде заманында әбием белән эти-әнием. Бу әйтемнең чын мәгънәсен мин бары үсеп җитеп, өлкәнәя башлагач кына аңлый һәм ни икәненә төшенә алдым. Әле анда да бу темага караган төрле әдәбият һәм тикшеренүләрне җентекләп өйрәнгәннән соң гына.

«*Татар-болгар – бертөрле*» («*Татары и булгары – одинаковы*»), ягъни алар бер үк халык, алар арасында бернинди аерма юк. Гасырлар чоңгылында сакланып калып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән әлеге әйтем русчага шулай тәрҗемә ителә һәм шулай аңлатыла да.

Чынлап та, совет тарихы аның дөньяда булуын, нигездә, Руська монгол-татарларның басып керүенә генә бәйләгән халыкның мең ярым еллык тарихын ничек итеп төшереп калдырган соң?

Ә бит бу тарих әле XIX йөздә үк Н.М.Карамзин, И.Н.Березин, В.В.Григорьев, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри кебек күренекле галимнәрнең һәм башкаларның, Казан татарлары Болгар дәүләтенең төп халкының, ягъни Идел буе болгарларының, беренче мәртәбә хәзерге Кубань территориясендә, Кара диңгезнең төньягында безнең эраның 550 елларында ук төрки телле болгар кабиләләре яшәвен раслаган готик анналлар һәм грек телендә язылган тарихи әсәрләрдә телгә алынган төрки телле халыкның тарихи үсеше нигезендә формалашуы турында ике төрле уйга урын калдырмаслык нәтиҗә ясалган булуына да карамастан юкка чыгарылган.

Югыйсә бит катлаулы тарихи процесс нәтиҗәсендә болгарлар Итил (Идел) белән Чулман (Кама) елгалары арасына безнең эраның VII йөзендә үк, ягъни Батый хан ябырылуыннан күпкә алдан килеп урнаша.

Шуның өстенә нәкъ менә алар, бүгенге Казан татарларының борынгы бабалары, биредә, Көнчыгыш Европада, беренчеләрдән булып, үз язуын булдыра, югары сыйфатлы чуен коя башлый, канализациясе һәм мунчалары булган искиткеч матур шәһәрләр төзи, тире, алтын, көмеш эшкәртү осталыгына ия була. Ә дәүләтчелегенең тарихы мең елны узып китә...

Бу хәлләр бераз соңрак булганга, хәзер исә тәртип буенча китәрбез.

### 1. ТӨРКИ БОЛГАРЛАРНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ТАРИХЫННАН

Кайбер галимнәр фикеренчә, безнең эрага кадәр VIII йөздән башлап безнең эраның IV йөзенә кадәр Евразиянең гаять зур дала киңлекләрендә – Көнбатыш Себер тигезлегеннән Түбән Иделгә, аннан Кара диңгез буйларының Төньягына кадәр җирдә – төрле вакыт аралыгында иран телле халыкның – *скиф-сармат* кабиләләренең күчмә урыннары җәелеп яткан.

Яңа эра чигендә Түбән Идел буен һәм Хәзәр диңгезе (Каспий) алды түбәнлеген шулай ук иран телле *аланнар* били.

Әмма бу урында түбәндәгеләрне дә әйтми китеп булмый:

*«Рәсми тарих фәнендә скиф-сака-сармат-аланнарны иран телле халык дип танучылар булса да, бу теория этимологик, археологик һәм дини-мифологик фактларга нигезләнә алмый...*

*...Скиф, сармат, аланнарның төрки булуы турындагы ышанычлы чыганаклар безнең көннәргә кадәр сакланган...*

*...Кайсы яктан гына тикшермә, киммер, скиф, сармат дигән гомуми этнонимнарны йөрткән халыклар нигездә төрки булганнар. Димәк, төркиләр – Евразиядә иң борынгы халыкларның берсе. Аларны Көнчыгыш Европага, шул исәптән Идел-Уралга безнең эраның IV йөзендә генә килә башлаулары турындагы фикер – тарихи уйдырма гына» (М.З.Зәкиев).*

Якынча шул ук елларда, безнең эрага кадәр III йөздән безнең эраның II йөзенә кадәр вакыт эчендә, Үзәк Азиянең Көнчыгыш өлешендә Евразия далалары күчмә кабиләләренең тәгаен билгеле беренче сәяси бердәмлекләренең берсе – Һуннар дәүләте, ягъни Һуннар каганаты оеша. Алга таба ул Европа һәм Азиянең байтак кабиләләре һәм халыкларының катлаулы этник процессларында үз ролен уйный.

Безнең эраның 155 елларында һуннарның күчмә урдасы тар-мар ителә һәм Үзәк Азиянең көнчыгыш районнарыннан һәм Кытай белән янәшә территорияләрдән сянбийлар тарафыннан кысрыклап

чыгарыла. Һуннарның төрки телле өлеше Көньяк Урал буе һәм Түбән Идел аръягы далаларына күчеп утыра һәм, ул җирләрдә якынча инде ун мең еллап яшәгән фин-угыр кабиләләре белән кушылып яши башлый.

Л.Н.Гумилев фикеренчә, борынгы төрки телле болгарларның бабалары – нәкъ менә югарыда телгә алынган *төрки-угыр* кабиләләре: *сарагурлар, оногурлар* һәм *уроглар*, ә борынгы ватаннары Көньяк Урал буе санала.

Яңа эра документларында болгарларның элгәрләре, борынгы бабаларының кабиләләре II–III йөзләрдә хәзерге Мордовия, Чуашстан һәм Мари Иле территорияләрендә яшәгән дип исәпләнә.

Бу чор турында үзенең «Борынгы төркиләр» һәм «Каспий тирәсендә мең ел» дигән хезмәтләрендә Л.Н.Гумилев менә нәрсә яза: «Безнең эрага кадәр VIII йөздә Евразия даласы менә нинди булган: иң әүвәл аңа кадәр биредә яшәгән *киммерларны* куып җибәргән скифлар өстенлек итә, 500 елдан соң – сарматлар, 700 елдан соң аларны төрки телле азиат һуннар, җирле угырлар (көньяк Себер һәм Урал тирәсе фин-угырлары) һәм сарматлар симбиозы – һуннар этносы алыштыра».

Алга таба болгарлар әлеге күпсанлы төрки кабиләләр составында Җаек һәм Итил елгалары арасындагы далалар аша беренче меңьеллык башында, нәтиҗәдә күчмә кабиләләрнең актив күчешен, этномәдәни бергәлекләрнең кушылуын һәм Рим империясенең җимерелүен китереп чыгарган һәм халыкларның Көнчыгыштан Бөек күчеше дип аталган чорында Европага килеп урнашкан *гуннар* яки һуннар (die Hunnen) дигән уртак исем белән очрый башлый.

350 елда әле II йөздән үк Урал буеның көньяк-көнчыгышында яшәгән болгарларның элгәрләре – һуннар урдасы кабиләләре – *савирлар, акацирлар* һәм аларга тугандаш *утугырлар* – басымы астында Азов буе һәм Кубань тирәсе далаларына барып чыга.

Шулай итеп, инде IV йөз урталарында төрки телле болгарлар үз көтүләрен Кавказ тирәсендә көтә башлый. Итил тамагын төрки телле хәзәрләр били, ә Хәзәр (Каспий) диңгезе түбәнлегендә аланнар урнаша.

371–375 елларда, алан, болгар һәм сармат кабиләләрен һуннар тар-мар иткәннән соң, түбәндәге вакыйгалар була:

Арал диңгезеннән көнбатышта аланнарның байтак гасырларга сузылган хакимлегенә чик куела, һәм алар Кавказ якларына китеп бара.

Көнбатыш Казахстан, Урал буе һәм Итил далаларында *номад-сарматлар* мәдәнияте юк ителә, үзләре Чулман аръягына күченә.

Ә болгарлар, үзләренә кардәш башка *төрки-угыр* кабиләләре белән берлектә, Көнчыгыш һәм Үзәк Европага юл тоткан һуннар армадасының бер өлешен тәшкил итә.

Әмма 370 елның икенче яртысында ук әүвәл һуннар белән бергә киткән төрки-угыр кабиләләренең шактый өлеше кире көнчыгышка таба китә башлый. Түбән Итилгә һәм Көньяк Урал буена, әлегә Һун империясенә буйсынган территорияләргә юл ала.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Паннониягә, Грециягә, Сүриягә, Мессопотамиягә бәреп кергән һуннар Төньяк Кара диңгез буеның антик дәүләтләренә җимергеч һөҗүм ясый һәм кайчандыр сугышчан, җиңелмәс гот кабиләләре берлеген (союзын) тар-мар итә. Заманында әлеге кабиләләр Сквандинавиядән үз десанты белән китеп, халыкларның Бөтендөнья күчешен башлап җибәрә. Боспор патшалыгын туздырып, һуннар Рим империясен җимерүдә дә катнаша.

(Кайбер тарихчылар фикеренчә, Алмания һәм Англия корольләре династияләре үз башлангычларын һуннарның борынгы бабаларыннан алган.)

Византия язма чыганакларыннан билгеле булганча, болгарлар Аттила һуннары белән тугандаш дип саналган. Аның хакимлеге чорында, 434–453 елларда, һун кабиләләренең әлеге хәрби-сәяси коалициясе иң зур куәткә ирешә. Аның сафларында һуннардан кала *остро-готлар, гепидлар, герул, бастарна, скир, алеман, бургуир, франк, тюринг, турлинг, руг, болгар* һәм *акацирлар (агадирлар)* сугыша.

Нәкъ менә һуннар башта «сигез ай юл озынлыгында, алты ай юл киңлегендә», ягъни Дунайдан Ленага кадәр сузылган җирдә, шактый соңрак Днепр белән Итил елгалары арасындагы далаларда Дәште Кыпчак (Дәшт-и Кыпчак), ягъни Кыпчак даласында формалашкан дала төркиләренең булачак гаять зур дәүләтенә нигез сала.

Әмма ләкин Аттиланың вакытсыз вафаты һуннар арасында эчке бәрелешләргә китерә. Бу бәрелешләр 463 елда болгар кабиләләренең Кавказ аръягына яу чабуы һәм һуннарның тылын тәшкил иткән *акацирларны* тар-мар итү белән тәмамлана. Шуннан соң инде Һуннар империясе какшый башлый һәм нәтиҗәдә гаять зур киңлекләргә тупланган берничә өлешкә таркала. Төп өлеше Византиядә (Добрудже) төпләнеп кала.

Бу вакыйгалар алдыннан һуннар конфедерациясенең таркалуы чорында, IV–V йөзләрдә, гомумһун мохитеннән төрки телле халыкларның *огур* кабиләләре төркеме бөтенләйгә бүленеп чыга. Аның иң зур өлешен *болгарлар* яки *булгарлар* тәшкил итә. Алар бу җыелма этноним астында берләшә, бергә туплана.

Шулай итеп, Евразия кыпчак даласында акацирларны тар-мар иткәннән соң һуннарны алдагы 200 елда борынгы болгар кабиләләре – *кутугырлар (кутругур), утугырлар (утругур), оногурлар, унногундурлар, огрлар (угырлар), сарагурлар*, шулай ук Көнбатыш Хәзәр диңгезе буенда көн күрүче *ак һуннар* дип аталган *савирлар (суварлар)* һәм *барсиллар (берсула)* алыштыра.

Итил белән Җаек (Урал) арасында яшәп ятучы огрлар яки угырлар алга таба хәзерге венгрларның борынгы бабалары була.

(Шул ук вакытта бернәрсәне билгеләп үтәргә кирәк: кайбер борынгы чыганаклардан күренгәнчә, элек санап кителгән кабиләләр һәм этнонимнары исемнәре аларның үзара якынлыгын раслаучы параллельләр уздыру мөмкинлеген генә түгел, *уй-гр, у-гр, вен-гр, ара-гр, ону-гр, бол-гр, куту-гр, уту-гр* яки *һун-гр* һ.б., ә бәлки бу этносларның барысы да асылда бер үк төрки нигездән булуын билгеләү мөмкинлеген дә бирә.)

V йөз ахырыннан VI йөз уртасына кадәр болгарлар, актив хәрби сәясәт алып барып, Көнбатышка кузгала һәм готлар белән сугыша. Аларны Италиядән кысрыклап чыгара, Византиягә бәреп керә, Фракия, Иллирия һәм Греция җирләрен басып ала.

Шул ук елларда Заберган җитәкчелегендәге кутугырлар *аварлар* белән берләшә. Бу хәл исә аларны Сандилх җитәкләгән утугырлар белән үзара каршылыкларга, низагларга китерә.

Нәтиҗәдә кутугырлар элекке бергәлектән аварлар бәйлелегенә килеп эләгә.

Болгар халкының формалашуында мөһим урын алган угыр-һун-гун һәм һуннардан соңгы чордан чираттагысына күчкәнче, бернәрсәгә игътибар итик: 552 елда үзләренең борынгы бабалары – элгәрләре дип легендар һуннарны санаган Алтай төркиләре Ашина нәселеннән булган Бумын хан җитәкчелегендә беренче мәртәбә Бөек төрки каганат төзи (552–630). Тиз арада аның чикләре Азов буйларына кадәр җитә, ә төркиләр үзләре шул еллардагы байтак евразия кабиләләре һәм халыклары этногенезында зур роль уйный.

Ә хәзер – «Дөнья тарихы атласы»ннан («Atlas Zur Welt Geschichte») берничә сүз. Мин аның белән Алманиядә таныштым.

Аның беренче өлешендә, 113 нче биттә түбәндәгеләр язылган:

*«Һун кабиләләре көньяк (Кара диңгез) далаларга кадәр җәелгән. Бирелә беренче Болгар империясенә нигез салынган. Үсешенең иң югары, чәчәк аткан ноктасы Кубрат хан хакимлек иткән чорга туры килә (679 елда вафат була).*

*Хәзәрләр яулап алганнан соң, Болгар иле ике өлешкә бүленә.*

*Бер өлеше Дунайга китә. Анда Дунай Болгар ханлыгы (үзәге Плиска шәһәре) төзелә, ә икенче өлеше – Иделгә (Итил) юл ала һәм анда Идел Болгар ханлыгы төзелә (үзәге – шәһре Болгар).*

*XIII йөздә Болгар ханлыгы монголлар тарафыннан җимерелә, ә калганнары (Хәзәр диңгезенең Итил яры буйларында) хәзәрләргә буйсына.*

Шулай итеп, 558 елда төркиләр Көнбатыш Себердә угыр кабиләләре бердәмлеген (союзын), Урал буенда угыз-кыпчак һәм буртасларның борынгы бабаларының (протобуртасларның) күчмә кабиләләрен буйсындыра һәм Түбән Итил буйларына килеп чыга. Анда Урта Азия кабиләләренә һәм Ирандагы Сасанидлар династиясе империясенә көчле һөҗүм ясый.

Шул ук елда Түбән Идел буйларыннан Көнчыгыш Европага сугышчан *аварлар* кузгалып китә. Соңрак Дунайдагы Византия җирләрендә урнашып калалар.

Төрки каганат 567–571 еллар арасында, хәзәрләр җирен, болгарларның барсил, савир, утугыр һәм алар янәшәсендәге алан җирләрен яулап алып, бөтен Төньяк Кавказга ия була.

Шул вакыттан алып 80 ел дәвамында хәзәрләр дә, болгарлар да, аланнар да, тел һәм рухи аралашуда алар тәэсирен тоеп, төркиләр хакимлегендә яши.

Әмма VII йөз башында Төрки каганат үзе Көнчыгыш һәм Көнбатыш каганатларга бүленә.

Кабат Л.Н.Гумилевка әйләнеп кайтыйк.

*«VII йөз башында Кавказ буйларын ике халык: Кубаньның уңъяк ярында (Донга кадәр аралыкта) яшәүче болгарлар (утугыр, унногундур, оногурларны һ.б. кабиләләрне дә кертеп) һәм Терек белән Итилнең түбән агымы җирләрендә тормыш итүче хәзәрләр били».*

Алар Көнбатыш Төрки каганат составына керә. Ул елларда бу каганат биләмәләре Көньяк-Көнчыгыш Европа далаларын да үз эченә ала.

Каганатның иң көчле өлеше 580 еллардан башлап һәрдаим үзара низаглар чыгып торган Хәзәр диңгезенең (Каспий) төньягыннан Кубаньга һәм Төньяк Кавказ тауларына кадәр җәелгән болгар кабиләләре җирләре була.

Шул заманда яшәгән гарәпләр бу җирләрне «савир иле» дип, ул чактагы әрмән чыганаклары исә «Төньяк Кавказ һуннары патшалыгы» дип атый.

Бу җирләрнең сәяси үзәге борынгы хәзәр шәһәрендә – «гаҗәеп шәһәр Варачан» дип танылган Беләнҗар шәһәрендә урнаша.

*«Каганатның дулу (ягъни төркиләр – дулу) юнәлешендәге көнбатыш чигендә болгарлар – унногундурлар уранашкан. Аларның кабилә башлыгы Кубрат (әнисе ягыннан дулуларга кардәш), 610*

*елда Константинопольгә барып, анда Патрикий саны ала, әмма чукынудан баш тарта. Дулу партиясенә болгарларны хәзәрләр белән көндәшлек этәрә».*

Озак та үтми, Төрки каганатның үз эчендә аларның Иран белән сугышта җиңелүе сәбәпле килеп чыккан чираттагы бәрелешләр булып ала. Шуның нәтиҗәсендә төрки дәүләт тулысынча таркала.

*«Ызгыш-талашлардан бары тик болгарларның кабилә башлыгы Кубрат кына ота. Иң элек ул, үзенең туганы Себер ханы ягында торып, төркетләр һәм хәзәрләрдән арына».*

Нәтиҗәдә 632 елда башында Кубрат хан торган Бөек Болгар дәүләте төзелә. Ул Азов буе далаларын, Тамань ярымутравын били, ә башкаласы Фанагория шәһәре була.

*«635 еллар тирәсендә Кубрат хан аварларны җиңә һәм шул ук вакытта Константинопольдә илчелек булдыра. Ираклий, моңа җавап итеп, зур бүләкләр җибәрә. Кутугырларның аварларга каршы баш күтәрүе Кубратка Кара диңгез буе далаларына ия булу мөмкинлеген бирә. Феофан елъязмаларында инде ул «Болгария һәм котраглар», ягъни кутугырлар башлыгы буларак телгә алына. Шулай итеп ул болгарларның бөтен кабиләләрен берләштерә».*

Бөек Болгар иле көнчыгышта – төркетләр белән бәйләнешен югалтмаска тырышкан хәзәрләр белән, көнбатышта – аварлар, Көньякта Византия белән дошманлашып яши.

Бөек Болгар иле Кубрат хан вакытында Төрки каганатка буйсынудан туктый, әмма 642 елда бу җирләр аның өч улына (кайбер чыганаклар буенча биш улына. Кара: М.Зәкиев. «Төрки-татар этногенезы») – Батбай, Аспарух һәм Котраг исемле улларына бүленә.

Мондый бүленеш Бөек Болгар илен нык какшата, көчсезләндерә. Хәзәрләр бу хәлләрдән файдаланып калырга ашыга. Аспарух җитәкчелегендәге болгар-унногундурлар үзләренең бәйсезлеге өчен көрәшкә күтәрелгәч, Батбай туганы аңа ярдәмгә килми.

Нәтиҗәдә Византия белән сугышны откан, Евразиядә өстенлек иткән Бөек Болгар дәүләте 651 елда Хәзәр каганаты басымына чыдамыйча җимерелә.

Шуннан соң инде Аспарух хан болгарлары Дунайга һәм Паннониягә китә. Анда, актив хәрби сәясәтне дәвам итеп, җиде славян кабиләсен берләштерә, Византия җирләрен, славяннарның Добрудже шәһәрен яулап ала һәм 681 елда Болгар патшалыгын игълан итә. Бу патшалык XI гасырга кадәр яши. Шуннан соң аны шул ук Византия үзенә буйсындыра. Соңрак әлеге болгарлар, славян кабиләләре белән кушылып бетеп, хәзерге *Дунай болгарларының* борынгы бабалары булып калалар.

Батбай хан җитәкчелегендәге болгарлар Хәзәр каганатына буйсына. Әмма болгар-барсиллар, болгар-савирлар яки суварлар, Хәзәр иле халкының күп өлешен тәшкил иткәнгә, үзенең зыялы һәм белемле булуы белән әлеге төрки телле дәүләтнең тормышында әһәмиятле роль уйнавын дәвам итә.

Болгарларның ул чакта Кубань территориясеннән киткән өченче өлеше исә Кавказда утырып кала. Алар – бүгенге *балкарлар, кумыклар* һәм *карачайлар.*

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: барлык бу вакыйгалар тәэсирендә VI йөздә үк башланган күченеш (миграция), ягъни көньяк далалардан үзенең борынгы җиренә – Урта Итил буе, Чулман һәм Олы Чирмешән елгалары, шулай ук Сура-Ука елгалары арасындагы җирләргә борынгы болгарларның (аларның элгәрләренең) аерым төркемнәренең үз җирләренә әйләнеп кайтуы активлаша. Соңрак бу җирдә хәзерге Казан татарларының барлыкка килүендә төп рольне уйнаган *Чулман-Итил-Болгар* халкы формалаша башлый.

Дунай буе болгарларының, балкар, карачай һәм кумыкларның тормышындагы тарихи вакыйгаларның алга таба барышын һәм үсешен калдырып торып, без киләчәктә Чулман белән Итил буйларындагы болгар-татар этносы нигезенә ятачак болгар кабиләләре турында гына бәян итүгә күчәбез.

Шулай итеп, VII йөз ахырында Хәзәр каганатында ике дәүләт бердәмлеге, саф хәзәр һәм болгарларның элгәрләре кабиләләре – сувар, барсил һәм бәләнҗәрләр бердәмлеге федерацияләре барлыкка килә.

Ә көмеш болгарлар исә (Болгар илендә көмеш әйберләр ясау нык үскән була. Бу һөнәр ияләрен көмеш болгарлар яки нухратлар дип йөрткәннәр (нухрат – гарәпчә эшкәртелгән көмеш) бу вакытта Урта Итилнең көньяк районнарын интенсив үзләштерә башлый.

Кайбер чыганаклар буенча, якынча шул ук елларда хәзерге Башкортостан территориясендә мадьярларның (маҗарларның) элгәрләре күчмә кабиләләреннән Бөек (Олы) Венгрия төзелә. Киләчәктә башҗырд (башгурд) этносының һәм *татар-мишәрләрнең* бер компоненты булачак күчмә *маҗар* кабиләсе алар белән бер союзда (бергәлектә) була, диелә.

Бу уңайдан профессор М.З.Зәкиев тикшеренүләренә дә тукталып, аның чыганаклар белән дәлилләнгән кайбер фикерләрен җиткерәсебез килә.

*«...Электән мишәрләр яшәгән җирләрне – Урта Иделдәге Ука-Сура буйларын, Ука-Дон тигезлеген яисә элекке Иске һәм Яңа Маджар шәһәрләре урнашкан җирләрне (Хәзерге Ставрополь өлкәсе) Олы Венгрия дип игълан итәләр. Гарәп-фарсы чыганакларындагы төркичә сөйләшә торган мәҗгарларны бары венгрга гына каратып, хәтта махсус хезмәтләр дә язылa...*

*Мишәр электән мадьяр-венгр булган, Идел буйларында Олы Венгр иле җәелгән дигән фикергә, тикшереп тормыйча гына, тулысынча ышану күп галимнәргә күчкән...*

*...Ә нинди реаль дәлилләр мишәрләрнең электән венгр булмыйча, баштан ук төрки икәнлекләрен раслый соң?*

*Беренчедән, әгәр дә Ука-Сура буйларындагы, Ука-Дон тигезлекләрендәге һәм Төньяк Кавказдагы мишәрләр (гарәп-фарсы чыганакларында – мәҗгарлар) венгр (мадьяр) булсалар, аларны кайсы да булса бер чыганак венгрча (мадьярча) сөйләшкән дияр иде. Ләкин гарәп-фарсы чыганаклары барысы да бертавыштан мәҗгарны төркичә сөйләшә дип басым ясап әйтә...*

*Икенчедән, мәҗгар венгр-мадьяр булса, аның этнонимы да гарәпчә маҗар дип язылыр иде. Мәҗгар исә мишәрдә очрый торган мижгар вариантына охшаган.*

*Өченчедән, әгәр дә мишәр элек венгр-мадьяр булып, соңрак төрки телле мишәргә әйләнгән булса, мишәр телендә һичшиксез венгр сүзләре сакланган булыр иде, ләкин алар юк. Димәк, мишәр баштан ук төрки булган, венгрдан ясалмаган.*

*Дүртенчедән, әгәр дә мәҗгар венгр булып, Төньяк Кавказдан алып Иделгә кадәрге җирләрдә Олы Венгрия урнашкан булса, бу тирәләрдә бик күп венгр топонимнары калган булырга тиеш иде... Алары да юк.*

*Шулай итеп, гарәп-фарсы чыганакларында мәҗгар дип бирелгән төрки телдә сөйләшүче кабиләләр мадьяр-венгрларга карамый, ә хәзерге мишәрләргә... карый. «...Венгр-башкорт» концепциясе» дә «венгр-мишәр» концепциясе» кебек үк уйдырма».*

Димәк, бернинди Бөек (Олы) Венгрия булмаган, ә нигездә мәҗгар-мишәрдән торган Мәҗгар дәүләте оешкан.

*«...Мәҗгар (мишәр) дәүләте XII йөзләр тирәсендә Болгар дәүләтенә буйсындырылган булса кирәк, XIII йөз чыганакларында мәҗгар-мишәр дәүләте аерым искә алынмый. Диалекталь үзенчәлекләре буенча болгар кабиләләре дә мишәрләрнең бер тармагын тәшкил иткән булса кирәк, чөнки Болгар дәүләте үзәге булган җирләрдә мишәр сөйләше сакланган...»*

Шул чакта ук, VII йөзнең беренче яртысыннан башлап, дөньякүләм вакыйгаларның төп үзәге Гарәбстан ярымутравына күчә. Анда яңа этник оешма – *гарәпләрнең* туплан191 һәм Мөхәммәт пәйгамбәр тәгълиматын бер дингә – *исламга* әйләндерү вакыйгалары башлана.

Гарәбстан кабиләләре хакимнәре ислам байрагы астында Византия империясен, Якын һәм Урта Көнчыгыш, Төньяк Африка, Көньяк-Көнбатыш Европа һәм Кавказ арты илләрен җимерә, ә аннан соң Кавказның үзен дә буйсындыра.

724 елда гарәпләрнең атлы гаскәре Кавказ алды аланнары һәм болгарлары җирләренә килеп җитә һәм аларны эзлекле рәвештә бөлгенлеккә төшерә. 727 елда Хәзәр (Каспий) диңгезе буйлары һәм Кубань елгасы буендагы болгар җирләрен туздыра.

Гасыр башында кабынып-кабынып торган әллә ни зур булмаган бәрелешләрдән башланып киткән гарәп-хәзәр сугышлары 721 елдан инде даимигә әйләнә, ә 730 елдан исә бер-берләрен юк итү максатында алып барыла башлый. Болгар-котраг һәм болгар-барсиллар җирләренә инде кабат үз хәленә кайтара алмаслык зыян салына, зарар китерелә.

Нәтиҗәдә VIII йөзнең беренче яртысында болгарларның элгәрләре кабиләләре Азов буеннан Көнчыгышка – Сок, Агыйдел, Ык, Дим елгаларының үрге агымы буйларына гарәпләр коллыгыннан качып китә.

Анда болгарлар угыр-мадьярларның вакытлыча тукталып яшәү урыннарына килеп чыгалар һәм шунда күчмә халыкларның болгар-мадьяр төркемнәренең формалашуы башлана.

Гарәпләрдән, бәрелешләрдән гарык булган башка төркемнәр дә төньяк-көнчыгышка таба күчеп китә.

Болгар-савирлар (суварлар) аланнарның бер өлеше белән Итилнең уңъяк яры буйлап – төньякка, ә болгар-барсиллар (бәләнҗәрләр) үзәктән читтә яшәүче хәзәрләр белән Итилнең сульяк яры буйлап китеп, мадьярларның (маҗарларның) элгәрләре белән берләшә.

Шулай итеп, берничә гасырдан соң Халыкларның бөек күчешенең һуннар чорына кадәр Көньяк Урал буйларында күрше булып яшәгән бу ике этнос юлы борынгы җирләрендә яңадан кушыла *(Г.С.Сабирҗанов)*.

VIII йөз ахыры – IX йөз башларында болгар кабиләләре бергәлеге (союзы) төзелә башлый. Монда киләчәктә булачак Идел Болгарының үзәк районнарын биләгән болгар-берсыллар (барсиллар) төп рольне уйный.

Бу бергәлеккә шулай ук суварлар, бәләнҗәрләр, эсегеллар (төркичәдән – иске ил, борынгы кавем), җирле төп халык – Имәнкискә культурасы дип аталган урын вәкилләре һәм фин-угыр кабиләләре – хәзерге *мари, мордва* һәм *удмуртларның* (ар, мукшы, чирмешләрнең) борынгы бабалары да керә.

Итил-Чулман кабиләләре бердәмлеге (консолидациясе) тыныч кына һәм бик тиз оеша.

Шул ук вакытта Итил аръягы далаларында төрле телдә сөйләшүче күчмә кабиләләр тупланмасыннан башында яңа этник бергәлек – Көньяк Урал буеннан күчеп киткән (кайчандыр Кара

диңгез буйлары аша Днепр белән Днестр елгалары аралыгына үткән) борынгы мадьяр (венгр) кабиләләре *бәҗәнәкләр* (*печенеглар*) торган куәтле берләшмә барлыкка килә.

Бәҗәнәкләр, төрки телле тамьян кабиләсе белән берләшеп (бу кабилә киләчәктә башҗырд (башгурд) этносының бер компоненты була), узган юлында көчле янгын һәм җимерекләр, хәрабәләр генә калдырып, Хәзәр каганатына юнәлә.

Бу вакытта Хәзәр каганатына ясак түләп торган болгар кабиләләре бергәлеге Итил буйлап Хәзәр (Каспий) диңгезе аша гарәп Көнчыгышы илләренә бара торган сәүдә юлларын киң файдалана, ә славян җирләре аша – Балтыйк буена, Чулман аша борынгы удмуртлар һәм коми-пермяклар иленә сәүдә юлы сала.

VIII йөз ахырыннан X йөз башларына кадәр Итил-Чулман халкының социаль-мәдәни үсешенең мөһим нәтиҗәсе булып Итил Болгариясенең яшь феодаль дәүләтен – Евразиянең урта гасыр тарихында якты эз калдырган Урта Итил буенда дәүләтчелеге булган һәм беренче бердәмлек төзү тора.

Болгарларның борынгы тарихына багышланган бүлекне йомгаклап, шуны да өстәп әйтергә кирәк: болгарлар – борынгы, архаик төрки телләрнең берсендә сөйләшкән халык. Идел буе болгарларының һәм славянлашуга кадәр Дунай болгарларының сакланып калган язма истәлекләре, ядкәрләре шуны раслый.

Борынгы болгар сөйләме күпмедер дәрәҗәдә Идел буенда яшәүче хәзерге татарларда да, чуашларда һәм төрки телдә сөйләшүче кайбер башка халыкларда да сакланган. Шунысы кызык: Балкан болгарлары, христиан динен кабул итеп, бөтен төрки сыйфатларын югалтканнар, ләкин үз иленең борынгы исемен саклап калганнар, Идел буе болгарлары исә, ислам динен кабул итеп, барлык гореф-гадәтләрен һәм йолаларын саклап кала алса да, үзенең төп исемен мәңгегә югалткан.

### 2. ИДЕЛ БОЛГАРИЯСЕ

...Болгар ханлыгының көнбатыш чиге булып Сура һәм Ука (Ока) елгалары, көнчыгышта Җаек елгасы торган, төньяк чиге – уң як кушылдыклары белән Чулман елгасының урта агымына кадәр җиткән, ә көньяктан хәзәрләр белән чикләнгән, ягъни Самара Борылышына кадәр булган.

Бай урманнар, игенчелек өчен уңдырышлы туфрак, аралашу юллары булып хезмәт иткән зур һәм тирән елгалар, бакыр рудасы, төзелеш ташлары, кыйммәтле җәнлек тиреләре һәм балык – боларның барысы да дәүләтнең зур тизлек белән икътисади үсешенә ярдәм иткән.

Болгарларда төп дәүләт дине буларак ислам диненең һәм руник язмага алмашка килгән гарәп графикасының раслану тарихы 922 елның маена барып тоташа, ягъни шушы вакыйгалардан соң инде мең елдан артык вакыт (!) үтеп киткән.

Бик еракта калган нәкъ менә шул елда шәһре Болгарга, ягъни Итил елгасы буендагы Бөек Болгарга, болгар патшасы илтабар Шилки угылы Алмышның (Алмасның) чакыруы буенча Багдад хәлифе Әл-Мокътәдирнең үзеннән дипломат һәм тарихчы Әхмәт ибне Фазлан ибне Әл-Аббас ибне Рәшид ибне Хәммәд җитәкчелегендә илчелек килеп төшә. Ибне Фазланның хәлифәткә бу илнең генә түгел, бәҗәнәкләр, төрки угызлар, хәзәр, рус, башҗырдларның (башкорт) да көнкүрешләре, культурасы, теле, сәүдә итүе, һөнәрчелеге, хәрби эше, дәүләт төзелеше турында язган һәм хәзергәчә сакланып калган хисабы бүгенге көндә күп нәрсәләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Билгеле инде, без ул чордагы Итил буе Болгар дәүләтенә чынбарлыктан торып бәя бирергә тырышырбыз. Шул күзлектән карап, үзенең куәтенә күрә гадәти бер Болгар иле белән һич чагыштырып булмаслык Гарәп хәлифәтенең әлеге илчелеге торган бу чорда феодаль дәүләткә кадәрге типтагы сыйнфый җәмгыятьнең булуын һәм анда төп җитештерүчеләр булып җәмгыятьнең ирекле әгъзалары торуын белербез *(А.П.Кавалевский)*.

Болгарлар Хәлифәттән үз илләренә ислам диненә өндәүчеләрне, мәчет һәм кальга төзелешендә ярдәм итәрлек кешеләр җибәрүне сорыйлар.

922 елның уртасында Җаушир(мә) елгасы ярларында (Хәзерге Чистай районының Яуширмә авылы янәшәсендә. Бүгенге көндә дә бу җирдә «Ханнар буасы» дип аталган урын бар. – *Ф.Т.*) җирле аксөякләрнең – болгар кабиләләре башлыкларының Алмыш хан җитәкчелегендәге корылтае була. Анда ислам дине Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми дәүләт дине дип янә бер кат игълан ителә.

Чынлап та, ул замандагы Көнчыгыш Европа тарихында нәкъ менә Идел Болгарының исламны кабул итүе иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе булып тора.

Бер үк вакытта түбәндәгеләргә дә игътибар итәргә кирәк: вакланып, бүлгәләнеп беткән Рус кенәзлекләре ул көннәрдә әле мәҗүси була, грек православиесе рәвешендәге христиан динен Киев Русе «дин сайлау» дип аталган чордан соң, 988–989 елларда гына, ягъни болгарлар ислам динен кабул иткәннән соң алтмыш ел вакыт узгач кына рәсми рәвештә кабул итә.

Тагын шуны да әйтү зарур: түбән Итил буендагы бөтен сугышчан күршеләрнең – башкаласы Итил шәһәре булган хәзәрләрнең хакимлек итүче өстен катлавы – яһүдиләр, ә гади халык мөселман була.

X йөздә Итил шәһәре, бөтен Хәзәр иле кебек үк, сәяси сәбәпләр һәм социаль закончалыклар аркасында гына түгел, ә бәлки, табигый бәла-каза – трансагрессия, ягъни диңгез өсте биеклегенең күтәрелүе сәбәпле җимерелә. Шәһәр Хәзәр диңгезе төбенә китә.

Бераз соңрак Итил елгасы буенча өстәрәк төрки исем – Хаҗи Тархан (Хаҗитархан) исеме белән яңа шәһәр барлыкка килә. Бу шәһәр Әҗдәрхан ханлыгының башкаласы була һәм, аны Русь дәүләте басып алгач, Әстерхан шәһәренә әйләнә.

Заманында дөньяны кеше сүзеннән генә түгел, үзе күреп белгән һәм Болгарны сәкалибә болгарларның төньяк дәүләте дип атаган Ибне Фазлан үзенең «Хәлиф әл-Мокътәдирнең Сәкалибә патшасына илчесе Әхмәт ибне Фазлан китабы»нда менә нәрсәләр язып калдырган:

*«Алар башлыча тары белән ат ите ашыйлар. Шулай булса да, аларда бодай белән арпа да күп. Һәркем үзе өчен чәчә һәм уңышыннан үзе файдалана.*

*Патшаның (аны элтабар (илтабар) дип атыйлар) халыкның иген уңышын тартып алырга бернинди хокукы юк. Алар патшага һәр елны йорт башыннан берәр кеш тиресе түли.*

*Барысының да башында бүрек. Аларның патшасы атта бернинди сакчысыз, озатып йөрүчесез, япа-ялгыз йөри. Ул базардан үткәндә, бар да аягүрә баса, бүреген салып, култыгына кыстыра.*

*Болгарларның барысы да тирмәдә яши. Патша тирмәсе бик зур, меңнән артык кешене сыйдыра һәм бар җиргә дә әрмән келәмнәре җәелгән. Аның уртасында – Византия парчасы ябылган тәхет. Элтабар белән янәшә патшабикә утыра. Ире янәшәсендә утыру – аларның гадәте.*

*Элтабар өстәленә бары тик кыздырылган ит кенә куела. Ул, пычакны алып, иттән бер кисәк кисеп ала да ашап куя. Моны өч мәртәбә кабатлаганнан соң, пашта иттән янә бер кисәк кисеп алып, аерым өстәл янында утырган хәлиф илчесенә бирә.*

*Шулай итеп, патша, иң хөрмәтле кунаклардан башлап, тирмәдә булган һәр кешегә үзе кисеп ит биреп чыга – аларда шундый тәртип икән: ризыкка беркем дә алдан кулын сузмый, үзенә биргәнне көтеп утыра.*

*Болгарларда тагын бер гадәт бар: яңа туган ир баланы бу малай ир-егет булганчы тәрбияләүдә әтисенә караганда күбрәк хокукы булган бабасы үзенә ала.*

*Бу җирдә күргән бихисап сәерлекләрнең берсе – еланнарның мыжлап торуы. Шулай күп булсалар да, аларга беркем тими, еланнар да аларга зыян салмый. Аларда әле яшел һәм әче алмалар да күп.*

*Иң гаҗәбе – чикләвек урманнарының күп булуы.*

*Урманнарында бал кортлары да бихисап. Алар бу эштә дә белекле – шактый күп бал җыеп алалар. Балдан ясалган эчемлекне* ***сөҗү*** *яки* ***набиз*** *диләр.*

*Бу илдә, бер җирдә дә булмаганча, яшен күп.*

*Болгарларда сәүдәгәрләр дә күп. Төркиләр җиренә барып, аннан сарыклар алып кайталар.*

*Алар шулай ук Вису иленә дә йөриләр, ул җирләрдән бик күп кеш һәм кара төлке кайтаралар».*

Нәкъ менә шул вакытларда Сувар шәһәре X йөзнең соңгы чирегенә кадәр шәһре Болгардан сәяси өстенлеккә (гегемониягә) хокук даулый. 976 елга кадәр Суварда үз акчасы сугыла, әмма ләкин X йөзнең беренче яртысында ук инде Болгарда «баш мәчет» эшләп тора. Шуңа күрә Сувар 976 елдан соң бу шәһәрнең Болгар иленең уртак сәяси үзәге булуын таныдырга мәҗбүр була *(Г.Сабирҗанов)*.

Шулай итеп, X йөздән Идел буе болгарлары үзләренең көмеш акчасын гарәп язуы төшереп суга башлыйлар: бу исә эчке һәм тышкы сәүдәнең, икътисадның үсеш дәрәҗәсен билгели торган ачык күрсәткеч. Икътисадта төп урынны игенчелек, тире эшкәртү – күн сәнәгате (мәсәлән, зур осталык белән эшкәртелеп ясалган йомшак күн – «болгар юфте» – дөнья тарихына кереп калды һәм бүгенге көндә дә Үзәк Азиядә һәм Иранда яхшы сыйфатлы күн һәм күн аяк киеме Болгарныкы дип атала), тире иләү сәнәгате, зәркәнчылык (алтын, көмеш әйберләр эшләү) һәм корал ясау, кара металлургия (Казан татарларының элгәрләре Европада беренчеләрдән булып югары сыйфатлы чуен койганнар), чүлмәк ясау һәм кирпеч сугу, умартачылык, сәүдә һәм терлекчелек били. Болгар төзүчеләре әле шул вакытта ук сигез манаралы мәһабәт мәчетләре, мәктәпләре, сарайлар, кәрван-сарайлары, үзәктән җылыту һәм вертикаль система белән мунчалары, таш һәм агач торак йортлары, суүткәргеч ясалма каналлары белән дан тота *(Г.Исхакый һәм В.Имамов)*.

Гарәп язучысы ибне Руста язып калдырганча, аларның авылларында һәм Сувар, Биләр һәм Болгар шәһәрләрендә (соңгысы инде ул чакта ук эре сәүдә үзәгенә әйләнә) мәчетләр һәм мәктәпләр була. Алар башында имам һәм мөәдзиннәр (мәзиннәр) тора.

Әгәр беренче чорларда шәһре Болгар Куябтан (Киевтан) шактый кечкенә булган булса, тиздән әһәмияте белән хәтта икенче урында торган Биләр шәһәре кайбер мәгълүматлар буенча 530 гектар җир били. Шул ук вакытта Киев – 150 гектар, Владимир – 160, ә Париж 439 гектар территориягә ия була...

Болгарларны мөселман дөньясына кертү бу халыкның рухи культурасы үсешенә көчле этәргеч бирә.

Бераз соңрак гарәп язуы яңа белемнәр: мөселман юриспруденциясен, яңа фәннәр алып килә. Үзләренең китаплары, шагыйрьләре, галимнәре, тарихчылары, астрономнары һ.б. өлгереп җитә.

Әдәбият дөньясында Кол Галинең «Кысса-и-Йосыф» әсәре 1212 елда язылган, болгар язма әдәбиятының зур әһәмияткә ия булган хезмәте (автор үзе 1236 елда монгол басып алулары вакытында

һәлак була), Сөләйман бине Давыд Суваринең (кайбер чыганаклар буенча – әс-Сәкъсини) (Сувар шәһәре) XII–XIII йөзләрдә язылган «Зөһрәтеррийаз...» китабы, Котбиның бераз соңрак, Алтын Урда чорында язылган «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы (1340), Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се (1354), Хисам Кәтибнең «Җөмҗөмә солтан»ы (1369), Сәиф-әс-Сараиның «Гөлстан»ы (1391) һәм «Идел буе төркиләре» теле дип аталган телдә, ягъни урта гасыр татар әдәби телендә язылган башка әсәрләр киң танылу таба.

Болгарларның ул вакытта ук тарихи язмалары була. Ягъкуб бине Ногман Әл Болгари тарафыннан XII йөзнең беренче яртысында язылган кульязма «Болгар тарихы» дип атала.

Хуҗа Әхмәт Болгари «Әль-Җәмигъ», «Әт-тарика» һәм «Әл-фәваид» дигән хезмәтләр калдыра.

Урта гасырның байтак тарихчылары IX йөздән башлап әле XII йөздә дә чәчәк атып утырган Идел буе Болгар дәүләтен яхшы белгән.

Мәсәлән, танылган инглиз тарихчысы һәм фәлсәфәче Роджер Бэкон үзенең «Opus Magnum» дигән китабында (XIII йөзнең икенче яртысы) болай дип яза:

*«Элек Этилия артында команнар Төньякта Бөек Булгария белән чиктәш була. Константинополь, Венгрия һәм Славания арасында яшәүче болгарлар шуннан килгән дә инде. Европада болгарлар күп түгел, алар анда Азиядә урнашкан Бөек Булгариядә яшәүче болгарлар телендә сөйләшә...»*

Урта гасырның башлангыч чорындагы тарихи процесслар барышында Казан ханлыгына әйләнгән һәм бүгенге көндә хәзерге Татарстан дәүләте булган Бөек Болгария, нык үскән дәүләт буларак, барлык илләр белән сәүдә итә: болгар күненнән ясалган әйберләр һәм мехлар Литва, Польша, Италия, Фландрияне дә кертеп, Көнбатышның бөтен илләренә дә барып җитә.

С.М.Соловьев дигән рус тарихчысы, Идел буе Болгариясе «сәнәгатьчеләре һәм кәсепчеләре»нең мәгърифәтле цивилизациясен тасвирлап, болай ди: «Бик күптәннән булып узган елларда, рус славяннары әле Ука елгасы буенда христиан чиркәүләре сала башламаган һәм Европа пространствосы дип аталган территорияләрне белмәгән заманда, болгарлар инде Итил һәм Чулман ярлары буенда Коръән сүрәләрен тыңлаган...»

### 3. РУСЛАР ТУРЫНДАГЫ МӘСЬӘЛӘГӘ ЯКЫН КИЛЕП

Иң элек, Идел буе Болгар дәүләтенең руслар һәм көнчыгыш славян кенәзлекләре белән үзара мөнәсәбәтләренә тукталганчы, хронологик тәртиптә кирегә кайтып, аларның борынгырак, әүвәлгерәк тарихына күз салыйк.

Көнчыгыш Европада Висладан алып Дунайга кадәр булган җирләргә таралып утырган һәм өч зур төркемгә – *славиннар, антлар* һәм *венедларга* бүленгән славян кабиләләренең элгәрләре турында беренче мәртәбә VI йөздә телгә алына.

Әлеге чорда Днепр яны җирләрендәге славяннар колонизациясенең антлар тармагы күчмә болгар-утугырлар белән күршеләр була. Бу хәл болгар һәм славяннарның үзара этномәдәни багланышларына китерә.

Һуннар яулап алулары чорында антлар гаять зур зыян күрә. Нәкъ шул елларда алар бергәлегенә славян телле *дулеблар* һәм *волыняннар* кушыла. Соңга таба антларның бу җирләре Куяб (Киев) каганатының үзәген төзи.

602 елда Паннониядән авар каганы ул вакытта Түбән Дунай белән Азов диңгезенең төньягы арасындагы җирләргә хуҗа булып алган антларга каршы хәрби отрядлар җибәрә. Нәтиҗәдә антлар таркатыла һәм шул сәбәпле алар Днепр буена күптән килеп урнашкан алман (герман) телле руслар белән кушыла.

VI–VII йөзләрдә көнчыгыш славян кабиләләрен көчләп күчереп утырту дәвам итә.

Бу елларда склавиннарның славян кабиләләре антлар җиренә килеп урнаша һәм алар белән кушылып бетә. Алар яшәгән территория төньякта – Балтыйк буена, ә көньякта Әдрән белән Балканга кадәр җитә.

Көньяк Балтыйк буеннан, Көнбатыш Двина һәм Висла районнарыннан көнчыгышка таба җәелә барып, славян кабиләләре Днепр тирәләренә һәм Ильмень күле бассейнына – герман телле русларның күпсанлы кабиләләре яшәгән җирләргә килеп чыгалар.

VIII йөздә гарәп чыганакларында беренче мәртәбә Куяб шәһәре, ягъни Киев шәһәре телгә алына.

Көнчыгыш Европаның гаять зур территориясе тулысынча күптөрле этник халык – *аланнар, болгарлар, хәзәрләр, угырлар* һәм *славяннар, полян, северян* һәм *вятич* кабиләләре, ә Итил-Чулман буе – *болгарлар, буртаслар, эрзя, чирмеш, ар, мукшы, чудь, мерей, весь, мурома, пермяклар* белән тула.

IX йөз башына славян кабиләләре Днепр буе территориясен биләп ала. Алардан көнчыгыштарак руслар килеп урнаша. Алар арасындагы мөнәсәбәт гаять киеренке була.

Шул ук вакытта антлар (поляннар) белән руслар локаль масштабта бер этноска кушылу процессын кичерә. 859 елда Борынгы Русь дәүләт буларак формалаша башлый.

Рус елъязмаларында күрсәтелгәнчә, варяг яки рус Рюрик, имештер, Ильмень славяннары тарафыннан кенәзлек итәргә чакырылган була. Ул – Ладогага, ә аның бертуган абыйлары Синеус һәм Трувар Белоозеро һәм Изборскка хуҗа булып алалар.

862 елда Рюрик яңа җирләрне буйсындыра һәм үз биләмәләренең башкаласы итеп Бөек Новгородны билгели. Славян кабиләләре – *словен* һәм *кривичлар*, шулай ук фин телле *чудь, вес* һәм *меря* җирләрен берләштереп, Рюрик Новгород Русена нигез салучы булып санала башлый.

864 елда Рюрик Аскольд белән Дирны Днепрның түбән агымы буйлап Грециягә җибәрә, юл уңаеннан алар Куябны (Киевны) яулап алалар һәм шуннан соң бу шәһәрне яңа башкала дип игълан итәләр. Әмма алга таба аларның Царьградны да (соңрак – Константинополь, ә хәзер – Истамбул) басып алу нияте барып чыкмый.

879 елда Рюрик вафат булганнан соң, аның Новгородтагы тәхетен скандинавлардан булган профессиональ сугышчы варяг Хельг (Олег) били.

882 елда каган (кенәз) Хельг (Олег) Киевка бәреп керә һәм анда кенәзлек итүче руслардан Аскольд белән Дирны үтерә. Хельг башкаланы Новгородтан Киевка күчерә һәм Киев Русенең яңа бөек кенәзе булып китә.

Идарә итү елларында, 882 дән 913 елга кадәр вакыт эчендә, ул *древляннарны, северяннарны, родимич* һәм *меряларны* буйсындыра, ә Киев «*рус шәһәрләре анасы*» дип атала башлый.

912–945 еллар – Рюрикның улы, Хельгның (Олег) варисы һәм Рюриковичларның кенәзләр династиясен башлап җибәрүче Ингварның (Игорь) кенәзлек итү еллары.

912 елдан Киев Русе чикләренә беренче мәртәбә бәҗәнәкләр (печенеглар) килеп чыга. Киев белән даими рәвештә сугыша-сугыша һәм аңа гаять көчле басым ясый-ясый, алар Төньяк Кара диңгез буйларында хакимлек итә. Бу хәл 1036 елга кадәр сузыла. Ниһаять, шул елда аларны Ярослав Мудрый тар-мар итә...

X йөз урталарында Киев кенәзлеге җитәкчелегендә борынгы рус халкын формалаштыру процессы зур көч белән башланып китә.

Бу чорда кабиләләрнең искечә бүленешләре бетерелә, таркала, кривичлар үзләренең бәйсез яңа дәүләтен – Кыпчак кенәзлеген төзи, ә Киев вятичларны буйсындыра. Аннан соң, 965 елда, бөек кенәз Святослав Игоревич, Идел буйлап төшеп, Хәзәр каганатына җимергеч һөҗүм ясый һәм Итил, Сәмәндар һәм Саркел шәһәрләрен туздыра... *(Г.Сабирҗанов)*.

Безнең алга таба бу чорның хронологик кысаларында М.Аджи хезмәтеннән өземтәләр китерәсебез килә. Аның тикшеренүләре кайберәүләр тарафыннан бөтенләй кабул итмәслек дип саналган, дөресрәге, бүгенге көндә Россия дип аталган дәүләтнең рәсми тарихына каршы килә торган юрамага (версиягә) нигезләнә (төпле чыганаклар булса да).

*«Иң әүвәл Бөек дала (Дәште Кыпчак – Дәшт-и-Кыпчак) барлыкка килә, славян иле һәм фин-угыр халыклары кенәзлекләре була. Бу җирләрдә яшәүчеләр чагыштырмача үзара килешеп яши.*

*Әмма IX йөздә аларга варяглар һөҗүм итә. Башта славяннарны буйсындыра, аннары кыпчакларны буйсындырмакчы була.*

*Алар басып алган дала (Төрки) каганат башкаласы Киев булган, «Украина» дип аталган. Каган Аскольд (биредә) соңгы төрки хаким була.*

*Варяглар Украинаны үзләренчә (русча) Киев Русе дип атыйлар. Алар яулап алган яңа биләмәләрнең барысы да гадәттә «Русь» дип йөртелә. Ак Русь һәм Кара Русь була.*

*Бу турыда Н.М.Карамзин ике төрле уйга урын калдырмаслык итеп болай ди: «X йөзнең икенче яртысына чаклы диярлек Россиядә ике телдә сөйләшкәннәр... Рус теле дип Скандинавия теле саналган. Дөрестән дә бу тел күпмедер вакыт кенәзләребез һәм чыгышлары белән норман булган зур түрәләрнең, вельможаларыбызның үзара аралашу чарасы булган, кулланылышта йөргән, әмма акрын-акрын алар, (Дунай) болгарлар славяннар арасында үз телләрен оныткан кебек, бу телдә сөйләшми башлаганнар».*

*Варяглар (яки руслар – барыбер) идарә иткәндә, алар буйсынуындагы халык «руслар» дип аталган. «Син кемнеке?» дип сорагач, славян «русский» яки «русич» дип җавап биргән – «Ирекле түгел», ягъни русларга буйсынулы, русныкы дигәнне аңлата.*

*Киев Русенең төркичә сөйләшүче халкы рухи яктан нык булган. Кыпчак-украиннар руслар хакимлеген кабул итмәгән, шуңа күрә аларга «русский» дигән исем ябышмаган.*

*Моңа бәйле рәвештә, Киевка нигез салуның 1500 еллыгына багышланган бәйрәм барышында булган түбәндәге фактны әйтеп китү зарур:*

*Радиодан Киев Русенең борынгы православие гыйбадәтләре, шулар арасында, рефрен булып, төрки телдә «Ходай алдында бетен адам ачык булсун» дигән сүзләр яңгырый.*

*Киев Русенда XVII йөздә чиркәүләрнең таркалуына, бер-береннән аерылуына кадәр, ягъни греклар Рус чиркәвенә көнбатыштан кергән яңалыкларны көчләп таккан, ә Россиядә христианлык исә үзенең борынгы дала йолаларын саклаган һәм үтәгән чорга кадәр, төрки телдә сөйләшкәннәр һәм гыйбадәт кылганнар.*

*Европа халкы буларак славяннар турында беренче мәртәбә Рим тарихчысы һәм язучысы Плиний Старшийның (24–79) танылган «Табигый тарих» дигән трактатында телгә алына.*

*Борынгы славяннарны ул венедлар дип атый. Итальяннар, немецлар, эстоннар һәм финнар әле хәзер дә аларны шул исем белән йөртә. Ә Россияне Европада еш кына Вения, ягъни венедлар иле дип әйтәләр.*

*Римның башка тарихчысы Тацит (58–117) Европаның төньягында, Висла белән Одер арасында яшәүче һәм күчмә терлекчелек белән шөгыльләнүче венедлар җирләре турында киң мәгълүмат бирә.*

*Ә менә тарихчы Иордан (VII йөз), венедларны искә алып, болай ди: алар үзләренең күпсанлы булуы белән дан тота, эстлар һәм Балтыйк буеның башка халыклары белән күршеләр булып яшиләр һәм үзләрен «словеннар» дип атыйлар.*

*Аларның элекке үз урыннарыннан Көнчыгышка күчеп китүенең сәбәбе – Халыкларның бөек күчеше, ягъни анда һуннар дип йөртелә торган төрки кыпчакларның Европага килүе.*

*Алар европалы җирле аборигеннарны кысрыклаганга, венедлар да, словеннар да Карпат, Альп, Балканга күчеп китәләр – бүгенге көндә бу җирләрдә Словения һәм Словакия. Аларның икенче өлеше хәзерге Германия, Италия, Польшаның кайбер өлкәләренә һәм Россиянең төньяк-көнбытыш төбәкләренә юнәлә һәм шул җирләрдә инде VI йөзгә тарихчы Иордан билгеләп үткән кабиләләр булып урнашалар.*

*Славяннар без күз алдында тоткан, без белгән славяннар түгел, бөтенләй икенче халык.*

*Менә урта гасыр елъязмачысы язмасыннан бер өзек: «Русларда сөрү җирләре юк, алар славяннар җиреннән китерелгәннәр белән генә туклана». «Руслар славяннарны яулап алырга бардылар» яки «Славяннар русларга ясак түли» кебегрәк фразалар инде гадәти була. Икенче төрле әйткәндә, руслар белән славяннар – икесе ике халык. Алар хәтта янәшә яшәгән халыклар да түгел.*

*Русларны халык буларак беренче мәртәбә 839 елда дөнья күргән «Бертин анналлары» («Бертинские анналы») хәбәр итә. Руслар беркайчан да «славяннар» дигән исемне әле шуның өчен дә кабул итмәсләр иде, чөнки колбиләүчелек һәм коллар белән сату итү чәчәк аткан чорда алар нәкъ менә шул славяннарны, мөһим һәм кыйммәтле товар буларак, коллыкка сату өчен Византиягә китерә торган булганнар.*

*Руслар – «варяглар», төгәлрәк әйтсәк, норманнар яки шведлар. Ул чорда финнар һәм эстоннар Швецияне «Роуссия» дип йөрткәннәр. Эстониядәге шведлар яшәгән урынны да Яңа Роуссия дип атыйлар...*

Шулай итеп, М.Аджи тарафыннан Россия хакимиятләренә «Ничек итеп *славяннарны русларга* әйләндерә алдыгыз?» дигән сорау куела, ә без бу сорауга шул ук хакимиятләргә «Идел буе болгарларын гади генә *татарлар* итәргә (хәтта *Казан татарлары* да түгел) ничек «башыгыз җитте»?» дип тә өстибез.

**4. БОЛГАРЛАР ҺӘМ КИЕВ РУСЕ**

Төрки телле Болгар иле үзенең аякка басу һәм үсеше башлангычында яңа барлыкка килә торган һәм үсеш алган рус һәм көнчыгыш славян дәүләтләре – X–XII йөзләрдә Киев Русе һәм XII–XIII йөзләрдә Владимир – Суздаль, Рязань һәм Новгород кенәзлекләре белән үзара тыгыз мөнәсәбәттә, бәйләнештә була.

985 ел – Идел Болгариясе тарихында сизелерлек эз калдырган этап: Киев Русеның бөек кенәзе Владимир Святославович (үз вакытында болгарлар Хәзәр иленә һөҗүм иткәндә Итил буйлап түбәнгә үткәреп җибәргән Святослав Игоревичның улы), төрки угызлар (гузлар) белән берләшеп, беренче тапкыр болгар җирләренә һөҗүм итә.

Сугышта алар җиңә, шулай булса да, үзара килешүгә ирешеп, кире кайтып китәләр. Рус елъязмалары вакыйгаларның болай борылышын түбәндәгечә аңлата: янәсе, бөек кенәз, әсир болгарларны карап йөргәндә, «барысының да күн итекләрдән булуын» күргәч, «*Болар безгә ясак түләмәячәкләр, чабаталыларны эзләп китик» («Сим дани нам не даяти, пойдем искать лапотников»)* дип, кире китәргә карар кыла.

Гамәлдә исә Идел Болгариясе белән Киев Русе арасында 985–986 елларда янәшә тыныч яшәү турындагы беренче шартнамә Владимирның болгар ханәкәсе (принцессасы) белән никахлашуы сәбәпле төзелә. Бу шартнамәдә Яклар тарафыннан расланган түбәндәге сүзләр дә була: *«Хәтта су төбеннән таш калкып, ышаныч суга батса да, без шартнамәне өзмәбез» («Даже если камень всплывет и надежда утонет в воде, мы не расторжем наш договор...»).*

Шул көннән башлап рус-төрки никахлары Русь белән Болгария мөнәсәбәтләрендә гадәти хәлгә әйләнә.

Киев Русенда «дин сайлау» дип аталган чор шулай ук игътибарны җәлеп итә.

986 елда болгар хакимнәре, Владимирны үз диненә аудару ниятеннән, Киевка мөселман диндарларын җибәрәләр. Бер елдан соң унлап ир-егет мөселман гореф-гадәтләрен һәм тәртипләрен өйрәнү өчен Болгар иленә килеп җитә.

Әмма Киев, болгарлардан тыш, Византия императоры да, Рим папасы да, яһүдиләр дә үз диннәрен һәм килешүле мөнәсәбәтләрен тәкъдим иткәнгә күрә, Византиягә өстенлек бирә. Һәм 988 елда Русьны чукындыру башлана.

Бу хәл, башкаларны да исәпкә алып, Киев Русе белән Идел Болгариясе арасында диннәр һәм рәсми идеологияләрнең каршылыкка керүен дә аңлата.

Инде 990 елларда ук Киев Русе үзе православие диненә өндәүче миссионер ролен уйный башлый. Шул ук Болгариягә фәлсәфәче Марк Македонянин җитәкчелегендә үз диндарларын, динчеләрен җибәрә.

Әлеге миссия уңышка ирешмәгәч, 994 елда бөек кенәз Владимир болгар җирләренә яңа походка чыга, бу эше дә уңышлы төгәлләнми.

Ике елдан соң, 996 елда Владимир кайчандыр Идел буена төрки угызлар (гузлар) белән этисе ясаган походын тулысынча кабатлый һәм хәзәр шәһәрләрен һәм авылларын туздыра, бөлдерә, ә халкына ясак сала. Итил шәһәре таш өеменә әйләнә, борынгы Бәләнҗәр һәм Сәмәндар шәһәрләренең гөрләп үсеп утырган бакчалары, йөзем агачлары бар җирне чорнап алган ут эчендә янып бетә.

Шулай итеп, Түбән Идел Киев Русе күзәтчелегенә күчә, югары өлеше элеккечә болгарлар кул астында кала, Көнчыгыш Европаның ул чордагы иң көчле ике дәүләте каршылыгы үскәннән-үсә бара.

XI йөз башы Урал тауларының көньяк районнарыннан Түбән Иделгә, аннан Идел аша Тынга (Донга) кыпчак кабиләләренең кубарылып күчүе белән билгеләнеп кала. 1055 елда кыпчаклар Киев Русе чикләренә килеп җитә.

Шул ук вакытта Идел белән Дон арасында, Белая Вежа шәһәре (элекке болгар-хәзәр шәһәре Саркел) тирәсендә кыпчаклардан котылып калган бәҗәнәк (печенег) урдасының бер өлеше күчмә тормышын алып бара.

Болгар сәүдәгәрләре 1006 елда Киевта Болгария сәүдәгәрләренә рус территориясендә *«...бөтен җирдә барысына да ирекле сәүдә итү, ә рус сәүдәгәрләренә... Болгарга бернинди шикләнүсез килеп сату итү мөмкинлеге бирү...»* турында шартнамә төзи.

Аннан соң корылык елларында Бөек Болгар иле русларга берничә мәртәбә ярдәм итә.

Мәсәлән, 1024 ел алдыннан рус елъязмачылары Русьта коточкыч ачлык булуын болай дип терки:

*«...бар халык Итил буйлап Болгарга барып, аннан бодай белән иген ашлыгы алып кайта һәм бары тик шул ашлык белән тукланып яши». (...Идоша по Волге все людие в Болгары и привезоша пшеницу и жито, тако от того жита кормяхуся.»).*

Шундый ук хәл 1229 ел алдыннан да, ягъни 200 ел үткәч кабатлана. Монголлар басып керүе алдыннан В.Н.Татищев теркәп куйган елъязмаларда яңадан шуңа охшаш язма бар: *«Бу вакытта бөтен Русьта ачлык ике ел дәвам итте һәм кешеләрнең күбесе үлеп бетте, бигрәк тә Новгородта һәм Белоозерода, әмма болгарлар, тынычлык китереп, Итил һәм Ука буйлап русларның бөтен шәһәрләренә иген ашлыгы ташыды, аларны сатып, зур ярдәм итте. Болгар кенәзе бөек кенәз Юрийга бүләк итеп 30 насад ашлык җибәрде» («В сие время глад был по всей Руси два года, и множество людей поумирало, а более в Новеграде и Белоозере, но болгары, учиня мир, возили жито по Волге и Оке во все грады русские, и продавали, тем великую помочь сделали. Князь же Болгарский прислал в дар великому князю Юрию 30 насадов с житами»).*

Әмма XI йөздә рус феодаллары Ука елгасының түбән агымында, мурома һәм мордва җирләрендә ныгып алганнан соң, беренче мәртәбә православие динендәге славяннар һәм мөселман болгарлар якын күршеләр булып кала. Аларның сәүдә мәнфәгатьләре кисешендә асылда ике цивилизация – Көнчыгыш һәм Көнбатыш цивилизациясе тоташа.

Шулай итеп, 1088 елдан алып монголларның болгар җирләрен яулап алуы башлануга кадәр Идел-Ука елгалары арасындагы гаҗәеп киң территория бер яктан – Идел Болгариясенең, икенче яктан Владимир Суздаль кенәзлегенең, Рязань белән Муромның каршылык күрсәтү мәйданына әйләнә.

Шулай да, бернигә дә карамастан, болгар белән русларның сәүдә элемтәләре һәм башка төр бәйләнышлары, әле үз вакытында ибне Фазлан күрсәткәнчә, тора-бара нигездә ныгый.

Мәсәлән, Болгариядән Киевка кадәр сузылган, көнбатыш белән көнчыгышны бәйләүче сәүдә кәрваны юлы монгол басып алуларына кадәр дә, Алтын Урда, Казан чорында да үз вазифасын үтәп торган. Әлеге болгар – бортас һәм Киев – рус юлының гомуми озынлыгы 15 мең чакрымны тәшкил иткән, ә юлының урта бер җире – Дон тирәсе (Подонье) – төркичә яки кыпчакча «Урта юл» дип аталган... *(А.Х.Халиков)*.

Л.Н.Гумилев та болгарлар белән руслар арасындагы уңай мөнәсәбәтләрне җөпләп болай ди: *«Славяннар христиан динен алып, Иделдәге төрки халыклар мөселман булып калсалар да, бу ике халык арасындагы мөнәсәбәтләр 250 елдан артык вакыт дәвамында, аларны Бату хан гаскәрләре тар-мар иткәнчегә кадәр, яхшы булып кала биргән».*

**5. БӨЕК БОЛГАР ИЛЕ МОНГОЛЛАРГА КАДӘРГЕ ЧОРДА**

XI йөзнең беренче унъеллыклары ахырына таба Алтай тауларыннан Дунайга кадәр (һәм Дунайны да кертеп) сузылган гаять зур территориядә тулы хокуклы хуҗалар булып төрки телле күпсанлы күчмә кабиләләр яши.

Урал буе далаларында һәм Хәзәр диңгезе түбәнлегендә бәҗәнәкләр кул астындагы кабиләләр бергәлеге хакимлек итә. Кара диңгез буе далалары исә, соңрак көньяк рус җирләре дип аталса да, ул чакта *кыпчаклар* кулында була.

Бөтен бу киңлектә этнослар арасында аралашуның гомумкулланылыштагы теле *төрки тел* була. Монда этнослар, кабиләләр, гореф-гадәт, йола-традицияләр, рухи һәм матди культура элементлары һәрвакыт кушылып, бер-беренә катышып тора.

Әлеге процесслар Тын (Дон) буе районнарында: хәзәрләр белән руслар, төрки телле кыпчаклар белән байтак рус кенәзлекләре халкы арасында бигрәк тә активлаша.

Л.Н.Гумилев әйткәнчә: *«Кыпчаклар яки куманнар – иң борынгы культура халкы».*

XII йөз урталарына таба Донның түбән агымында, Азов буенда ике телле руслардан, дөресрәге, рус-кыпчак телле метислардан торган *бродниклар* дип аталган байтак санда авыллар яшәп килә. Аларның киләчәк буыннары *казаклар* буларак таныла.

Ике төрле мәдәният, культура дөньясында: бер яктан – православие (Грузия, Византия, Киев Русе), икенче яктан – мөселман (Урта Азия, Идел Болгариясе, Кавказ) культурасында яшәгәнгә, кыпчаклар аларның мәдәни казанышларын бик тиз үзләштереп алалар.

Кыпчаклар Идел буе болгарлары белән тыгыз бәйләнештә яши – хәрби хезмәткә яллана, уртак гаиләләр кора, Болгар җирендә урнашып кала, игенчелек, һөнәрчелек, сәүдә осталыгына өйрәнә.

Шулай итеп, төрки-кыпчак дөньясы монголларга кадәр чорда Көнчыгыш Европаның барлык халыклары тормышында да гаять зур этнолингвистик һәм этномәдәни роль уйный *(Г.Сабирҗанов)*.

Әндәлүстән (Әндәлес) 1135 һәм 1155 елларда шәһре Болгарга килгән танылган гарәп сәяхәтчесе һәм галим Әл-Гарнатый «Көнбатышның кайбер могҗизаларының ачык бәяны» дигән китап яза. Анда ул болай ди: *«Ә Болгар шулай ук зур шәһәр, тулысынча нараттан төзелгән, ә шәһәр диварлары – имәннән. Аның тирәсендә исә иксез-чиксез (төрле) халык...»*

Шундый ук сүзләрне Болгарга 1145 елда килгән һәм аның төзелешләрен, корылмаларын Византиянеке белән чагыштырган икенче бер гарәп авторы (Әл-Җәвали) да яза.

Ул чорда Болгариядә Сувар шәһәре әһәмияте буенча – икенче урында, Ашлы (Ошель) шәһәре өченче урында тора.

Рус сәүдәгәрләренең сәүдә өлкәсендәге көндәше (конкуренты) – Идел Болгариясе белән сугышлар – бөек Киев кенәзе һәм Владимир Мономахның Долгорукий кушаматы алган улы Ростов Суздаль кенәзе Юрийның тышкы сәясәтенең төп юнәлешләренең берсе була.

Долгорукийның ике мәртәбә өйләнгән – беренче тапкыр кыпчак кенәзе кызы белән, икенчесендә Болгар ханы кызы белән никахлашкан улы Владимир кенәзе Андрей Боголюбский шундый ук сәясәтне алга сөрә.

1164 елда чираттагы һөҗүмнәренең берсендә Боголюбский Болгар иленең берьюлы биш шәһәрен җимерә һәм талый. Шуннан соң болгарларның баш каласы илнең түренә – Биләр шәһәренә күчерелә.

Үз чиратларында болгарлар да, җавап йөзеннән, русның Муром, Рязань һәм башка шәһәрләренә һөҗүмнәр ясый.

Болгариядән көньяктарак урнашкан кыпчаклар иленнән – Дәште Кыпчактан да болгар җирләренә еш кына яу килә.

Шулай итеп, XII йөздә үзара рус-болгар мөнәсәбәтләре феодализм чорына күрә гадәти була, чит җирләр байлыгын талап алу һәм колларга әйләндерү, коллар базарларында сату өчен әсир төшерү максатында алып барылган хәрби бәрелешләр белән характерлана.

Территорияләрне басып алу планнары әлегә булмый.

XIII йөз дә килеп җитә.

Руслар һәм болгарлар бер-берләрен чиратлашып талаган һәм рус кенәзлекләре үзара сугышлар белән алга таба да бүлгәләнүен дәвам иткән арада, Байкал артындагы ерак далада һәм Монголиянең төньяк-көнчыгыш районнарында киләчәктә бөтен дөньяны тетрәндерәчәк башлангыч феодаль дәүләт барлыкка килә.

1206 елда Бөек Монголия империясенә корылтайда Чыңгыз хан (төрки-монгол теленнән – «диңгез», «дәрья», «иксез-чиксез», «бөек») титулын алган кырык дүрт яшьлек Тимучин нигез сала һәм җитәкли.

1219 елда аның гаскәре Урта Азиядәге Хәрәзем (Хорезм) шаһлары дәүләтенә басып керә; 1222–1223 елларда Иран аша Кавказ аръягына, Төньяк Кавказ далалары буйлап кыпчакларга чыга.

Кыпчак ханы Котяк ярдәм сорап үзенең киявенә – Галиция кенәзе Мстислав Удалайга мөрәҗәгать итә, һәм Киевта рус кенәзләре съездында монголларга каршы бергәләп сугышу турында карар кабул ителә.

Әмма 1223 елның 31 маенда Калька сугышында 80 меңлек рус-кыпчак гаскәре тар-мар ителә.

Руслар белән кыпчакларны зур уңыш белән җиңгәннән соң, якынча биш меңлек монгол отряды Идел Болгариясенә юнәлә.

**6. МОНГОЛЛАРНЫҢ БОЛГАР ИЛЕНӘ БАСЫП КЕРҮЕ**

Шул рәвешчә, Болгар дәүләтенең алга таба үсеше монголларның ябырылуы, басып керүе аркасында туктап кала. 1223 елның көзендә Җәбе белән Сүбәдәй җитәкчелегендәге беренче һөҗүмне, руслар белән кыпчаклардан аермалы буларак, болгарлар кире кайтара, ә монголлар ул чакта беренче мәртәбә җиңелә.

Монголлар басып алган Хәрәзем һәм Дәште Кыпчак Чыңгыз ханның өлкән улы Җучи хакимлегенә бирелә. Әмма 1227 елда ул вафат булганнан соң әлеге олыс аның улы Батыйга күчә.

Шул ук вакытта кыпчакларның байтак нәсел төркеме, монголлардан качып, Венгриягә, Литва кенәзлегенә, Ростов Суздаль җирләренә китә.

Болгарның үзендә исә маҗар кабиләләренең бер өлеше генә яшәп кала. Венгрия монахы Юлиан аларны шунда очрата.

Чыңгыз хан ихтыяры, таләбе белән монголлар өчен яңа җирләрне яулап алуның мөһим юнәлешләреннән берсе – Төньяк илләр. Шуңа күрә 1229 елда аларның 30 меңлек гаскәре Уралга, Хәзәр диңгезе буйларындагы далаларга һәм Идел буена юнәлә.

Күкдәй белән Сүбәдәй гаскәре, Җаек елгасын кичеп, Хәзәр каганатына бәреп керә һәм хәзәр халкы яшәгән Саксин шәһәрен яулап ала.

*«...һәм кыпчаклар түбәннән Татарлардан алда Болгарларга йөгерделәр...»*

Шуннан соң монголлар, Җаек янында сакта торган болгар отрядларын тар-мар итеп, Болгарга кабат һөҗүм ясый, әмма болгарлар 1229 елда да алар һөҗүмен кире кайтара.

Барлык бу вакыйгалар болгар хакимнәрен күрше рус кенәзлекләре белән мөнәсәбәтләрне яхшырту юлларын эзләргә мәҗбүр итә. Шул ук 1229 елда болгар ханы бөек Владимир Суздаль кенәзе белән тынычлык турында килешү төзи һәм шул ук елда, иген уңмаган һәм ачлык елында, болгарлар Руська ярдәм кулын суза.

1232 елда монголлар яу белән Болгарга өченче тапкыр китә. Шул чорның елъязмаларында болай диелә: *«...татарлар килделәр һәм Бөек шәһре Болгарга җитәрәк туктап кыш чыктылар». («...придоша татарове и зимовата не дошедше Великого града Болгарского»).*

1235 елда Чыңгыз хан варисы, Монголия империясе каганы Үгәдәй гомуми корылтай җыя, һәм анда, *«Батый станы янәшәсендәге һәм әлегә тулысынча буйсындырылмаган, үзләренең күпсанлы булуы белән горурланучы болгар, ас һәм рус илләрен яулап алырга.» (Иран (фарсы) тарихчысы, монгол яулап алулары елъязмачысы Әл-Җувайни)* дигән карар чыгаралар.

Һәм, шулай итеп, Көнчыгыш Европага моңарчы күз күрмәгән походка әзерлек башланып китә.

Монголларның һәм Үзәк Азия (монгол) татарларының күпсанлы гаскәре 1236 елның июнендә Җаек елгасы тирәсендә туплана башлый.

*«...Сугышчыларның биниһая күплегеннән җир ыңгырашты һәм гүләде, ә яуларның иксез-чиксез булуыннан кыргый җәнлекләр һәм ерткыч хайваннар катып калды» (Әл-Җувайни).*

Шул ук елның көзендә Батый ханның 150 меңлек гаскәре Болгар иленә бәреп керә һәм Бөек шәһре Болгарга юнәлә. Шәһәрне батырларча саклауга да карамастан, 45 көнлек камалыштан соң башкала җиңелә, һәм Болгар дәүләте коточкыч җимерелүгә дучар була. Биләр, Кернек, Юкәтау (Җукәтау), Сувар шәһәрләре дә җир йөзеннән юк ителә.

Игътибар итик: Батыйның шул ук гаскәре икенче елда Русьның бөек кенәз Георгий Всеволодович утырган баш шәһәре Владимирны бары тик биш көндә яулап ала. Рязань шәһәрен дә биш көн эчендә җимерә...

1236 елда Лаврентьев елъязмасында, зур кызгану белән: *«Көнчыгыш иленнән Болгар җиренә имансыз Татарлар килде һәм шанлы Бөек Болгар шәһәрен алды, һәм коралы белән картлардан алып, нәни сабыйларга кадәр кырды, һәм күпләгән товар алды, ә шәһәрне ут җибәреп яндырды, һәм аларның бөтен җирләрен буйсындырды»,* – диелә. *(«Придоша от Восточной страны в Болгарьскую землю безбожнии татаре, и взята славный Великий город Болгарьский, и избита оружием от старца и до сущаго младенца, и взята товара множество, а город их пожгота огнем, и всю землю их пленища».)*

Батыйның Европага походының баштагы чорындагы мондый кансызлыгы, бер яктан, болгарларга каршы беренче мәртәбә яу чапканда зур югалтулары өчен үч алу булган булса, икенче яктан, киләчәктә булачак дошманнарына курку салу, котын алу теләге белән аңлатыла *(Э.Хара-Даван).*

Болгар илендә каршылыкның төп чыганакларын бастырып, монголлар 1236 елның көзендә һәм 1237 елның кышында башкортларны, аннары, хәзәр һәм кыпчакларны тар-мар итеп, мордваларны буйсындыра.

1237 ел ахырында рус җирләрен – Рязань, Коломна, Мәскәү, Владимир, Ростов, Углич, Ярославль һәм башка шәһәрләрне яулау башлана. 300 шәһәрнең ундүрте яндырыла һәм тулысынча җимерелә.

1238–1240 еллар дәвамында монголлар тарафыннан Тюржок, ике айга якын каршылык күрсәткән Козельск, аннан Переяславль, Чернигов, Кырым, Киев, Галицко-Волын җирләре, Польша, Венгрия яулап алына.

Монголларның төп көчләре Көнчыгыш Европада булган чагында, 1239 елда, мордва һәм руслар, ә 1240 елда Идел Болгариясендә баш күтәрәләр.

Шул вакыттан башлап, болгарларның монголларга каршылык күрсәтүе, кайбер туктап торулар белән, кырык елга якын дәвам итә. Бу хәлне, асылда, болгарларның икенче җиңүе дип санарга була, чөнки монголларның алга таба Көнчыгыш һәм Үзәк Европага басып керүен тоткарлап торуда аларның шиксез өлеше булып тора.

Бары тик Чехиядә, Оломоуц шәһәре янындагы Морава елгасы буенда нык арыган монгол гаскәре җиңелеп, ә Каракорумда бөек каган Үгәдәйнең вафатыннан соң гына, 1242 елда, Батый үз гаскәрен кире көнчыгышка бора.

Европага һөҗүмен туктатып торып һәм кире кайтып, Батый, алга таба буйсындырылган рус җирләрен Идел буенда тиз арада барлыкка килгән Алтын Урда дәүләте составына кушудан баш тартып, тынычсыз, һәрвакыт болганып торган Болгарда үзенең вакытлы ставкасына нигез сала (1242–1246).

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Русь дәүләте дә яулап алучылар белән бу көрәштә болгарларга ярдәм итеп тора *(А.Х.Халиков)*.

Һәм XIII йөзнең урталарында агрессордан күргән күп газапларга түзеп торган һәм башка төр бәла-казадан (чума, корылык) интеккән Идел буе болгарлары, кайбер урыннарда төпләнеп калып, үз иленең төньягына күчеп китә башлый. Соңыннан күренгәнчә, бу төпләнү вакытлыча гына булмый, гомерлек яшәү урынына әйләнә.

Шундый җирләрнең берсе – Казансу ярындагы әүвәл Болгар-әл-Җәдид яки Яңа Болгар, аннан соң Казан дип аталган элекке чик буе шәһәрчеге.

Шулай итеп, 1236 ел вакыйгалары белән Идел Болгариясенең мөстәкыйль үсеше туктала.

Монгол басып алулары болгарлар язмышында гына түгел, аларның күршеләре – башкорт кабиләләре, Хәзәр диңгезе буендагы хәзәрләр, Дәште Кыпчак җире кыпчаклары, бортаслар, мукшы, эрзя, мишәр, рус, чуаш-вирьял, чирмеш, арлар язмышында да кискен борылышларга китерә.

Идел Болгариясе монголлар килгәнче Русьта, Урта Азия илләрендә, Персиядә, гарәп дөньясында һәм Көнбатыш Европада уңышлы үсеп килүче халык дәүләте буларак киң танылу таба.

Ул кырларының уңдырышлылыгы, мал-туарының күплеге, һөнәрчеләренең осталыгы, сәүдәгәрләренең булдыклылыгы, мәдәниятенең үзенчәлекле булып аерылып торуы белән шөһрәт казанган дәүләт була.

Монгол басып алуларына кадәр болгарларның рухи культурасы үсешенең иң югары ноктасы булып алда телгә алынган Кол Галинең 1223 елның маенда язып тәмамланган «Кыйсса-и-Йосыф» поэмасы тора.

Идел Болгариясе Идел буенда һәм Урал буенда, ягъни Идел-Урал елгалары арасында яшәүче башка халыкларның этногенезында, социаль һәм рухи тормышында да гаять зур роль уйный.

Яңа чорга, үз бәйсезлеге өчен Казан дәүләтен төзегәнгә кадәр дәвам иткән көрәш чорына аяк баскан Болгар дәүләтенең эшчәнлек нәтиҗәсе менә шундый...

## 7. БОЛГАР ИЛЕ ҺӘМ АЛТЫН УРДА

Болгар тарихының нәкъ менә бу чоры Россия хакимияте һәм тарихчылары тарафыннан төрле, башлыча сәяси интерпретацияләүгә (төрлечә аңлатуга) дучар ителгәнгә күрә, ул бүгенге көндә принципиаль кызыксыну уята, чөнки монголлар явы һәм Болгар дәүләтен басып алу, җимерү алга таба болгарларга яңа этноним – «*татарлар*» дигән исемне ябыштырып калдыруда төп сәбәп була.

Болай итеп яңа исем тагуның сәбәпле бәйләнеше турында берничә юрама йөри. Без исә аларның берсенә тукталырбыз һәм вакыйгаларның алга таба үсешен күзәтүне дәвам итәрбез.

Моннан тыш, түбәндәге хәл турында да бәян итү кирәктер: Россия тарихында бүгенге Казан татарлары үткәненнән нәкъ менә әлеге чор – 1236 елдан – монгол яулары Болгар дәүләтен тар-мар итүеннән алып, 1437 елга – Казан ханлыгы төзелгәнгә кадәр вакыт аралыгы бары тик бер үк халык язмышын бергә бәйләп торучы җепне өзәр өчен генә сызылып атыла...

Көнчыгыш Европада яңа дәүләт – Алтын Урданы төзи башлау вакыты 1243 елга туры килә.

Ул чакларда Батый ханның вакытлы ставкасы шәһре Болгарда була.
Болгарлар каршылыгын, бузасын бастырганнан соң һәм монда яшәүче халыкның күп өлеше кырылганнан һәм Идел буе болгарларының дәүләтчелеге тәмам бетерелгәннән соң, аларның бай, төзекләндерелгән җирләренә монголлар көньяктан килгән, яңа хуҗаларда сак хезмәтен башкаручы һәм аларга хезмәт күрсәтүчеләр белән тәэмин итеп торучы кыпчаклар күчереп утыртыла башлый.
Идел буе Болгариясенең суварлар яки савирлар яшәгән үзәк районнары иң зур зыян күргән, иң күп интеккән өлеше була.
Монголия башкаласы Каракорумда XIII йөз урталарында барган үзара низаглар, бәрелешләр һәм хакимлек итү өчен көрәш аны аерым кенәзлекләргә тарката. Нигездә Дәште Кыпчак территориясен биләгән Алтын Урда дәүләте дә шул исәптә була.
Алтын Урданың беренче ханы – Батый (Бату, 1243) хан. Әмма бу чорда Урда Монголия империясенең бер өлеше була. Шулай булса да, Батый үз акчасын сугуга ирешә, моны 1967 елда шәһре Болгарда табылган көмеш тәңкәләр хәзинәсе дә раслый (*Г.Федоров-Давыдов.* «Болгардан XIII йөз көмеш тәңкәләренең ике хәзинәсе»).
Дәүләтләрнең башкалалары Идел буена урнаша: алар үз ханнары исемен йөртә. Башта Сарай-Бату* шәһәре була (1254–1480). Хәзерге Әстерхан өлкәсенең Селитренное авылы тирәсендә була ул. Аннары – Сарай-Бәркә шәһәре (1260–1395). Ул хәзерге Волгоград өлкәсенең Царев авылы янында урнашкан була.
Болгар иле, Алтын Урда хакимлегенә күчерелгәч, ике олыска – Болгар һәм Мукшы олысларына бүленә.
Урта Идел тарихының монгол яулап алулары чорының демографик аспектларын караганда, түбәндәге мөһим хәлләрне дә күздә тотарга кирәк: Батый гаскәрләрендә үз монголлары һәм Үзәк Азия (монгол) татарларының саны 9 мең гаиләдән артмый, ягъни барлыгы 40–45 мең кеше була. Алтын Урда төзелгәннән соң, 1243 елда, монголларның төп көчләре кире Монголиягә әйләнеп кайта, ә бер өлеше, Руська һәм Көнчыгыш Европа илләренә яу белән барганнан соң, Идел буенда утырып кала.
Монда гомумкабул ителгән бернәрсә бар: ханлык монголлар тарафыннан төзелгән булса да, анда ханнар үзләре һәм хәрби аксөякләрнең бер өлеше генә этник монголлар, ә халыкның төп өлешен болгарлар, хәзәрләр, кыпчаклар һәм төркиләр тәшкил итүе принципиаль булып санала *(Г.Исхакый)*.
Идел буеның төп халкы бу вакытка 700 мең кеше исәпләнә, ә даладагы кыпчаклар санының исәбе юк, исәпләп бетереп булмый.
Бу этномәдәни мохиттә монголлар шулкадәр аз була, алар тиз арада кыпчак телен өйрәнергә мәҗбүр булалар, чөнки бу тел инде XI йөздә үк Кара диңгездән алып Идел буе Болгариясенә кадәр этникара аралашу чарасы вазифасын башкара.
Шулай итеп, икътисади һәм мәдәни яктан нык үсеш алган, әле монголларга кадәр үк кыпчаклар белән аралашып яшәгән болгарлар һәм аларга якын һәм болгарлашкан борталар үз мәдәниятен һәм телен Урда халкына тарата.
Нәкъ менә бу хәл, шулай ук Батый ханнан соң хакимлек иткән Бәркә ханның һәм Алтын Урданың башка феодалларының 1261 елда ислам динен кабул итүе алга таба Алтын Урданың үз эчендә билгеле бер этномәдәни үзгәрешләргә китерә.
Ислам динен кабул иткәч, Бәркә Хәрәзем һәм Болгарның мөселман сәүдәгәрләренә һәм руханиларына йөз тота.
Шул ук вакытта Идел-Чулманда элекке болгар хакимияте тулысынча юкка чыгарыла. Аны әле Батый хан хакимлеге вакытында да җирле борынгы династия вәкилләре җитәкләгән була. Ә шәһре Болгар үзе XIII йөзнең 50–60 елларында Алтын Урда ханнарының җәйге резиденциясе була, шуңа күрә биредә торгызу эшләре алып барыла, яңа мәчетләр, сарайлар, мәһабәт мунчалар салына.
Чираттагы хан Менге-Тимур үз исемен куеп акча да суга, һәм аның заманында 1269 елда өч олыс хакимнәренең Талас елгасы буенда (Казахстан) үткәрелгән корылтаенда Алтын Урда тулысынча мөстәкыйль дәүләт булып аерылып чыга.
Ул чорда товар алмашуның, сәүдәнең киң үсеш алуы болгар сәүдәгәрләренең сәүдә-эшмәкәрлек эшчәнлегендә дә уңай роль уйный. Ә рус руханилары шактый йөкләмәләрдән азат ителә.
Әлеге мәсьәләне күздән кичергәндә, түбәндәгеләрне дә исәпкә алырга кирәк.
Монгол яулап алулары – бер нәрсә, Алтын Урда исеме белән мөстәкыйль төрки дәүләтнең яшәве – бөтенләй икенче нәрсә.
Билгеле, һәр төр сугыш вакытында элекке дәүләт, империя җимерелә, аның урынына яңасы төзелә; кешеләр дә, шәһәрләр дә тар-мар ителә, җиңелә, юк ителә.
Әмма монгол яуларыннан иң күп зыян күргән җирләр –Азиянең, ягъни күчмә тормыш алып баручы дөньяның көнчыгыш районнары, шулай ук Хәрәзем шаһларының Чыңгызга үзирек буйсынудан баш тарткан Урта Азия җирләре.
Көнбатыш илләрендә хәл башкача була: илбасарлар бәреп керү мизгелендә коточкыч тетрәнү кичергән, әмма бирешмәгән һәм ничек тә яшәп калырга тырышкан халык үзен саклап кала алган.

Бигрәк тә монголларның утрак тормышта яшәүче халыклар (Русь, Идел Болгариясе, Кырым һәм көнбатыштагы башка җирләр) өстеннән хакимлеге Урда баскакларына ясак җыярга ярдәм иткән җирле, ягъни рус һәм башка феодал-кенәзләрнең югары катлавы аша алып барылган. Шуның өстенә, абсолют азчылык булганга, Алтын Урда монголлары бу җирдә залим режим төзүнең реаль мөмкинлегенә ия була алмый. Ул гына да түгел, бирედә урнашып калган аз санлы монголлар тора-бара, җирле төрки халык белән кушылып, ассимиляцияләнеп, бу мохиттә «эреп» бетә.

Гарәп тарихчысы, Мисыр солтаны Әл-Омариның сәркатибе, Русьта һәм Төньяк Кавказда Алтын Урда ханнары хакимлеге рәвешенә тукталып, болай ди: *«Чиркәсләр, рус һәм ясларның (аланнар, осетиннарның борынгы бабалары) бу илләр солтаннарына (ягъни Алтын Урда ханнарына) каршы торырлык көче юк, шуңа күрә, үз патшалары булса да, алар хакимлеге астындагы халык кебек буйсынып яшиләр.*

*Әгәр аңа үзләренең буйсынуын күрсәтеп бүләкләр белән мөрәҗәгать итсәләр, ул аларны тынычлыкта калдыра, киресенчә булганда, аларга һөҗүмнәр ясап, камап торулары белән җәфалый» (Р.Фәхретдинов).*

Шулай итеп, килгән монголлар күпсанлы, төрки телле җирле халык арасында инде үзләре бик тиз кушылып бетә. XIX йөздә бу дәүләтнең рәсми теле булып гомуми «төрки» тел традицияләренә нык буйсынган һәм беренче чорларда дәүләт теле булган монгол телен тулысынча алыштырган кыпчак теле санала *(М.З.Зәкиев)*.

Соңга таба бөтен законнар – Алтын Урда ярлыклары бу телдә язылa. Алтын Урдага килгәләп торган гарәп сәяхәтчеләре аны монгол ханлыгы дип түгел, ә кыпчак ханлыгы дип атыйлар *(Г.Исхакый)*.

Менге-Тимур вафат булганнан соң, Алтын Урдада 1282 елдан башлап XIV йөзнең беренче унъеллыкларына кадәр акрын-акрын феодаллар арасындагы низагларга, каршылыкларга китергән тәхет өчен көрәш башлана.

Нәкъ менә шул елларда Жучи хан буыны Ногайның дәрәҗәсе үсеп китә. Аның кыпчак, төрки, угыз һәм төрки телле башка этносларны, мангытлар кабиләсеннән торган монголларны берләштергән «нәсел тирмәсе» соңга таба, XIV йөз ахырларына, Итил-Җаек елгалары аралыгындагы олыска ия була һәм ул Ногай (Нугай) Урдасы дип атала башлый.

Бу вакытта, XIII йөзнең соңгы чирегe һәм XIV йөз башында, болгарлар олысы Алтын Урданың икътисади нык үскән өлкәсенә әйләнә.

*«Болгар иленең шәһәр халкы арасында да элекке болгарларның яңа яулап алучылар (нигездә, төркиләр) белән хакимлек итүче аксөякләр йөзендә монголлар белән акрынлап кушылуы күзәтелә башлый.*

*Шул сәбәпле Болгария иленең «татар золымы» дип аталган чордагы шәһәр культурасы мөстәкыйльлекнең шундый ук чорының турыдан-туры дәвамы булып тора, һәм гаять зур территорияләрнең Чыңгыз хан империяләренә сәяси берләшүе нәтиҗәсендә бу төбәккә тагын да ирeклерәк рәвештә бары тик көнчыгыш йогынтысы гына килеп кушыла алгандыр, мөгаен» (Н.И.Воробьев, Г.Исхакый).*

Алтын Урда халкының гомуми массасы эчендә Итил-Чулман болгарлары авылларда – утрак игенчеләр булып, ә шәһәрләрдә сәүдә-эшмәкәрлек эшчәнлеге, һөнәрчелек традицияләрендә тәрбияләнгән халык булып аерылып тора. Биредә ислам һәм гарәп-мөселман мәдәнияте культурасы торган саен киңрәк җәелә.

Ул чорда шәһре Болгар яңадан Русь, Көнчыгыш Европа, Кавказ, Персия, Урта Азия, Монголия һәм Кытай сәүдәгәрләре өчен кәрванлы транзит сәүдәсе үзәге буларак киң таныла.

1313 елда Сарайда хан тәхете ислам илләренә һәм сәүдәгәрләргә йөз тоткан аксөякләр даирәсе ярдәме белән Үзбәк Солтан Мөхәммәдкә күчә. Аның чорында Алтын Урда сәяси һәм икътисади үсешендә иң биек ноктасына җитә.

Идарә итү системасын үзәкләштерүне көчәйтү максатларында ул элекке олыслар урынына бүгенге өлкәләргә охшаш яңа административ берәмлекләр төзи, аларны әмирләр (кенәзләр) җитәкли. Әлеге идарәләрнең чиновниклары булып казыйлар (судьялар), диван (иң югары түрәләрдән киңәшү органы) сәркәтипләре, салым җыючылар, тоткаулы (застава башлыклары), тамгачылар (таможня хезмәткәрләре) һ.б. билгеләнә.

Дәүләтнең бердәнбер дине дип ислам дине игълан ителә.

Бер генә динне раслау биредә гарәп язуының таралуына, гомуми әдәби тел нормаларын, архитектура корылмалары һәм аларның монументаль-декоратив җиһазларының тиешле стилен булдыруга ярдәм итә.

Әл-Омари Үзбәк хан турында мондый сүзләр язып калдыра: *«...үзенең динле булуын ачыктан-ачык күрсәтүче һәм мөселман кануннарын берсүзсез үтәүче хан динле саф мөселман...»,* ул үзенең башкаласында *«...фән өчен мәдрәсә төзи, фәнгә һәм фән кешеләренә ихлас бирелгән...»*.

Алтын Урданың куәтле хакиме Җанибәк хан исламның раслануына, ныгуына, фән һәм сәнгатьнең үсешенә тагын да зуррак игътибар бирә.

Бу хәлләрнең барысы да, элекке Идел Болгариясе җирләрендә мөселман руханилары эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудырып, Идел-Уралның төрки телле халыкларын этномәдәни унификацияләүгә, берләштерүгә ярдәм итә, ә бу процессның нигезендә яткан тел (үзәк территорияләрдә яшәүче төп халык) кыпчак теле була *(Г.Сабирҗанов)*.

Нәкъ менә шул елларда Алтын Урда чоры тарихка зур территорияләрдә шәһәр төзелешенең, мәдәният һәм дәүләт идарәсе үсешенең чәчәк ату чоры булып кереп кала, шуның белән гамәлдә киләчәктә булачак Россия империясенә һәм Советлар Союзына нигез сала.

*«Евразиянең монголларга кадәрге шәһәр цивилизациясенең (Урта Азия, Болгар, Кара диңгез буе) иң яхшы, иң алдынгы традицияләрен үзенә җыеп, төрки дөньяның гаять зур байлыгы һәм үзенчәлеге чагылышы булган Дәште Кыпчакның күчмә һәм шәһри культурасы симбиозын да (үзара ярдәмләшеп янәшә яшәвен) кертеп, очсыз-кырыйсыз кыпчак далаларында 150 дән артык (!) шәһәр төзелә.*

*Шәһәрләрнең исемнәре дә, Көнчыгышның үзе кебек үк, гаҗәп матур, шигъри: Гөлстан, Сарай, Сарайчык, Аксарай, Аккирмән, Актүбә, Шәһәр-әл-Җәдид һ.б.*

*Ул гына да түгел, әле кайбер шәһәрләр үзләренең күләме һәм халык саны ягыннан Көнбатыш Европа шәһәрләреннән күпкә өстен була. Чагыштыру өчен: XIII йөздә Римда – 35 мең кеше, XIV йөздә Парижда – 58 мең, шул ук XIV йөздә Сарайда 100 меңнән артык (!) кеше яши.*

*Байтак илләрдән 200 ел буена мөселман дөньясының дөньякүләм сәясәте үзәгендә торган Урдага кызыксынучан сәяхәтчеләр һәм бай сәүдәгәрләр, оста дипломатлар һәм зирәк сәясәтчеләр килеп йөри.*

*Алар бу дәүләтнең көчле, кодрәтле ханнары белән таныша, анда яшәүче күпсанлы халык турында мәгълүмат туплый, бай базарлары һәм көнчыгышның зиннәтле архитектура үрнәкләрендә төзелгән зур шәһәрләре белән хозурлана.*

*Моңарчы күрелмәгән хан сарайлары, мәчет-мәдрәсәләр һәм мавзолейлар, мунча һәм кәрвансарайлар, башка корылмалар үзләренең матурлыклары белән таң калдыра» (Р.Фәхретдинов).*

*«Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Алтын Урдада барлык диннәр дә бер үк дәрәҗәдә иркеле була.*

*Чыңгыз хан кануннары нигезендә динне кимсеткән кеше үлем җәзасына тартыла.*

*Һәр диннең руханилары салым түләүдән азат ителә.*

*Гарәп сәяхәтчеләре раславынча, башкала – Сарай зур һәм төзек сәүдә шәһәре була.*

*Сарай шәһәрендә хан сарайлары, мәчетләр һәм башка диннәрнең гыйбадәт кылу йортлары (храмнар), мәктәпләр, җәмәгать бакчалары, мунчалар һәм суүткәргечләр төзелә.*

*Әйткәнебезчә, Сарай – сәүдә үзәге, анда даими күпсанлы чит ил сәүдәгәрләре дә яши, тик – аерым кварталларда.*

*Сарай әле үз вакытының мәдәният үзәге булып та санала.*

*Алтын Урдада фарфор һәм балчыктан савыт-саба ясыйлар, алтын һәм көмеш тәңкәләр сугалар.*

*XIV йөзнең беренче яртысына Алтын Урда дөньякүләм әһәмияткә ирешә» (Г.Исхакый).*

Шул ук елларда рус кенәзлекләре арасында, аерым алганда, Мәскәү белән Тверь арасында, сәяси өстенлек өчен көрәш бара – һәрберсе гомумрус метрополиясе үзәге булырга тели.

Үзбәк ханнан Владимир җирләрендә кенәзлек итү ярлыгы алганнан соң, аннары аның сеңлесенә өйләнеп, Мәскәү кенәзе Юрий Данилович Тверь шәһәре ханының җәза отрядын җитәкли. Аны 1318 елда төбенә кадәр җимереп, Михаил Тверьскойны җәзалап үтерүгә ирешә.

1327 елда Тверьда шәһәр халкының Алтын Урда илчелегенә каршы бузасыннан соң, инде Мәскәүнең икенче кенәзе Иван I Данилович Калита шулай ук җәза отряды белән килеп: *«...бөтен Рус җирен кыра» («...всю землю Русскую положиша пусту»).*

Шулай итеп, *«...кыргыйлану һәм туганнар арасында ачуланышу куркынычы»*н үзенә сеңдергән рус кенәзләре арасында үз-үзен саклап калу һәм читләр байлыгын тартып алу өчен көрәш ахыр чиктә Мәскәүнең җиңүенә китерә. 1236 елда шул уңайдан Успен соборы төзелә, һәм православие чиркәвенең гадәттә башкалада яшәүче башлыгы, элек Киевтан Владимирга күчерелгән кебек, Мәскәүгә күчерелә...

## 8. АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАРКАЛУЫ<br>ҺӘМ КАЗАН ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ТӨЗЕЛҮЕ

Ни генә булмасын, 1359 елда Алтын Урда үзенең баешына таба борыла, чөнки кабатланып торган үзара ызгыш-талаш, бәрелешләр, хакимлек итү өчен көрәш, ханнарны бер-бер артлы үтерү илне җимерелүгә алып барып җиткерә. Шуны гына әйтү дә җитә: 250 ел яшәү дәвамында гына да Алтын Урдада 50 хан хакимлек итә.

Бу фетнә Алтын Урда составындагы яки аңа караган өлкәләрдәге барлык халык тормышына авыр тәэсир ясый.

1357 елның язында үзенең улы да катнашкан бузачылар тарафыннан Җанибәк хан үтерелә. Ике елдан соң әтисен үтерүче үзе фетнәчеләр кулыннан һәлак була.

Шул вакыттан башлап, ханнар «буталчыклыгы» егерме елга сузыла: «Алтын Урда башкаласында 24 хан алышына. 1379 елда тәхеткә Җучи токымыннан булган Туктамыш килгәч кенә бу хәл туктатыла.

1361 елда Болгар ханлыгы территориясендә мөстәкыйль кенәзлек (әмирлек) оеша. Аны олыс әмирләреннән берсенең улы Булат Тимур җитәкли. 1367 елда Урда таләбе, ихтыяры белән рус Нижегород Суздаль кенәзе Шәһре Болгарны җимерә һәм аерымланучыны (сепаратистны) җәзалап үтерә.

1368 елда, Алтын Урданы аякка бастырган чираттагы фетнәдән соң, Сарай ханы Хәсән (Асан) үзенең тәхетеннән баш кага һәм яңадан болгар җирләрен Алтын Урда буйсынуыннан чыгару максатында үзен болгар кенәзе дип игълан итә.

Әмма икенче елда ук Болгарга «ушкуйниклар» – Новгородның елга пиратлары бәреп керә, ә 1970 елда Сарайдагы хакимлекне үз кулына алган Мамай күрсәтмәсе белән Суздаль кенәзе Дмитрий үз гаскәрен болгар кенәзе Хәсәнгә каршы җибәрә. Нәтиҗәдә, Мамай әмере буенча, Болгар хакиме Хәсән белән бергә әле балигъ булмаган солтан Мөхәммәд хакимлек итә башлый.

Болгар халкына бу вакыйгалар бер генә нәрсә китерә – шәһәрне системалы рәвештә туздыру, бөлдерү һәм аяктан егу.

1376 елның мартында Хәсән (Асан) белән Мөхәммәднең (Мәмәд Солтан) Болгар кенәзлегенә бөек кенәз Дмитрий Донской һәм Суздаль кенәзе Дмитрий үз гаскәрләрен яуга җибәрә. Русларның сан ягыннан күпкә артык гаскәре, Болгарны саклаучыларның утлы корал һәм буртасларның дөяләрдәге отрядларын файдалануына да карамастан, шәһәрне басып ала һәм:

*«Болгарстан кенәзләре Хәсән белән Мөхәммәд кенәзгә баш орды һәм шәһәрдән түләм бирде...» (князи Болгарстан Асан и Мамед Солтан биша челом князю и даша откуп с града...»).*

Аннан соң 1377 елда Сарай Бәркәдәге чираттагы буза нәтиҗәсендә хакимияткә килгән Урус хан Алтын Урданың Итилдән Көнчыгышка таба бөтен территориясен, шул исәптән Идел буе болгарлары җирләрен үзенә буйсындыра.

Аның Көнбатыш өлеше исә бередә әүвәл Идел буе ханлыгын оештырган, ә 1380 елда, Урус хан вафатыннан соң, чынлыкта Сарайның үзендә дә хакимлекне үз кулына алган Бирдебәк хан кияве һәм хәрби башлык Мамайда кала.

1391 елда Сарайдагы тәхет тирәсе аксөкләреннән берсенең улы Идегәйнең Мангыт юрты Җаек елгасы тамагында урнашкан Сарайчык шәһәре үзәге белән Нугай Урдасы нигезенә әйләнә.

Аннан соңгы бөтен вакыйгалар – Мамайның Туктамыш һәм рус кенәзлекләре белән, алга таба Туктамышның Мавәрәэннәһер хакиме Тимур белән Алтын Урданы тетрәткән көрәше – элекке Идел буе Болгариясе халкына авыр йөк булып ята.

Мәсәлән, 1395 елда Тимур гаскәрләре Туктамышны куып барганда, Болгарның Чулман аръягы территорияләре тулысынча, нигезенә кадәр җимерелә, аннан соң Хаҗитархан, Сарай, Сарайчык шәһәрләре юк ителә.

Барлык бу бәла-каза болгарларны Казан тирәсенә, Казансу елгасы аръягына һәм җиңел генә үтеп булмый торган башка җирләргә күпләп-күпләп күчеп китәргә мәҗбүр итә.

Әмма 1396–1399 елларда, Түбән Новгородның Суздаль кенәзе Семен Дмитриевич белән Урда ханбәге Ентәк тарафыннан талануына җавап итеп, *«бөек кенәз Василий Дмитриевич Московский ... үзенең туганы Юрий Дмитриевичны көчле гаскәр белән Казанга җибәрде, алар, юл уңаеннан, Болгар һәм Җүкәтау (Юкәтау), Казан һәм Кирмәнчек шәһәрләрен һәм башка күп кенә шәһәрләрне яулап алып, анда өч ай булып, сугышып һәм халыкларны буйсындырып, әсир итеп, шактый байлык белән үз өйләренә әйләнеп кайттылар...»*

Шул ук поход вакытында руслар *«...барлык бу шәһәрләрне нигезенә кадәр җимерделәр, ә Казан патшасын, үзенең патшабикәләре белән бергә, ярсып, котырынып кылыч белән кыйдылар һәм шәһәрдә яшәүче барлык сарациннарны, хатыннарын һәм балаларын туракладылар. Бераз вакытка Казан буйсынды һәм басылды, ярлыланды, 40 ел буе буш торды».*

1407 елның җәендә Болгар яңадан игътибарны җәлеп итә башлый.

Тәхеттән Идегәй куып җибәргән Җәләлетдин хан үзен Болгар ханы дип игълан итә. Моңа җавап итеп Идегәй болгар җирләрен кабат талый, шуның өстенә аларны әле Новгород ушкуйниклары да борчып тора.

1409 елда монда ике мөстәкыйль Болгар кенәзлеге барлыкка килә: берсенең үзәге – Болгарда, икенчесенеке Юкәтауда була.

Казан беренче мәртәбә Болгар җирләренең административ-сәяси үзәге буларак 1411 елда, Болгар һәм Юкәтау кенәзләре исә Казанга буйсынган кенәзләр, ягъни «Казантия кенәзләре» дип телгә алына.

XIV йөз ахырында – XV йөз башында Алтын Урданың үзәк районнарының чиге булмаган үзара низаглардан, сугышлардан гарык халкы янәшә, күрше дәүләтләргә – Литва, Польша, һәм рус җирләренә күчеп китә башлый. Бөек Литва кенәзлегендә генә дә алар 40 меңләп сугышчы саналган, ә гаиләләрен дә исәпкә алсаң, 120–150 мең кеше дигән сүз.

Шулай да Алтын Урданың җимерелүенә һәм таркалуына үзара ызгыш-сугышлар гына сәбәп булмый. Монда XV йөздә Һиндстанга ачылган су юлы, Осман төрекләренең Алтын Урда белән Венеция һәм Генуя арасында сәүдәне авырлаштырган Константинопольне һәм бугазларны басып алуы да кечкенә роль уйнамый.

Моннан тыш Урданың хәлсезлегеннән Мәскәү дәүләте дә оста файдалана: Сарай шәһәренә генә түгел, болгарларның башка шәһәрләренә дә күп мәртәбәләр яу чаба һәм аяусыз талый.

Сарайда 1421 елда династия өчен аяусыз көрәш нәтиҗәсендә Жучи улларының берсенең нәселеннән булган Тукай-Тимурның һәм Туктамышның туганы Олуг Мөхәммәднең тәхеткә утыруы элекке, кайчандыр бөек һәм кырыс булган Жучи олысы – Алтын Урданың ике өлешкә – көнчыгыш һәм көнбатыш өлешкә бүленүе белән бер вакытка туры килә.

Көнчыгыш өлеше, үз чиратында, Нугай һәм Себер ханлыкларына, көнбатыш өлеше исә Әстерхан һәм Кырым ханлыкларына, шулай ук Алтын Урда башкаласы тирәсендәге территорияләргә һәм әлеге дәүләтнең аерылмас кисәге була алмаган Идел Болгариясе җирләренә бүленә.

Олуг Мөхәммәд 1426–1427 елларда Әстерхан һәм Болгарны буйсындырып, шул уңайдан үзенең исемле тәңкәләрен суктыра.

Яңа үзгәрешләр болгарларны үз авылларын ташлап китәргә мәҗбүр итәләр, алар, таралып, Казансу ярлары буена, Чулман-Нократ елгалары аралыгына, Итилнең тау ягына килеп урнашалар.

1429 елда болгар җирләренең яңа сәяси үзәге Казаннан Галич һәм Кострома шәһәрләренә хәрби походлар беренче мәртәбә телгә алына башлый. Болгар падишаһының улы Галимбәйнең бу походы уңыш китерми, һәм Василий II *«...татар һәм басурманнарны куып җибәрде һәм кыйнады...» («... угониша да их биша, татар и бесермен...»)* диелә елъязмада.

Монда шунысы мөһим: елъязмачы «бесермен» (басурман – мөселман) – болгар һәм «*татарларны*» – кыпчакларны (болгарлар аларны ханбәкләре белән бергә чакыра) тәгаенли, төгәл итеп аерып күрсәтә...

Моңа җавап итеп, ике елдан соң Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II *«...Идел буе һәм Чулман буе Болгарга кенәз Федор Давыдович Пестрыйны гаскәр белән җибәрде, ул барып, алар белән сугышып, бөтен җирләрен әсир итте...» («...посылал ратью на Болгары Волжскиа и Камскиа князя Федора Давыдовича Пестрого, он же шед, воева их и всю землю их плени...»*)

Бу хәлләрдән соң инде шәһре Болгар үзенең элекке дәрәҗәсен, әһәмиятен, Казан шәһәренә күчереп, бөтенләйгә югалта.

Әстерхан ханы Кечек (Кече) Мөхәммәд белән Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд арасында Дәште Кыпчак җирләре өчен барган көрәш Сарай шәһәре хакиме дә булган Кечек Мөхәммәд файдасына төгәлләнә.

Олуг Мөхәммәд 1437 ел кышын үткәреп җибәрү өчен рус җиренә китә. Әмма Василий II, Сарайдагы яңа хуҗадан – Кечек Мөхәммәдтән куркып, аңа каршы 40 меңлек гаскәр җибәрә. Олуг Мөхәммәд рус шәһәре Белев тирәсендә бу гаскәрне тар-мар итә.

Җиңсә дә, Олуг Мөхәммәд рус җиреннән китә һәм, Сарай хакимлегеннән урдалылар өчен инде үз булып саналган Идел буе болгарлары җирен бүлеп алып, анда мөстәкыйль дәүләт төзергә ниятли. Һәм 1438 елда руслар тарафыннан һәрдаим кысрыкланып торган һәм бөлеп калган *«ярлы болгарлар Казанда... аңа шат булдылар...» («худые болгары в Казани... рады ему бысть...»).*

*«Һәм аның казанлылары аңа үзләренең бәла-казаларыннан яклаучы һәм көчләүләрдән, рус яуларыннан саклаучы, ярдәм итүче булырга үтенделәр, ялвардылар... Патша исә аларның торакларында урнашты... патша янына төрле илләрдән, Алтын Урдадан, Әстерханнан, Азов белән Кырымнан вәхшиләр күпләп килә башлады» («И молита его казанцы быти ему заступника бедам их, и помощником от насилия, воевания русского... Царь же вселился в жилищах их... ... начата збираться ко царю многзи варвари от различных стран: от Златыя Орды, от Астрохани, и от Азова, и от Крыма»).*

Шулай итеп, 1438 елда элекке Болгар җирендә инде Казан дип аталган башкаласы белән яңа дәүләт барлыкка килә, ә дәүләт үзе Казан патшалыгы (ханлыгы) дип атала. Шуннан соң *болгар* этнонимы белән беррәттән, бу җирләрдә яшәүчеләргә карата *казанлылар* этнонимы да куллана башлыйлар.

*«Казан ханлыгына нигез салу планын даһи дип атарга мөмкин, чөнки Мөхәммәд хан җирле халыкның борынгы мәдәни (мирасы) үзенчәлеген яхшы аңлаган һәм, Урта Идел буенда мөселман дәүләтен торгызуны ниятләп, аның тотрыклы яшәп кала алуына дөрес бәя биргән. Киләчәкне күздә тоткан бу проект зур осталык белән гамәлгә ашырылган...» (М.Худяков).*

Бу очракта ике нәрсәгә игътибар итәргә кирәк.

Беренче. Яңа ханлык башына элекке Урда зыялылары утырса да, халыкның, мәдәниятенең, социаль-сәяси төзелешенең һәм икътисадының нигезендә җирле Болгар-Казан традицияләре ята. Ягъни бу – шул ук халык, шул ук болгарлар, хәзер инде казанлылар, соңга таба Казан татарлары дип аталган һәм барлык авыл хуҗалыгы, сәүдә-икътисади казанышларны, интеллектуаль культураны, фән, әдәбият һәм фәлсәфә өлкәсендәге казанышларны мирас итеп алган болгарлар дигән сүз.

Икенче. Казан дәүләтенең үз халкы үзендә хакимлек итүчеләрне «*патшалар*» дип атый, ә дәүләтнең үзен ханлык дип түгел, ә «*патшалык*» (фарсыдан – «*падишаһ*») дип йөртә. Шул ук вакытта төркиләр тарихында барлыкка килгән башка яңа ханлыклар – Әстерхан, Кырым, Себер һәм Нугай ханлыклары – башкача була, чөнки, беренчедән, Казанның күтәрелеп китүенең нигезендә борынгы Болгар ята; икенчедән, Казанныкыннан аермалы буларак, башка ханлыклар хакимнәре үз көчләрен элеккечә хәрби кәсепкә – җитештерү, сәүдә, хуҗалыкның үз эчендәге тормыш һәм мәдәният үсешенә зыянга юнәлдерә...

Чынлап та, оешуының беренче көннәреннән үк Казан ханлыгы сәяси яктан да, мәдәни һәм икътисади яктан да көчле дәүләткә әйләнә.

Бу түбәндәгеләрдән чыгып аңлатыла: *«ханлыкка нигез салган Олуг Мөхәммәд, инде әзер иҗтимагый формалардан файдаланып, бу җирдә бары тик яңа сәяси һәм хәрби оешма тудыра, чөнки без әле яңа гына оештырылган дәүләтнең көчле дәүләткә әйләнүен һәм Көнчыгыш Европада тотрыклы урын биләвен (мәсәлән, Мәскәү өчен инде Алтын Урданы алыштырып) күреп торабыз.*

*Әгәр Олуг Мөхәммәд бары тик үзенең Кырымнан алып килгән өч меңлек дружинасына гына таянган һәм иҗтимагый, һәм икътисади яктан нык оешкан халкы булмаган булса, моның булуы мөмкин булмас иде» (Н.И.Воробьев)*.

Казан инде сәяси һәм икътисади мөнәсәбәттә Болгар урынын били, шуңа күрә, зур сәүдә үзәге буларак, чит ил сәүдәгәрләрен үзенә тартып тора.

Алтын Урда, аннан соң Казан ханлыгының аерым чорлары болгар тарихына мәдәният, культура һәм шәһәр төзү эшләренең чәчәк ату чоры булып кереп кала.

Ул гына да түгел, бу халыкның дөньякүләм тарихта прогрессив ролен киметүнең гомуми санында варислардан, ягъни алардан соңгы буыннардан яшерелгән факт – әле 1480 елларда ук, Коперниктан 150 ел элек, шагыйрь Сәйф Сараиның шигъри юллар белән Җирнең Кояш тирәли әйләнүе турында язу факты да бар...

1436–1452 елларда Азак шәһәрендә (хәзерге Азов) яшәгән һәм соңрак Италиянең сәяси эшлеклеләренең берсе булып киткән Венеция сәяхәтчесе һәм эшмәкәре Иосифат Барбаро безнең халык тарихындагы әлеге чор турында менә ниләр яза: *«1438 елда далаларда Улу-Мөхәммәд хан хакимлек итә. Ул Бөек Мөхәммәд император дигәнне аңлата...*

*Хәрби кешеләр иң югары дәрәҗәдә гаярь һәм батыр...*

*Алар гаскәрендә һөнәрчеләр – тукучылар, тимерчеләр, корал ясаучылар һәм башкалар, гомумән, кирәкле бөтен һөнәр ияләре бар...*

*Татарлар чиксез күп... Әгәр Эдиль (Идел) елгасы буйлап Мәскәүгә барсаң, унбиш көн буена яр буйларында аларның хисапсыз кабиләләре белән очрашасың...»*

1430 ел ахыры шулай ук Алтын Урданың яшәүдән туктавы белән билгеле. Аның урынына кыпчак далаларында Олы Урда барлыкка килә.

1440 ел урталарына исә Урта Идел буе халыклары гамәлдә Алтын Урда ханнары хакимлегеннән котыла...

1444–1445 елларда Олуг Мөхәммәд икенче мәртәбә рус җиренә яу чаба. Сугышлар баштагы мәлләрдә алмашынып торган уңыш белән бара, әмма хан, Түбән Новгородны кулга төшергәч, үзенең ике улын – Мәхмүд белән Якубны – Мәскәүгә яу белән җибәрә.

Суздаль янындагы сугышта Василий II җиңелә, әсир төшә һәм Түбән Новгородка китерелә.

Бик күп контрибуция (җиңелү түләме) түләп, Казанга Мещера җирләрен кайтарып, Василий II Мәскәүгә китә. Аның белән бергә Олуг Мөхәммәднең 500 кешесе бара, шуның белән болгар-казанлыларның Руська йөрү процессы дигән нәрсә башлануга нигез салына.

Тиздән Мещера җирләрендә Казан хакиме улларының берсе Касыйм үзенең Касыйм ханлыгын төзи. Бу ханлык 1681 елга кадәр яши. Казаннан килгән зыялы вәкилләргә Русьта төрле административ вазифалар, шулай ук «туендырып торуга» волостьлар һәм шәһәрләр бирелә.

1445 елда Олуг Мөхәммәд вафатыннан соң Казан хакимлеген болгар кенәзе Галимбәй үз кулына алмакчы була. Әмма Олуг Мөхәммәднең олы улы, гаскәр башлыгы Мәхмүд, Казанны алып, Галимбәйне үтерә.

Шулай итеп, Казандагы болгар династиясе юк ителә. Казан тәхетендә алдагы көннәрдә утырган 14 ханның 7 се Урдадан чыккан хан була.

Мәхмүд хакимлек иткән чорда (1446–1466) Идел-Чулман халкы озак көтелгән тынычлыкка ирешә: бу ике дистә ел эчендә рус кенәзлекләре, Олы Урда белән дә тыныч мөнәсәбәтләр бер тапкыр да өзелми. Казан университеты профессоры Н.Фирсов язганча, бу хәл *«Казан тиз арада тернәкләнеп, Көнчыгыш Европада коммерция һәм икътисад үзәге буларак бөек дәрәҗәгә иреште, лаеклы урын алды» (Г.Сабирҗанов)* дип әйтү өчен төп нигез була.

**9. КАЗАН ХАНЛЫГЫ БЕЛӘН МӘСКӘҮ РУСЕ КАРШЫЛЫГЫ**

Әмма Алтын Урда җимерелгәннән соң актив рәвештә үзәкләштерү юлыннан барып, үз территориясен киңәйтү нияте белән янган славян-русларның Мәскәү Русе өчен Казанның көчәеп китүе бер дә файдага булмый, шуңа күрә Мәскәү аңа карата тәгаен билгеләнгән дошман позициясен ала.

Бу мөнәсәбәт иң әүвәл Казан дәүләтенең Русьның Көнчыгышка экспансионистик омтылышын нык итеп чикләвенә һәм аның тарафыннан баштагы мәлдә көрәшнең Казанга гына түгел, Әстерханга да караган Идел сәүдә юлын яулап алу өчен алып барылуына бәйле була.

Шуңа күрә XV–XVI йөзләрдә үк Мәскәү дәүләте Казанга карата, үзен торган саен ешрак агрессор сыйфатында күрсәтеп, актив хәрби сәясәт алып бара башлый.

Мәсәлән, 1461 елдан 1553 елга кадәр Русь тарафыннан 30 дан артык хәрби походлар һәм һөҗүмнәр оештырылса, казанлылар тарафыннан шул ук вакыт эчендә бары 7 җавап һөҗүме ясала, әле аларның берсе дә Мәскәүгә булмый, бары тик төньяк җирләр генә зыян күрә. Болар – рус елъязмачылары язмаларыннан һәм башка тарихи язмалардан.

Мәсәлән, Австрия илчесе С.Герберштейн, Казан ханлыгы турында үзенең тәэсоратларына нәтиҗә ясап, 1526 елда болай яза: *«Бу татарлар башкаларыннан мәдәниятлерәк, алар үз кырларын эшкәртәләр, йортларда яшиләр, сәүдәнең барлык төрләре белән дә шөгыльләнәләр һәм бик сирәк сугышка керәләр».*

Мәскәү позицияләренең ныгуына һәм Казанның хәлсезләнүенә Казан тәхете өчен барган даими сугышлар да ярдәм итә. Бу вакыт эчендә шул максатта гамәлдә элекке Алтын Урданың барлык яңа төзелгән дәүләтләре – Кырым һәм Себер ханлыклары, Олы Урда, Нугай Урдасы – төрле дәрәҗәдә катнаша. Мәскәү дә читтә калмый.

Әлеге вакыйгалар хроникасын карап үтик:

1467 елда Казанда, Мәхмүд хан үлгәч, тәхет өчен янә көрәш башлана. Аңа беренче мәртәбә актив һәм ачык рәвештә Мещераның аерым өлкә кенәзе Касыймны яклаган Мәскәү дә кушыла.

Әмма хан тәхете 1468 елдан 1479 елга кадәр Мәхмүд хан улы Ибраһим кулында кала. Ул хакимлегенең беренче көннәреннән үк ханлыгы чикләрен киңәйтергә карар кыла. Бу карар Казан ханлыгы белән ул вакытта инде Иван III җитәкләгән Бөек Мәскәү кенәзлеге арасында 1468–1469 еллардагы ике еллык сугышка сәбәп була.

Үзара сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә берәүләренең Галич, Кострома, Кичменга, Муром, Хлынов шәһәрләрен, икенчеләренең Казан шәһәрен камап торуы сәбәпле, сугыш килешү белән тәмамлана.

1469 елның бу килешүе белән урнашкан тыныч мөнәсәбәтләр алга таба сигез ел дәвамында бер як тарафыннан да бозылмый.

Бу тын алу Бөек Идел сәүдә юлында сәүдәне үстерергә, күрше дәүләтләр арасында икътисади мөнәсәбәтләрне ныгытырга мөмкинлек бирә, әмма әлеге су магистрален буйлаган бөтен җирдә хакимлек итү өчен көрәш булачагы елдан-ел ачыклана бара.

Һәм Мәскәү, төньяктан һәм төньяк-көнчыгыштан Казан территорияләрен яулап алу, үз биләмәләрен киңәйтү максатында, 1460–1470 елларда Бөек Пермь кенәзлеген буйсындыра һәм, төзелеп килә торган Русь дәүләте составына кертеп, Югор җирләренә протекторат билгели.

Шул ук елларда Бөек Литва кенәзлеге составына керергә ниятләгән Новгород феодаль республикасы белән Мәскәү арасындагы мөнәсәбәтләр катлауланып китә. Иван III кризисны бастыра, ә республика тулысынча бетерелә.

Ибраһим хан, Новгородтагы хәлләрдән файдаланып калырга тырышып, үз гаскәрләрен Нократ (Вятка) җирләренә юнәлтә, әмма хәлләр бу юлы да Казанны утка тоткан Мәскәү белән тынычлык турында килешү белән тәмамлана.

Алдагы 1479 елда Ибраһим хан үлә. Ике хатынынnan биш улы кала. Әлеге биш угыл тәхет өчен көрәш башлауга тагын бер сәбәпкә әйләнә.

Башланып киткән бу көрәшне Иван III хөкүмәте Казанның эчке тормышына һәм тышкы сәясәтенә үз йогынтысын көчәйтү өчен файдалана.

Нугай Урдасына йөз тоткан көнчыгыш сәүдә партиясенең җиңүенә һәм тәхеткә Ибраһимның беренче хатыны Фатыймадан туган өлкән улы Алихан утыруга да карамастан, Мәскәү Ибраһимның икенче хатыны – Бөек Мәскәү кенәзе йортында үскән, хәзер инде, Ибраһим хан үлгәч тә, Кырым ханы Миңлегәрәйнең яңа хатыны булган Нугай ханәкәсе Нурсолтаннан туган ун яшьлек Мөхәммәд Әмингә өстенлек бирә.

Кече яшьтәге Мөхәммәд Әмин Мәскәүгә җибәрелә. Анда аңа төркиләрнең Руська йөрүе процессында кул астындагы җир (удел) сыйфатында Иван III тарафыннан Кашира шәһәре бирелә.

1480 ел Олы Урда ханы Әхмәт белән Польша короле Казимир IV нең рус җирләренә уртак зур походы белән билгеле.

Әмма Иван III, Угра елгасында «бөек каршылык»ны күтәреп, бернинди югалтуларсыз диярлек һәм тыныч юл белән җиңүгә ирешә һәм Урданың соңгы ханнарыннан Русьны тәмам азат итү процессын башлап җибәрә.

Киләсе елда Әхмәт хан Казанны буйсындыру уе белән килгән Себер ханы Ибак тарафыннан Сарайда үтерелә.

Һәм Мәскәү кенәзлеге, Себер ханлыгының Нугай Урдасы һәм Казан белән берләшүеннән куркып, аның алдыннан гына Коми җирләрен үзенә кушып, Казан белән сугышка әзерләнә башлый. Әмма Казан тынычлык турында килешү белән чыга һәм чираттагы сугыш башланмыйча кала.

1484 һәм 1485 елларда Казанда хан тәхете өчен ике туган арасында көрәш яңадан кискенләшә.

Баштагы мәлдә хакимлек руслар ярдәмендә Мөхәммәд Әминдә булса, соңрак нугайларның хәрби отрядлары ярдәмендә Алиханга күчә.

Ике сәяси төркемнең мондый каршылыкта торуы Казанда гражданнар сугышына китерә, шуннан файдаланып, 1487 елда славян-рус Мәскәве аңа зур поход оештыра.

Тугыз атналап камап торганнан соң, Мәскәү воеводалары Казанны яулый һәм тәхеткә кабат Мөхәммәд Әминне утырталар, Иван III үзе «Болгар кенәзе» дигән титул ала. Моннан тыш 1445 елда төзелгән килешү буенча Мәскәү вассал булган булса, хәзер инде үзе ханлыкка протекторат билгели һәм шуның белән русның йогынтысын раслап куя. Ибраһим ханның ике улының хакимлек өчен Казандагы бу көрәше биниһая зур кыйммәткә төшә.

Соңрак бу килешү, ул ел вакыйгаларында катнашучылар үзләре бу турыда уйламаган булсалар да, «татар-монгол» изүен юкка чыгару өчен нигез була...

Мәскәү Русе тарафыннан яулап алынган җирләр саны яңадан арта һәм инде Бөек кенәз Иван III нең дәүләт мөһерендә *«Владимир һәм Мәскәү, һәм Новгород, һәм Псков, һәм Тверь, һәм Югор, һәм Пермь, һәм Болгар, һәм башкаларның Бөек кенәзе»* дигән язма урын ала.

1491 елда инде Мәскәү-Казан уртак гаскәрләре, Касыйм татарлары отрядлары белән берлектә, Сарай ханнарының Кырым ханы Миңлегәрәй җирләренә һөҗүмнәрен кире кайтара – Мәскәү Евразия далаларында эчке мөнәсәбәтләрне менә шулай оста итеп көйли.

Әмма дүрт елдан соң Казанда, көнчыгышка йөз тоткан феодал аксөякләр йогынтысы яңадан нык үсеп китеп, тәхеткә Себер ханы Ибакның туганы ханбәк Мамук утыра. Мөхәммәд Әмин инде ничәнче мәртәбә рус җиренә чыгып кача. «Хезмәттәге патша» дигән титул алып, үзенә элек бирелгән Каширадан тыш, Серпухов һәм Хотунь шәһәрләренә дә ия була.

Хан тәхетендә ханнарның мондый алышынулары алдагы 1496 елда да кабатлана.

Һәрвакыт Казанга буйсынган удмурт кенәзләре идарә иткән Арча кенәзлегенә ясаган сәер походыннан кайтып килгән Мамук ханны казанлылар шәһәргә кертми һәм ул үзенең Себеренә кайтып китәргә мәҗбүр була.

Һәм тәхет 1502 елга кадәр Мөхәммәд Әминнең кече туганы – Кырымда мөселман дөньясында тәрбияләнгән һәм руска каршы фикердә булган Абдул Латыйфка күчә.

XVI йөз башында булган вакыйгалар турында тәфсилләп сөйләү сорала.

Иван III Мәскәүгә тагын берничә кенәзлекне – Новосильское, Перемышль, Одоев, Белев, Кондын һәм Обдор кенәзлекләрен дә куша.

Казанда һәм Мәскәүдә рус яклы феодал аксөякләр фетнә, заговор оештырып, бергәләп эш итүгә килешеп, 1502 елда Мөхәммәд Әминне тәхеткә кайтаралар, ә Абдул Латыйф Белоозерога сөрелә. Бу хәлләргә кадәр, 1500 елда, Мөхәммәд Әмин Русиянең Литва белән сугышында рус гаскәрләренең башкомандующие була.

Иң мөһиме, Кырым ханы Миңлегәрәй 1502 елда Шәех Әхмәтнең соңгы Урда отрядларын тар-мар итә. Олы Урда яшәүдән туктый.

Мәскәүдән Казанга инде 30 яшькә җитеп әйләнеп кайткан Мөхәммәд Әмин, 65 яшьлек авыру Иван III көтмәгәндә, көнчыгыш яклы аксөякләргә таянып, Казан ханлыгының тулы бәйсезлеген торгызу өчен көрәш башлап җибәрә. Казандагы рус сәүдә рәтләрен пыран-заран китереп, Мөхәммәд Әмин нугай отрядлары белән бергә Түбән Новгородка яу чаба. Әмма юлы уңмый.

Мәскәүнең Иван III не алыштырган яңа кенәзе Василий III 1506 елда Казанга җавап итеп яу белән килә, әмма шәһәр диварлары янында тар-мар ителә.

Җиңүенә дә карамастан, Мөхәммәд Әмин сугышны дәвам итми, Мәскәүгә солых тәкъдим итеп, янәшә тыныч яшәү турында 1507 ел килешүе төзелә.

Шуны да әйтергә кирәк: шул елдан башлап 1521 елга кадәр бу солых беркем тарафыннан да өзелми. Ул гына да түгел, бу документның гамәлен ныгыту өчен 1512 елда сәед Шаһ Хөсәен Казан ханлыгы исеменнән Мәскәүдә Мәңгелек солых турындагы шартнамәгә кул куя: *«бөек кенәз белән Ходай биргәнгә кадәр мәңгелек тынычлык һәм какшамас ярату урнаштырдык».*

Шулай итеп, Мөхәммәд Әминнең патшалык итүе кайбер өзеклекләр белән 21 елга сузыла, ә хан үзе, төрле тетрәнүләргә, каршылыкларга да карамастан, Казан тарихына мәгърифәтле хаким, шагыйрь һәм сәнгатьне яратучы һәм яклаучы булып кереп кала.

1518 елда Мөхәммәд Әмин хан үлә, шуның белән Казан тәхетендә үз вакытында аны Олуг Мөхәммәд башлап җибәргән Чыңгызыйлар династиясенә нокта куела. Бер генә ел алдан ниндидер бер сәер хәлләрдә Мәскәү янындагы Каширада аның туганы Абдул Латыйф үтерелә. Һәм Казанда тәхет

өчен тагын көрәш башлана. Бу көрәш славян-рус Бөек Мәскәү кенәзлеге тарафыннан ханлыкның җимерелүенә китерә.

Казанлыларның Миңлегәрәй белән Нурсолтан улы, Кырым ханзадәсе Сәхибгәрәйне Казан тәхетенә чакыру ниятен белеп, Кырымның Казан белән династияләр берләшүе хисабына көчәеп китүеннән куркып калган рус хөкүмәте Мәскәүдә Касыйм кенәзенең унөч яшьлек улы Шаһгалине Казан ханы дип игълан итә. Бераз соңрак Олы Урда ханы Әхмәтнең бертуганының улын рәсми рәвештә тәхеткә кую тантанасы – «хан күтәрмәк» Казанда да була.

Әмма 1521 елның язында Сәхибгәрәй җитәкчелегендәге өч йөз кырымлыдан торган отряд җиңел генә, берниндиi каршылыксыз диярлек Казанга керә.

Псков, Смоленск һәм Рязань кенәзлекләрен берләштерү, шулай ук 1512–1522 еллардагы рус-литва сугышы белән мәшгуль Мәскәү Казанда хакимиятнең үзгәрүенә җавап итеп ни дә булса эшләргә өлгерә алмый кала. Ул гына да түгел, бертуган Гәрәйләр – Кырымнан Мөхәммәд һәм Казаннан Сәхибгәрәй – тиз арада Түбән Новгородны, Коломна шәһәрләрен яулап, Мәскәүгә юнәләләр.

Василий III солых төзергә, Кырым ханына бәйлелеген танырга һәм алга таба Кырымга ясак түләп торырга мәҗбүр була. Казан исә рус протекторатыннан арына, яңадан бәйсез дәүләткә әйләнә *(Г.Сабирҗанов)*.

**10. КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ҖИМЕРЕЛҮЕ**

Уңышларны, җиңүләрне тагын да арттыру ниятеннән Сәхибгәрәй Мәскәү белән мөнәсәбәтләрне алга таба да кискенләштерүгә бара. Мәскәү 1523 елда Әстерхан белән бердәмлек турында килешү төзеп өлгерә.

Моңа җавап итеп Кырым ханы Мөхәммәд Әстерханны яулап ала, ә Василий III ике мәртәбә килеп Казанны штурмлый. Әмма җиңүгә ирешми.

1524 елда Кырымда Мөхәммәд хан үтерелә. Хакимлек руслар яклы Сәадәтгәрәйгә күчә, ә Казанда Сәхибгәрәй үзе утырган тәхетне туганының улы Сафагәрәйгә бирә.

«Сәхибгәрәй чорында Кырымдагы дәүләт идарәсе эшләре дә, реформаланып, шактый төзек юнәлеш ала. Ил белән, халык белән идарә итү дә билгеле бер тәртипләр-кануннар буенча башкарыла.

...Мәгърифәтле хан яңа мәчетләр, мунчалар салынуга, мәдрәсәләр ачылуга зур өлеш кертә...

...Иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге буенча башка ханнардан күпкә өстен Сәхибгәрәй үзенең төс-кыяфәте, буй-сыны белән дә аерылып тора.

...1524 елны тынгысыз, болганчык Казан ханлыгы тәхетен менә шундый эшкә сәләтле, эшчәнлеге ил-дәүләт өчен файдалы булган өметле шәхес ташлап китә, 1551 елны төрек солтаны әмере буенча Сәхибгәрәйне улы Газыгәрәй белән явызларча суеп үтерәләр, ханга илле, улына исә унөч кенә яшь була...» *(М.Госманов)*.

Җыеп әйткәндә, ханнар алышынуы бу тарихи чорда да дәвам итә. Сафагәрәй аннан соң Казаннан ике тапкыр куыла, шулай да анда, тоташтан булмаса да, 1549 елга кадәр хакимлек итә.

Казан 1524 елдан 1531 елга кадәр, ягъни җиде ел дәвамында, инде ирешелгәннәрдә тукталып калырга теләмәгән Мәскәү белән тынычлык турында авыр сөйләшүләр алып барырга мәҗбүр була.

Агрессив славян-рус кенәзлеге, 1487 елда Иван III тарафыннан Казанның алынуын нигез итеп, ханлыкны яулап алуны ике уйлап тормаслык бурыч итеп куя. Янәшә тыныч яшәү турындагы сөйләшүләр Мәскәү тарафыннан өзелә һәм Василий III Казанны кабат камый. Бу юлы Казанны якларга чуашлар, марилар, Нугай Урдасыннан кенәз Мамай сугышчылары һәм Әстерханнан кенәз Яглыч сугышчылары килә. Һәм шәһәр бирелми.

Әмма Мәскәү яклы төркем хакимлекне яңадан үз кулына ала. Казан тәхетенә Шаһгалинең туганы, Касыйм ханзадәсе, 15 яшьлек Җангалине утырталар. Өч елдан соң, Мәскәү ризалыгы белән, Җангали Нугай мирзасы Йосыф кызы Сөембикәгә өйләнә. Шулай итеп, бу ике төрки халыкның хакимлек итүче йортлары үзара туганлаша.

1533 елда Василий III нең үлеп китүе Мәскәүдә ун елга сузылган «боярлар идарәсе» дип аталган чорны – патша сараендагы мәкер эшләр, дворяннар арасындагы бәрелешләр, шәһәр халкының фетнә-бузалары чорын башлап җибәрә.

Казанның хакимлек итүче аксөякләре моннан файдаланып калырга ашыга – 1536 елда Мәскәү куйган Җангали үтерелә, ә тәхеткә 25 яшьлек Сафагәрәй әйләнеп кайта һәм Җангалинең тол калган хатыны Сөембикәне икенче хатыны итеп ала.

Яңа вакыйгалар Казанда Сафагәрәй тирәсендәге кырымлыларның золымына, җәберенә китерә. Ханның бөтен казнаны Кырымга җибәрүе казанлыларда ризасызлык, нәфрәт тудыра. Шулай булса да, Мәскәүнең яңа хакиме Иван IVнең 1545 елда Казанга һөҗүме кире кайтарыла.

Бары бер ел – 1546 ел эчендә генә дә Казанда хакимлек ике мәртәбә алышына: башта – Шаһгалигә, аннары яңадан Сафагәрәйгә күчә.

Хакимлекнең Сафагәрәйгә күчүен руска каршы, бары Кырымга йөз тоткан көчләрнең җиңүе дип аңлатырга була.

Чиктән тыш эчке киеренкелек чорында күренекле казанлыларның руслар ягына күпләп китүе күзәтелә башлый. 1546 елның сентябрендә генә дә Мәскәүгә җитмеш алты аксөяк күчеп китә. Гамәлдә Казанның хакимлек итүче структурасы Кырым татарлары кулында кала.

1547 елның гыйнварында Иван IV, рус кенәзләреннән беренчеләрдән булып, патша титулын ала һәм бу үзәкләштерелгән Россия дәүләтен оештыру юлында мөһим адым була *(Г.Сабирҗанов)*.

Әлеге вакыйгадан соң ике дәүләт каршылыгы тагын да арта, кискенләшә.

Бер якта Сафагәрәй үлгәннән соң аның урынына килгән Кошчак угъланның руска каршы сәясәт алып барган һәм тулысынча Кырым татарларыннан гына торган хөкүмәте булса, икенче якта мөселманнарга түзеп тормаслык дәрәҗәдә яман дини караштa торган Иван IV нең сугышчан рухтагы режимы тора.

Метрополит Макарий җитәкләгән руханилар һәм рус администрациясе позицияләре һәм карашларының тагын да кискенләшүе дворяннарда, хезмәт күрсәтүче катлау һәм боярларда да чагылыш таба. Казанга карата усал караштa торган Иван Пересветов белән Андрей Курбский, Казан җирләре: *«безгә зыянсыз һәм дуслыкта торса да», басурманнарның (мөселманнарның) сугышчанлыгын тәмам бетерергә һәм бу патшалыкны үзебезгә буйсындырырга һәм алар җирләрен мәңгегә бастырырга» кирәк»* дигән өндәмә белән чыгалар.

Бер үк вакытта Казанны «Урда капкасы», ә Казан дәүләтен «Урда кыйпылчыгы» дип игълан итәргә идеологик омтылышлар шактый арта *(А.А.Халиков)*.

Һәм Иван IV, 1521 елда төзелгән мәңгелек солых турындагы килешүне бозып, Казан ханлыгына һәм Кошчак-Сөембикә хөкүмәтенә каршы бер-бер артлы хәрби акцияләр башлап җибәрә.

1548 елда Казанны яулап алырга тырышу барып чыкмый.

1550 елның язында Казанга чираттагы рус походында Мәскәү ягыннан Шаһгалинең Касыйм татарлары һәм Ядегәрнең Әстерхан татарлары да катнаша. Шуны да әйтергә кирәк: Кошчак угълан белән Сөембикә ханбикәнең читтән ялланган, дөресрәге, кырымлылардан торган гаскәре төп казанлыларда ышаныч яуламый. Шулай булса да, Казан Кремлен саклаучылар аны русларга бирми. Руслар кабат җиңелә.

Уңышка ирешмәгән әлеге поход рус патшасына хәрби реформалар үткәрүне башлап җибәрүдә зур этәргеч була: регуляр укчы частьлар төзелә, хәрби дисциплина ныгытыла.

Шуның нәтиҗәсе буларак, 1551 елның языннан Казан ханлыгы тома камауда кала – русның хәрби күзәтчеләре (дозорлары) барлык төп су һәм коры җир юлларын үз күзәтүенә ала. Бу хәл исә башкаладагы эчке каршылыкларны тагын да кискенләштерә.

Моңа җавап итеп, Сөембикә ханбикәнең әтисе Нугай мирзасы Йосыф Төркия, Нугай, Әстерхан һәм Кырым ханлыклары көчләрен берләштергән коалиция төзергә уйлый, әмма бу уе гамәлгә ашмый.

Ханлыкның зур өлешен рус гаскәрләренең басып алуы һәм башкаласын камау, тормыш шартларының авырлашуы Казанда фетнә-күтәрелешләрнең башлануына сәбәп була.

*«...казанлылар белән кырымлыларның бүлгәләнүе башланды. Арча чуашлары кырымлыларга сугыш белән килделәр.»*

Казаннан качып китүе Кошчакны коткарып кала алмый – рус күзәтчеләренең берсе аны качып барганда тота, һәм ул Мәскәүдә җәзалап үтерелә.

Ходайкол угълан, Нургали мирза һәм сәед Кол Шәрифнең яңа хөкүмәте шундук солых һәм Казанны саклап калу турында сөйләшүләр башлап җибәрә. Һәм 1551 елның июлендә, тәхеткә Шаһгалине кайтару шартына ризалашып, Мәскәү белән солых турында килешү төзелә.

Әмма Шаһгалинең, Тау ягы Руська киткәнгә күрә, ханлыкның бары тик сулъяк яр буендагы җирләре белән генә идарә итәргә тиеш булуы үзе бер яңа проблемага әйләнә. Мәскәүгә ничек кенә табынмасын, бу хәл белән ул килешә алмый, ханлык һәм Тау ягы язмышын хәл итү өчен халык җыены – корылтай уздырырга карар кылына.

Тик 14 августта әлеге корылтайда рус воеводалары үзләренең патшасының уңъяк яр буйларын Русь дәүләтенә кушу һәм барлык рус әсирләрен азат итү турында карар кабул итүенә ирешәләр. Шундый шарт белән килешүгә кул куела һәм 16 августта, казанлыларның яңа ханга антыннан соң, Шаһгали Казанга керә.

Бу вакытта тәхетеннән сөрелгән Сөембикә ханбикә һәм аның кечкенә улы Үтәмешгәрәй хан Мәскәүгә озатыла. Казан халкы елап кала. Бу турыда бүгенге көнгә кадәр тарихи-әдәби әсәрләр, шигырь-поэмалар языла.

*Казансуда дулкын ярып,*
*Ерак илгә көймә китә.*
*Шул көймәдә угылы белән*
*Әсирлектә Сөембикә.*

*Йөрәгендә ут янса да,*
*Күз яшьләре инде кипкән.*
*Сафагәрәй рухы шулчак*
*Ялварадыр кебек күктән:*
*«Ташлап китмә, Сөембикәм!*

*Дәүләтеңдә татар ханы*
*Тәхет тотмас инде бүтән:*
*Бәйсезлеге китә илнең*
*Синең белән, Сөембикәм.*

*Зар елашып озатып калган*
*Казан халкы шәфкать көтә.*
*Син аларга соңгы тапкыр*
*Борылып кара, Сөембикә!*
*Чит-ятларга бирәсез, дип,*
*Рәнҗеп китмә, Сөембикә!..»*

*(«Ташлап китмә, Сөембикәм!»*
*Ф.Тарханова, 2005)*

Казан, Тау ягын югалтуы белән килешмичә, 1551 елның октябрендә Мәскәүгә яңа сөйләшүләр алып барыр өчен илчеләр җибәрә.

Әмма Иван IV Казан илчеләрен тоткын итеп ала. Шуннан соң Казанда канлы үч алулар, җәбер-җәза һәм үтереш-суеш башлана. Аксөякләрнең бер өлеше – Нугай мирза биләмәләренә, янә бер өлеше Кырымга кача.

Бу хәлләрне туктату өчен 1552 елның гыйнварында Мәскәү хөкүмәте шулай да элек тоткын ителгән Казан илчеләре белән сөйләшүләрне башлый. Хөкүмәт үзе үк, Шаһгалине бәреп төшереп, Казанга патша наместнигын (идарә башлыгын) җибәрүне, шулай да ханлыкның мөселман хакимиятен һәм финанс автономиясен саклап калуны, ягъни җирләрне кушуны, Казан белән Мәскәү арасындагы уния (берләшмә) итеп калдыруны тәкъдим итә.

Шул максат белән Казанга патша мөһерен саклаучы А.Адашев килә. Үзенең тәхеттән куылуы белән килешсә дә, Шаһгали кальганы рус наместнигына бирүдән баш тарта һәм алтынчы мартта үзенең 300 Касыйм татарыннан һәм 200 рус укчыларыннан торган гарнизоны белән Казаннан Свияжскига китә.

Алга таба эш шуңа барып җитә: Казан акрынлап, тыныч юл белән рус патшасы хакимлегенә күчә башлый, һәм тугызынчы март идарә итү өчен рус наместнигының шәһәргә керү көне итеп билгеләнә.

Шул көннең иртәгесен рус гаскәрләренең Свияжскидан чыгып Казанга таба юнәлүе фаҗиганең башы була. Моны белеп алган кенәзләр Ислам белән Кибәк һәм морза Аликәй Нарыков ханлыкның иреген һәм бәйсезлеген корал белән сакларга чакыра.

Түнтәрешне оештыручылар шундук вакытлы хөкүмәт төзи, аны кенәз Чапкын Отучев җитәкли, ә тәхеткә моңа кадәр Нугай кенәзлегендә яшәгән Әстерхан ханзадәсе Ядегәрне чакыралар. Казанлыларның бу адымына Ядегәрнең 1550 елда Русь дәүләтендә хезмәттә булган чагында русларның Казанга походында катнашуы да комачауламый хәтта.

Әйтергә кирәк, мөселман дөньясы Казан язмышына битараф калмый – Төркия һәм Дәүләтгәрәйнең Кырым ханлыгы 1552 елның июнендә рус җирләренә басып керә. Тула камалышын өзеп, төрек янычарларын һәм кырымлыларны куып җибәргәннән соң, Иван IV үз гаскәрләрен янә Казанга җибәрә.

Казан, артиллериягә, утлы коралга һәм азык-төлеккә кытлык кичергәнгә, язмышы хәл ителгән булса да, шәһәрне саклауга әзерләнә башлый.

Шәһәр эчендә – утыз мең хәрби, ә тышында – егерме меңнән торган атлы отрядлар һәм Нугай кенәзлегенең ике меңләп җайдагы була.

16 августта шәһәрне саклаучылардан берничә мәртәбә артык булган йөз илле меңлек рус гаскәре соңгы егерме сигез ел эчендә Казанны бишенче тапкыр һәм соңгы тапкыр камап ала.

Шәһәрне саклаучылар үз-үзләрен аямый сугыша, әмма, әйткәнебезчә, аларның саны күпкә аз булганга, 2 октябрьдә соңгы һөҗүмнән соң *«шәһәрдә һәлак булып егылганнарның саны шулкадәр күп иде ки, хәтта бөтен шәһәрдә үлекләрдән гайре аяк басар урын юк иде...» («...побиты во граде толико - множество лежаще яко по всему граду не бо где ступати не на мертвых») (Г.Сабирҗанов)*.

1552 елның 2 октябрендә, 41 көн буе штурмланганнан соң, шәһәр бирелә. Казан ханлыгы Иван Грозный тарафыннан вәхшиләрчә җимерелә һәм талана. Шуннан бирле ханлык мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктый.

Бу вакыйга моңарчы күрелмәгән канлы вәхшәт булып тарихка гына түгел, әдәби әсәрләргә дә кереп кала. Бүгенге көнгә кадәр ул татар халкының төзәлмәс ярасы булып тора.

*Казансуны тутырып татар каны,*
*Мәетләрдән изелеп татар җаны*
*Бөелә-бөелә аккан бер мәлдә,*

*Шәһит киткәннәрнең исемнәре*
*Килер буыннарга күчкән дә*
*Хакыйкатьне гел агартып тора,*
*Хәтерләрне гел яңартып тора*
*Гасырларны узган көннәрдә.*

*Милләт бәйсезлеген сакларга дип,*
*Газиз җиребезне якларга дип,*
*Гарасатның канлы дәһшәтенә*
*Халкы белән кергән Кол Шәриф.*
*Җимерелгән кальга урынында*
*Кырылып яткан яугирләр турында*
*Алтын юллар тезгән чал тарих...*

*(«Кремль диварлары янында»,*
*Ф.Тарханова, 2005)*

Һөҗүм барышында, кайбер риваятьләр буенча, Казанның соңгы ханбикәсе, Нугай ханәкәсе – тиңе булмаган Сөембикә Кремльдәге бүгенге көндә дә аның исемен йөрткән манарадан ташланып һәлак була, имеш.

Әмма тарихка кереп калган башка күп кенә чыганакларда: «1546 елда туган һәм ике яшьлек чагында хан итеп билгеләнгән Үтәмешгәрәй хан 1551 елда тәхеттән төшерелә һәм әнисе Сөембикә ханбикә белән Мәскәүгә озатыла. Бер елдан соң Сөембикәне, аның соравы буенча (?), Шаһгалигә кияүгә бирәләр... Үтәмеш ханны, Казан җиңелгәч, җиде яшендә әнисеннән аерып алалар. 1553 елның 8 гыйнварында Чудово монастыренда чукындыралар һәм Александр дигән исем бирәләр... Әмма Үтәмеш-Александр озак яшәми, 1566 елның 11 июнендә 20 яшендә Мәскәүдә үлә. Ул Кремльдәге Архангель соборында патша нәселе әгъзалары белән янәшә күмелә», – диелә.

*«Яулап алынган Казан халкының вәхшиләрчә җанын кыю рус тарихының иң авыр битләренең берседер.*

*Христоска табынган гаскәрнең казанлыларга каршы «тәре походы», рус дәүләтенең территорияләрне яулап алу юлына беренче чыгуы шуның кадәр дә зур кеше корбаннары гетакомбасы (биниһая күп сандагы кешеләрне алдан ният кылып үтереп бетерү) белән тәмамланды» (М.Худяков).*

Бөтен Рус патшасы, гаять зур шәһәрнең бөтен халкын кырып бетереп, болгар тарихын көлгә әйләндерә, шәһәрнең үзен бетереп талый, мәчетләрне, Хан сараен, Милли китапханәне һәм күп кенә башка архитектура ядкәрләрен җир белән тигезли *(В.Имамов)*.

Моннан тыш, үзенең башка титулларына, икейөзлеләнеп, «...һәм Болгар патшасы» (татарныкы да түгел, хәтта Казанныкы да түгел) дигән титул өсти. Ягъни Мәскәү үзенең монголлар яки татарлар белән түгел, нәкъ менә болгарлар белән сугышуын белеп кенә калмыйча, яшереп тә тормый. Ул гына да түгел: хәзер инде тәхеткә утырту таҗы да болгар-казан чыгышлы булыр...

Казан ханлыгына янәшә дәүләтләр халкын да куркытып торыр өчен рус командованиесе Идел буенча түбәнгә Казанны саклаучыларның тау-тау өелгән мәетләре белән күпләгән саллар агызып җибәрә.

Яулап алынган Казан трофейларының әле исәбенә дә чыгып өлгермәгән Андрей Курбский, зур бер соклану белән, бөтен бу байлыкны бары тик күктәге йолдызлар белән генә чагыштырырга мөмкин, дип язып куя.

Казан җирләрен рус баскыннары, гомумән, бар нәрсә дә эш сөюче, тырыш һәм түзем казанлылар кулы белән ясалган булса да, җирдәге оҗмах дип атыйлар. Рус җирләре үз вакытында салымны Казанга түгел, Алтын Урдага түләгәнгә, Казанга моның бернинди катнашы булмый: шуңа күрә Казан җирендәге бер генә нәрсәгә дә рус дәүләте дәгъва белдерә алмый.

Сарай, Иске Казан, Бөек Болгар шәһәрләре территорияләрендә алып барыла торган археологик казылмалар бар нәрсәнең дә нәкъ менә шул җирдә җитештерелүен, ясалуын, ягъни читтән кертелмәгән булуын раслый.

Бу турыда сугарылма савытларны яндыру мичләренең, җитештерү комплекслары (остаханәләр, домна миче һ.б) калдыклары, шулай ук күпләгән сугарылма керамик, тимурид дип аталган чичикай савытлар, металл, пыяла, балчык, сөяктән ясалган әйберләр һәм башкалар сөйли, алар моңа дәлил.

Монда тәңкәләр дә сугыла – нигездә, көмеш җучи дирһәмнәре. Тәңкә сугу үзәкләре булып утыз ике шәһәр санала, аның дүртесе элекке Идел Болгары, ягъни Казан ханлыгы территориясендә була.

Кызганыч, боларның барысы да тиз арада талана һәм туздырыла.

Җыеп әйткәндә, озаклап каршылык күрсәтелүгә дә карамастан, Мәскәү Русе үзе өчен гаять мөһим һәм зур җиңүгә ирешә. Казан исә, мөстәкыйльлеген югалтып, аның составына керә. Шушы вакыйгалардан соң, Русьның башта Көнчыгышка, аннан Көньяк белән Көнбатышка өермәдәй дулап узган хәрби походлары башлана. Бу хәл XVIII йөздә гаҗәеп зур Россия империясе төзелүенә китерә.

Бу турыда бераз соңрак.

**11. БОЛГАРЛАРНЫҢ РУСЬКА КИТҮЕ**

Мәгълүм булганча, дөньяда этник саф бер генә халык та юк. Халык яки милләтнең сафлыгын эзләү буш кына түгел, хәтта куркыныч эш.

Моңа бәйле рәвештә, инде югарыда телгә алынган тарихи күренеш турында аеруча басым ясап сөйләргә кирәк. Мин төрки телле болгар-казанлыларның әүвәл монголлар ябырылуының беренче елларында баскынчылар әле басып алмаган Руська чыгуын, инде әйтеп кителгәнчә, Казан һәм Мәскәү дәүләтләренең каршылыклы елларында аның тагын да активлашып китүен күздә тотам.

Мәсәлән, 1551 ел башына Мәскәүдә Казаннан туганнары белән бергә киткән биш йөзгә якын кенәз һәм морза яши.

Шул ук елда Сөембикә һәм Шаһгали белән – 70, соңрак янә 84 кенәз һәм морза китә. Аларның варислары алга таба Россиянең иң абруйлы кешеләре була. Бу турыда «саф» рус тарихчылары һәм төрле эшлеклеләр әллә ни җәелеп китәргә теләми, әлбәттә. Алар бу зыялыларның төрки-болгар-кыпчактан чыгуын, ягъни мөселман булуын яшерәләр. Югыйсә боларның барысы да «Бархатная книга», «Общий гербовник дворянских родов Российской Империи» родословные книги, «Писцовая книга Казани» дигән китаплар һәм башка документлар белән рәсми расланган. А.А.Халиков хезмәтләрендә бу турыда тәфсилләп язылган.

Руська китүнең сәбәпләре төрле тарихи чорда төрлечә була.

Мәсәлән, беренче мәлләрдә бу хәл яулап алучыларның бәреп керүенә бәйле булса, соңрак казанлыларга карата Казанның үз хакимиятеннән, шулай ук рус хакимиятеннән килә торган «аерым» шартлар һәм таләпләр белән аңлатыла.

Шулай булса да, элекке төрки феодалларның көнчыгыш һәм көнбатыш рус җирләренә күчеп китүе һәм анда чукынып, православие диненә күчеп, шуңа яраштырып яңа исем-фамилияләр алуы соңыннан байтак күренекле рус фамилиясенә нигез сала. Моны Россия кенәзләре һәм дворяннарының генеологиясе һәм шәҗәрә китаплары, аларның тугралыклары раслый.

Мәсәлән, Абдулловлар (Казан ханы Абдул Латыйфка 1502 елда Кашира җирләре бүлеп бирелә, киләчәктә бу нәселдән танылган дворяннар, галим һәм артистлар чыга); Аксаковлар (төрки сүз «аксак» (хромой) – нәсел башы чынлап та аксак була – Урдадан чыккан бу төркиләргә XV йөздә Клязьма буенда Аксак авылы бүлеп бирелә, аннан соң алар «Новгородка күчерелә»).

Шулай итеп, бүгенге көндә биш йөздән артык (!) атаклы рус һәм Россия фамилияләрен (алфавит буенча): Алябьев (Али бәй), Апраксин, Аракчеевлар («аракчы»), Ахматовлар, Байбаковлар, Баскаковлар, Басмановлар, Бахметьевлар, Бердяевлар, Болгарскийлар, Булгаковлар, Булгариннар, Буниннар, Бухариннар һәм үзләренең нәсел башы Болгар-Казан мохитеннән чыккан башка бик күп фамилияләрне атап булыр иде.

Алар исәбендә инде телгә алынган Н.М.Карамзин – язучы, шагыйрь һәм тарихчы (нәсел башы – Кара Морза); А.П.Ермолов – рус генералы, 1812 ел герое һәм М.Н.Ермолова – танылган актриса (бу турыда дворяннар нәселенең гомуми тугралыгында болай диелә: «Ермоловларның ерак бабасы Арслан морза Ермола (чукындырылганда Иоанн исеме кушыла) 1506 елда Урдадан бөек кенәз Василий Ивановичка килә»); Е.Дашкова – Россия Фәннәр академиясе президенты; бөек Г.Р.Державин; композиторлар С.В.Рахманинов (казанлы Мирали Рахманинов нәселеннән) һәм Римский-Корсаков («карсак» – кечкенә буйлы дигән сүз); язучы И.С.Тургенев (нәсел башы – якынча 1440 елда Урдадан чыгып киткән Турген Арслан морза, «турген» – җитез, кыю дигәнне аңлата); акыл иясе П.Я.Чаадаев һәм башка бик күпләр, хакимият вәкилләре аларны бөек руслар дип атаса да, төркиләрдән, Казан татарларыннан чыккан.

Мәсәлән, кыпчак морзасының нәсел тармагы, шагыйрь, күренекле рус вельможасы (зур түрәсе) һәм А.С.Пушкинның укытучысы Г.Р.Державин үзенең «тирән рус тамырларын» яшермичә мондый сүзләр яза:

Мин җырладым, җырлыйм һәм җырлармын,  
Шаян сүзгә кушып чынбарлыкны.  
Онытылып яткан татар җырын,  
Якты нурдай сибеп, яшь буынга  
Җиткерермен, раслап моң барлыкны.

(«Я пел, пою и петь их буду,  
И в шутках правду возвещу.  
Татарские песни из-под спуду,  
Как луч, потомству сообщу».)

Боларның барысы да яки нәкъ менә шулар рус һәм башка көнчыгыш славян телләренә инде гомумкабул ителгән төрки-болгар-кыпчак сүзләренең һәм алынмаларның үтеп керүенә ярдәм итә.

Мәсәлән: сабля, хоругвь, телега, япанча, алтын, безмен (бизмән), басма, арба, шарвар (шаравар), булат, кирпич (кирпеч), чугун (чуен), таможня (тамга(ханә) һәм башкалар шундыйлардан.

Ә менә элек төрки-кыпчак исемнәрен йөрткән, тора-бара трансформацияләнгән (үзгәргән) шәһәр һәм урын-төш исемнәре: Тумень – Төмән (ун мең дигәнне аңлата; хәзер – русча Тюмень); Кияб – Кияү (Киев); Тары су (елганың тараеп киткән урыны – тар су) – Таруса; Сары тау – Саратов; Тула (тулы); Төмән Тархан – Таматарха – Тмутаракань; Хаҗи Тархан – Әстерхан – Астрахань; Кипензай – Пенза; Буруninеж – Воронеж; Челяба – Чиләбе – Челябинск; Кашира һәм башкалар.

Тел белгечләре көнчыгыш славян телләренә аерым бер үзенчәлек керткән мондый алынмаларны биш йөз тирәсе дип билгелиләр.

Алга таба күбесенчә казанлылар һәм аларга якын мишәрләрдән Россиянең рус дәүләтендә хезмәт итүче йомышлылар катлавы, ягъни өч йөзгә якын төрки фамилияле йомышлы дворяннар катлавы барлыкка килә. Алар арасыннан Адашевларны, Еникеев, Мамонов, Турчанинов, Салтыковларны һәм башка бик күпләрне күрсәтергә була.

Шул заманнарда ук аларны, рус һәм төрки телләрне камил белгәнгә, Россиянең дипломатик һәм хәрби-фискаль хезмәтендә актив файдаланалар.

XV–XVI йөзләрдә Россия илчеләре булып Кырымда – Бикләмешевлар; Италиядә – Карачаровлар; Польша белән Литвада – Бәхтияровлар; Польшада, Дания һәм Стокгольмда – Шәрәфетдиновлар; Англиядә, Голландия, Кырым һәм Төркиядә – Агишевлар; Персиядә Бохаровлар, Шараповлар h.б. хезмәт итәләр *(А.Х.Халиков, М.Аджи)*.

Шул ук вакытта Россиядә хезмәттә булган һәр казанлы да үз халкында әйбәт фикер калдыра дип әйтеп булмый.

Мәсәлән, чукындырылганнан соң Алексей Тәвкилев (Тевкелев) булган Котлымөхәммәт Мәмәш мирза XVIII йөзнең беренче яртысында Россиянең колониальләштерү сәясәтендә гаять актив эшчәнлек күрсәтә.

Нәкъ менә ул, әүвәл Россия илчесе буларак, Казахның Кече жуз ханы Әбелхәердән (1730) Россиягә тугрылык антын алып, аның белән бергә Ор елгасында – казах-башкорт күчмә халыклары арасындагы чиктә Оренбург шәһәр-кальгасын төзү, Җаек елгасын куәтле кирмәннәр һәм гарнизоннар белән ныгыту, мөселман старшиналары арасында ришвәтчелек һәм дошманлык тарату һәм аларны шул юл белән хөкүмәт ягына аудару, төрки-татар авылларына рус авылларын күчереп утырту һәм бу урыннарда заводлар төзү инициаторларының берсе була. Аннары ул үз халкына каршы оештырылган җәза отрядларында да актив катнаша *(В.Имамов)*.

Бу эшләр соңрак булганга, әлегә рус гаскәрләренең Казан дәүләтенә басып керүе һәм аны җимерүе чорына әйләнеп кайтыйк.

## 12. МӘСКӘҮ КРЕМЛЕ СУГЫШЛАРЫ<br>ҺӘМ ТЕРРИТОРИЯЛӘРНЕ ЯУЛАП АЛУ

Россия тарихы – беренче чиратта, төп максаты территорияләрне һәм сәяси яулап алу булган баскынчы сугышлары тарихы.

Аңлашыла ки, «Россиянең галим ирләре» безгә Русьның агрессияне кире кайтару сугышлары турында гына сөйли. Андый сугышлар тарихта күп түгел, аларны хәтердән дә санап чыгып була: бәҗәнәк һәм «башсыз» хәзәрләрнең һөҗүм итүе, тәре походлары һәм Чуд күле, монголлар ябырылуы һәм аларның аңлашылмый торган «золымы», Наполеон җитәкчелегендәге француз армиясенең басып керүе һәм фашистлар Германиясенең һөҗүме.

Әмма үзе агрессор, оккупант һәм яулап алучы булган сугышлар турында матур итеп кенә дәшми калына яки «башка җирләрне Россиягә кушуның алдынгы (прогрессив) әһәмияте турында» дигән теория аша гына тар карашлы, башлары бер генә юнәлештә эшли торган мәгънәсез бәндәләргә ирештерелә. Моңа ничек һәм ни белән ирешелгән, яулап алынган халыкларга әлеге «кушу» чынлыкта нәрсә бирде – прогрессмы яки регрессмы (алгарышмы әллә артка чигенүме) – боларның барысы да читтә кала.

Беренче бөтендөнья сугышы һәм 1917–1918 еллар нәтиҗәләре Польша, Финляндия, Литва, Латвия һәм Эстониягә Советлар Россиясеннән бәйсезлек алу мөмкинлеге бирә.

Әмма Икенче бөтендөнья сугышы башлану совет империясенең географик йөзен яңадан үзгәртеп куя.

1940 елда фин сугышыннан соң, Виннури шәһәре (Выборг) һәм Карелиянең бер өлеше СССРга күчә; Риббентроп – Молотов яки Гитлер – Сталин пактыннан соң Литва, Латвия һәм Эстония яңадан яулап алына, тик бу юлы Кызыл Армия тарафыннан; фашистлар Германиясе белән яңа килешү – Көнбатыш Украина, Көнбатыш Белоруссия, аннан соң Буковина белән Бессарабия Россиягә күчә.

Әле Сталин хөкүмәте, территорияләрне оккупацияләп (басып алып) һәм кушып кына калмыйча, җирле, төп халыкны үз җиреннән куып чыгара, ягъни халыкны физик яктан юк итү белән бергә көчләп күчерүгә дучар итә.

Мәсәлән, 1937 елда Ерак Көнчыгыштагы Приморьеда Корея халкын депортацияли. 1940 елда Балтыйк буе, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссиянең «азат ителгән» өлкәләре халыкларын сайлап алып депортацияли; 1941 елда Идел буе немецларын, аларның дәүләтчелеген бетереп, соңгы кешесенә кадәр депортацияли, шундый фаҗигагә калмык халкы да дучар була; 1944 елда Кавказ һәм Кавказ артының барлык мөселман халкын тулаем һәм Кырым татарларын тоталь депортацияли.

Сүз дә юк, элекке СССР җитәкчелегенең һәм барлык халкының Европаны Германия фашизмыннан азат итүдә роле искиткеч зур һәм бәһасез. Әмма аңа нинди сәбәпләр китергәнен, сугыш алдыннан гына ниләр булганын белгәч, шундый нәтиҗәгә киләсең: вагыйгалар үзләре беренче чиратта үзен генә кайгыртучы һәм яклаучы Мәскәүне бары тик соңыннан гына әлеге миссияне үтәргә мәҗбүр итә.

Икенче бөтендөнья сугышында җиңү һәм аның тәмамлануы 1945 елда РСФСРга яңа территорияләр – Кенингсберг шәһәре белән Көнчыгыш Пруссиянең бер өлешен, Көньяк Сахалин һәм Куриль тезмәсенең дүрт утравын кушарга мөмкинлек бирә *(А.Закиров)*.

1953 һәм 1968 елларда совет гаскәрләренең Венгрия һәм Чехословакиягә бәреп керүе; 1979–1989 елларда совет гаскәрләренең Әфганстанга һөҗүм итүе һәм әллә ничә мең тыныч халыкның, Хрущев һәм Брежнев Кремле сәясәте тоткыннары – совет солдатларының гомерен өзгән ун елга сузылган сугыш.

Горбачевның үзгәртеп кору дип аталган чорында үз милли чикләрендәге хәлләрне тикшерүдә тоту мөмкинлеге булмау аркасында бөтен бу зур империя шартлап ярыла башлый, рәсми Мәскәү яңадан армиясен файдалана – Алма-Ата, Тбилиси, Вильнюста бернинди гаебе булмаган тыныч тормышта яшәүче халык яңадан һәлакәткә дучар ителә.

Милләтләр арасында башланып киткән һәм әле кичә генә тугандаш республикалар арасында урыны-урыны белән чын-чынлап сугышка әйләнгән канлы бәрелешләр һәм үтерешләр нәтиҗәсендә илдәге хәлләр Кремль күзәтүеннән тулысынча ычкына.

Нәтиҗәдә бу чор өчен гадәти хәл туа – СССР таркала. Шулай итеп, элек СССР составында булган 14 союздаш республика кан түкмичә генә, сугышсыз-орышсыз Мәскәү бәйлелегеннән котыла.

Шулай да унбишенчесе – РСФСР – бары Россия Федерациясе генә булып калып, элекке Россия империясе, элекке Советлар Союзының тулы хокукый варисына әйләнә, һәм, дүрт ел да узып өлгерми, аның беренче президенты Б.Н.Ельцин Чечня җиренә бәреп тә керә һәм чечен халкы белән чираттагы сугышны башлап та җибәрә.

Шунда туктап торып, 1552 елда Мәскәү Кремленең оккупацион һәм территориаль яулап алу омтылышлары раслануының башлангыч чорына әйләнеп кайтыйк.

## 13. ИДЕЛ-УРАЛ – РУСЬ, РОССИЯ ҺӘМ СОВЕТ ХАКИМИЯТЕНЕҢ КОЛОНИАЛЬ РЕЖИМЫНА КАРШЫ КӨРӘШТӘ

Безнең халыкның азатлык өчен көрәше алдагы өч гасыр ярым дәвамында, биредә совет властен урнаштырганчыга кадәр дәвам итә.

Казан татарларының һәм Идел буенда яшәүче башка халыкларның Россиянең колониаль режимына каршы көрәшен вакыйгалар һәм фактларның түбәндәге кыскача хроникасы раслый.

1552 елның октябре – Иван (IV) Грозный яулап алган төбәкнең башына наместник (идарәче) килеп утыра. Казан халкының кырылудан сакланып калган бер өлеше шәһәрдән куыла, зур вәкаләтләр бирелгән епископ Гурий җитәкләгән епархия булдырыла.

Ә Мәскәүдә Казанны яулап алу хөрмәтенә үрнәге урта гасыр Казанының баш мәчете – ак таштан гына өелгән, сигез манаралы, кисеп эшләнгән болгар ташлары белән бизәлгән, җимерелеп, урынына Благовещение соборы салынган гаять зур корылма – Кол Шәриф мәчетеннән алынган Василий Блаженный соборы төзелә.

*«Василий Блаженный соборының көнчыгыш гөмбәзләре белән капланган сигез каланчасы Кол Шәриф мәчетенең сигез манарасына турыдан-туры охшашлыгын күрсәтә» (М.Худяков)*.

Өстәвенә ике собор да – Казандагысы да, Мәскәүдәгесе дә – бер үк архитектор Постник Яковлев тарафыннан салына. Бу рус дәүләтенең бөтен тарихы дәвамында иң мөһим җиңүе булганга, моңа аеруча зур әһәмият бирелә.

Казанлыларның үзләренә шәһәрдән чыгып китәргә боерыла. Аларга якын-тирә авылларда гына яшәргә рөхсәт ителә. 1557 елда шәһәрдә элекке кырык мең кеше урынына бары тик Көрәеш бистәсендә генә яшәүче алты мең татар гына кала. Йөз елдан соң сәяхәтче Адам Олеарий, шәһәрдә бары тик руслар гына яши, дип яза.

Казан җиңелгәч, Идел-Чулман төбәгендә яшәүче халыкны көчләп чукындыру башлана.

Ислам гомумән тыела. Ислам динендә булганнарга аерым бер рухи һәм физик авырлык – икеләтә салым, хәрби хезмәт һәм бернинди хокукның да булмавы йөкләнә.

Моңа җавап итеп, 1553 елның башында ук Казаннан унбиш чакрым ераклыкта, Биектау төбәгендә, Япанчы кенәзнең атлы отрядының исән калган сугышчыларыннан хәрби ополчение төзелә һәм ул русларның ике отрядын тар-мар итүгә ирешә.

Тау ягында Җансәет һәм Сарый батыр җитәкчелегендәге отряд русларның бояр Б.Салтыков туплаган дүрт йөз кешелек җәза отрядын туздыра.

Шуннан соң Казан хакимнәренең берсе Мәмәш Берды җитәкләгән баш күтәрүчеләр, Чалым кальгасында үз ставкасын оештырып, Идел буе татарларының дәүләтчелеген торгызырга ниятлиләр һәм хан итеп Сөембикә ханбикәнең туганы Али Әкрәм морзаны чакыралар.

Али Әкрәм Нугай кенәзлеге башкаласы Сарайчыктан Казан ханлыгының вакытлыча башкаласы Чалымга өч йөз сугышчысы белән килеп җитә.

Нугай морзасы Йосыфның Әстерхан ханы белән бергә сугышка керү һәм Казанлыларга ярдәм итү нияте Мәскәү ягына авышкан нугай феодаллары – аксөякләре аркасында бу юлы да тормышка ашмый кала.

Иван (IV) Грозный, үз чиратында, А.Адашев җитәкчелегендәге баскынчы яңа отрядларын җибәреп, казанлылар, чуаш, мариларга каршы оештырылган коточкыч террор белән бу төбәкне буйсындырырга керешә.

1553 елның ахырына рус армиясе халыкны тәгаен кырып бетерү, тормышның икътисади нигезен җимерү, Казан татарларының тарихи һәм мәдәни үзәкләрен юк итү өчен аяусыз сугыш алып бара.

*«Рус отрядлары илне рәхимсез таладылар. Алар, юлларындагы бар нәрсәне җимереп, авылларны яндырып, мал-мөлкәтне тартып алып, халыкны әсир итеп, авылдан авылга йөрделәр...» (М.Худяков).*

Бары бер поход барышында гына да Казан татарларыннан алты меңгә якын ир-егет, унбиш меңләп хатын-кыз һәм бала-чага әсир ителә.

Нәтиҗәдә 1554 елның җәендә Руська каршы сугыш ханлыкның бөтен территориясенә тарала. Кенәз И.Мстиславскийның махсус хәрби формированиеләренең бу төбәктә яшәүче җирле халыкны рәхимсез бастыруына һәм кыруына да карамастан, Мәмәш Берды белән Али Әкрәм ханның Чалым кальгасындагы ставкасы таралмый.

Алдагы 1555 елда җәза отрядлары терроры белән, янгыннар, талау-туздыру нәтиҗәсендә җирле халык, нигездә, җиңелә, бастырыла.

1556 елның язында Мәмәш Берды белән Али Әкрәм баскынчыларга каршы восстание күтәрә. Әмма апрельдә Чалым шәһәре бирелә, Казан ханлыгының иң соңгы ханы Али Әкрәм белән бергә баш күтәрүчеләрнең ике меңлек гаскәре тар-мар ителә. Мәмәш Берды Мәскәүдә җәзалап үтерелә.

Икенче җәза экспедициясе Арча һәм Чулман ягы ир-егетләрен кырып бетерә, хатын-кызлар һәм балалар әсир ителә.

Шулай итеп, бу төбәк бастырыла һәм буйсындырыла.

1557 елда Казан Русь дәүләтенә тулысынча кушыла, шуннан соң Русь хөкүмәте ханлыкны яулап алуда катнашканнарга, чиркәү, монастырьларга Казан җирләрен бүлеп бирә башлый. М.Худяков язганча, «төбәккә Русь җирләреннән күчеп килүчеләр ташкыны агылды».

Алдагы 1572–1573, 1582–1584, 1592–1593 елларда каршылык күрсәтү яңадан кабынып китә, шулай булса да, беренче елларындагы кебек көч ала алмый. Өстәвенә шул ук елларда патша Федор Ивановичның татарларны көчләп чукындыру, чиркәү һәм монастырьлар төзү, чукынган һәм чукынмаган болгар-казанлыларны аерым урыннарга күчереп утырту, барлык мәчет-мәдрәсәләрне җимереп бетерү турында указы чыга: *«татар мәчетләрен исә бөтенесен дә җимереп, себереп түгәргә һәм татарларга үзләренә мәчетләр салмаска...»* – диелә анда.

Бу акциядән соң Казаннан илле чакрым ераклыкта булган тирәләрдә бер генә татар авылы да калмый.

1612 ел. Русьта Ялган Дмитрийга бәйле болганчык еллар булуыннан файдаланып, болгар-казанлылар поляклар белән элемтәгә керә һәм Казанның бәйсезлеген кире кайтара. Әмма Ялган Дмитрийның җиңелүе Казанның җиңелүенә китерә.

1615 ел. Еналиев восстаниесе. Сәбәбе – «читләр» («инородец») дип йөртелгән халык өчен акчалата салым кертү, йомышлы Казан татарларын хәрби хезмәткә алу һәм аларның иң яхшы җир кишәрлекләрен тартып алу.

1628 һәм 1648 елларда махсус указлар чыга. Алар нигезендә мөселман морзаларына крепостной христианнар тоту тыела, шул ук вакытта чукынган казанлы алпавытларга крепостной христианнары белән биләмәләре калдырыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Мәскәүгә нәкъ менә бу указлар Казанга карата тактикасын бераз үзгәртергә мөмкинлек бирә: үз ягына татар морзаларын, кенәзләрен аударып, аларга көнчыгышка кагылышлы бөтен эшләрне алып бару йөкләнә, хәтта Казан татарларыннан булган генераллар Польша, Литва белән сугышта рус гаскәрләре белән җитәкчелек итә.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: төрки-татар фамилияле күпсанлы боярлар менә бу указлар чыкканнан соң барлыкка килә башлый.

1650–1658 еллар. Русь крепостьларыннан Чулман аръягы ныгытма линияләре төзелә.

1682 ел. Сәет Җәгъфаров җитәкчелегендә Казан, Минзәлә, Уфа, Көнгер һәм башка воеводстволарда чираттагы восстание.

Идел буенда яшәүче бөтен халык диярлек Степан Разин восстаниесендә катнаша.

1672 һәм 1694 еллар. Казанда чыккан көчле ике янгын мөселманнар кулы белән төзелгән шәһәрне көл итә, аның милли үзенчәлеге юкка чыга.

XVIII йөз башында моңа кадәр Казан ханлыгы дип аталган бу төбәк император Петр I тарафыннан губернага әйләндерелә, нәтиҗәдә ул мөстәкыйльлекнең хәтта шәүләсен дә югалта.

Крестьяннардан салым алуны тагын да арттыруга җавап итеп, Казан татарлары һәм башкортларның сигез елга сузылган Алдар Күчем восстаниесе кабынып китә, аннары Илмәк абзый восстаниесе (1735) һәм Кара Сакал восстаниесе (1739) була. Алар шулай ук рәхимсез бастырыла.

Тарихчы П.Рычков фикеренчә, 1735–1737 еллардагы Акай Килмәк восстаниесе вакытында Казан губернасында 696 авыл яндырыла, 16893 кеше үтерелә яки җәзалап үтерелә, 3406 кеше сөргенгә сөрелә, Казан татарларының 9194 хатын-кызы һәм баласы русларга коллыкка бирелә, штраф сыйфатында 17154 баш терлек тартып алына.

Мөселманнарны эзәрлекләү һәм кысрыклау артык көчәеп киткән заманда Яңа чукындырылганнар конторасы гамәлләре вакытында шулай ук авыр көннәр башлана.

Мәсәлән, 1742 елда бары тик Казан өязендә генә дә 546 мәчетнең 418е җимерелә, оброкны (имана салымы) да чукынган татарлардан чукынмаганнарына күчерү гадәте кереп китә, мөселман балалары православие рухында тәрбияләү өчен тартып алына, төрки-татарларга тимерчелек-слесарьлык эшләре белән шөгыльләнү тыела һ.б.

1774 ел. Казан татарлары, башкорт һәм чуашлар, Емельян Пугачевка кушылып, бердәм көч белән Казанны яулап алалар.

Бу восстание шулай ук бастырылса да, мөселманнарның анда актив катнашуы Екатерина II не рус булмаган халыкларга карата сәясәтен үзгәртергә мәҗбүр итә.

Шуннан соң хакимиятләр тарафыннан мөселманнарга дин тоту рөхсәт ителә, руслар басып алганнан соң беренче мәртәбә Казанда мәчет төзелә, шәһәргә Төркестан, Кытай һәм Персия белән сәүдә итү, сәнәгать белән шөгыльләнү хокукы бирелә.

Бу чаралардан соң гына төбәктә сәүдә һәм сәнәгатьнең интенсив үсеше белән тасвирланучы чагыштырмача сәяси тотрыклылык урнаша.

XX йөз башында гына, 1905 елгы инкыйлабтан соң, Казан татарларында үз газетларын, журналларын бастырып чыгару мөмкинлеге туа. Бу исә, үз чиратында, җирле халыкның идея омтылышларына бәйле алдынгы эшенең – китап басу эшенең барлыкка килүенә ярдәм итә.

Нәтиҗәдә бастырып чыгарылган әдәбият саны буенча Казан татарлары тиз арада бөтен Россиядә беренче урынга чыга.

Моңа кадәр вакытлы матбугат ролен альманахлар уйнаса, хәзер исә даими нәшер итү эшчәнлеге Казан татарларының рухи һәм интеллектуаль дөньясын үзгәртә. Кайбер китапларның тиражы 2 млн. данәгә җитә.

XX йөз башында милли сәнәгать һәм сәүдә үсеше нык көчәеп китә, һәм инде бу төбәк Россия икътисадында күренекле урын били.

XIX–XX йөзләр кисешендә Казанда һәм татарлар яшәгән башка эре үзәкләрдә – Мәскәү, Уфа, Петербург, Әстерхан, Сембер (Ульяновск), Оренбург, Уральск, Троицк шәһәрләрендә милли яңарыш процессы башлана.

Татар телендә дистәләрчә, йөзләрчә газет-журналлар дөнья күрә, яңа музыка һәм театр сәнгате барлыкка килә.

Шуны да әйтергә кирәк, Казан-татар әдәбиятына нигез бик борынгы заманнарда ук салына, һәм Казан татарларының белем дәрәҗәсе бик югары була, чөнки башлангыч мәктәпләр һәр авылда оештырыла. Ә югары белем бирүче татар мәктәбе – мәдрәсә дини белем генә түгел, дөньяви фәннәрнең бөтен спектрын да бирә.

Бу урында бераз узган тарихка борылып карыйк.

Идел буе болгар-татарларында иске төрки әдәби тел, X–XIV йөзләрдә инде формалашкан булып, бу телдә язылган әсәрләр дә дөнья күрә башлый. Рус язма әдәбиятыннан 200 ел элек, XIII йөз башында, 1183 еллар тирәсендә Идел буе төбәгендә туган, уналты-унҗиде яшьләренә кадәр мәдрәсәдә укыган, -аннан белем эстәп Шәрык илләренә китеп, шагыйрьләр, галимнәр белән аралашкан, хаким шәехләрнең, суфиларның лекциясен тыңлаган, күп еллардан соң үз туган иле Болгарга кайтып, үзе дә мөдәррислек иткән һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, Болгарда монгол яулары вакытында һәлак булган Кол Галинең XIII йөз башында язылган «Кыйссаи Йосыф» («Кысса-и-Йусуф») поэмасы татар халкының

язма әдәби һәм авыз иҗаты мирасында ныклы урын алып тора. Менә инде сигез йөз елдан артык вакыт дәвамында татар халкының рухиэстетик дөньясына даими тәэсир итеп килә.

XV йөздә Казан ханлыгында иске татар әдәби теле барлыкка килгәнче, иске төрки әдәби телдә байтак әсәр язылa. Мәсәлән, Сәйф Сараиның «Гөлстан бит төрки»е, Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Котбинең «Хөсрәү вә Ширин»е һ.б. әсәрләр дөнья күрә. «Иске татар әдәби теле болгар-татарлар арасында гына түгел, хәтта башкорт һәм казахларның элгәрләре тарафыннан да актив кулланыла» *(Н.А.Баскаков, 1973)*.

Алай гына да түгел, аны Русь хөкүмәте Көнчыгыш илләр белән мөнәсәбәтләрне ныгыту өчен дипломатик аралашу коралы итеп тота. Шуңа күрә ул чиновниклар әзерли торган рус мәктәпләрендә, хәтта югары уку йортларында XVII йөздән үк укытыла башлый...

Иске татар әдәби теленең иң ачык үрнәкләрен без Мөхәммәдьярның «Төхвә-и Мәрдән», «Нуры Содур» (XVI йөз), Мәүлә Колый (XVII йөз), Утыз Имәни (XVIII йөз), Гали Чокрый (XIX йөз) әсәрләрендә таба алабыз.

Немец галиме Отто Гётч язганча, «1910 елда аларның (татар-мөселманнарның) меңнән артык басма китабы, йөздән артык язучысы, алты югары, биш мең түбән мәктәбе була. Казан татарларында йөз илле кешегә бер мәчет, бер мулла булса, шундагы ук русларда һәм башка христиан халыкларда бер мең биш йөз кешегә бер священник туры килә. Татарларда йөз ир һәм кыз балага бер мәктәп, христианнарда исә бер мең биш йөз-өч мең кешегә бер мәктәп (приходская школа) туры килә. Китаплар һәм газеталар чыгару һәм тарату буенча татар-мөселманнар христианнардан тагын да алга киткән. (В.И.Ленин, т.28, 513–515 б.). Бу өзеккә янә шуны да өстәп әйтергә кирәк: ул чорда дәүләт хисабына бары рус мәктәпләре генә эшли, татар мәктәп-мәдрәсәләре татарның үз шәхси байлыгына гына нигезләнә *(М.З.Зәкиев)*.

Инде өзелгән сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. 1905–1917 еллар арасында татар газеталары, журналлары күпләп чыга башлый, дидек.

Бу чорда алар татарлар тупланып яшәгән Петербург, Мәскәү, Казан, Уфа, Сембер, Самара, Оренбург, Әстерхан, Уральск, Екатеринбург, Троицк, Томск, Төмән, Семипалатинск һәм Ташкент шәһәрләрендә басыла. Октябрь революциясеннән соң моңа Омск, Новосибирск, Эстәрлетамак, Златоуст, Алма-Ата, Бохара, Орск, Пермь, Березники, Харьков, Богорыслан, Макеевка, Пенза, Донецк, Петропавловск һәм Түбән Новгород шәһәрләре дә өстәлә.

Нәтиҗәдә татар язучылары, шагыйрьләре, журналист, тарихчы, композитор, музыкантларның талантлы буыны үсеп чыга. Үз вакытында күренекле мәгърифәтчеләр булган Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдин, Садри Максуди һәм шундый бик күпләргә алмашка Дәрдемәнд, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Һади Такташ, Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Фәрит Яруллин, Сәгыйть Рәмиев һәм тагын бик күп әдәбият һәм сәнгать әһелләре килә.

Революция алдыннан дистәләгән газет-журналлар чыгып кына калмыйча, төрле сәяси оешмалар да барлыкка килә; татарлар мөселман съездларын оештыру инициаторлары булалар, ә Садри Максуди Икенче Дәүләт Думасында һәм аннан соңгы Дәүләт Думаларында мөселман фракциясен җитәкли.

1916 елда Йосыф Акчура Лозанна конгрессында төрки халыклар мәнфәгатен яклый.

1917 елның февраль инкыйлабы (революциясе) милли хәрәкәттәге хәлләрне, беренче урынга дәүләтнең үзбилгеләнүен чыгарып, кискен үзгәртә.

1917 елның 1 маенда Мәскәүгә чакырылган Бөтенроссия мөселманнары съезды «Россия федератив-демократик республика булырга тиеш» дигән карар чыгара.

1917 елның Октябреннән соң татарларның үз дәүләтен төзүнең берничә варианты туа.

Элекке Казан, Уфа һәм Оренбург губерналары территориясендә Идел-Урал дигән бәйсез штат төзү варианты алар арасында үзәк вариант була. Бу вариантны күтәреп чыгучылар – Садри Максуди һәм Гаяз Исхакый.

1917 ел ахыры – 1918 ел башында Уфада Милли Мәҗлес алты департамент составында Урал-Идел буе штатын һәм Милли администрациясен төзү турында игълан итә. Бу идеяне шулай ук башкортлар, чуашлар, марилар һәм бу төбәктә яшәүче башка халыклар да хуплый.

Әмма большевикларның Ленин хөкүмәте, лидерларны кулга алып, милли хәрәкәтне тарата, типографияне конфискацияли.

Шул ук вакытта Мулланур Вахитов белән Мирсәет Солтангалиев Идел-Урал штаты чикләренә туры килгән территориядә Татар-Башкорт республикасы төзергә омтылыш ясый.

Тик ни теге, ни бу вариант Советлар басымы аркасында гамәлгә ашмый кала.

Шуның өстенә милли хәрәкәт лидерлары арасында да бердәмлек булмый.

Нәтиҗәдә Зәки Вәлидов (Вәлиди), Совет Россиясе белән килешү төзеп, Кече Башкирия төзүне башлап җибәрә.

Озак та үтми, картада территориясе һәм хокуклары нык кечерәйтелгән вариантта автономияле Татарстан Республикасы пәйда була. Кремль башкага рөхсәт итми, милли мәсьәлә сыйнфый мәсьәләгә буйсындырыла.

Сталинның республикаларны сортларга, автономияле һәм союздаш республикаларга бүлгәләвенә каршы чыккан М.Солтангалиев соңрак НКВД төрмәләрендә черетелә, ә М.Вахитов ак чехлар тарафыннан үтерелә.

Башка лидерлар – Гаяз Исхакый, Йосыф Акчура, Садри Максуди, шулай ук бердәм милли фронтны таркаткан Зәки Вәлиди – Төркиягә китәргә мәҗбүр булалар.

Казанның беренчеләрдән булып тарихны чынбарлыкта булганча ачып биргән күренекле тарихчысы М.Худяков 1936 елда Ленинград НКВДсы төрмәсендә атып үтерелә.

Академиклар В.Бартольд, М.Покровский, тарихчы һәм археолог М.Артамонов һәм аның укучысы, күренекле Л.Гумилев үзләре исән чагында рәсми танылу тапмый.

Сталин чорының озакка сузылган трагедиясе, фаҗигасе, аерым алганда, милли төркемнәрне дискриминацияләү, Казан татарларының һәр гаиләсенә килеп кагыла. Бу котычкыч еллар әлеге империянең күпләгән халкы, бигрәк тә аз санлы халыклары җанында мәңге төзәлмәс яра, эзләр калдыра...

Ә инде алга таба Совет власте заманында республика хакимиятләре тарафыннан хокуклар һәм статус турындагы мәсьәләгә кире кайтуга бернинди омтылыш ясалмый, хәтта читләтеп кенә булса да бу мәсьәлә күтәрелми. Мәскәү җитәкчелеген мондый «телсезлек» канәгатьләндерә, билгеле.

Рус дворян монархиясе һәм православие чиркәвенең бүленмәс хакимлеге чорында, аннан соң бу төбәкнең җирле, төп халкын руслаштыру сәясәте һәм милләтләрне изүне планлаштырып гамәлгә ашыру чорында Россия империясе составында өч йөз илле еллап көн иткән Казан татарлары үзләренең телен, динен, мәдәниятен, этнопсихологиясен, гадәт-йолаларын, үзенчәлеген, империянең аз санлы башка халыкларының гомуми массасында эреп таркалмыйча, үзен халык буларак та саклап кына калмый, ә бәлки, Европа һәм Азиянең башка дәүләтләре мәдәниятләре белән үзара хезмәттәшлеген, багланышын да дәвам итә.

Һәм, ниһаять, 1990 елның 30 августында «Дәүләт суверенитеты турында декларация» кабул ителгәннән соң, Казан татар халкының яңарыш чоры башлана. Сайлап алынган юлның дөреслеген 1992 елның 21 мартында Республикада үткәрелгән бөтенхалык референдумы раслый.

Монда шуны да танымый мөмкин түгел, СССР таркалганнан соң үзеннән-үзе бәйсезлек алган элекке союздаш республикалардан аермалы буларак, Татарстан өчен бу чын-чынлап дәүләт бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлегенә юлның башы гына иде әле.

Анда безне ни көтә һәм бу юл кая алып чыгар?..

Бу инде – хәзерге көн вакыйгалары.

Яңадан икенче меңьеллык уртасына әйләнеп кайтыйк.

**14. ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫНЫҢ ЮККА ЧЫГУЫ**

Урта гасыр вакыйгаларына кире кайтсак, ул чорның Европа карталарында (мин алар белән Германиядә таныштым), Франция, Швеция, Польша корольлекләре, Литва һәм Мәскәү кенәзлекләре, Новгород республикасы, Алтын Урда ханлыгы белән беррәттән, үзәге Казан шәһәре булган REICH der BULGARENның (Болгар империясе яки ханлыгының) да күрсәтелүенә игътибар итәргә кирәк («1400 елга кадәр урта гасыр Европасы картасы»).

Монгол басып алуларыннан соң, ул еллардагы башка Европа дәүләтләре кебек үк, шактый мөстәкыйль яшәүче Мәскәү, Алтын Урда һәм Болгар дәүләте дә аерым һәм аерып күрсәтелгән.

Аннары шул ук Европа карталарында әле XVI йөз башларында да Казан җирләре элеккечә «Bulgaria Magna» яки Бөек Болгар иле дип атала.

1657 елның Европа картасында шактый соңрак, ягъни инде XVII йөз уртасында, шулай ук аерып «CAZAN REGION. BULGARIA», «RUSSIA», «MOSKOVIA» күрсәтелә, ә монгол-татар җирләре «TARTARIA PAPS» дип билгеләнә.

Шул ук вакытта совет чорының тарихи карталарында һәм дәреслекләрендә сез Иделдә, ягъни хәзерге Россиянең үзәгендә Болгар иле (Булгария) дигән дәүләтне тапмассыз.

Алай-болай кайда да булса күзегезгә чалынса да, аның кайдан монда барлыкка килгәнен, аннан кая киткәнен һич аңлый алмассыз. Бары тик махсус энциклопедик әдәбиятта гына мәгълүмат таба алырсыз, анда да кыска һәм өлешчә мәгълүматны гына.

Бүгенге көнгә кадәр Мәскәүдә чыга торган матур әдәбиятта һәм кинофильмнарда Казан татарлары һәм аларның меңьеллык тарихы, мәдәнияте һәм мәгърифәте элеккечә үк нык бозылып, ә кешеләре вәхшиләр итеп күрсәтелә.

Шактый алга киткән, үз вакыты өчен цивилизацияле булган һәм үсеш алган бу дәүләт һәм аның төп халкы, ягъни болгарлар кая киткән соң? Ә бит аларның барлык күршеләре, болгарлардан аермалы буларак, дәүләтчелеге дә булмаганнары, язмыш талкуына – бетмәс эчке низаглар, сугышлар, талау,

үтерешләр, үләт һәм басып алу, җимерүләргә дә карамастан, бүгенге көндә дә уңышлы гына чәчәк атып утыра. Әйтик, шул ук руслар, башкорт, чуаш, мордва, коми, фин, венгрлар һәм башкалар...

Тулы бер халыкның икенчесендә эреп таралуы яки, киресенчә, тулаем аны йотуы мөмкин түгел ләбаса.

Монда эш нидә соң?

Шул ук Россия тарихчысы Н.Карамзин сүзләре белән әйтсәк, тиктомалдан гына «*халыклар күктән төшми һәм җиргә кереп китми*» *(М.Аджи буенча)*.

Шулай булгач, бу исем кайдан килеп чыккан соң? Бит болгарларга гына түгел, Кытай белән янәшә территорияләрдә, Буир-Нор күле буенда, Гоби чүленнән төньякта һәм төньяк-көнчыгышка таба урнашкан Керулен елгасы бассейнында күчеп йөргән чын монгол татарлары белән берничнди бәйләнеше булмаган башка халыкларга да кайдан килеп ябышкан? Бөтенләй башка дин һәм расадагы, монгол телендә сөйләшкән халыкка?

Ул гына да түгел, Идел буе болгарлары, инде әйтеп кителгәнчә, әле X йөздә үк ислам динен кабул итә, ә басып кергән монгол татарлары исә мәҗүси була, бүгенге монголлар, нигездә, будда динен тота.

Мәсәлән, Бату (Батый) хан мәҗүси була, улы Сартак – христиан, ә Бәркә хан мөселман динен кабул итә.

Бөтен дингә дә тигез караган Бәркә хан Александр Невскийга Сарай шәһәрендә православие епископлыгын төзергә рөхсәт итә.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: славян-рус халкы, «монгол-татар золымы»на да карамастан (бүгенге көндә саф тарихи күзлектән караганда бу – бәхәсле мәсьәлә, һәм билгеле бер сәяси сәбәпләр йогынтысында уйлап чыгарылган булуы да ихтимал), монголлар тарафыннан ни мәҗүсилеккә, ни будда диненә көчләп күчерелми, алар болгарлардан яки тагын кемнәндер булса ислам динен дә кабул итми.

Алай гына да түгел, нәкъ менә шул елларда рус халкында православие дине тагын да ныгый, һәм моңа баскынчылар берничнди киртә дә кормый, каршы да килми.

Алар әле Русьның үз дәүләтчелеген, шәһәрләре һәм кенәзлекләре чикләрен саклап калалар. Бернигә дә карамастан, аларда һөнәрчелек, шәһәр төзү эшләре һәм башкалар үсеш ала. Гомумән, Җучиның тугыз меңлек атлы гаскәре алты миллион славян-русларны җәберләп, үзгәртеп бетерә алыр иде микән?..

Шулай да күп чәйнәлгән бу «золым» нидән гыйбарәт булган соң?

Ачыкланганча, ул элекке, бүлеп бирелгән һәр рус кенәзлегеннән ун процент күләмендә ясак җыюдан гыйбарәт була. Әле аны да бөек рус кенәзләре үзләрендә, үз халкыннан җыеп, аннан соң үзләре үк иректә рәвештә Алтын Урда ханнарына тапшыралар.

Ул заманда Русьта Урда хакимнәре тарафыннан чиркәү, мәктәпләрне ябу турында әмер бирелми, русларны ислам диненә көчләп кертү сәясәте алып барылмый, буйсындырылган Русьта төрки-татар теле көчләп кертелми, ягъни тел мәсьәләсе тулы мөстәкыйльлектә кала.

Ул гына да түгел, чиркәү нинди дә булса салым-җыемнардан тулысынча азат ителә.

Һәм боларның барысы да «золым» дип атала икән, соңрак руслар тарафыннан яулап алынган җирләрдә булган коточкыч хәлләрне ничек атарга соң?..

Тарихта рәсми теркәлеп калган фактларны, аерым алганда, «басурманнарны», ягъни мөселманнарны нәкъ менә көчләп чукындыру – Идел буе болгарларын һәм башка төрки халыкларны XVI–XVIII йөзләрдә православие диненә көчләп кертү фактын кая куярга? Аны ни дияргә?

Элекке Урда ханлыклары үрнәгендә һәм территориясендә ул чакта ук үзенең туачак һәм бүгенге көндә дә яшәп килүче империясенә нигез сала башлаган яңа баскынчы колонияләштерү сәясәтенең башлануын нәкъ менә шуның кирәклеге белән акларга тырышалар.

## 15. ТӨРКИ ТЕЛЛЕ ЧУЛМАН ҺӘМ ИДЕЛ БОЛГАРЛАРЫ – КАЗАНЛЫЛАРГА МӨНӘСӘБӘТТӘ «ТАТАРЛАР» ЭТНОНИМЫНЫҢ КИЛЕП ЧЫГУЫ

Төрле чыганаклардан күренгәнчә, «татарлар» этнонимының киң таралып китүенең нигезендә монгол-татарларның яулап алу сугышлары ята. Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европада нәкъ менә шул елларда барлык төрки телле кабилә һәм халыкларны, гомумиләштереп, шулай атый башлыйлар.

Шул ук вакытта монгол белән татарның икесе ике төрле этнос икәнен дә әйтеп үтәргә кирәк.

Татарларның яшәгән урыннары турында без югарыда телгә алган идек инде, ә менә монголлар, риваятьләрнең берсе буенча, алардан төньяк-көнбатыштарак, Онон белән Орхон елгаларына таба күчеп йөргәннәр. Татарлар базык гәүдәле, киң йөзле, җәлпәк борынлы, кысык кара күзле булса, монголлар, киресенчә, озын буйлы, аксыл чәчле, сакаллы була.

Монгол татарларын күпсанлы сугышчан кабилә тәшкил итә. Пекин императоры белән бер союзда торып, ул чакларда калган барлык янәшә күчмә кабиләләр арасында өстен көчкә, төп көчкә ия була.

«Татар кабиләләре кытайларга безнең эрага кадәр үк билгеле булган. Мәсәлән, Хань империясе чорында (б.э.к. 206 – б.э.ның 220 еллары аралыгында) татарлар Кытайга өзлексез һөҗүм итеп торганнар. Монголлар өстенлек алганчы (ягъни XII йөзгә кадәр), татарлар бик көчле булганнар. Төньяк Кытайны үзләренә буйсынырга мәҗбүр иткәннәр» *(М.Зәкиев, Ж.Неру)*.

Монголлар, арта барып, чжурчжэнейлар һәм татарларга бәйлелектән котылырга омтылганнар.

Иң әүвәл үз олысында хакимлеген ныгытып, Тимучин яки Җиһанны тетрәткән бөек Чыңгыз хан иң көчле кабиләләре – татарлар, кереитлар һәм найманнар – белән бергә бөтен монголлар (этнонимның киң мәгънәсендә) өстеннән хакимлек итү өчен, килешүгә юл калдырмаган көрәш башлый.

Беренче чиратта татарлар белән, чөнки татарлар белән монголлар һәрдаим аяусыз сугыш алып бара, заманында татарлар кулыннан Чыңгыз ханның әтисе Есугай батыр һәм туганы (нәселдәше) Амбагай хаган һәлак була.

1202 елда Чыңгыз ханның кереитлар, чжурчжэнейлар һәм монголлар белән бергә тупланып, нык әзерләнеп, татарларга каршы оештырган походлары татарларны тар-мар итә. Чыңгыз хан кабилә башлыкларын гына җәзалап калмый, асылда, бөтен татарны диярлек кырып бетерә.

1247–1318 елларда яшәгән фарсы галиме һәм монгол илһаннары вәзире Рәшид-эд-дин (монда һәм алга таба ул Е.Кычанов буенча китерелә) әлеге хәлне менә ничек тасвирлый. Чыңгыз хан татарларны *«кылычының азыгы итте», «беркемне дә исән калдырмыйча ...хатын-кызларны һәм яшь балаларны да үтереп бетереп, ...буйларын арба чикәсенә тигезләп кисеп, бабалары һәм аталары өчен үч алып...»*.

Шулай итеп, XIII йөз башында ук, әле монголлар күтәрелеп киткәнче, үз исемен барлык монгол кабиләләренә күмәклек, гомуми исем итеп биргән татар-монгол кабиләсе менә шулай һәлак була. Соңрак Европага ябырылган монгол гаскәрләре составында саф татарлар саны бик аз була.

Моны европалылар бик яхшы белә. Гильом де Рубрук бу турыда менәниләр яза: *«Чыңгыз бөтен җирдә дә алдан (исән калган) татарларны җибәрде, һәм шул сәбәпле, аларның исеме таралды, чөнки бөтен җирдә «Әнә татарлар килә» дип кычкыралар иде».*

*Әмма күптән түгел генә шактый еш алып барылган сугышларда аларның бөтенесе дә диярлек үтереп бетерелгән иде.*

*Шуннан чыгып, телгә алынган Моаллар бүгенге көндә, бу исемнән котылып, үз исемен күтәрергә телиләр».*

«Бу этноним ни өчен сакланып калган соң?» дигән сорауга җавапны түбәндәгеләрне язган шул ук Рәшид-эд-дин аңлатмасыннан алып булыр төсле.

*«...алар даирәсендә (ягъни татарлар арасында) хөкем сөргән бөтен дошманлыкка да карамастан, алар инде бик борынгы заманнарда ук байтак вакыт яулап алучылар булды һәм, башкалардан үзләренең гаярьлеге, бөеклеге һәм тоташ абруе белән кабиләләрнең һәм өлкәләрнең күп өлешендә хаким булып яшәделәр».*

*«Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм мактаулы дәрәҗәсенә күрә, башка төрки халыкларны, исемнәренең һәм токтан урыннарының аерымлылыгына да карамастан, алар исеме белән татарлар дип йөрделәр.*

*Һәм ул төрле нәсел-кабиләләр үзләренең бөек һәм абруйлы булуын үзләрен татарларга керткәнгә күрә дип санадылар һәм бу исем белән танылдылар».*

Татарларны үтереп бетерә язсалар да, кайбер тикшеренүчеләр күрсәткәнчә, монголлар үзләре үк алар телен саклап калып, үзләре дә татарча сөйләшә башлый, чөнки аларның бөтен ут күршеләре этнослар арасында үзара аралашу теле булып хезмәт иткән татар телендә сөйләшә.

Шуңа күрә дә алга таба урта гасыр сәяхәтчеләре һәм тарихчылары татарлар һәм монголлар дигән атамаларны бер үк мәгънә белдерүче синонимнар итеп кабул итәләр, ягъни татарлар этнонимы монголлар этнонимы белән бер үк нәрсә, дип саныйлар.

«Монгол-татарлар» дигән сүзтезмәне беренче мәртәбә урта гасырның әрмән тарихчылары куллана, ә рус тарихчыларына исә бу бары тик XIX йөз башында гына барып җитә.

Әлеге монгол яулап алуларының башлангыч чорында Иске Русьтан көнчыгышка таба алар басып алган һәм бер дәүләткә берләштерелгән барлык төрки телле кабиләләр татарлар дип атала башлый. Бөек Дала тар-мар ителгәч, көнчыгыш елъязмаларында Иске Русь шулай ук Татария дип атала.

Шактый еллар узгач, башлыча Урда ханлыклары таркалгач, бу сүзнең мәгънәсе тарая башлый. Ул инде Алтын Урда территориясендәге төрки теллеләргә генә карый, чөнки аның феодаллары һәм хәрби аксөякләре үзләрен татар дип, ә дәүләтен нигездә татар дәүләте дип атый (*М.З.Зәкиев*).

Алтын Урда үзе әле төрки-монгол, әле төрки-татар дәүләте дип йөртелә.

Ни өчен төрки дип? Чөнки халыкның күп өлеше – төркиләр, кыпчаклар. Татар дип, риваять буенча, Чыңгыз хан үзе әнисе ягыннан монголларның кара татар нәселеннән булганга. Шулай итеп, династия һәм аның тирәсендәге аксөякләр атамасы Алтын Урда халкына да күчә.

Россия тарихчысы Н.И.Воробьев үзенең танылган «Казан татарларының матди культурасы» дигән хезмәтендә менә ниләр яза:

*«Татар» атамасы (руслар Алтын Урда халкын рәсми шулай атый) Идел-Чулман төбәге халкына мөнәсәбәттә руслар тарафыннан бары тик Казан ханлыгы оештырылганнан һәм бу ханлык русларны зур уңыш белән җиңгәннән соң гына кулланыла башлый. Казан татарлары (ягъни болгарлар) Алтын Урданың саф татарларын күмеп китә, һәм русларның Алтын Урдага карата инде көйләнгән барлык элекке мөнәсәбәте Казан ханлыгына һәм аның халкына күчерелә.*

*Анда яшәгән фин кабиләләре аларны татарлар дип түгел, элеккечә, «болгарлар» дип йөртәләр.*

*Болын чирмешләре (марилар) бүгенге көнгә кадәр татарларны «суас», ә вотяклар «бигер», ягъни «болгар» диләр.*

*Татарлар үзләрен беркайчан да бу исем белән йөртмәгән, киресенчә, Казан татарлары (болгарлар) бу исемне кимсетү кушаматы дип кабул иткәннәр».* (*Г.Исхакый*).

Җыеп әйткәндә, XIII–XIV йөзләрдә Алтын Урдада барган катлаулы этник процесслар нәтиҗәсендә бу дәүләттә сан ягыннан өстен торган төрки-кыпчаклар калган барлык төрки-монгол кабиләләрен ассимиляцияли. Әмма Алтын Урда халкын руслар, Европа һәм Азиянең бүтән күпсанлы халкы «татарлар» дип йөрткәнгә, аларга бу этноним ябышып кала башлый.

Алтын Урда таркалгач барлыкка килгән татар ханлыкларында нигездә кыпчак-нугайдан чыккан Алтын Урда татарларыннан торган феодаль һәм хәрби аксөякләр үзләрен татар дип атый.

Ә инде бу ханлыклар да җимерелгәч, әлеге атама акрынлап гади халыкка да күчә башлый. Моңа русларның үзләре яулап алган элекке Алтын Урда ханлыкларының бөтен халкын «татарлар» дип күрсәтүе дә ярдәм итә.

Шулай булса да, бу этноним халыкка шактый авыр бирелә, чөнки ул озак еллар буе тискәре мәгънәдә йөрүен дәвам итә *(Д.М.Исхаков)*.

Шул ук вакытта (Казан ханлыгының төп халкын күздә тотып) русның Никон елъязмасы хәтта 1530 елда да, ягъни XVI йөз уртасында, алар турында өзеп болгарлар хакында язгандай яза: *«...алар хәзер казанлылар дип йөртелә*», – ди.

«Татарлар» этнонимы Идел болгарларына һәм казанлыларга, элекке Казан ханлыгы халкына рәсми рәвештә бары тик XIX йөзнең икенче яртысыннан, патша хакимиятләре аларның яңа исемен – Идел яки Казан татарлары дип соңгы нәтиҗәне ясаганнан соң гына кушыла.

Иртә дә түгел, соң да түгел. Кемдер теләсә-теләмәсә дә, бу – тәгаен билгеләнгән тарихи факт.

Нәкъ менә шул вакытта гомуми иске төрки тел «татар теле» дигән исемне ала, ә берничә елдан соң татар (ягъни төрки) телнең Казан сөйләме алар тарафыннан мөстәкыйль тел булып таныла.

Казан татарлары теле турында сөйләгәндә, түбәндәгеләрне ассызыклап күрсәтергә кирәк:

XIII йөзнең ахырында – XIV йөзнең беренче яртысында Алтын Урда шәһәрләрендә гомуми әдәби тел барлыкка килә.

Аның нигезенә кыпчак теле ята. Монгол һәм башка телләр белән беррәттән, ул Алтын Урданың дәүләт тормышында киң кулланыла, һәм, беренче чиратта, империянең гаҗәеп зур кыпчак дөньясының состав өлеше булган Идел Болгариясе, башкорт иле, Хаҗитархан (Әстерхан) кебек читтәрәк урнашкан төрки телле өлкәләре белән бәйләнешләр алып бару өчен кирәк була.

Билгеле булганча, дәүләтнең эчке тормышында кулланылган телләр дини табынулар, гыйбадәтләр, йолалар теле булып та, конфессиональ (дини) уку йортлары – мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укыту теле булып та тора.

Барлык бу хәлләр элекке Идел Болгары халкының, этник яктан нигездә болгар булып калса да, үзенең этнолингвистик тормышында торган саен күбрәк кыпчак теленә күчә баруына этәргеч була.

Күргәнебезчә, бу хәл 1930–1980 елларда элекке Советлар Союзының казанлы татар халкын тоташ руслаштыру буенча максатка юнәлдерелгән ассимиляция сәясәтенә охшап тора... *(Г.Сабирҗанов)*. Әмма бу очракта, советлар сәясәтеннән аермалы буларак, җиңел ягы да бар: болгар һәм кыпчак телләре – бер-беренә якын төрки телләр һәм ике як та бер-берсен тылмачсыз да аңлый торган телләр.

Шулай итеп, нәтиҗәдә 1926 елның сан исәбен алу вакытында элекке Идел һәм Чулман *болгар-казанлыларның* (бүгенге Казан татарлары) күбесе үзләрен *татар* дип яздыра.

Патша заманында үзенең тарихи исеменнән «мәхрүм» калган Идел болгарлары шул ук империя (инде Совет власте вакытында) мәнфәгатьләрендә аларда X йөздән алып XX йөзнең 1928 елына кадәр, ягъни мең (!) елдан артык кулланылган гарәп графикасы һәм язмасыннан да аерыла.

Гарәп графикасы һәм алфавиты башта латин шрифты, аннары 1939–1940 елларда кириллица, ягъни рус графикасы белән алыштырыла. Аңа телебездә булган тагын алты авазга махсус алты хәреф өстәлә. Нәтиҗәдә татар теле шәһәр мәктәпләреннән чынлыкта кысрыклап чыгарыла.

Менә шулай итеп, бу халыкның чорлар һәм буыннар арасындагы бәйләнеше тәмам өзелә.

Татар мәдәниятен һәм динен эзәрлекләүнең аяныч нәтиҗәләргә китергән бер генә мисал: бүгенге көндә сигез миллион татарның дүрт миллионнан артыгы ана телен белми диярлек, ә алты миллионы үзләренең тарихи ватаныннан читтә яши, меңьеллык мәдәнияте традицияләрен һ.б. белми.

Икенче яктан караганда, бу сан үзе дә бәхәсле. Әлеге этноним белән кайбер башка төрки телле халыклар да берләштерелә.

Мәсәлән, беренче сан алуга кадәр, Россиядә 1917 елга 196 милләт вәкиле яшәсә, хәзерге көндә алар йөздән дә ким.

Каядыр киткән, «төшеп калган» бу халыклар Совет власте заманында җир йөзеннән шулай җиңел генә юкка чыкмаган бит инде...

## 16. «ТАТАР-МОНГОЛ ЗОЛЫМЫ», КУЛИКОВО СУГЫШЫ ҺӘМ РОССИЯ ТАРИХЫ ХӘТЕРЕННӘН ТӨШЕП КАЛГАН КАЙБЕР БАШКА ФАКТЛАР ТУРЫНДА. АХЫР ЧИКТӘ БУ КАЗАН ТАТАРЛАРЫ КЕМНӘР СОҢ?

Кешелекнең дөньякүләм елъязмасыннан халыкны, аның күпгасырлы тарихын һәм традицияләрен сызып ату – йомшак итеп әйткәндә, мәсхәрәләү. Бөтенләй булмаган кебек, әлеге фактны танымау, бигрәк тә игътибар итмәү – бары тик томана, наданнарга һәм бөек державачыл милләтчелек һәм ялган патриотизм белән үтәли агуланган кешеләргә генә хас нәрсә.

Мондый фикерне әйтергә мине замандашыбыз, тарих фәннәре кандидаты В.Кучкинның «Русь золым астында: бу ничек булган?» («Русь под игом: как это было?», 1991) брошюрасы этәргеч бирде.

Ул анда:

*«XV йөздә яңа халык – татарлар барлыкка килде»,* – ди. Бу фикер белән һич тә килешә алмыйм.

Татарларның монголлар белән бергә килүен, биредә нинди дер Идел Болгариясе булуын танып һәм шактый ышаныч белән төрле тарихи фактларга таянып, автор шул ук вакытта иң мөһим, төп мәсьәләне – нәкъ менә, бу Болгар иле кайдан барлыкка килгән дә үзенең бөтен цивилизациясе белән кая китеп барган? дигән сорауны «кинәт кенә башыннан чыгара».

Төрки этнос белән кушылу дөньяга Чаадаевны һәм Бердяевны, Аксаков һәм Тургеневны, Салтыков-Щедрин һәм Римский-Корсаковны, Рахманинов, Келдышлар һәм Ахматованы һ.б. биргәнне танып та, шул ук вакытта «рәсми фаразларда ни өчен алар бары тик «бөек руслар» дип кенә әйтелә? Ни өчен аның башка ягы күрсәтелми?..» дигән нәрсә шулай ук исәпкә алынмый.

Аның фикерләренә таянып, яңа халыкның барлыкка килүе турындагы нәтиҗәне автор, Алтын Урда нигездә төрле төрки халыклардан торган һәм, аларның кушылуы сәбәпле, яңа халык (татарлар) барлыкка килгән, дигәннән чыгып ясаган, дияргә була.

Шуның өстенә ул, Казан һәм Кырым татарлары аермасы украин белән белоруслар аермасыннан артык түгел, дигән нәтиҗә дә ясап куя.

Алар арасында аерма бармы-юкмы һәм ул ни дәрәҗәдә икәнен бу халыклар үзләре генә әйтә ала. Үзен «өлкән буларак» бу эшкә хокуклы, димәк, мәсьәләнең асылын бөтенләй белмәсә дә, һәрвакыт «дөресен генә сөйләүче» итеп санаган беркемнең дә моңа хакы юк.

Үзенең чын тарихы һәм генеологиясе турында шулай ук бу халык үзе генә сөйли ала. Юл уңаеннан үзе ни тели, кемнеңдер мәнфәгатьләренә һәм амбицияләренә – сәясиме ул, милли, икътисади, әллә шәхсиме – ярарга тырышып теләсә нәрсә уйлап чыгаручылар эше түгел ул.

Әлеге темага багышланган төрле әдәбиятны укыганда миңа очратырга туры килгән бөтен сәбәп-нәтиҗәләрне бераз күпертеп берләштерсәң, болгарлар 200 елдан артык монгол-татарлар хакимлегендә яшәгәнгә күрә татарларга әйләнгәннәр, дигән нәтиҗәгә килеп төртеләсең.

Алар дәрәҗәсенә төшәсем килмәсә дә, миңа да югарыда әйтелгәннәр буенча әлеге галим – фән эшлеклеләре рухында һәм стилендә фикер йөртергә рөхсәт итегез.

Рәхим итеп, әйтегез әле: шул ук тарих буенча шул ук монгол-татарлар хакимлегендә шулай ук 200 елдан артык яшәгән, әле нинди дер явыз золым астында яшәгән славян-рус халкын кемнәр дип атарга?

Әллә бу теория буенча мәҗүси баскынчы монгол белән православие динендәге рус кызы (марҗа) бер-берсе белән очрашып, аларның кушылуыннан дөньяга православие динендәге рус барлыкка киләме?

Ә менә шул ук монгол мөселман болгар кызы белән кушылгач, ни өчендер алардан мөселман татар туган!

Ул гына да түгел! Хәтта русларның төрки болгарлар белән яки татарлар белән төзегән гадәти, нормаль уртак гаиләләрендә дә барыбер рус туган...

Һәм боларның барысы да, кабат әйтеп китик, әлеге дә баягы «золым» вакытында барган...

Шунысы кызык: бөекдержавачыл Россия тарихчыларының бу квазитеориясе ни өчендер бары тик Казан татарларына гына кагыла. Ул, билгеле инде, славян-русларның үзләренә дә, болгар-казанлылардан аермалы буларак, Россиягә үзирек кушылган башка халыкларга да карамый.

Дөрес, уртак тормыш алып барганда милләтләрнең кушылуы яки метизация дә, бер-беренә якын халыкларның ассимиляциясе дә булган, аны беркем дә инкарь итми, бу – табигый процесс, бүгенге көндә дә ул дәвам итә. Шулай булса да, югарыда әйтелгән дәрәҗәдә була алмый бит инде: ничек итеп төрки-болгарларның монголлар белән кушылуыннан монголлардан тамырдан аерылып торучы, ә

болгарларга кыяфәте, теле, дине һәм бөтен йолалары, гореф-гадәтләре белән тәңгәл килүче яңа, өченче халык барлыкка килсен?

Шул ук вакытта, шул ук төбәктә башка халыклар кушылуыннан нишләптер бернинди яңа халык тумый. Шундый наданлыкка барып җитәргә кирәк бит, җитмәсә бу ялганны, бармактан суырылган уйдарманы төкерек чәчә-чәчә раслап маташалар.

Империя тарихының яшәү дәверендә, үз хуҗаларыннан алынган заказны үтәгән, тарихны алар теләгәнчә бозган өчен титуллар, исемнәр һәм югары вазифалар алып, менә шундый «белдекле эшлеклеләр» язган да инде...

Чынлыкта исә эш шунда: бары тик «болгарлар» һәм «казанлылар» этнонимнары дошман исеме «татарлар»га үзгәрә, ә бу үзгәреш исә монголлардан соң килгән рус патшасы йөзендәге рус баскынчыларының яулап алулары нәтиҗәсендә барлыкка килә; шул рәвешле алар беркайчан да үзләренеке булмаган җирләрне колониягә әйләндерүне акларга тырыша.

Шул ук монголлар яки татарлар башка халык белән кушылудан антропологик яктан танымаслык булып үзгәрә алмый лабаса!

Мәсәлән, монгол-татарлар ставкасында булган Плано Карпини менә ниләр яза: *«Тышкы кыяфәтләре белән алар аерылып тора... Аерым алганда, күзләр арасы һәм яңаклар арасы киңрәк, яңаклары калкып тора, аларның борыны җәйпәк һәм кечкенә, күзләре дә зур түгел, һәм керфекләре кашларына кадәр күтәрелгән».*

Икенче төрле әйткәндә, бу татарларда, югарыда телгә алынган тарих фәннәре докторыннан аермалы буларак, мин Казан татарын һич таный алмыйм, чөнки биредә антропологик яктан бөтенләй башка тип кешеләр, башка раса вәкилләре турында сүз бара.

Ул елларның башка замандашы, XV йөзнең гарәп тарихчысы һәм әдәбиятчысы, төрек солтаны Мөхәммәд I нең сәркатибе, Тамерланның биографиясен язучы һәм материал җыю өчен Алтын Урдага килгән һәм безнең элгәрләребез – борынгы бабаларыбыз турында язып киткән Ибне Арабшах язмалары моны раслый.

*«Аның кешеләре – ир-егетләр (чын мәгънәсендә), аның сугышчылары гаҗәп оста укчылар. Телләре буенча – иң матур сөйләшүче төркиләр, тормышлары буенча – иң гадел, битләре белән – иң гүзәл, матурлыклары белән – иң камил...»* (*Р.Фәхретдинов*).

Л.Н.Гумилев буенча, гамәлдә яки симбиоз турында – бер төбәктә һәрберсе үзенең экологик «почмагын» биләүче ике яки берничә этносның (ягъни шул ук славян-руслар, болгар-казанлылар, кыпчак һәм монголларның) янәшә яшәве, яисә *химера* – төрле этносларның бер үк экологик җирлектә яшәве турында сөйләргә кирәк.

Үзенең бер әңгәмәсендә Л.Н.Гумилев болай ди: *«...Нинди дә булса халыкны икенчесе белән җенси кушылу нигезендә берләштерү – мәгънәсезлек. Кешеләр баш һәм йөрәк белән уйлый – гәүдәнең түбән өлеше белән түгел...*

*Бүгенге Татарстан территориясендә яшәүче татарларның элгәрләре дип, беренчедән, Чулман болгарларын; икенчедән, анда килеп урнашкан кыпчакларны; өченчедән, рус славяннарын санарга кирәк.*

*Ягъни бу этнос (теләсә кайсы башка этнос кебек үк) табигате һәм тарихы белән болганып беткән. Аның мөселман өлеше Чулман болгарлары дип аталса, православие динендәгеләр – руслар...»*

Билгеле инде, тәгаенләнгән һәр эпизодта боларның барысы да бәхәссез дип әйтеп булмый, тик теләсә кайсы очракта да ул шактый реаль нигезгә ия.

Аңлашыла ки, үзәк рольне болгар нигезе уйный, аннан соң гына кыпчаклар күренә.

Идел-Чулман болгарларын кыпчаклаштыру процессы турында сөйләгәндә, ягъни Казан татарларының болгар-кыпчак нигезен күрсәткәндә, моның тигез дәрәҗәдә мишәрләргә дә, типтәрләргә һәм керәшеннәргә дә, ягъни бер-береннән аерып карап булмаган барлык этник компонентларга да каравын онытмаска кирәк. Алар – бүгенге көндә *Казан татарлары* дигән бер этноним белән берләштерелгән бер организм.

Алга таба шуңа да игътибар итү зарур: фәнни әдәбиятта, инде югарыда телгә алынган болгарларның Руська китүенә һәм башка элемтәләр, бәйләнешләргә дә карамастан, төрки-татар һәм славян-русның үзара багланышлары, йогынтысы әле һаман да җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән һәм яктыртылмаган. Фактлар славян-рус халкының формалаша башлавыннан алып бөтен урта гасыр тарихы дәвамында төрки телле халыклар белән дәүләт сәясәте дәрәҗәсендә генә түгел, иң гади халыкларның шәхси элемтәләре планында да тыгыз бәйләнештә торуын күрсәтә.

Кызганыч, X йөздән аларны диннәр аера башлый, төгәлрәк әйтсәк, дини идеологияләр каршылыгы туа. Ә инде 1460 ел ахырыннан моңа рус кенәзләренең Казан ханлыгын буйсындыру, аннары бөтенләй бетерүгә юнәлдерелгән басып алу сәясәте дә кушыла. Шул вакыттан бөек рус шовинизмы, милләтара дошманлыкны кабызып җибәрү һәм татарларны күралмау идеологиясе дә башланып китә.

Әмма бу аларга акрын-акрын бер-беренең телен өйрәнергә, хуҗалык һәм сәяси тәҗрибәне үзләштерергә, сүз байлыгы, гадәт, йола, әхлак нормаларын белергә һәм алмашырга һич тә комачауламый.

«Золым»га да чынбарлыктан чыгып, тыйнаклык һәм тотнаклык белән, объектив, тарихи фактларны Россия властьларының хакимлек итүче идеологиясенә яраштырмыйча, ә бәлки, чынында ничек булган, шулай кабул итеп якын килергә кирәк. Җыеп әйткәндә, аны Русьның Урда белән тиешле компромиссы дип аңларга кирәк, чөнки Московиянең алга таба көчәеп китүе, монголлар буйсындырган бөтен Русь җиреннән төп ясак җыючы вәкаләтен һәм ул территориядә зур уңыш белән шул ук Урда урынын алуы да шуның нәтиҗәсендә була.

Әлеге «золым» турында сүз чыкканда, шулай ук, инде югарыда билгеләп үтелгәнчә, Русьның Алтын Урда составына кермәвен дә әйтергә кирәк. Русь кенәзлекләре ясак түләү планында гына аңа бәйлелектә тора, ә сәяси буйсыну исә, шул ук тарихи карталар һәм шул ел документлары күрсәткәнчә, асылда, юк дәрәҗәсендә була.

Русьта сәясәт, икътисад һәм дин, билгеле инде, көнчыгыштан Урда факторын, көнбатыштан католиклар факторын исәпкә алып, үз җае белән, ягъни шактый мөстәкыйль үсеш ала.

Шул ук вакытта биниһая зур территориядәге Алтын Урда үзенең эчке каршылыкларыннан һәм чыңгызыйларның күпләгән варислары арасында тәхет өчен туктаусыз көрәш алып баруларыннан кисәкләргә таркалуын һәм шул сәбәпле аның Ак Урдага һәм Күк Урдага бүленүен дә онытмаска кирәк. Хакимлек өчен даими алып барылган бу көрәшләрнең дәлиле – бары бер ел эчендә генә дә алты (!) хан алышынуы турында сөйләгән тарихи этап.

Боларның барысы да ахыр чиктә Алтын Урданы хәлсезләнүгә һәм таркалуга китерә дә инде. Әүвәл – Алтын Урда, аннан – Мәскәү Русе, Русь патшалыгы һәм Россия империясе, алга таба СССР, хәзер Россия Федерациясе – болар бер чылбырның бәйле кисәкләре. Монгол-татар басып алуларының моңа нигез салуы – хәзер инде гомумкабул ителгән, бары тик Россия тарихчылары гына танып җиткермәгән факт.

Тарихи дөреслек шунда: Урданың әлеге варислары, шул ук географик һәм милли-демографик киңлектә чыңгызыйлар традицияләрен мирас итеп алып, рус-татар симбиозы базасында барлыкка килә.

Аның нигезе – славян һәм төрки халыкларның кушылуы.

Мәскәүнең киләчәктә булачак күтәрелешенең башында чынлап та Куликово сугышы (1380) тора, тик империя тарихчыларының без күнеккән, без ишетеп арыган интерпретациясендә (аңлатуында) түгел, чөнки чын хакыйкать, һәрвакыттагыча, алар тарафыннан яшерелә яки, әйтик, бөтенләй башкача була.

Ярый әле, бәхеткә диикме, бу вакыйгаларда катнашкан башкаларның дәлилләре бар, алар ярдәмендә чын бөртек күлчәдән (тиле бодайдан) аерыла да инде. Дөресен әйткәндә, инде күп тапкырлар кабатланганча, бүгенге көндә безнең өчен ачыш булган күп нәрсәне бөтен дөнья әллә кайчан белә.

Мәсәлән, 1380 елда Урус хан үлгәннән соң Алтын Урдада тәхет өчен гаскәр башлыгы Мамай белән чыңгызый токымы Туктамыш хан арасындагы көрәш Мамайны Бөек Литва кенәзе Ягайло белән берләштерә (моннан тыш, аның төп көчен ялланган венецианнар һәм генуэзлар отрядлары, кыпчак-татарлар, бортас-мордвалар тәшкил итә), ә Туктамыш ханны Дмитрий Донской, ягъни Мәскәү-Владимир кенәзлеге белән дуслаштыра, чөнки моңа кадәр чыңгызыйлар Урдасы Руська литвалылардан, шведлардан һәм немецлардан котылу өчен берничә мәртәбә ярдәм иткән була.

Мамайның бу вакыттагы төп максаты – яңадан Мәскәү.

Шул уңайдан, Россиянең рәсми тарихи хәтереннән чыгып киткән тагын бер фактны искә төшерергә кирәк: элек Александр Невский уңышларының нигезендә шулай ук Урда белән стратегик союз, аерым алганда, аның Батый ханның улы Сартак белән дуслашуы һәм Монголлар хаканаты башкаласы Каракорумга сәяхәте ята. Бары шул сәбәпле алардан хәрби ярдәм алгач кына баш күтәргән Новгородны, Нева елгасында шведларны һәм Чуд күлендә немецларны җиңүгә ирешә.

Шуны да искә төшерик: XIII йөз ахырында – XIV йөзнең беренче яртысында рус кенәзләре үзләренең үзара сугышларында да Урда аксөякләренә ярдәм сорап мөрәҗәгать итәләр, һәм тегеләре еш кына үз гаскәре белән теге яки бу рус кенәзенә – әле Мәскәү, әле Рязань, әле Тверь кенәзенә ярдәмгә килә.

Рус кенәзләренең Урда ханнары туганнарына өйләнүләренең гадәти хәлгә әйләнүе шулай ук мөһим фактор булып тора.

Мәсәлән, Ростов һәм Белоозеро кенәзе Глеб Васильевич Сартакның кызына (христиан диненә күчкәч – Федора) өйләнә; 1317 елда Юрий Данилович Московский Үзбәк ханның сеңлесен хатынлыкка ала һ.б.

Тагын бер нәрсәне әйтеп китәбез: 1380 елда, ягъни Куликово сугышы вакытына Русьның төп дошманы Алтын Урда түгел, ә Литва була.

Русьның берләшүенә әлегә бик ерак. Рим Папасы православие динендәге русларга каршы игълан иткән икенче (1258) һәм өченче (1262) тәре походлары вакытында рус кенәзлекләренең төп

союзниклары Алтын Урда гаскәре, ягъни литвалыларны һәм Ливон немецларын тар-мар итәргә булышкан монголлар, болгарлар, кыпчаклар һәм башка дала төркиләре була. Шуңа да карамастан, Көньяк-Көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш рус җирләре әле һаман да бөек Литва кенәзе биләмәләре булып кала бирә һәм алар Урдага ясак түли. Ул гына да түгел, 1386 елда Литва Смоленск кенәзлеге территориясен басып ала, һәм инде хәзер чик Можайск шәһәре янынннан үтә.

Шулай да Куликово сугышына кайтыйк әле.

Тула шәһәре янындагы сугышта Мамай җиңелә. Монда хәлиткеч рольне Дмитрий Донской җитәкчелегендәге засада полкы уйный. Бу сугышка Сергей Радонежский фатихасын бирә. Ягайло исә соңга кала, бары тик сугышның ахырына гына килеп җитә, ә эш узган була инде – руслар җиңә. Шулай итеп, бу сугыш русларның монголлар белән сугышы түгел, ә бер монгол-кыпчак-рус гаскәренең икенче монгол-кыпчак-литва-итальян-рус гаскәре арасындагы сугыш була. Өстәвенә ике як гаскәрләре дә нигездә төрки кыпчаклардан тора.

Ә иң мөһиме – Куликово сугышыннан соң 150 (!) ел үткәч кенә, үзендәге эчке үзара сугышлар нәтиҗәсендә Урда хәлсезләнгәч һәм таркалгач кына, Угра елгасында каршылыкны кан коюларсыз җиңеп, һәм шуннан соң Русь ясак түләүдән котылгач кына көчләр берләшә һәм Мәскәү башка рус шәһәрләрен һәм аз санлы халыкларның җирләрен басып ала башлый.

1380 елдагы бу сугыш, Руська Мәскәү йөзендә үз көчләрен бергә туплау мөмкинлеген бирүче үзәкне күрсәтеп, шул чакта Туктамышка Идел ханлыгын буйсындырырга һәм Алтын Урданы берләштерергә ярдәм итә: ул Әстерханны басып ала һәм шул ук елның көзендә Сарайны буйсындыра. Алга таба, бер елдан соң, 1382 елда Туктамыш хан Идел болгарлары гаскәрләре һәм һаман шул ук рус отрядлары (Түбән Новгород кенәзе Дмитрий һәм Рязань кенәзе Олег отрядлары) ярдәме белән Дмитрий Донской гаскәрен җиңә һәм Мәскәүне ала. Шуннан соң Мәскәү Алтын Урдага ясак түләвен дәвам итәргә мәҗбүр була.

Бары тик ун ел үткәч кенә, 1392 елда, Туктамыш, Тимурга каршы сугышка әзерләнгәндә, Түбән Новгород, Муром, Таруса һәм Мещера белән идарә итү хокукын инде чираттагы Мәскәү кенәзе Василий I гә сата.

Мамай исә Куликово сугышыннан соң Литвага кача, аннан генуэзлыларга – Кафа (хәзерге Феодосия) шәһәренә китә. Шунда токкарлана һәм үтерелә.

Моның дәвамы тагын да кызыклырак һәм мавыктыргыч. Аның улы Мансур Литвада кала, ә аның улларының берсе, ягъни Мамайның оныгы, славян княжнасына өйләнә һәм шул никахтан кызы Елена Глинская туа.

Ул рус кенәзе Василий III кә кияүгә чыга һәм аңа ир бала табып бирә. Әлеге угыл киләчәктә русның Иван Васильевич Грозный дигән шәфкатьсез һәм канечкеч патшасына әверелә.

Язмыш дигән нәрсә бар нәрсәне дә менә шулай болгата, нәтиҗәне үзенчә чыгарып куя. Телисезме, теләмисезме: Рюриковичларның скандинавлар нәселеннән булган беренче славян-рус патшасының әнисе Мамайның туруны була...

Менә шуннан соң бәхәсләшеп, тартышып карагыз инде: кем-кем булган яки кем гаепле, кем хаклы, яисә кем кемне җиңгән... (*З.Краснов, А.Халиков, О.Куленов*).

## СОҢГЫ СҮЗ

Һәр халыкның тарихында бөек дәрәҗәләргә дә, хәсрәтле, аяныч хәлләргә дә урын бар. Шул уңайдан, минем I Бөтендөнья татар конгрессында катнашучылар игътибар иткән ике мәсьәләгә тукталасым килә.

Беренчесе – язмыш шаяртуы аркасында безнең халык басып алучыларның берсе (руслар) ихтыяры белән икенче баскынчылар этнонимын кабул итеп ала, нәтиҗәдә Идел болгарларыннан үзгәреп, татарлар булып китә.

Әмма бүгенге көндә бу, ул чакта Татарстан Фәннәр академиясе Президенты булган М.Хәсәнов фикеренчә, милләт исемен кире үзгәртеп, яңадан «*болгар*» этнонимына кайту кирәклеген аңлатмый. Чөнки тарих күзлегеннән караганда, без – болгарлар да, Казан татарлары да. Безнең җаныбызда барыбер дә болгарлар рухы, җаны яши, шуңа күрә беркем дә аны инкарь итми, инкарь итә дә алмаячак. Монысы – хак.

Борынгыдан килгән Болгар илен
Күз алдыма китерәсе килеп,
Гасырларны үтәм уй аша.
Ни дисәң дә, безнең тирән тамыр
Буталчык һәм борма юллар белән
Болгарларга барып тоташа.
...Шул еллардан бирле без – мөселман,
Табынабыз тик бер Аллага,
Йөзебездә балкый иман нуры,

Инкарь итеп булмый: ни дисәк тә,
Мең кат үлеп, мең кат терелсәк тә,
Безнең тамырларда әле һаман
Болгарлардан кергән кан ага!

*(Ф.Тарханова, «Тамырлар», 2006)*

Шулай булса да, этнонимны үзгәртү, аңа кире кайту мәсьәләсеннән китсәк тә, аны бүгенге көндә «сәяси зарарлы» дип катгый билгеләү шулай ук дөрес түгел дип уйлыйм. Анда бары тик сәясәтне генә күрергә ярамый. Кайда гына яшәсә дә безнең халык үз тарихы, үзенең чыгышы турында, ул нинди генә булмасын, белергә тиеш. Һәм бүгенге көндә саф сәяси яки фәнни яктан кайсы караш файдалырак, зарарсыз булыр икән дип фикер йөртү шулай ук үзен акламый.

Чөнки безнең тарих, безнең үткәнебез һәм бүгенге көндәге безнең этноним – инде хакыйкый булган тарихи һәм сәяси факт, аннан, теләсәң-теләмәсәң дә, китеп булмый, өстәвенә беркем дә бер чиктән икенчесенә ташланырга тормый. Моны без инде күпләгән тапкырлар башыбыздан кичердек. Ә менә чын тәрбияви планда бу безнең барыбызга да уңай йогынты ясаячак, бездә милли горурлык хисен үстерүгә, бөтен дөньяга таралган Казан-татар милләтен ныгытырга һәм берләштерергә ярдәм итәчәк.

Шул ук конгресста Европа һәм Себер мөселманнарының Диния назәрәте мөфтие Тәлгать Таҗетдин менә ниләр әйтте:

*«Татар халкы беренче мәртәбә 922 елда ислам динен кабул итү уңаеннан җыелган иде, ә бүген без икенче мәртәбә җыелдык.*

*Ике корылтай арасында төрле тарихи вакыйгалар күп булды. Монголлар ябырылуы да булды. Бүгенге көндә без мең ел элек безгә хисапсыз бәла-каза һәм хәсрәт китергәннәр исеме белән аталып йөрсәк тә, заманында безнең борынгы бабаларыбыз дошманга каршы бердәм күтәрелгәннәр.*

*Шуңа күрә бу корылтайны өченче корылтай дип атасак та дөрес булыр иде.*

*Әгәр дә 1552 елда халыкның кырык бер көн буе «Аллаһы әкбәр» дип әйтә-әйтә Казанны сакларга күтәрелгәнен исебезгә төшерсәк, бу корылтайны дүртенче дип әйтергә дә булыр иде.*

*Бүген без бердәмлек, килешү һәм туганлык хакына җыелдык.*

*Безнең бүгенге корылтай – 450 елга сузылган мәхрүмлектән, югалган өмет һәм ышанычтан соң беренчесе...*

*Без иң кадерле һәм иң кирәкле нәрсәне – милләтебез исемен чак кына югалтмый калдык. Болгарларның дәвамчылары, болгар нәселе бүгенге көндә үзен татар дип атый.*

*Без, исемебезне югалтсак та, үз Ватаныбызны, иманыбызны, Ана телебезне саклап кала алдык.*

*Дин, Ана теле һәм Ватан! Алар яшәгәндә без дә яшәрбез!..*

*Без милләтне сайлап алмадык. Без башкалардан бер ягыбыз белән дә ким түгел. Бөтен кешелек гөлләр бакчасы булса, без шул бакчадагы гөлләрнең берсе...*

*Бөтен милләтләр дә – Аллаһ гаиләсе. Безне ничек кенә атамасыннар: болгармы, татармы – без барыбыз да җир йөзендә яшибез...*

*Без Ватанны да сайлап алмадык, шулай ук күршеләрне дә, без Аллаһ ихтыяры белән Идел ярларында... Татарстан безгә Аллаһ тарафыннан бирелгән...*

*Мең ел элек безнең борынгы бабаларыбыз исламны кабул иткән. 1989 елда без бу вакыйганың 1100 еллыгын билгеләп үттек.*

*Соңгы җитмеш өч ел эчендә без упкын кырыенда яшәдек. Борынгы бабаларыбыз, борынгы болгарлар бөтен гомере буена үзләренең уйларын һәм гамәлләрен Аллаһы Тәгалә белән килештергәннәр...»*

Бөтен дөньядан килгән татарларга мөрәҗәгать итеп, мөфти үзебезнең барлык бәла-казаларыбызда гаеплеләрне эзләмәскә чакырды, чөнки алар, инде билгеле булганча, нәкъ менә үз арабызда килешү һәм бердәмлекнең булмавы нәтиҗәсендә килеп чыкты, диде. Шуңа күрә без максатыбызның дөреслегенә, хаклыгына ышанып, өметсезлек хисеннән арынырга тиешбез, барлык халыклар белән дә тыныч һәм дуслыкта яшәргә, әүвәл үзеңне ихтирам итеп, аннан башка милләтләрне дә ихтирам итә белергә, бер-беребезгә ярдәм итәргә, мәңгелек гомумкешелек кыйммәтләренә тугры калырга тиешбез.

Тәүбәгә килмичә, таркалган булуыбыздан тәүбә итмичә, бөек ислам дөньясына кайтмыйча яңарыш мөмкин түгел, ә моның өчен безгә бердәмлек, тынычлык һәм бер-беребезгә карата түзеп торучанлык кирәк...

Бөтендөнья татар конгрессында катнашучыларның узган гасырларны анализлаганнан соң игътибарын җәлеп иткән икенче нәрсә – безнең халкыбызның чиксез белемгә омтылуы, гаделлекнең өстенлегенә һәм дәүләтчелек хисенә аеруча нык ышану.

Мәсәлән, Казан университеты профессоры, озак еллар татарларның көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнгән Карл Фукс әле 1844 елда болай дип яза: *«Казан татарлары үзләрен буйсындырганнан соң хәтта өч йөз ел дәвамында шактый үзенчәлеген, миллилеген саклап кала алган, бу хәл күзәтүчән этнографның аерым игътибарына лаек.*

*Алар руслар алдында һәм үзләре тирәсендәге башка халыклар алдында да ...хәтта бүгенге көндә кайчандыр борынгы бабаларына хас булган өстенлекләрен югалтмаска, дәвам итәргә тырышалар.*

*Алар үзләренең югары әхлакый сыйфатларга ия булулары, диннәре, көнкүрешләре белән горурланалар, болар исә – аларны башкалардан аерып торучы сыйфатлар».*

*«Читтән килгән һәркемгә, гомумән әйткәндә, Казан татарларында кайбер Европа халыкларыннан да белемлерәк халыкны табу һичшиксез гаҗәп булып тоелыр.*

*Укый-яза белмәүче татарны милләттәшләре санга сукмый, аңа нәфрәт белән карый һәм ул гражданлык буларак та хөрмәт ителми».*

Безнең халык, 450 ел дәвамында кимсетелүләргә дә карамастан, үзен беркайчан да кол итеп санамады.

Моңа дәлилләр күп: әүвәл монгол яуларына, аннан русларга озаклап һәм кискен каршылык күрсәтү генә түгел, Разин һәм Пугачев баш күтәрүләрендә, һәм халыкның башка болганышларында күпләгән Казан татары катнаша;

татар-башкорт полклары 1812 елгы сугышта беренчеләрдән булып Парижга бәреп керә;

Польша татарлары 1939 елда Варшаваны иң соңгылардан булып саклый;

Икенче Бөтендөнья сугышында 184 татар Советлар Союзы Герое, 57 татар Дан орденының тулы өч дәрәҗәсе кавалеры исеменә лаек була (руслар, украиннар һәм белорусларда гына күбрәк, чөнки сугыш алар территориясендә барды һәм алар халкы безнекеннән күплеге белән дә аерылып тора). Кайбер татар авылында икешәр-өчәр Герой.

Ул гына да түгел: атып торган дошман дзоты амбразурасын үзенең күкрәге белән каплаган Александр Матросов та татар егете – ятимнәр йортында үскән Шакирҗан Мөхәммәтҗанов. Тик никтер аның татар булуы телгә алынмый кала. (Бер караганда гаҗәп тә түгел, бөек полководецлар Суворов белән Кутузовның, фельдмаршал Шереметьевның да һ.б. татарлардан булуын сирәк кеше белә). Югыйсә бу батырлыкны аннан бераз соңрак шулай ук татар егете Газинур Гафиятуллин да кабатлый. Шуның өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелсә дә, аның бу батырлыгы турында киң күләмдә сөйләнми;

рәсми идеология уйдырмасыннан аермалы буларак, рейхстаг өстенә җиңү байрагын биш сугышчан дус кадый һәм аның берсе милләттәшебез Газиз Заһитов була;

бүгенге заманда, 1996 елда, Татарстан, БДБ илләрендә генә түгел, гомумән бөтен дөньяда әллә ни күп булмаган яклаучыларның берсе булып, чечен халкына үзенең теләктәшлеген белдерде һәм аларга карата Россия агрессиясен гаепләп чыкты;

Россия дәүләтенең (СССРның да) иң күренекле шәхесләре арасында татарларның күплеге шулай ук куанычлы. Мисалга танылган ориенталист, археограф һәм мәгърифәтче, Археологлар җәмгыяте әгъзасы Хөсәен Фәезхановны; танылган химик Александр Ерминингельдович Арбузовны; күренекле химик Гыйлем Камайны; мәшһүр архитектор Исмәгыйль Гайнетдиновны; күренекле хирург Ренат Акчуринны; танылган генералларыбыз: Советлар Союзы Герое Дмитрий Карбышевны, Якуб Чанышев, Рәсим Акчурин, Мәхмүт Галиевне һ.б.; күренекле артистлар: Сергей Шәкүров, Тәлгать Нигъмәтуллин, Марат Бәшәров, Чулпан Хамматова һ.б.; җырчылар Алсу, Ринат Ибраһимовны һ.б.; дөньяга танылган спортчылар: Галимҗан Хөсәенов, Вагыйз Һидиятуллин, Ренат Дасаев; Марат Сафин, Алина Кабаева, Ләйсән Үтәшева, Зиннәтулла Билалетдинов, Мария Шарапова, Динара Сафина, Наилә Гыйләҗева, Лилия Нуретдинова һ.б.; Россия Федерациясе министрлары Эльвира Нәбиуллина һәм Рәшит Нургалиевне, шулай ук башка бик күпләрне китерергә мөмкин булыр иде;

татарлар Россиягә генә түгел, бөтен дөньяга мәшһүр шәхесләр бирде. Хәзерге вакытта, узган бүлекләрнең берсендә телгә алынганнардан гайре, аларга «оча торган татар», Италия, Франция, Америка, Вена һ.б. сәхнәләрдә биегән Рудольф Нуриевны, Англиядә «Ковент Гарден» театрында биюче, Британия империясе ордены кавалеры Ирек Мөхәммәдовны, Норвегия, Дания королевалары, Финляндия, Мисыр, Франция, Россия, Татарстан президентлары һ.б. күренекле кешеләр портретларын ясаган мәшһүр рәссам Мансур Саттаровны, космос физикасы өлкәсендә күренекле физик, академик Роальд Сәгъдиевне, Германиядә яшәп иҗат итүче композитор Софья Гобәйдуллинаны, Американың «Хьюстон Гранд Опера» сәхнәсе җырчысы Альбина Шаһиморатованы һәм башкаларны өстәргә була.

Танылган миссионер Ильминский сүзләренә караганда, боларның барысы да татар халкының күп гасырлар яшәү чорында, бернигә дә карамастан, үзен һәрвакыт сәләтле халык дип санавыннан туган һәм туа. Чынлап та, үзенең беренче – Болгар дәүләте чорыннан (ягъни VI гасырның беренче яртысыннан) 1552 елга – Казанны яулап алган көнгә кадәр асылда тугыз гасыр дәвамында ул мөстәкыйль дәүләтле булды. Аның хәтта алдагы 450 ел буе Россия дәүләте составында яшәве дә мәңгегә халкыбыз җанына сеңеп калган әлеге хисне бетерә алмады.

Кызганыч, рус халкы хәтеренә мәктәп эскәмиясеннән кереп калган тарих шулкадәр үзгәртелгән, ялган-ясалмалылыкка корылган, гел бер яклы гына күрсәтелгән ки, шуңа күрә бүгенге көнгә кадәр рус кешесенең башына инкыйлабка кадәрге Россиядә, аннан соң СССРда, ә хәзер яңа Россиядә башка халыкларга карата (чечен, татар, яһүд, төньяк халыклары һ.б.) геноцид алып барылуы турындагы уй

керә дә алмый. Шунысы аяныч: руслар, ихтыярый булмаса да, вакыйгаларның үсешен үз каланчасыннан гына күрә, бары үзен генә һәм үзенең борчу-газапларын гына таный, ә башкаларныкы аңа кагылмый...

Кабатлап та тормас идек, әмма ләкин мәктәп дәреслекләрендә, фәнни һәм матур әдәбиятта халкыбыз тарихының шулкадәр дә бозылып, ялганга төрелеп бирелүе җанны әрнетә. Нәтиҗәдә башка халыкларда да «татар» дигән сүз бары тик курку һәм ышанмау тудыра.

Мең ярым ел тыныч хезмәт белән шөгыльләнеп, икмәк үстергән, аннан аны саткан, китап бастырып тараткан, шуның белән үз халкын гына түгел, күрше халыкларның да күбесен һәм Көнчыгыш халыкларын мәгърифәтле иткән, бары тик басып алучыларга каршы гына көрәшкән һәм берничә мәртәбә шул ук рус халкын яклаган, саклаган безнең халык андый гаделсезлеккә лаек түгел.

Ә инде русларның безнең халыкка карата наданлык белән, тарихны, үткәнне белмәгәнгә күрә әйтелә торган төрле кимсетү сүзләре бернинди кысаларга да керми. Аларда бары тик зәһәрлек һәм көчсезлек. Башка берни дә түгел.

Гомумән, бары тик, инде әйтеп үткәнчә, томаналык кына бер кешенең икенчесенә карата шундый мөнәсәбәтен тудыра ала. Бер халыкның, өстәвенә янәшә, нигездә дус булып яшәүченең, икенчесенә мондый мөнәсәбәте һич акларлык һәм гафу итәрлек түгел.

Әле шуны да онытмаска кирәк: башкаларны кимсетү, рәнҗетү – зәгыйфь акыллылык билгесе. Иң мөһиме, әйдәгез, бергәләп яхшылык эшлик һәм аны бергәләп гамәлгә ашырыйк, чөнки ул һәрвакыт кайчан да булса безнең бөтенебезгә дә яхшылык булып әйләнеп кайтачак...

Теманы йомгаклап һәм тәвәкәлләп, бернәрсәне яңадан раслап китәсем килә: һәр халыкның тарихта аерым урыны бар, шуңа күрә һәр халык үзе өчен үзе сөйләргә тиеш. Өстәвенә, кайберәүләр аны аңлатырга тырышса да, гамәлдә бар да бик гади – бу җирдә руслар һәм монголлар, татарлар һәм кытайлар, башкортлар һәм чуашлар, болгарлар һәм казахлар, алманнар һәм төрекләр, болгарлар һәм карачайлар, балкарлар һәм венгрлар һәм күп кенә башка халыклар һәм милләтләр яшәгән һәм яши.

Ә инде башка кешеләрнең һәм халыкларның белер-белмәс теләсә ни сөйләп, фикер әйтергә тырышып йөрүләренә кәефең китсә дә, ахырга кадәр аңа карата хөрмәт һәм тотнаклылыкны, тыйнаклылыкны саклап кала белү – барыннан да өстен сыйфат.

Бары шуннан соң гына, диаметраль каршы булса да, үзеңнең карашыңны белдерергә кирәк.

Чынлап та, бернинди сугышларга да карамастан, бер генә халык та хәзерге меңьеллык уртасында башка халыкны тулысынча кырып бетерә яки йота алмас иде, чөнки бернәрсә дә һәм беркем дә бу дөньяда эзсез югала алмый.

Бигрәк тә мондый тирән тарихлы бөтен бер халыкка кагылышлы булганда.

Төптән уйлап карагыз әле: дөрестән дә, үзенең дәүләтчелеге, дине, мәдәнияте булган бөтен бер халыкның, кинәт кенә җир йөзеннән юкка чыгуын, икенче халык эчендә тәмам эреп бетүен яки бөтенләй башка халыкка әверелүен күз алдына китереп буламы? Өстәвенә аның, бу халыкның, җаны шул ук вакытта элеккечә үк, мең ел элек булгандагыча калырга, элеккечә үк буыннан буынга бер халыкны икенчесеннән, бер кешене башкасыннан аера торган күзгә күренмәс бизәкләрне тапшырып, шуның белән безнең һәрберебезгә дә үзенә генә хас билгеләрне, үзенчәлекләрне һәм аерым бер «кыйпылчыкларны» биреп хәбәр итеп торырга тиеш. Минем уемча, әлеге мәсьәләне тикшергәндә иң мөһим нәрсә – менә шул.

Чөнки *Идел болгарлары* һәм *казанлылар* этнонимына алмаш булган *Казан татарлары* этнонимы әле болгарлар исеме белән халык формалаша башлаганга кадәр булган этноинтеграция процессы чорында туган этногенетик, этносоциаль, хуҗалык-икътисади һәм мәдәни-сәяси бәйләнешләрнең күчешен, варислыгын туктату дигәнне аңлатмый.

Россиядә Казан татарларына карата бу рәсми тарихи теориянең дөрес булуына шикне узганның һәм бүгенгенең байтак күренекле кешеләре белдерде һәм белдереп килә. Әлеге сорауның куелышы, минем карашка, әгәр дә бу оныту, хәтердән төшереп калдыру һәм бозу-үзгәртү еллары булмаса, тагын шул наданлыкның дәлиле булган булыр иде.

Сүземне төгәлләп, мисал рәвешендә, Ч.Вәлихановның 1856 елда басылып чыккан «Көньяк Себер кабиләләре тарихы буенча язмалар» дигән хезмәтеннән түбәндәге өземтәне китерәм (дөрес, бу хезмәт бөтенләй башка сәбәп белән, аерым алганда, ислам диненең төрки халыкларга тискәре йогынтысы, дигән темага язылган):

*«...Казан татарларын гына алыгыз, алар – безгә тарих әйткәнчә (тагын шул –, кемнеке һәм нинди тарих? – Т.К.), Батый монголларының нәсел тармагы яки Батый сугышчыларының төрки кабилә – кыпчаклар белән кушылмасы.*

*Әйтегез әле, зинһар, Идел монголында (ягъни Идел болгары – татарда. – Т.К.) аның чыгышын билгеләүче берәр нәрсә бармы (ягъни нәкъ менә монголдан. – Т.К.)?*

*Бернәрсә дә.»*

Бөтен җавап шул.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Әлеге бүлектә төрле авторларның кырыктан артык хезмәте файдаланылды. Аларның кайберләре турында, югарыда күрсәтелгәнчә, текстның үз эчендә әйтелә, әлеге мәсьәләне ачыклауга үз өлешен керткән башка хезмәтләр арасында исә түбәндәгеләр бар:

«Путешествие Ахмеда Ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии Ислама» – борынгы кулъязма буенча, рус телендә беренче мәртәбә 1939 елда басылып чыга;

**Исхакый Г.** Идел-Урал. Беренче мәртәбә 1933 елда Берлинда – татар телендә; Парижда – рус һәм француз телләрендә; 1934 елда Токиода – япон телендә; 1938 елда Варшавада – поляк телендә; 1988 елда Лондонда инглиз телендә басылып чыга;

**Имамов В.** Татарларның яшерелгән тарихы;

**Хуҗин Ф, Ситдыйков А.** Борынгы Казан – замандашлар һәм тарихчылар күзлегеннән;

**Исхаков Д.** Татарлар;

**Закиров А.** Россия тарихының «караңгы почмаклары;

**Фәхретдинов Р.** Алтын Урда һәм татарлар, Халык күңелендә ни бар?, Мин – татар улы, Алтын Урда ханнары;

**Салихов Р., Хәйретдинов Р.** Татарстан: татар халкының тарихи һәм мәдәни ядкәрләре (XVIII йөз ахыры – XX йөз башы);

Atlas zur Welt Geschichte (немец телендә);

**Доктор Р.О.** Тюрккан. Кто мы? (төрек телендә);

Төрки телле халыкларның бөтендөнья корылтаеннан (Әнкара шәһәре, 1996, март);

**Халиков А.Х.** 500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения. Бу хезмәт галим тарафыннан тарихи документларга – «Бархатная книга» (кенәз һәм дворяннарның нәсел шәҗәрәсе китабы), рус дворяннарының нәсел тарихы, Россия империясе дворяннары нәселләренең гомуми тугралыгы, Узган еллар повестьлары, - Рус елъязмаларының тулы җыентыгы һәм башкаларга нигезләнеп әзерләнгән;

«Полынь половецкого поля» («Кыпчак кыры әреме») – М.Аджиның Евразия төрки халыклары тарихына кызыклы бер карашы;

**Садриҗиһанов.** Хатирәләр;

Бөек тарихчы Л.Н.Гумилевның «От Руси до России» («Русьтан Россиягә кадәр»), «Открытие Хазарии» («Хәзәр илен ачу») дигән хезмәтләре. Аның ике хезмәте – «Древние тюрки» («Борынгы төркиләр») һәм «Тысячелетие вокруг Каспия» («Хәзәр диңгезе әйләнәсендә мең ел») инде югарыда телгә алынган иде;

**Шакарим Кудайберды** улы. Родословная летопись (Шежере). Ул 1911 елда Оренбург шәһәрендә «Кәримов, Хөсәенов һәм Компания» типографиясендә басылып чыга;

Франция короле Людовик IX ның илчесе, Фламандрия монахы Гильом де Рубрук. «Көнчыгыш илләренә сәяхәт»;

Рим папасы Иннокентий IX ның илчесе, Францискан монахы Джиованни дель Плано Карпини. История монголов (Монголлар тарихы). 1911 елда С.-Петербургта А.Суворин нәшриятында басыла;

**Вәлиханов Ч.** Әсәрләр җыентыгы, 5 томда;

Бөтендөнья татар конгрессының 1992 елдагы стенографик хисабы;

**Кычанов Е.** Жизнь Темучжина, думавшего покорить мир (Дөньяны буйсындырырга уйлаган Тимучин тормышы);

**Зәкиев М.З.** Татар һәм татар теле тарихыннан, Төрки-татар этногенезы. (Мәскәү ; Казан, 1998);

**Госманов М.Г.** Гасырдан гасырга;

**Сабирҗанов Г.С.** Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков (Урта Идел һәм Көньяк Урал халыклары – гасырлар яссылыгында);

**Мәрҗани Ш.** Казан һәм Болгар тарихы чыганаклары (татар телендә);

**Кляшторный С.**, **Солтанов Т.** Казахстан. Летопись трех тысячелетий (Казахстан. Өч меңьеллык елъязмасы);

**Хара-Даван Э.** Чингиз хан как полководец и его наследие (Полководец буларак Чыңгыз хан һәм аның мирасы). Беренче мәртәбә 1922 елда Белград шәһәрендә басылып чыга;

«Kazan», The Enchanted Capital, R.Bukharaev, London, 1995;

**Таһиров И.** Бәйсезлек баскычлары (татар телендә);

**Краснов З.** Великое в малом (Кечкенәдә – бөеклек);

Совет энциклопедик һәм әдәбият сүзлекләре;

**Чибилев А.** Река Урал (Җаек елгасы);

**Дариенко В.** Классовая борьба на Яике в XVII – нач. XVIII вв. (XVII гасырда һәм XVIII гасыр башында Җаекта сыйнфый көрәш);

«Көнбатыш Казахстан тарихының хәл ителмәгән мәсьәләләре» дигән төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (Гурьев шәһәре, 1991, май);

**Салгарин К.** Династии ханов (Ханнар династияләре);

**Куленов О.** Куликовская битва: истина и легенда (Куликово сугышы: хакыйкать һәм риваять);

«Казахи» («Казахлар»), тугыз томлык тарихи белешмәлек;

**Шоинбаев Т.** Прогрессивное значение присоединения Казахстана к России (Казахстанны Россиягә кушуның прогрессив әһәмияте);

**Абдиров М.** Хан Кучум: известный и неизвестный (Билгеле һәм билгесез Күчүм хан);

«Евразийское сообщество» журналы мәкаләләре (1997, №3), кайбер башка материаллар һәм басмалар.

## II. КӘРИМОВЛАР

*Теләсә кемнең, теләсә кайсы гаиләнең язмышы кайчандыр үзләре яшәгән яки бүгенге көндә яши торган дәүләт тарихына нык бәйле. Башкача булуы мөмкин дә түгел.*

*Шуңа күрә безнең фамилиянең биографиясе дә (кызганыч, мин дүрт буыннныкын гына беләм), миллионлаган башка фамилияләрнеке кебек үк, аларга яшәргә туры килгән дәүләтләрдәге бөтен катаклизмнар белән тыгыз бәйләнештә һәм бер-бере белән үрелгән.*

*Һәм мин бу бүлектә аларның хәтерләренә сеңеп калган, әлегә юкка чыкмаган истәлекләрдән, шулай ук сакланып калган кайбер документлар нигезендә үземнең борынгы бабаларым турында миңа билгеле булганнарны бәян итәргә тырышып карыйм. Мин моны, беренче чиратта, киләчәк буыннарыбыз өчен әлегә бөтенләй югалып бетмәгән нәрсәләрне саклап калу өчен эшлим.*

Каспий диңгезе ярына, Жилая Коса дигән бистәгә (бүгенге көндә Атырау өлкәсенең Жылой районы, элек – Гурьев өлкәсенең Жилая Коса һәм Эмба районнары территориясе) Кәримовлар XX йөз башында Казаннан күчеп килгән.

### 1. КАСПИЙ БУЕ ТӨБӘГЕ ТАРИХЫННАН

Күп меңьеллар дәвамында бөтен Каспий буе төбәгенең стратегик артериясе булып Урал елгасы хезмәт иткән. Ул Азия белән Европаны бүлүче ролен түгел, ә бәлки бер Евразия континентына берләштерүче ролен башкарган.

Безнең эрага кадәр V йөздә бу елга Ликос исеме белән йөртелгән. Аның аша сакларның, массагыт, киммер, скиф, савромат, сармат, гот, алан, һун (гун), хәзәр, авар, бәҗәнәк, угыз һәм кыпчакларның нәсел-кабилә берләшүләре үткән.

Кодрәтле Батый һәм Күчүм ханнар монда үзләренең станнарын корганнар...

Төркичә ул Данк, аннары Янк, Җаек дип йөртелгән. Ул үзенең бүгенге исемен агымы башланган тауларның гомумтөрки исеменнән алган.

XI–XII йөзләрдә Түбән Җаек һәм Каспий диңгезенең яр буйлары аша Түбән Иделдән Хәрәзем, Бохара, аннан Көнчыгышка һәм кирегә диңгез һәм коры җирдән сәүдә юллары үткән. Әлбәттә, бу юлның бөтен буена колонистлар һәм әлеге җирдә яшәүчеләр тарафыннан шәһәрчекләр һәм торак җирлекләрнең төзелүе – табигый хәл.

XIII йөздә Җаекның түбән агымында төзелгән Сарайчык шәһәре – Кече Сарай (Алтын Урда башкалалары Сарай-Бату һәм Сарай-Бәркәгә охшатып), бүгенге Атырау шәһәреннән 30 чакрым ераклыкта гына булып, үз вакыты өчен бу төбәк, иң зур транзит базары ролен үтәп кенә калмыйча, XVI йөзнең ахырына кадәр Алтын Урда чорының мәдәни һәм сәяси үзәкләренең берсе дә булган.

Шуны да билгеләп үтү кирәк: Җаек елгасындагы беренче шәһәрчекләрнең берсе Сарайчык (Сарайҗук) тарихы вакыйгаларга бик бай.

Башта ул Алтын Урданың иң бай шәһәрләренең берсе булган: үзенең зиннәтле сарайлары, керамика әйберләре, оста һөнәрчеләре, гаскәр башлыкларының кәнизәк йортлары (гаремнары), мал-туарның күплеге белән дан тоткан. Аның йөзмә (понтон) күпере кичүеннән сәүдә кәрван юлы үткән.

Биредә акча сугу йорты да булган, анда көмеш һәм бронза тәңкәләр сукканнар, зәркан әйберләр эшләнгән, шәһәрдә суүткәргеч тә булган.

Заманында Үзбәк хан белән Җанибәк хан бу шәһәрдә туктала торган булганнар һәм теләгән кадәр яшәгәннәр дә...

Әмма 1395 елда, хакимлек өчен эчке чуалышлар, ызгышлар, көрәшләр аркасында Алтын Урда ханнарының куәте кимеп барганда, Җаектагы бу шәһәр беренче мәртәбә Мавәрәэннәһер хакиме Тимур, ягъни аннан алда гына Туктамыш ханны тар-мар иткән Урта Азиянең рәхимсез һәм кансыз әмире Тамерлан тарафыннан җимерелә.

Әүвәл, Туктамышка каршы барганда һәм Сарайчык шәһәреннән ерак түгел генә елга кичкәндә, Тамерлан бу шәһәргә һөҗүм итми кала, бары тик кире кайтканда гына шәһәрне җимерә...

Шунысын да әйтик: Тимурның яулап алу походлары һәрвакыт коточкыч вәхшилек һәм кансызлык белән бара. Мәсәлән, 1387 елда ул Исфаганны алганда үз сугышчыларына 70 мең гади халыкның башын кыярга, шул башлардан пирамидалар төзергә боерык бирә. Һиндстанда исә 1398 елда, Сарайчык шәһәрен җимереп киткәннән соң, аның әмере белән 100 мең әсир үтерелә.

Тамерланнан соң күпмедер вакыт Каспий буе далалары буш тора...

Алга таба, инде Алтын Урда тулысынча таркалганнан һәм аның урынында биш ханлык төзелгәннән соң, XV йөзнең беренче яртысында Сарайчык шәһәре Нугай Урдасының (бу исем этник түгел, ә сәяси) башкаласы (яки ставкасы) була. Ул төркиләшкән монголларның күчмә кабиләләрен берләштерә һәм

Иделдән алып Иртешкә кадәр, Каспийдан һәм Аралдан алып Төмәнгә кадәр булган территорияне били. Хакимлек мангыт әмирләренә күчә.

Урдада яши торган нәсел-кабиләләрнең элгәрге генетик бәйләнешләре саклардан, усунь, кангюй, аннары түргеш, карлук, угыз, кимак, кыпчак, аргын, найман, хәзер инде нугайлардан торган казах халкын формалаштыруда турыдан-туры катнашы бар...

Әмма 1554 елда шәһәр кабат җимерелә. Бу юлы инде торгызылмас дәрәҗәдә. Моны Русьтан Җаекка беренче күчеп килүчеләр, нигездә, качкын крепостнойлардан торган Идел казаклары һәм башка криминал элементлар, «бурлыкта йөрүчеләр» эшли. Сәүдәгәрләр үтеп йөри торган Хан ставкасы турында хәбәрдар булган бу адәмнәр Сарайчыкны рәхимсез талый, бар нәрсәне вата-җимерә, шул исәптән тыныч халыкны да үтереп бетерә.

Алар хәтта иң борынгы – Алтын Урда, Нугай Урдасы, Казах ханлыгы заманындагы аксөяк затлар күмелгән зиратның да астын-өскә китерә. Риваятьләргә караганда, анда Алтын Урда ханнары Сартак, Бәркә һәм Җанибәк, Күк Урда ханы Тухтаки, Нугай Урдасы ханнары Измаил һәм Ураза, Казах ханлыгына нигез салучыларның берсе Касыйм хан күмелгән була.

Н.М.Карамзин бу уңайдан: *«Ташта-ташны калдырмадылар һәм, каберләрне казып, мәетләрне чишендереп, бай табыш белән чыктылар»,* – дип яза.

Бу хәлләрдән соң бөтен бу төрки дәүләт юкка чыга: халыкның калган өлеше Урус кенәз белән башта Җаекның түбән агымына (тамагына) таба, аннан Хива якларына китеп бара.

Шунысы кызык: Сарайчыкның җимерелүеннән соң ук патша Иван IV казакларга нәфрәт белән ташлана: аларның бер өлешен Иделдә тар-мар итә, ә ике атаманны – Бритоусов белән Юрьевны Мәскәүдә нугай илчеләре алдында астыра.

Нугайларның китүе бу җирләрне колониальләштерүгә һәм Җаекта беренче казак торак җирлекләрен (авылларын) төзүгә ярдәм итә. Шулай ук монда, Төньяк Каспий буена, күчмә халык – 1630 елда торгоут дигән кабиләсе Иделнең түбән агымына килеп урнашкан калмыкларның килүенә дә сәбәп була.

Җунгарлар (ойрат яки калмыклар) һәм аларның монголларның көнбатыш тармагын тәшкил иткән кабиләләре союзы (бердәмлеге), ул елларда көтүлекләр эзләп, Семиречье, Көнчыгыш Төркестан, Көнбатыш Себердәге ныгытма-шәһәрчекләргә һәм казах җирләренә бөлдергеч һөҗүмнәр ясый-ясый, бөтен җиргә дә үлем һәм хәрәбәләр генә китереп, Җаекка һәм Иделгә килеп чыгалар...

1640 елда Җаек елгасының Каспий диңгезенә койган урыннарыннан уналты гына чакрымда казакларга сиздермичә генә рус сәүдәгәре Гурий Назарьев тарафыннан кызыл балык тоту өчен эре балык промыселы (балык кәсебе) хуҗалыгы – учуг төзү белән бер үк вакытта, башта агач казык читәннән ныгытмалар, ә биш елдан соң укчылар сагындагы каланчалар белән таш коймалар куела.

Ул елларда учуглар, балык промыселы станнары һәм ныгытманың үзе өчен төп куркыныч нугайлардан, каракалпаклардан, калмык, казахлардан килә. Бигрәк тә Тын (Дон), Җаек казаклары, бу ныгытмаларны һәрвакыт камап, һөҗүм итеп тора.

Шуңа да карамастан, Усть-Яик (Җаек Тамагы) таш шәһәрчегенә нигез салучы Михаил Гурьев раславынча, казна 27 ел дәвамында гына да (1640–1667) пошлина һәм Җаек промыселларының уылдык белән тәэмин итүе рәвешендә көмеш белән 500 мең сум саф табыш ала. Ул елларда бу гаять зур сумма була.

Россия патшасы һәм Бөек кенәз Федор Алексеевичның Михаил Гурьевка биргән һәм аны төрле салым-йөкләмәләрдән азат иткән Жалованная Грамотасында әлеге вакыйгалар менә ничек бәян ителә:

*«...Михайло Гурий үзенең балалары, үзенең абыйлары һәм әтисе белән, Безне, Бөек Патшаларны кайгыртып, һәм Безнең Дәүләт казнасына бөтен нәрсәдән табыш эзләп, диңгез аръягында Җаек елгасында үз акчасына таш кала һәм балык тоту өчен учуг төзетте;*

*безнең Бөек Патшалар казнасына шул Җаек учугының яңа заводыннан акча казнасына откупка уылдык промыселыннан һәм пошлинадан барлык шәһәрләрдә дә табыш бик зур булды, алга таба да шул Җаек учугыннан бу табыш Безнең Бөек Патшалар казнасына шулай ук тотрыклы (булыр)».*

Бу шәһәрчектә вакыйгалар алга таба мондый күренеш ала: чирек гасырдан соң Җаек казаклары, бу көнгә инде шактый зур көч булып берләшеп, кирмәнне тулысынча диярлек җимерәләр, чөнки анда төзелгән әлеге учуг аларга югары агымда балык тотарга комачаулый.

1667 елның июнендә шәһәрчекне Степан Разин җитәкчелегендәге Җаек һәм Дон казаклары яулап ала. Мәскәүне борчуга салган нәкъ менә бу поход Россиядә XVII йөз крестьяннар сугышының кереш өлеше, башлангычы була.

Шуның өстенә, Гурьевка барганчы, Разин кирмәннән көньякка таба 60 чакрым ераклыкта диңгез эчендәге Шутовы Шалыги дигән яр буе утравында туктый. Анда Бурдюк (Турсык) шәһәрчеге дип аталган шәһәрчек кора. Баш күтәрүчеләр, бераз монда булганнан соң, тиз арада Җаек шәһәрчеген алалар, чөнки анда урнашкан укчылар гарнизонының якынча 500 укчысы шундук болар ягына чыга.

Дипломатик уңышсызлыкка очраган Әстерхан хакимияте патша таләбе белән Гурьев кирмәнен камап ала. Бу камалыш өзеклекләр белән 1668 елның мартына кадәр сузыла, һәм, ниһаять, Разин үзенең баш күтәрүчеләре белән бергә коралланган 24 ишкәкле көймәдә камалыштан чыга.

Степан Разинның Гурьевтан китүен генә көткәндәй, безнең шәһәрчектә 1668 елның көзендә укчылар һәм казакларның һәм 1698 елның язында ярлы казакларның Әстерхан халкын нык куркуга салган һәм патша администрациясе аяусыз бастырган баш күтәрүләр яңадан кабынып китә. Соңгысы нәтиҗәләре буенча Петр I фәрманы белән казакларның бер өлеше Җаек шәһәрчегендә җәзалап үтерелә, аларның җитәкчесе И.Шамин исә Мәскәүдә аяк-куллары чабылганнан соң җан тәслим кыла...

Шул ук елларда, XVII йөз ахырында, Җаек шәһәрчеге диварлары буенда җирле гаскәри казак атаманнары, башкорт восстаниесе тар-мар ителгәч, каракалпакларга качкан һәм инде үзләренә, Уфа өязенә кайтып баручы меңгә якын коралсыз башкортны суеп чыгалар.

1705–1706 елларда шәһәрчекнең укчылар гарнизоны Әстерхан восстаниесендә катнаша. Алар да фельдмаршал Шереметьевның даими император полклары тарафыннан җиңелә.

1708 елдан соң шәһәрчек үзенә нигез салучы Михаил Гурьев истәлегенә Гурьев дип атала башлый.

Җаек казакларында 1720–1723 елларда мөлкәтле катлаулар барлыкка килүе нәтиҗәсендә казакларның ярлыланган катлавы яңадан баш күтәрә. Хөкүмәт гаскәрләре аны да бастыра.

Казах халкы өчен 1723–1727 еллар бөек фаҗигаләр, һәлакәтләр чоры булып санала – бөтен өч жуз да җунгар баскыннарының коточкыч талавына һәм туздыруына дучар була. Шуннан соң Кече жуз – Хива һәм Каракалпак ягына, Урта жуз Бохарага китә, Олы жуз исә Җунгариягә бәйлелеген, буйсынуын танырга мәҗбүр була.

Шулай да алдагы ике елда казахлар җунгарларны ике мәртәбә җиңүгә ирешә. Халык гаскәрен (ополчениесен) Кече жуз ханы Әбелхәер җитәкли. Аннары ул калмыкларны кысрыклый-кысрыклый Җөм (Эмба) елгасының уңъяк ярына чыга, Уралдагы казак гаскәрләре җирләренә якыная. Һәм шул ук 1730 елда, егерме җиде күренекле старшина тарафыннан хупланып, Җунгариягә каршы Хәрби союз төзү һәм Россиягә кушылу турында сөйләшүләр башлый.

Җаек елгасы 1734 елда Көнчыгышка кадәр сузылган Россия белән казах биләмәләре арасындагы чик ролен үти.

Җаек Емельян Пугачевның крестьяннар сугышы вакытында яңадан Бөтенроссия вакыйгалары үзәгенә әйләнә. Бу сугышта Кече жуз казахлары актив катнаша. Восстаниене бастыргач, 1775 елда патшабикә Екатерина II (Әби патша) Җаекны Урал дип үзгәртә: *«Җаекта булган хәвефле вакыйгаларны бөтенләй оныту өчен»,* – ди ул.

1793–1797 елларда Кече жуз Срым Датов күтәргән восстание ялкынына чума.

1801 елда, барлык бу вакыйгалардан соң, Урал белән Идел елгалары арасындагы түбәнлектә Букей хан Кече жуз казахларыннан яңа ханлык – Россия империясе составына керә торган Эчке яки Букей ханлыгы төзи.

Ханлыкны алимул нәселеннән булган кытайлар, беришләр, шеркеш, адай, жаппас, маскар, ысык, есентемир, байбакты, алаша, тана, кызыл курт, байулы нәселеннән; тазлар, тама, табын, кердери һәм торелар, ягъни жетыру нәселе тармагыннан ханнар династиясе варислары (барлыгы 16 нәсел) тәшкил итә. (*Ш.Кудайберды улы*).

Табигый ки: Россиянең казах һәм Урта Азия ханлыклары белән Көнчыгыш Каспий сәүдәсендә Казан яки Идел татарлары актив катнаша.

Руслар Казан һәм Әстерхан ханлыкларын яулап алганнан соң, Россия хакимиятләренең Казан татарларында сәүдәгәрләрне генә түгел, бу казах далаларында мөселман диненә өндәүчеләрне дә күреп, рәсми тыюларына да карамастан, аларның Каспий буена һәм Урал буена мөстәкыйль хәрәкәте, йөрүе дәвам итә.

Моңа бәйле рәвештә, югары мәгърифәтле, гарәп, фарсы, рус һәм татар телләрен камил белгән, хатыннарының берсе Уфада мөфти булып торган Казан татары кызы булган Букей Урдасы ханы Жангир ханны аерып күрсәтү сорала (1824–1845).

Казанга һәр килүендә Жангир биредә фән, әдәбият һәм сәүдә өлкәсендә кайнаган зыялылар белән очраша.

Казахлар арасында мәгърифәтне тарату эшләрен алып барган өчен хан Казан император университетының Мактаулы әгъзасы булып сайлана.

Ул хакимлек иткән елларда түбәндәге үзгәртеп коруларны санап китеп булыр иде: канцеляриядән, биләр Советы, депутатлар төркеме, хан йомышчылары, есауллардан идарә аппараты төзелә, игенчелек үсеш ала, казах җирендә беренче дөньяви мәктәп ачыла, ярминкәләр үткәрелә. Бу ярминкәләрдә катнашу өчен Казан губернасыннан ел саен сәүдә белән далага ике меңнән артык татар килә торган була.

Нәкъ менә моннан, казах җиреннән, Россиягә ел саен 300 мең сарык, дуңгыз мае, кәҗә мамыгы, сарык, ат, кәҗә, куян һәм корсак тиреләре, дөя йоны, сайгак мөгезләре җибәрелә.

Дәүләт идарәсе системасында ислам диненнән файдалану нияте белән хан мәчетләр төзи, ә муллаларны Казаннан китертә – Казан татарларын чакыра.

Шул ук вакытта әлеге төбәктә яшәгән казах халкы тарихының бу чоры рәсми тарих фәнендә бер яклы гына яктыртыла. Иң әүвәл халыкның Исатай Тайманов һәм Махамбет Үтәмисев исемнәре белән

бәйле (сүз дә юк, алар – үз вакытының күренекле шәхесләре) эчке болганышлары чоры буларак кына телгә алына...

Шул ук елларда православие чиркәве даирәләрендә, алга таба Россиянең яңа төбәген – Сарыроссияне булдыру ниятеннән, казахларны чукындыру планы өлгерә. 1870 елда Халык мәгарифе министрлыгы белдергәнчә, *«безнең ватаныбыздан читтә яшәүче барлык чит халыкларга белем бирүнең соңгы максаты, һичшиксез, аларны руслаштыру һәм рус халкына кушу булырга тиеш», – диелә.*

Казахларны руслаштыру юлында төп киртә булып, Россиянең рәсми даирәләре фикеренчә, аларга татар-мөселман йогынтысы тора. Мәсәлән, Казанның уку-укыту округы попечителе В.Попов күрсәткәнчә, «татарларның күбесе, сәүдәгәр сыйфатында далага килеп, сәүдәгәрлеген «оныта» да укытучы һәм ислам белән татар телен таратучы булып китә.

Шуңа күрә «шәкертләргә» – Казаннан килгән татар муллаларына Букей Урдасында урнашып яшәү тыела».

*«Руслар өчен, аның мәдәнияте өчен дошман булган мондый татар чыганагы зыяннан башка берни дә бирми. Кыргызларны мөселман традицияләрендә тәрбияләү һәм шуның белән биредә татар милләтен булдыру һәм көчәйтү дәүләтебез максатларына туры килми» (А.Харузин).*

Бу сәясәткә расламаны күренекле казах тикшеренүчесе Ч.Вәлиханов хезмәтләрендә дә табып була. Минем карашка, ул, исламны казахларның Европа цивилизациясенә таба хәрәкәтендә тотрык (тормоз) дип санап, православиене кабул итү идеясен үз күргән. 1856 елда ул менә ниләр язып куя:

*«Төрки һәм монгол кабиләләреннән чыккан һәм үзләренең шаманлыгына – жрецлар диненә табынган Себер нормандлары һәм күчеп йөрүче җәнлек аулаучылар холык-фигыльләрендә (характерларында), тормыш һәм телләрендә, Осман төрекләренә һәм Казан татарларына караганда, үзенчәлекләрен күбрәк саклый алганнар. Мөселманлык аларда үзенчәлекнең teләсә нинди чаткысын, милләтлелекне сүндерә... Төрки мөселманнарда дини-схоластик юнәлештәге берьяклылыкны гына күрәсез, башка яктан алар соң чиккәчә надан һәм берниндi эшчәнлеккә сәләтле түгел, ә менә аларның мәҗүси кардәшләре, белемнәре буенча шактый түбән дәрәҗәдә торсалар да, акыл ягыннан күпкә югары...»*

Далада элеккенең яңалык белән көрәше турында сөйләгәндә, ул мондый сорау куя: киләчәктә иминлек өчен ни яхшы – Көнчыгышка йөз тоткан мөселманлыкмы, рус динеме әллә инде элеккечә дин иреген саклап калумы?..

*«Яңа өлгереп, оешып килгән һәм бар нәрсәне кабул итәргә, сеңдерергә әзер кыргыз халкы татар мәгърифәтеннән уй-хисләрнең үсешен тоткарлап торырга гына сәләтле үле схоластикадан гайре ни көтә ала? Без, берниргә дә карамый, татарлык чорын әйләнеп үтәргә, ә хөкүмәт (Россия) бу эштә безгә ярдәм итәргә тиеш. Безнең өчен бу батып баручыларны коткару булган кебек, аның өчен дә шулай ук мәҗбүри».*

Аннан соң, 1862 елда хакимиятләрнең элекке чит халыклар хокукларыннан аларны өстен куючы мещан һәм казаклар катлавына чукынган казахларны да өстәп язуны законлаштырган карарын хуплап, Ч.Вәлиханов болай дип яза:

*«Христианлык мәнфәгатьләрендә мондый әһәмиятле чараны кабул иткәндә, өлкә идарәсенә аның белән бергә исламга карата да репрессив чаралар кабул итәргә кирәк иде, моннан башка христианлыкның уңышы мөмкин түгел».*

Шунысын да әйтик: бары 1914 елгы Беренче бөтендөнья сугышының башлануы гына рус самодержавиесенең һәм аның идеологларының бу ниятен туктатып кала алды...

Шулай да Гурьев шәһәрчегенә әйләнеп кайтыйк әле.

Башта ул Әстерхан, аннары Ырынбур (Оренбург) губернасына керә, ә 1752 елда Җаек гаскәренә кушыла, 1896 елда Урал өлкәсе төзелгәч, иң кечкенә – башта өяз, аннары округ шәһәрчеге булып, аның составына керә. 1865 елда Гурьев шәһәр статусын ала.

XVII–XIX йөзләрдә безнең Урал-Эмба төбәгендә шактый танылган байтак тикшеренүче, галим һәм сәяхәтчеләр булып китә.

Алтын Урда чорыннан соң 1717 елда Петр I фәрманы белән бу төбәкләргә фәнни максатта Бекович-Черкасскийның беренче хәрби экспедициясе килә. Ул географик һәм гидрогеологик белешмәләр, мәгълүматлар калдыра. Биредә танылган галимнәрдән Лепехин (1771), Гельмерсен (1783), Рычков (1772), Паллас (1775), Гмелин (1783) һәм башкалар була.

1850 елда Форт-Александровскига (хәзерге Форт-Шевченко) сөргенгә барганда Гурьевны танылган украин язучысы Т.Шевченко да күреп китә.

1852–1872 елларда шәһәрдә күренекле рус сәяхәтчесе һәм табигать фәннәре белгече Г.Карелин яши һәм эшли.

1857 елда Эмбаның түбән агымында танылган галим Н.Северцев була һәм ул Н.Баршов белән бергә бу төбәкләрдә нефть байлыгы булуын билгели.

1874 елда нефтьнең булуын тәгаенләү өчен Д.Кирпичников тикшеренүләр үткәрә; 12 елдан соң – тау инженеры Новаковский, 1890 елда – Г.Грумм-Гржимайло, 1892 елда геолог С.Никитин җитәкчелегендәге Геология комитеты экспедициясе булып китә.

XIX йөз ахырында, 1897 елда, ягъни 100 ел элек, гомуми мәйданы 40435,4 кв/чакрым (верста) булган территориядәге бөтен Гурьев округында, шәһәрдәгеләр белән бергә, даими рәвештә 87376 кеше яши.

Аларның 44882 се – ир-егет, 42494 е – хатын-кыз.

Милли составы – күбесенчә казахлар, татарлар, калмыклар, аннары руслар.

Гурьев шәһәрчегенең үзендә 9316 кеше яши, аның яртысы казак катлавы.

Шәһәрдә 25 койка/урынлык, кабул итү бүлмәсе белән хастаханә, дарухanә, ветеринария лабораториясе бүлеге, мал-туарны дәвалау бүлеге, почта-телеграф һәм балык-пошлина конторлары эшли. Алмашу йорты да була. Анда шәһәр халкы белән казахлар арасында сәүдә, дөресрәге, терлек һәм терлекчелек продуктларын ипигә һәм иң кирәкле башка әйберләргә алмашу барган. Ярминкәләр үткәрелгән, ике сыйныфлы шәһәр училищесы, диңгездә йөзү класслары, башлангыч белем бирүче мәктәп эшләгән. Әстерхан белән пароход элемтәсе булган.

Шәһәр халкы балык тоткан, бакчачылык белән – йөзем, алма, груша, персик, чия, абрикос үстерү белән шөгыльләнгән.

Гурьев округының җир өсте – тозлы күлләр һәм чүп үләне «сибелгән» комлы һәм тозлы туфраклы киң дала. Төп сугару чыганагы – Урал елгасы. Бөтен торак җирләр диярлек шул елга буйлап урнашкан.

4,25 млн. дисәтинә җирнең 80820 дисәтинәсе генә яшәү өчен уңайлы саналган. Аның 333 дисәтинәсе – биләмәләр; 420 дисәтинәсе – җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы; чәчү җирләре – 186 дисәтинә; урманнар – 4069, ә болын һәм печәне чабыла торган җирләр – 75044 дисәтинә.

Бу якларга килеп утырган русларның чәчү мәйданы – 40 дисәтинә, ә казахларныкы исә 9554 дисәтинә булган. Бу җирләрдән 1898 елда төрле ашлык уңышы 600 мең потка кадәр яки 9 мең 828 тонна икмәк (!) җыеп алынган. Моннан тыш, русларның җирләреннән 2200 пот яки 36 центнер бәрәңге җыелган.

Төп шөгыль – Урал елгасында балык тоту. Аннан 3,25 млн. сумлык балык тотылган, терлекчелек шулай ук нык үскән була – барлыгы 1 млн. 206 мең 176 баш терлек исәпләнгән.

Аларның русларга – 5638 е, казакларга – 438560 ы, ә казахларга 761978 е туры килгән.

XIX йөзнең ахыргы елында, әүвәл июнендә, аннары ноябрендә, Кара Шунгул дигән җирлектә беренче мәртәбә нефть фонтаннары бәреп чыга.

Леман компаниясенең нефть чыгаручылары нефтьне махсус турсыкларда дөяләргә төяп Хивага һәм алга таба реализацияләү һәм ягулык сыйфатында куллану өчен Каспий яры буйлап Ракуша портына җибәрәләр...

XX йөзгә Гурьев округы менә шундый уңышлар белән килеп керә. Тиздән аның территориясендә урнашкан Жилая Коса бистәсенә Кәримовлар да килеп урнаша.

## 2. ЖИЛАЯ КОСА

Бүгенге көндә юкка чыккан, ә XIX йөз ахырында, төче сулы Эмба елгасы тамагында, Каспий диңгезенең төньяк-көнчыгышындагы сай сулы ярында җайлы гына урнашкан бу бистә шулай дип аталган. Аның шулай җайлы урнашуы биредә балыкны беренчел эшкәртү процессы белән чагыштырмача куәтле балык промыселлары үсешенә этәргеч ясаган.

Беренче вакытта нигездә Әстерхан балыкчылары килеп урнашкан яр буе диңгез борыны (коса) Жилая Коса дип аталган, әлеге бистә урнашкан җирне җирле төп халык Кен Жылы-ой, ягъни Киң, Җылы култык дип йөрткән.

Ә соңрак бу исемнәр, Жилая Коса да, Жылы-ой да, төрле вакытта барлыкка килгән административ-территориаль субъектларга – волость һәм районнарга кушыла килгән.

Тарих фәннәре докторы Х.Табылдиев мәгълүматларына караганда (Мәскәү шәһәре архивына сылтама белән), Жилая Коса 1878 елда төзелә башлый. Беренче килеп утырган кешеләре Степанов белән Григорьев була.

Әгәр элекке шәһәрчек, христиан һәм мөселман (нугай-казах) зиратлары калдыклары буенча фикер йөртсәк, монда торак хуҗалыкларының әлеге датадан элегрәк төзелгән булуы һәм бу хуҗалыкларда рус, татар һәм казах халкы яшәве, шулай ук башка халыкларның – австрияле һәм азәрбайҗаннарның да булуы турында сөйләп булыр иде.

Шулай итеп, әгәр боларның барысын да һәм биредә яшәгән аксакалларның истәлекләрен, шул исәптән безнең туганнарның риваять-хикәятләрен бергә җыйсаң, түбәндәге күренеш барлыкка килә: бу шәһәрне XIX йөзнең 60 нчы елларында руслар төзи башлый. Сөйләүләргә караганда, шәһәр диңгез ягыннан матур булып күренеп торган. Ул вакытта барлык хәрәкәт, йөк ташу бары тик диңгез юлы

буйлап кына гамәлгә ашырылган. Биредә яшәүче руслар бер-ике катлы торак йортлар һәм шактый зур итеп таш чиркәү салып куйганнар. Алар ике урам тәшкил иткән. Шәһәрчекне Жилая Коса дип атаганнар. Руслардан соң бирегә төрле шәһәрләрдән (Әстерхан, Казан, Ырынбур) татарлар килә башлаган. Казахлар аларны нугайлар дип атаган. Алар бу хәлгә тыныч караганнар, тискәре реакция булмаган. Татарларның өйләре шулай ук ике-өч урам тәшкил иткән. Алар мәчет белән мәдрәсә төзеп куйганнар. Татарлар арасында, нигездә, сәүдә, балык тоту һәм терлекчелек белән шөгыльләнүче байлар күбрәк булган.

1912 елда Гурьев өяз үзәгенә әйләнгәннән соң, Жилая Косаның статусы да үзгәргән – Жилин волосте дип йөртелә башлаган.

Ул чакларда биредә 300 гаилә, 1943 кеше яшәгән, 73 сәүдә лавкасы эшләп торган, төп шөгыль шулай да балык тоту булган. Үз вакыты өчен ул Гурьев өязенең шактый зур торак пункты булып саналган.

1911 елдан соң, ягъни бу якларда Урал-Каспий нефть җәмгыяте, чит ил капиталы белән «Нобель» җәмгыяте һәм башкалар тарафынан нефть ятмаларын сәнәгати үзләштерү башланганнан соң, әлеге волость үзәгенең әһәмияте дә үзгәргән: хәзер инде ул балыкны Әстерхан аша Россиягә һәм аннан да ераккарак җибәреп кенә калмыйча, якын тирәдәге нефть промыселларына да озаткан, чөнки бирегә Бакудан һәм башка сәнәгый төбәкләрдән беренче эшчеләр җыела башлаган. Анда, Гурьев өчен эшче сыйныф формалашып, 1913 елда алар Доссорда беренче забастовка да күтәрәләр. Аны бастыру өчен Уральскидан губернатор Мордвинов үзе килеп җитә...

Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Эмба төбәге нефть чыгару буенча, Баку белән Грозныйдан кала, Россиядә өченче урында тора.

Жилая Косага әйләнеп кайтыйк.

XIX йөзнең ахырында биредә яшәгән, танылган совет язучысы Ф.Гладков үзенең «Вольница» дигән повестенда аның турында менә ниләр яза: «*Октябрь башының кояшлы көннәре. Күк йөзе шундый йомшак, зәңгәр, шундый якын һәм шуның өстенә гаҗәп җылы кебек тоела. Һава коры һәм яңгыравык, ә офыкта көзгедәй ялтырап тора. Диңгез ерактан күзләрне чагылдырып җемелди һәм комлы сай җирнең сары шадралары, җыерчыклары артыннан хыялдагы нindидер бер сәер нәрсә булып күренә. Бик еракта офыкта балыкчыларның ак җилкәннәре җилферди. Әйтерсең алар, кояшта җылынып, бер урында туктап калганнар. Диңгез өстендә акчарлаклар өере тирбәлә.*

*Безнең промысел казармалары – бистәнең комлы урамы очында, ә алар артында алтын көртләр һәм кинәт туктап калган дулкыннар булып, рәшәдәй җемелдәп, офыкның үзенә кадәр ком җәелгән...*

*Менә шул калкулык һәм көртләрдә якты таплар булып ниндидер куаклыклар һәм чәнечкеле үләннең тыгыз бәйләме яшелләнеп утыра. Бу каты һәм зәһәр үлән бөтен җирдә – урамда да, ишегалдында да, хәтта казарма һәм сарайларның камыш түбәләрендә дә үсә. Әлеге чүл комы арасында барханнар итәге буйлап сарык көтүенең утлап йөрүен күрү гаҗәп тә, сәер дә...*

*Бу ком өстеннән көн саен берсе артыннан берсе ниндидер уйга чумган дөяләр атлый.*

*Курганнар өстендә, түбәндәрәк тилгәннәр әйләнә...*

*Урам аша, озын агач койма артында гаҗәп киң урам булып безнең промысел җәелгән.*

*Диңгез ягыннан ул ачык һәм сөзәк битләү булып яр буе комлыгына төшә. Уң якта камыш диварлы, бер-беренә сыенып торган лабазлар, ә алар артында дүрт рәт булып тезелгән баганалардагы ике кыеклы камыш түбә астында киң сал тора...*

*Урам бистәнең үзәгенә таба шактый еракка сузыла һәм киң мәйданга чыга.*

*Анда камыш түбәләр өстеннән зәңгәрсу-күк каланча тырпаеп тора. Яр буе ягында төрле хуҗаларның балык промыселлары бер-беренә сыенып утырган, ә икенче ягында озын казармалар һәм такта коймалар сузылган.*

*Бистә шактый зур. Базар аның нәкъ уртасында булып, якшәмбе көннәрендә анда халык кайнап тора.*

*Биредә агачтан һәм балчыктан салынган шактый төзек өйләр, тәрәзә капкачлары матур итеп буялган, тәрәзләрдә матур пәрдәләр, төпләрендә чәчәк атып утыручы гөлләр, капкалар ике кыеклы түбә белән эшләнгән. Мәйданның ике ягыннан биек болдырлы бишпочмаклы ике өй кукраеп утыра. Берсенең кәрнизенә – «Мәктәп» дип, икенчесенекенә «Волость идарәсе» дип язылган...*

*Лабазларда ике рәт булып хәйран киң түгәрәк чокырлар – тирән итеп җиргә күмелгән түгәрәк чаннар «акаеп» тора. Бу чаннарда эшчеләр озын колгалар белән тозлык (тузлук) – нык тозлы эретмә болгатып торалар. Аннары шунда тачкалар белән вобла китереп бушаталар».*

Балык тоту вакытында рус промышленниклары эшчеләрне Әстерханда җыеп, аннан соң диңгез юлы белән баркасларда, баржа һәм судноларда Жилая Косага алып килгәннәр.

Төп халык – казахларны Россия хакимиятләре ни диңгезгә, ни төче сулы Эмбага, ни сусыл үлән үскән ерикларына якын җибәрмәгәннәр. Аларның барысы да кайчандыр төп халыкныкы булган да бит югыйсә.

Ә хәзер алар, бу комлыкларда ачтан үлмәс өчен, балыкны да яшереп кенә тотарга һәм арык малларын да яшереп кенә ашатырга мәҗбүрләр.

Һәм картлар, элекке иркен тормышны исләренә төшереп, үзләренең моңлы җырларында үзләренә кайчан да булса иреклe, иркен тормышны кайтаручы Батыр турында хыялланганнар...

**3. КӘРИМОВ МИФТАХЕТДИН**

1862 елда туган безнең бабабыз сәүдәгәр була. Үзенең шәхси эшен зурайту, үстерү ниятеннән XX йөз башларында Казаннан үзенең яшь хатыны – безнең әбиебез белән бу якларга килеп чыга һәм Каспий яры буендагы Жилая Коса бистәсендә диңгез балыгы промыселын оештырып җибәрә. Шуңа өстәп эре терлекчелек хуҗалыгын булдыра һәм сәүдә лавкалары, кибетләр ача.

Жилая Косаның үзәк бер җирендә, Олы Базарда, 12 бүлмәле, зур ишегалды һәм балык тозлау өчен, кош-кортлар һәм мал-туар өчен хуҗалык корылмалары, склад бүлмәләре һәм көндәлек товар өчен склад белән ике катлы гаҗәп иркен йорт салып куя.

Аның туганы – үзе белән бергә килгән ике туган абыйсы Химади (Гыймади) Караозек елгасында балык кәсебе белән шөгыльләнә һәм анда балык эшкәртү өчен лабаз куя. Күргән-белгәннәр сөйләве буенча, шәһәрчекнең бөтен үзәк өлешен һәм соңга таба Красноармейская дип аталган янәшә урамның бер почмагын аларның йортлары һәм кибетләре били.

Бабай диңгез, елга һәм коры җир юллары буйлап төрле юнәлешләргә Каспий балыгының байтак төрләрен төяп җибәрә, ә бу якка, беренче чиратта Казаннан, мондагы халыкка кирәк булган китаплар һәм мануфактура, сәнәгать товарлары кайтарта. Һәм билгеле бер вакытка кадәр мөхтәрәм һәм абруйлы кеше була, чөнки ул балык тоту вакытына гына килми, ә бәлки иң якын туганнары белән биредә төпләнеп кала.

Эшчеләрне дә Әстерханнан ялламый, җирле халык белән эш итә, ягъни үз эшчәнлеге белән бистәне үстерүгә дә өлеш кертә, ә китаплар – басма әдәбият кайтартып, мондагы халыкны мәгърифәтле итә.

1870 еллар уртасында әбиебезне күрергә дип Гурьевка килгән (Жилая Коса кешеләре раславынча) Мифтахетдин Габбар улы Кәримов, үзенең төпле булуы һәм эшкә нәтиҗәле мөнәсәбәте белән танылган шәхес буларак, татар мохитенә генә түгел, бу шәһәрчекнең революциягә кадәрге салмак тормыш тәртибенә дә үзенчәлекле бизәк (колорит) өсти.

Жилой районының танылган сугыш һәм хезмәт ветераны А.Аманбаев аның турында менә ничек яза: *«Мөфти атай, өлкәннәр сүзе буенча, безнең төбәк халкы арасында, казахлар арасында гаять зур хөрмәт һәм абруйга ия иде.*

*Күренекле терлекче булып саналды. Бик күп ат, сыер, көтү-көтү сарык тотты.*

*Бай булды, әмма карун булмады – Атымтай-жомарт кебек (ислам риваятьләрендәге герой) юмарт булды.*

*Үзенең терлекче казахларын беркайчан да рәнҗетмәде. Аның терлек караучысы булып Шеркеш нәселеннән Терекбай уллары (Дербис (Каракемпир) тармагы – Макаш хаким нәселе) эшләде. Терекбайның Киюша (агай) дигән улы хезмәте өчен ел саен 100 әр сарык алуы турында искә төшереп сөйләргә ярата иде.*

*Мөфти атай һәр җәй саен Җөм (Эмба) елгасы буена зур тирмә куеп, анда ял итәргә ярата, кымыз һәм казахларның башка ризыкларын тәмләп ашый-эчә иде. Казаннан һәм Әстерханнан килгән кунакларын да һәрвакыт җылы каршылый, шундый ук мөнәсәбәт илә озатып кала иде».*

Бу һәм башка истәлекләр буенча ул көчле характерлы, бай һәм аягында нык басып тора торган кеше була. Бары үз көченә нык ышанган, җитәрлек күләмдә капиталы (байлыгы) булган һәм үзе бара торган төбәкнең перспективасын яхшы белгән кеше генә әле үзләштерелмәгән бу якларга бөтен гаиләсе белән күчеп килергә, аннары хәзерге Стахеев, Леман һәм Нобель үрнәгендә үз капиталын алга таба территориясендә уникаль нефть һәм газ запаслары тупланганы билгеле булган районның табигый байлыкларын үстерүгә кертергә батырчылык итә алган...

Бабайның абыйлары, әбием әйткәнчә, ул елларда Россия, Урта Азия һәм Казахстанда мәгърифәт һәм мөселман дөньясында шактый танылган була. Алар аерым игътибарга лаек.

Мөхәммәтҗан белән Шәрифҗан Кәримовлар, Уфадагы һәм Казандагы мануфактура, сәүдә лавкаларыннан тыш, үз исемендәге типография дә ачалар. Анда мөселманнарның изге китабы Коръән, ул еллардагы мәгърифәтчеләрнең хезмәтләре басыла.

Бертуган Кәримовлар типографиясендә, мәсәлән, бөек казах шагыйре һәм акыл иясе Абайның поэмаларыннан берсе, С.Сәйфуллинның «Узган көннәр» дигән беренче шигырьләр җыентыгы, дини-дидактик, фәнни-популяр, матур әдәбият, публицистик һәм тарихи әдәбият, дәреслекләр, сүзлекләр, газеталар татар, гарәп һәм рус телләрендә басыла. 1901–1917 елларда алар 20 милион (!) данә китап бастырып чыгаралар.

Алар милли татар интеллигенциясенең типик вәкилләре була: Татарлар Мәҗлесе утырышларында чыгышлар ясый, Стокгольм һәм Истамбул белән швед, француз, төрек телләрендә язышалар; мөгаен,

Казан губернаторы һәм губерна жандарм идарәсе, Казан полицмейстеры күзәтүенә нәкъ менә шуның өчен алыналардыр. Ике туган берничә мәртәбә тентүгә дучар ителә. 1991 елда мин соратып алган Татарстанның Үзәк дәүләт архивы мәгълүматлары моны шулай ук раслый.

Империяләргә милли интеллигенциянең чын вәкилләре, хакимнәрнекенә охшамаган, туры килмәгән карашлы кешеләр бервакытта да яраклы булмаган.

Аларның карашы һәм гамәлләре хакимиятләргә элекке, патша режимында да, яңа, Совет режимында да ярашмаган. Шуңа күрә әбием хатирәләреннән чыгып шуны әйтә алам: октябрь вакыйгаларыннан соң алар Россиядән Франциягә күчеп китәләр. Сенная (хәзерге Г.Тукай) урамындагы типографияләрендә яңа хакимиятләр инде Казанның РСДРП(б) органы – «Рабочий» газетасы басыла башлый...

Әбиебез исә, Кәримова Маһибәдәр, кыз фамилиясе Дәүләтгәраева, 1890 елда Казаннан 60 чакрым ераклыктагы Кушлавыч авылында, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга кардәш булган Гәрәй һәм Ганиянең күп балалы крестьян гаиләсендә туа.

Җиде баланың барысы да – соңлап туган балалар. Әбиебез кияүгә чыгып киткәннән соң, алар да аның артыннан башта Гурьевка, аннары Жилая Косага күченеп киләләр һәм шунда үз гаиләләрен коралар.

Ә менә әбиемнең әнисе күпмедер вакыт Әстерханда үзенең икенче кызы Мөхетдинова Майшәкәрдә яшәп ала.

Шагыйрь Габдулла Тукай белән кардәшлекне әбием һәм башка туганнарның истәлекләре раслый. Мәсәлән, аларның берсе Бөек Ватан сугышында катнашкан пенсионер Вәкил Мөхетдинов болай дип язган иде: *«...без Габдулла Тукайның ерак туганнары, ул безнең авылдан... Г.Тукайны тәрбияләгән икетуган апа аннан соң Гурьевта без дәү әти дип йөрткән Гыйззәт абыйларда яшәде. Ул минем әтиемне дә (Абдулланы) Казаннан алып килде».*

Үз чиратында Г.Тукай да 1956 елда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган татар телендәге әсәрләренең 4 томлыгына кертелгән хатларының берсендә (якынча 1902 елда язылган) Гурьевта бай кардәшләренең булуы, аларның 15 сум акча бирүләре һәм шул акча ярдәмендә мәдрәсәгә кереп, инде укып йөрүе хакында яза...

Язмыш кушуы буенча, безнең әни ягыннан булган икенче бабабыз – 1878 елда Бәшир дигән татар авылында дөньяга килгән Мөхәммәтгариф Габдрәхип улы Тулбаев та хәзерге Казахстан территориясенә килеп чыга.

Үзенең әтисе (безнең бабабызның әтисе булып чыга инде) эзеннән китеп, рухани була. Ул чактагы Россия империясенең башкаласы Санкт-Петербургта югары дини белем алып, Төркиядә – Истамбулда тәҗрибә туплаганнан соң ул Уральск шәһәренең өч мәчетләренең берсенә – татар тыкрыгындагысына, соңыннан билгеле булганча, указлы соңгы мулла (имам) итеп җибәрелә.

Калган ике мәчетнең берсе Куреньдә, икенчесе Югары Базарда була. Ә ул мулла булган кызыл кирпечтән төзелгән мәчет үзләре яшәгән өйнең янәшәсендә генә була. Яннарында гына Чаган елгасы аккан һәм Ханнар урманы шаулап торган...

Шунда ук, мәчетнең үзендә мәдрәсә дә була. Анда дини фәннәр генә түгел, грамота һәм башка гомуми белем бирүче фәннәр дә укытыла. Дәресләр, дин кушканча, аерым алып барыла: малайлар – беренче катта, кызлар икенче катта укый.

Бу мәдрәсәне тәмамлаучылар арасыннан Урал татар интеллигенциясенең үз мөгаллименә олы хөрмәт белән караган байтак вәкиле чыга. Соңыннан, сугыш башлангач, алар үзләренең өлкән сыйныф укучылары белән фронтка китә һәм кайберләре «халык дошманы» рәтләрен тулыландыра...

Дәресләр үткәрергә ул чакта аңа безнең әбиебез, әниемнең әнисе Тулбаева (Исхакова) Гөлсем Хәби кызы булыша. 1893 елда гади татар гаиләсендә туган әбиебез Уральскига килгәнче, үзе әйткәнчә, Кенәз бистәсендә (хәзер шул ук Көнбатыш Казахстанның Калмыково бистәсе) яши.

## 4. УНҖИДЕНЕҢ БӨЕК ОКТЯБРЕННӘН КЫРЫК БИШНЕҢ БӨЕК ҖИҢҮЕНӘ КАДӘР

Әмма 1917 елның Октябрь инкыйлабы минем бабаларым язмышын, миллионлаган кешеләрнеке кебек үк, тамырдан үзгәртә: андагы берничә буынны, гамәлдә бүгенге көннәргә кадәр, хөкемдарлар, хакимнәр каршында хокуксызлыкта тигезләп куя.

1920 елның гыйнварында Жилая Косаны эшче-крестьян Кызыл Армиясе отрядлары алганнан соң, Кәримов Мифтахетдинның бөтен мөлкәте национализацияләнә. Икенче төрле әйткәндә, Гурьевта яши торган Гыймади абыйсыныкы кебек конфискацияләнми, ә «үзирек тапшырыла», ул шуңа күрә алга таба сайлау хокукыннан мәхрүм ителми. Ул елларда гаиләнең барлык әгъзасы өчен дә бу хокук иң мөһим фактор була.

Бу урында әлеге елларда Каспий буенда барган тарихи вакыйгаларны ачыклап китү кирәк дип саныйм.

1917 елның 9 маенда Гурьевта барлыкка килгән эшче һәм солдат депутатлары Советы 1918 елның 23 мартында контрреволюцион казаклар һәм акгвардиячеләрнең хәрби хөкүмәте тарафыннан тар-мар ителә.

1918 елның 9 июленнән 10 июльгә каршы төнендә Пешный ярымутравында Гурьевның беренче совет депутатлары һәм биш Әстерхан делегаты атып үтерелә.

1919 елның мартыннан 1920 елның гыйнварына кадәр Урал буе һәм төньяк Каспий территориясендә үзен Уралның гаскәри атаманы дип игълан иткән генерал-лейтенант В.Толстов режимы урнаштырыла. Элек ул Колчакка, аннан Деникинга буйсына.

1918 елның кышыннан «башкаласы» Гурьевта булган хәрби диктатураның социаль нигезен Урал казакларының өстен катлавы һәм сәнәгати буржуазия тәшкил итә. Шунда ук инглизләрнең майор О'Брайен җитәкчелегендәге хәрби миссиясе, «Коткару комитеты» һәм «Фронтовиклар союзы» – В.Толстов оештырган хәрби-монархистик оешмалар урнаша. Ул шулай ук инглизләрнең диверсия хезмәте үзәге булып торган Урал-Каспий нефть җәмгыятен дә җитәкли.

1918 елның апрелендә эшчеләрне бастыру өчен Толстов казаклар отряды белән автомобильдә килеп, Доссор промыселларында була һәм кинотеатрда митинг үткәрә. Аннан соң Гурьев казнасының алтын запасын төяп алып, инглизләр корал, амуниция һәм броневиклар җибәрсен өчен, аны Бакуга озата.

Әмма Кызыл Армиянең М.Фрунзе җитәкчелегендәге Төркестан фронтының 1919 елның ноябрь – 1920 елның гыйнвар аралыгында үткәрелгән һөҗүм операциясе Толстовның Урал армиясен һәм «Алаш Урда» гаскәрләрен тар-мар итә.

1920 елның 5 гыйнварында И.Бубенец җитәкчелегендәге 25 нче Чапаев дивизиясенең кавалерия бригадасы – Гурьевны, 8 гыйнварда – Доссор бистәсен, 10 гыйнварда Жилая Коса бистәсен ак казаклардан азат итә. Толстовлылар штабы инглиз корабларында Гурьевтан Красноводскига, ә калган акгвардиячеләр, ат менеп диңгез яры буйлап китеп, Төрекмәнстан аша Иранга чыга.

Жилая Косаны азат итүдә катнашкан Н.Коноплев ул чакта Совет иленең иң югары бүләге – Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

1920 елның 20 августында В.Ленин һәм М.Калинин кул куйган РСФСР составында «Автономияле Кыргыз (казах) Совет Социалистик Республикасын төзү турында» ВЦИК һәм РСФСР ХКСы декреты казах халкының киләчәге һәм яңа шартларда аның дәүләтчелеген формалаштыру өчен гаҗәп зур сәяси әһәмияткә ия вакыйга була.

Жилая Косадагы инде гадәткә кергән тормыш рәвешен бик тиз җимерсә дә, Совет власте монда, утызынчы елларга кадәр сузылып, зур авырлык белән генә урнаша. Төп авырлык – коммунистларның аз булуы һәм терлекчелек белән шөгыльләнүче җирле халыкның күчмә тормышы.

1920 елда теркәү участогы башлыгы Лещинский: *«...кайбер авылларда бүгенге көнгә кадәр Советлар оештырылмаган һәм бернинди дә власть юк»,* – дип яза.

Беренче мәлдә, кызыллар килгән вакытта, биредә 15 коммунист булган булса, 1922 елда партия ячейкасы гомумән таркала. Ул бер елдан соң гына бары өч кеше составында кабат оеша.

Бер үк вакытта шуны да исәпкә алырга кирәк: 1921 елның июнендә безнең төбәкне үз эченә алган Урал губкомы РКП(б)сы Урал бүлеген КАССРдан аеру турындагы мәсьәләне карап тикшерүгә куя. Әмма аны РКП(б)ның Үзәк комитеты Кирбюросы хупламый...

Тиздән Совет власте Казахстан халыкларының киләчәк язмышы өчен мөһим карар кабул итә: 1924 елда Урта Азияне милли дәүләтләргә ызанлап бүлү казах җирләрен берләштерүгә китерә, ә 1925 елның апрелендә халык этнонимы – казах яңадан кайтарыла. Дөрес, русча әйтелеше белән.

1925 елда Жилая Косада партия ячейкасы секретаре, вакытлыча килеп эшләүчеләр арасында бернинди дә пропаганда эшләре алып барып булмый, чөнки алар рус телен белми, шуның өстенә, сезон беткәч, бөтен җирле халык, волость башкарма комитеты белән бергә далага күчеп китә, аннан кышка гына кайта, дип хәбәр итә.

Моннан тыш, хуҗалыкларны торгызуга һәм эшләрне башкаруга 20 нче ел ахыры һәм 30 нчы ел башларында котырынган корылык белән ачлык кына түгел, ә бәлки күрше Адай өязе халкының моннан һәрвакыт күп санда терлек куып алып киткән һөҗүмнәре һәм талаулары да зур каршылык булып тора. Бу бәрелешләр ун ел буе дәвам итә һәм кайчакларда алар җирле халыкны үтерү, хатын-кызларны урлап китү белән тәмамлана.

Шул ук вакытта далада җирле бандалар да хәрәкәт итә: талый, үтерә, җимерә.

Яңа властьлар шулай ук зур авырлык, зур югалтулар һәм һәлакәтләр белән урнаша.

Мәсәлән, 1928 елдан 1931 елга кадәр салым җыю, байларның мал-мөлкәтен конфискацияләү һәм коллективлаштыру барышында биредә районның байтак җитәкчесе – район башкарма комитеты рәисе урынбасары, башкарма комитетының җаваплы секретаре, финанс бүлеге һәм район милициясе башлыклары, терлекчелек бергәлеге хезмәткәре һәм башка вәкаләтле хезмәткәрләр үтерелә.

1928 елның июнь-гыйнвары өчен округ комитетының мәгълүмати хисабында күрсәтелгәнчә, биредә *«...иң кыргый, артта калган күчмә хуҗалык халык хуҗалык итү рәвешен үзгәртүгә, аны рациональләштерүгә омтылмый да...»*

Шулай булса да, Жилая Косада Совет власте, бөтен җирдәге кебек үк, зур каршылыклар белән, әмма һичшиксез алга таба бара.

Жилая Косада уздырылган Беренче Май бәйрәмнәренең беренчеләреннән булган берсендә Өяз комитеты вәкиле Крапивицкий менә болай ди: *«1 майда халык сәгать 12 дә кузгалып китте, барлык предприятиеләр дә җыелу урынына юнәлде, бу йөрештә 1000 гә якын кеше – мөселман, кыргыз һәм руслар катнашты. Бару юлында берничә тукталыш булып аларда ораторлар чыгыш ясады, хор «Интернационал»ны башкарды.*

*Йөреш көндезге 4 тә тәмамланды. Шуннан соң балаларны сыйлау, мәктәп бинасында бүләк өләшү тантанасы булды. Балаларның шатлыклы йөзләре барысына да уңай тәэсир итте. Аннары спектакль күрсәтелде, кыллы оркестр уйнады».*

Тиздән биредәге барлык балык промыселлары берләштерелеп, беришесе – Урал-Каспий трестына, икенчеләре балык сәнәгате буенча кредит ширкәтенә кертелә.

1930 елның 9 февраленә районда 121 хуҗалыкны берләштергән дүрт балык тоту колхозы оеша, аның өчесе – Жилая Косада, берсе Прорвада була.

Авыл хуҗалыгы артельләрен торгызу эшләре дә бара. 1928 елда конфискацияләнгән 431 хуҗалык базасында 1785 кешене үз эченә алган утыз колхоз оеша.

1934 елга халыкның инде 89,6 проценты колхозларга керә.

Жилая Коса районының булачак нефть мәйданнарында (аның территориясендә киләчәктә дөньядагы иң зур нефть-газ ятмаларының берсе – Тенгиз ятмасы ачыла) зур тизлек белән разведка-эзләнү эшләре алып барыла башлый. Ул чакта әле Казахстанның иң беренче ятмасы Карашунгул, аннары Каратон, Иманкара һәм Коечагыл ятмалары була, 1932 елда алардан нефть фонтаны бәреп чыга*.

Районның Совет власте җирле халыкны грамоталы итү өчен зур көч куя.

Әгәр 1920 елда укый-яза белгәннәрнең саны бары өч процент кына булса, 1926 елда исә бу күрсәткеч 19,4 процентка җитә. Хатын-кызларның белемлелеге искиткеч дәрәҗәдә түбән була.

Ул елларда киң таралган мәдәни-агарту учреждениеләре – уку йортлары (изба-читальня) һәм кызыл юртлар, шулай ук «Наданлыкны бетерик» дигән оешма.

1928 елда биредә мәктәп яшендәге бөтен баланың 13,1 проценты гына укыса, җиде районда беренче баскыч мәктәпләр саны бары дүрт кенә булса, 1932 елда исә беренче баскыч мәктәпләр утыз тугызга җитә. Өстәвенә биш балалар бакчасы, биш акушер-фельдшер пункты, дүрт клуб, ике хастаханә һәм бер даруханә ачыла.

Безнең бабабыз, Кәримов Мифтахетдин, яңа власть урнашкач, ни җәмәгать тормышында, ни икътисади тормышта катнашмый. Үз гаиләсен ничек тә туйдыру өчен ат белән кеше ташучы (извозчик) булып эшли. 1932 елда шунда ук, Жилая Косада ул дүрт баласын: Әдһәм, Гөлбахрам, Гөлчирә һәм кече улы, минем әтием Әкрәмне калдырып үлеп китә.

Сүз уңаеннан: Казанның соңгы ханы, Сөембикә ханбикәнең абыйсы Али Әкрәм* була. Ә безнең әбиебез, алар турында күп нәрсә белгәнгә, ханбикә турында да, Мамай хан турында да, Кушлавыч авылы, гомумән, Совет заманына караганда, инкыйлабка кадәрле тормыш турында күбрәк сөйли иде.

Гражданнар сугышы елларында Уральскида да давыллы, даулы вакыйгалар булып тора: шәһәр берничә мәртәбә әле кызылларга, әле акларга күчә. Аннан китә коллективлаштыру, индустрияләштерү һәм «халык дошманнары» белән көрәш.

Руханиларны, дин әһелләрен Сталин режимы күпләп репрессияли башлагач, Тулбаев Мөхәммәдгариф, Уральскидагы пединститутта гади каравылчы гына булып эшләсә дә, Көнбатыш Казахстан өлкәсе буенча НКВД идарәсе тарафыннан кулга алына.

1940 елның 23 октябрендә, Советка каршы сүз сөйләде дип, ул чакта инде көйләнгән гадәт буенча кемнеңдер әләге белән аны төн уртасында өеннән алып китәләр.

Аннары СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмәнең 1941 ел, 21 май карары белән сәяси сәбәпләр аркасында (58 ст. – 10.1 кисәк), ягъни «халык дошманы» тамгасы белән Тулбаев Мөхәммәдгариф аралашу, язышу хокукыннан мәхрүм ителеп, Үзбәкстанга биш елга сөргенгә озатыла. Анда ул 1942 елның 28 гыйнварында Үргәнеч шәһәрендә үлә. Уральскида биш баласы – Рафик, Фоат, Рауза (безнең әниебез), Әминә, Әсма ятим булып кала.

Бары тик 1964 елның 16 ноябрендә генә Уральскиның өлкә суды Президиумы карары белән СССР НКВДсы каршындагы Махсус киңәшмә чыгарган элекке карары гамәлдән алынып, безнең бабабыз үлгәннән соң аклана һәм, аның эшләрендә җинаять составы булмау сәбәпле, җинаять эше туктатыла.

Җирле хакимият исемнәре үзгәртелгән Г.Тукай һәм 8 Март урамнары почмагындагы аның мәчетен башта склад, аннары ФЗУ (фабрика-завод училищесы) итә... Монда әле берара милли-кулланма сәнгать мәктәбе дә булып ала, ә хәзер ул бөтенләй ташландык хәлендә.

Нәтиҗәдә Тулбаев Гариф әлеге мәчетнең соңгы имамы булып кала...

Безнең белемле, эшлекле һәм үз вакытының алдынгы карашлы, зыялы (цивил) затлары булган менә бу ике бабабыз яңа власть «булышлыгы белән» берсе – олаучы, икенчесе каравылчы булып эшләргә мәҗбүр була.

Алар бер-берсен беркайчан да белмәгән, күрмәгән һәм киләчәктә дә күрергә насыйп булмаган, бер баласының туенда да күңел ачмаган, оныкларын, ягъни безне, алларына утыртып сөймәгән, сөя алмаган. Алар балаларының, безнең әти-әниләребезнең, үзләре дә сизмичә, белмичә, бер-береннән шактый аерылып торган, шул ук вакытта халкыбызның шундый охшаш генеалогик тармакларын берләштергән никахларыннан соң туган шушындый язмышлар бәйләнешен һәм хәлләрне хәтта күз алдына да китерә алмаганнар...

Безгә, аларның улларына, нәрсәнедер сайлап алырга насыйп булыр, мөгаен...

Ике гаиләдә дә аңа кадәр дә, аннан соң да өйдәгене тышка чыгару түгел, хәтта без – балалар үсеп җитми торып, үткәннәр турында гомумән сөйләмиләр һәм искә төшермиләр иде. Репрессияләр куркынычы, яңадан «халык дошманы»* рәтендә булу мөмкинлеге һәм тормыш юлындагы башка куркынычлар акрын-акрын буыннар бәйләнешен өзә килде...

Боларның һәммәсе дә соңрак булды, ә хәзер яңадан сугыш алды елларына әйләнеп кайтыйк әле.

Утызынчы елларда – Сталинның «коммунистик» идеяләрдән акыллары зәгыйфьләнгән бандитлар өере идарәсе елларында үз иленең миллионлаган һәм бер гаебе дә булмаган гражданнары корбан ителә.

Шуның белән бергә хакимлек иткән бәндәләр 1917 елның Октябреннән соң дөньякүләм кешелекнең иң гуманлы идеясен – социаль гаделлек җәмгыяте төзү идеясен дискредитацияләүне дәвам итте, һәм инде хәзерге юлбашчы, хакимнәребез уртак көч белән беренче чиратта үзләренең булдыксызлыгы, наданлыгы аркасында аны тупикка кертте...

Совет Казахстанында бу чор Голощекин репрессияләре еллары буларак билгеле. Моннан тыш, югарыда әйтелгәнчә, республикада моңарчы күрелмәгән масштабта җир өстен боз элпәсе каплап алганга ашатырга азык булмаганлыктан, терлекләр кырыла. Авылларда көчләп колхозга кертү сәясәте яңадан миллионлаган кешене теге дөньяга алып китә.

Шуның өстенә, төче сулы Җөм (Эмба) елгасы сусыз калып, Каспий диңгезе дә кешеләрдән кинәт кенә чигенә, китә башлый. Балык запасларының шулай ук кинәт кимүе һәм эчә торган су чыганакларының югалуы, бетүе Жилая Косаның бушап калу сәбәпләренең берсе була. Косчагыл нефть промыселын сәнәгати үзләштерү башлангач, үзенең элекке административ һәм икътисади әһәмиятен бөтенләй югалта*.

1935 елның маенда ВКП(б) Үзәк комитеты Политбюросы әгъзасы, азык-төлек промышленносте буенча халык комиссары А.Микоян, Жилая Косага килеп, кибеп бара торган елганы китеп бара торган диңгез белән тоташтырырга тырышып карауны тәкъдим итә. Әмма аның инициативасы белән төзелгән дүрт чакрым озынлыгындагы «Микоян каналы» да инде ярдәм итәрлек булмый...

Шул арада Сталинның 1936 елда кабул ителгән СССР Конституциясе нигезендә Казахстан АССР союздаш республикага әйләнә, ә 1938 елның гыйнварында Гурьев өязе өлкә статусын ала.

Шул ук 1938 елда район үзәге Жилая Косадан Косчагыл эшчеләр бистәсенә күчерелә. Ул вакытка инде анда суүткәргеч сузылган була; Орск шәһәренә кадәр уздырылган нефтьүткәргеч тә шуннан башланып китә.

Жилая Коса районының киләчәге балык тармагында түгел, ә нефть сәнәгатен үстерүдә икәнлеге инде көн кебек ачык була.

Өлкән уллары Әдһәм РККА сафларына хезмәткә алынгач, Абдулла Мөхетдиновлар ярдәмендә Кәримовлар өлкә үзәге – Гурьевка күченеп китә. Аның Эмба яки Бохара ягына – Урал елгасы аша тимер субайларга салынган үзәк күпер белән янәшә, уртасында һәйкәле торган Киров мәйданына килеп урнаша.

Элекке тыныч тормышның яңалар килгәч башланган тентүләрдән һәм күченүләрдән шул көннәрне хәтерләтеп торучы шаһиты, төгәлрәге, кыйпылчыгы булып авыр имән комодлар, зур көзге һәм патша заманында ясалган төрле савыт-саба, асылма телендәге данлы аббревиатурасы, циферблатындагы латин (рим) саннары белән Алманиядә эшләнгән ачкычлы стена сәгате могҗиза белән сакланып кала. Әле тагын безне генә түгел, шактый гаиләне авыр елларда суыктан һәм ачлыктан саклап калган бөтен дөньяга танылган Zinger тегү машинасы, әбиебез әниемә бүләк итеп биргән кызылсу алтыннан ясалган күбәләк рәвешендәге брошка. Соңрак аны урладылар, ә хәзер ул бары тик фоторәсемдә генә саклана.

Озак та үтми, Икенче бөтендөнья сугышы башлана. Бу ике гаиләнең өч өлкән баласы илне коточкыч фаҗигадән – фашистлар хакимлегендә калудан азат итәргә китә. Калган балалар һәм өлкәннәр тылда хезмәт итә.

Тик Ватанны саклап ут эчендә йөргән абыйларның икесе, кайгынамәләрдә күрсәтелгәнчә, геройларча һәлак була.

Капитан Әдһәм Мөфти улы Кәримов 1944 елның 7 июлендә Белоруссияне азат иткәндә һәлак була. Аның әле егерме сигезе дә тулмый кала...

1944 елның 24 октябрендә сугышка алынган, сугышлар белән Симферополь һәм Севастополь шәһәрләрен үткән, Румыниянең Тульчи шәһәренә барып җиткән Кара диңгез флотының икенче статья старшинасы, егерме яшьлек Фоат Гариф улы Тулбаев стратегик объект – маякны Бандера бандасы һөҗүменнән саклаганда 1948 елның 1 гыйнварында һәлак була.

Фронттан 1947 елда бары тик шәфкать туташы Тулбаева Рафика гына кайта. Аңа Урал хәрби госпитале составында союздаш өч держава башлыгының күпләргә билгеле Ялта Конференциясе вакытында Кырымда булырга туры килә. Нәкъ шул көннәрдә, Ливадиядә йөргәндә, ул АКШ президенты резиденциясендә инвалид коляскасындагы Ф.Рузвельт белән күзгә-күз очраша.

Әле сакчылары да шунда була.

Шул ук Ялтада, эсминецта эзләп табып, абыйсы Фоат белән соңгы тапкыр очраша...

Ниһаять, сугыш тәмам.

Бу дөньядан әтиләрен югалткан әлеге гаиләләр, инде өлкән улларын да югалтып, тагын бер кат ятимлек ачысын татый.

Нинди генә батырлык күрсәтмәсеннәр, алар турында – Икенче бөтендөнья сугышы солдатлары Кәримов Әдһәм, Тулбаев Фоат һәм Тулбаева Рафика турында рәсми хакимиятләр беркайчан да, беркайда да искә дә алмады, сөйләмәде дә, язмады да.

Алар Ватанны сакларга киткәннәр, үзләренең изге эшләрен эшләп, мәңгегә эзсез югалды.

Аларга хәтта һәлак булган, репрессияләнгән яки тылда гарипләнгән гаиләләр рәтеннән дәүләт тарафыннан нинди дә булса компенсация турында сүз дә булмады. Элек Совет хөкүмәте игътибар итмәгән булса, хәзер Казахстанныкы да шундый мөнәсәбәттә.

Биредә бу хакта ниндидер карарлар һәм указлар кабул ителде ителүен, әмма алар сугышта катнашучыларның нигездә югары даирәләрдәгеләренә яки инде дөньядан киткәннәргә, инде берни дә кирәкмәгән затларга гына карый.

Шуның өстенә, бәлки, алар биредә чыгышына, милләтенә, партиядә тору-тормавына карап, һәрвакыттагыча алдан билгеләнгән (геройларның берсе дә беркайчан да партиядә тормаган, соңгы сугышка кергәндә дә һәлак булган очракта, барысы да үзен коммунист дип санауларын теләмәгән икән), ә бүгенге көндә хакимлек итүчеләр белән үзара туганлык, дуслык, симпатия һәм башка элемтәдә тору-тормавына карап әвәләнгән һәм хәзер дә әвәләнеп торучы геройларның образларына туры килеп бетмәгәндер...

Бары тик минем әти-әнием, Әкрәм Мифтах улы белән Рауза Гариф кызы Кәримовлар гына, үзләренең гомерләре белән киләчәк тыныч тормышны фашизмнан тартып, яулап алган бу каһарманнарның истәлеген хөрмәтләп, дүрт улының өчесенә (миннән кала) аларның исемен – Әдһәм, Фоат һәм Рафик дип кушкан.

Бары 50 (!) елдан соң гына аларның исемнәре Хәтер китабына язылып куелды: берсе – Атырау (элекке Гурьев) шәһәрендә, икенчесе – Уральск шәһәрендә. Шуның белән бетте – вәссәлам. Кызганыч, бу вакытка аларның ни әниләре, ни Рафика апа, ни минем әтием бу дөньяда юк иде инде, шуңа күрә алар бу хәлләрне белми калдылар...

Ә бит кара кайгы китергән хәбәрнамәдә алар турында, социалистик Ватан өчен сугышта биргән антларына туры калып, батырлык һәм каһарманлык күрсәтеп, хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булды, дип язылган. Рәсми хәрби башлыкларның куллары куелып, мөһер сугылган раслама бит ул. Аларның дошманны илдән сөрү өчен гомерләрен аямыйча сугышуына кире кагылмаслык дәлил ләбаса. Алар кебек башка бик күпләрнең рәнҗешеннән, хәтта бүгенге көнгә кадәр күмелмичә, сөякләре бөтен җир өстендә таралып, сибелеп яткан һәм ике дә уйламыйча шуларны таптап йөргәннәргә яисә таптатып йөрткәннәргә шулай ук рәнҗешле җаннар каргышыннан дөнья яман якка үзгәрмәс микән?!

Безнең әбиләребез, сугышта улларын югалтканнан соң, җан ярасы гына түгел, тән ярасы да ала: берсе сукырайса, икенчесе чукраклана.

Кәримова Маһибәдәр эвакуацияләнгән хәрби кыр госпиталендә санитарка булып эшли. Гурьев шәһәрен Гитлер авиациясе бомбага тоткан бер мәлдә ул ишетми башлый.

Фельдмаршал Ф.Паулюсның Германия гаскәре Иделнең түбән агымына, Гурьев белән Уральск өлкәләренә якынлашкан чакта була бу хәл. 500 чакрымга сузылган бу ара Совет Армиясенең фронтка иң якын торган тылы өчен гаять зур хәрби-стратегик роль уйнаган Сталинград фронты чиге булып кала.

Безнең нефть төбәге ул чакта фронт алды режимында эшли башлый. Биредә компартиянең Гурьев өлкәсе комитетының Беренче секретаре М.Бекжанов* җитәкчелегендә шәһәрнең саклану комитеты төзелә.

Сугышның беренче айларында ук монда диңгез юлы белән 57 мең кеше эвакуацияләнә, бер елдан соң тагын 35 мең. Әстерханнан бик күп йөк, диңгез суднолары һәм нефть тутыру баржалары җибәрелә, шулай итеп, резерв порты төзелә башлый. Гурьевта Каспий флотилиясенең Әстерхан хәрби-диңгез базасы, эвакуацияләнгән машиналар төзү, механика һәм суднолар ремонтлау заводлары, тегермән урнаштырыла.

Биредә дөньяда беренче тапкыр диңгез буйлап цистерналарда нефть ташу ысулы кулланыла. Аннан соң 441 нче Союз заводы (бүген – АНПЗ) төзелә башлый, Эмба районында дошман десанты тар-мар ителә, ә соңга таба Гурьев халкы Орлов өлкәсе җимерелгән хуҗалыкларын торгызу буенча шефлык-ка ала...

Уральск өлкәсендә Сталинград фронты Уральск-Урбах тимер юлы участокларында урнаша, биредә хәрби-кыр оператив аэродромнары, госпитальләр, хәрби заводлар, училищелар булдырыла, истребительләр батальоннары оештырыла, хуҗалык итү тәүлек әйләнәсендә фронтны бар нәрсә белән тулысынча тәэмин итүгә юнәлдерелә.

Һәм шул чакта безнең икенче әбиебез Тулбаева Гөлсем көне-төне туктаусыз тегү тегүдән тулаем диярлек сукырая...

Билгеле, бүгенге көндә тиз хәтердән чыккан ул елларны, Сталин репрессияләре елларын, кешеләрнең хәтта үз шәүләсеннән куркып яшәгән елларны күз алдына китерү авыр. Совет халкының бөтен яшәеше нигездә исән калу өчен көрәштән гыйбарәт иде.

«Халык дошманы» дип аталганнарның гаиләләренә тагын да авырга туры килде.

Мәсәлән, Уральскиның пенсия фонды хезмәткәрләре, 1948 елның мартында «халык дошманы» Гариф Тулбаев гаиләсенә аның улы Фоат Тулбаевның геройларча һәлак булуы турында кайгынамә килгәч, «катлаулы» хәлдә калалар. Бер яктан, туендыручысын югалткан анага пенсия түләргә тиеш кебек, ә икенче яктан – «дошманнар». Үзләренә проблема ясамас өчен аларны учреждениеләре бусагасыннан үткәрмәскә дигән карарга киләләр...

Шулай ярымач хәлдә, кимсетүләрне, рәнҗетүләрне дәшми-тынмый гына үткәреп җибәрә-җибәрә яшәгәндә, унике яшьлек Асия Тулбаева, беркемгә берни әйтмичә, бу турыда СССР Югары Советы Президиумына бөтен кешегә дә таныш булган: «Мәскәү. Кремль. Шверникка» адресы белән хат язып җибәрә. Алтынчы сыйныф укучысының менә шундый тәвәккәл адымы гына Уральскиның җирле хакимиятләренә тәэсир итә. Икенче караганда, бу хәлнең фаҗигале төстә бетүе дә ихтимал иде.

Менә шул рәвешчә, ирсез калган ялгыз аналар – сукыр калган һәм чукракланган әбиләребез сугыштан соң берүзләре балаларын аякка бастырып, ягъни үстереп һәм тәрбияләп, әле оныкларына да нәрсәдер биреп калырга өлгереп, дәшми-тынмый гына үз гомерләрен үткәрделәр һәм бу дөньядан тыныч кына китеп тә бардылар.

Алар соңгы көннәренә кадәр ике шәһәрдә дә яшәүче Казан татарлары арасында зур ихтирам казанып яшәделәр, ә Тулбаева Гөлсемне Уральскида әле хәзер дә хөрмәт белән абыстай дип искә алалар.

Безнең хәтергә алар менә шундый булып кереп калдылар...

Икенче бөтендөнья сугышы темасын тәмамлап һәм аңа карата Кәримовларның һәм Тулбаевларның мөнәсәбәтен белдереп, Гитлер фашистларына каршы сугышта үз өлешләрен керткән башка туганнарымның да исемен атап үтәсем килә. Менә алар:

Кәримов Шәриф – яраланып госпитальдә ятканнан соң хатыны Клавдия белән Гурьевка кайтты, ЗКГУ (Көнбатыш Казахстанның геология идарәсе) да эшләде;

Кәримов Шакир – сугышта кулын өздереп кайтты, Ырынбурда яшәде;

Кәримов Мәннаф – ут чолгап алган танкта контузия ала, Гурьев өлкәсенең Күл-Сары бистәсендә яшәде;

Рәшит һәм Ришат Тулебаевлар – сугыштан соң Үзбәкстанга киттеләр;

Мөхетдинов Вәкил – фронттан кайткач, Джамбул шәһәренә китеп урнашты;

Исенбаев Ярулла – сугыш башланганда Ерак Көнчыгышта була. Гурьев шәһәрендә Петровский исемендәге заводта балта остасы булып эшләде;

Исимбаев Әшрәф – Ленинградның мәшһүр «Тормыш юлында» шофер, Гурьевта (хәзерге Атырау шәһәре) шофер булып эшләде;

Мингалиев Салих – берничә мәртәбә дошман тылына җибәрелә, зур хәрби һәм хезмәт биографиясенә ия шәхес. Озак еллар Мәскәүдә Лихачев исемендәге завод – ЗИЛның генераль директоры урынбасары булып эшләде...

## 5. «ӘКРӘМ КӘРИМОВ ХЫЯЛЫ»

Шундый башисем белән 1981 елның 14 мартында «Гурьевнефтехимстрой» трестының күптиражлы «Зур химия өчен» газетасының 20/1122 нче санында О.Крылова мәкаләсе басылып чыкты. Аннан өземтәләр белән сезне дә таныштырып үтәсем килә.

Искәртеп үтим: бу кыска гына сюжетта автор тарафыннан әтиебезнең биографиясе дә, характеры да, эшкә мөнәсәбәте дә төгәл һәм дөрес итеп бирелгән.

Аның турындагы хатирәләр якыннары, туганнары күңелендә мәңге сакланыр; үзенең алтын куллары белән нидер ясарга булышкан, ярдәм иткән һәркем аны яхшы хәтерлидер дип уйлыйсы килә. Аның

турындагы бу мәкалә бердәнбер «җәмгыяви» истәлек һәм аның хезмәтен, гади бер эшченең олы хезмәтен тану булып тора.

Менә ул язма.

*«Алтынчы разрядлы слесарь Әкрәм Мөфти улы Кәримов коллективта зур ихтирам казанды, аны һәркем намуслы эшче, яхшы кеше буларак белә.*

*Әкрәмнең бала чагы җиңел булмый: башта әтисе үлә, дүрт баласы әтиләре тәрбиясеннән, әтиләре назыннан мәхрүм кала. Шул арада сугыш башланып китә. Каһәр суккан бу сугыш гаиләнең тагын бер туендыручысын – өлкән улы Әдһәмне алып китә...*

*Әкрәм казах мәктәбендә алтынчы сыйныфны тәмамлагач, инде гаиләгә ярдәм итәр вакыт җитте дип, эшкә урнашырга карар кыла. Унбиш яшьлек малай «Гурьевэнерго»га килә һәм токарь булып эшкә урнаша.*

*Торак-коммуналь конторда Әкрәм Мөфти улы 1958 елдан бирле эшли. Мондагы коллектив аңа шундук ошый, тик яңа эшенә ул акрынлап ияләнә. Авырлыклар да була, алар хәзер дә бар, ә инде кеше үзенең эшен ярата икән, бу авырлыклар, кыенлыклар тиз үтә, сизелмичә дә кала.*

*Бүгенге көндә Әкрәм Мөфти улы 8 нче трестның тулай торагына хезмәт күрсәтә, аварияләрне туктата. Эш күп, канализация, суүткәргеч һәм җылыту системасы – аларның көйле эшләве слесарь Кәримовның оста кулларына һәм күпьеллык тәҗрибәсенә бәйле...»*

*«Һәр яңа аварияне тиз арада туктатканнан соң, нишләптер һәрвакыт бер канәгатьләнү һәм горурлык хисе тоясың, – ди ул...»*

*«Безнең конторның һәр эшчесе үз хезмәтенә күбрәк ярату һәм кайгырту хисе салсын, шуның белән совет кешесенең яшәү урынын тагын да матуррак, җайлырак һәм җылырак, ә шәһәребезне гүзәл, яшел һәм чиста шәһәр итсен иде. Бу – минем күптәнге хыялым», – диде ул хушлашканда».*

Безнең әтиебез – сәүдәгәр һәм балык промышленнигы улы, гади эшче, слесарь-сантехник булып эшләгән Әкрәм Кәримовның тормышы менә шулай үтеп китте.

«Халык дошманы», Уральск шәһәренең Совет власте репрессияләгән указлы мулласы кызы – әниебез Рауза Гариф кызы Кәримованың (Тулбаева) тормышы да моннан әллә ни аерылып тормады: пенсиягә чыкканчы «Гурьевнефтегазгеология» җитештерү берләшмәсендә машинистка булып эшләде.

Икәүләшеп, гади һәм авыр тормышта яшәп, һәрдаим өстәмә эшләрдә эшләп, әтием әле каравылчы, әле ягучы яки итекче булып, әни һәр басма бит өчен 20 тиен акча белән өстәмә эш алып, Урал елгасы ярында, шәһәрнең Бохарага китә торган ягында менә дигән йорт җиткереп, дүрт угыл тәрбияләп үстерделәр (төзелеш конторындагы корымнан каралып беткән кочегаркада янып торган мазутның тавышы һәм ялкыны; аяк киеме тегү һәм ремонтлау өчен төрле җайланмалар һәм формалар; «Казнефтегазразведка»ның төнге идарәсендә өй эшләрен эшләп дәресләргә әзерләнүем; ипи һәм онга чиксез чиратларда яңгырлы һәм пычрак кичләр буе туңып-калтырап торулар... – барысы да әле бүген дә хәтеремдә).

Аларның һәрберсен, иң әүвәл үзләре сайлаган белгечлекне алуда ярдәм итеп, аннары туйларын ясап, олы юлга чыгардылар – кеше иттеләр, ә хәзер инде без үзебез – аларның балалары – үз балаларыбызны тәрбияләп, олы юлга әзерлибез...

Шул ук елларда Урал елгасының икенче ярында, аның Самарага китә торган ягында, колхоз базары янында Әхмәровларның зур гаиләсе яши. Гаилә башлыгының исеме безнең әтиебез исеме кебек – Әкрәм. Шуның өстенә аның әтисе дә инкыйлабка кадәр сәүдәгәр була.

Икенче бөтендөнья сугышы кайчандыр Гурьев шәһәренең үзәгендә, шәһәрнең элекке «Балалар дөньясы» (соңрак КГБ бинасы) буларак билгеле иске өлешендә зур йортта яшәгән сәүдәгәр Ибраһим Әхмәров гаиләсе язмышында да тирән эз калдыра.

Аның биш улы да сугышка китә. Дүртесе – Сафа, Әкрәм, Хәмит һәм Риза – яраланып булса да, өйләренә әйләнеп кайта, ә бишенчесе – иң өлкәне Абдрахман һәлак була; аның истәлегенә энекәшләренең берсе үз улына Абдрахман дип исем куша.

1940 елның июнендә Кызыл Армия сафларына алынган һәм сугышны 1941 елның августында дошманның күпкә өстен көчләре чолганышында калып зур югалтулар кичергән 329 нчы укчы полк составында башлаган Әкрәм Ибраһим улына Германиядә әсирлекнең коточкыч газапларын татырга туры килә. Сугыштан соң, өч инфаркт кичереп, озак еллар инвалид булып яши.

Һәм 1985 елның августында мин һәм аларның (Әкрәм белән Маһинур Ганиева-Әхмәрованың) иң кече – җиденче кызлары Әминә белән Казан татарларының бу ике тармагын берләштердек, туганлаштырдык.

Әмма бу шатлыклы көннәрдән соң берәр еллап вакыт үткәч, төгәлрәге 1986 елның декабрендә, әтиебез Әкрәм Кәримов эшләп йөргән җирендә кинәт үлеп китә.

Гомере буе ул слесарь булып эшләде, шуның 28 елы – бер предприятиедә. Аңа бары 56 ел гына яшәргә насыйп булган икән. Үзе әле шактый яшь булса да, авыр һәм пычрак эштән һәм кырыс сынаулардан ул үз яшеннән күпкә олы күренә иде...

Тиздән, гомер буе авыр тормышта яшәүдән, Әкрәм белән Маһинур Әхмәровлар да бер-бер артлы бу дөньядан китеп бара...

Алар язмышына туры килгән авырлыклар, газаплар, рәнҗетелү, кимсетелүләр чиксез иде шул...

Безнең хәтердә алар сабыр, тел-тешсез, хезмәт сөючән, үзләренең рәнҗетелүләре өчен беркемнән дә хисап таләп итмәгән бу изге җаннар менә шундый булып сакланыр.

Хәзер дә элекке кебек үк: бер караганда, сәяси һәм икътисади системалар да үзгәрде кебек, барлык шигарьләр һәм исемнәр дә алышынды, илебез картасында яңа дәүләтләр дә барлыкка килде сыман, ә асылда берни үзгәрмәде – бар да элеккечә калды. Дәүләтебездә һаман шул ук җавапсызлык, икейөзлелек һәм цинизм хөкем сөрә, алар – узгандагы һәм хәзерге җитәкчеләр – хөкемдарларның һич аерылмас, арына алмас сыйфатларыдыр инде, мөгаен...

## III. ӘДҺӘМ МӨФТИ (МИФТАХЕТДИН) УЛЫ КӘРИМОВ

*Шулай бервакыт, җитмешенче елларның икенче яртысында бугай, өебезнең чарлагына менсәм, иске әйберләр арасыннан, нәкъ кинодагыча, кибеп, бүлтәеп беткән күн портфель табып алдым.*

*Табигый кызыксыну белән аны ачып җибәргән идем, әүвәл шаккаттым, аннары, берни аңламыйча, аска, ишегалдына, әтием янына төшеп киттем. Бу чын-чынлап архив, дөресрәге, безнең әтиебезнең бертуган абыйсы – Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булган Әдһәм абыйсының тормыш юлы турындагы документаль материаллар иде. Аның турында безгә кечкенәдән үк күп сөйлиләр иде, һәм ул безнең өчен, безнең гаилә өчен чын риваять һәм йөрәк әрнүе иде.*

*Минем беркайчан да шулкадәр күп документлар тупланмасын күргәнем юк иде.*

*Монда бар да бар: мөһере сугылган характеристика, автобиография, тентүләрнең беркетмәләре, газеталардан кисеп алынган материаллар, мандатлар, рөхсәтнамәләр, үткәреп җибәрү таныклыклары, ВКП(б) съездлары материаллары һәм фронттан язган өчпочмаклы хатлары. Фронтка киткәнче үз документларын тырыша-тырыша үзе туплаган булса, һәлак булгач – башта әби, аннары әти туплаган. Барысын да таслап җыеп, кеше күзеннән яшереп, өлкән угыл һәм абый турындагы бу материалларны үз вакыты җиткәнчегә кадәр саклауга куйганнар. Хәзер менә аларны әти миңа сузды...*

Ул 1917 елда Жилая Коса бистәсендә туа.

Монда да болганчык еллар. Югыйсә бу бистә – дөньяның бер караңгы почмагы. Бирегә Совет власте беренче кораллы отрядлар йөзендә 1920 елда гына килеп җитә. Әбием сүзләренә караганда, аларның вәкилләрен каршыларга бабай үзе чыга. Шулай булса да икенче көнне үк диярлек ул бөтен мал-мөлкәтен «үзирек» биреп җибәрергә мәҗбүр була (ни эшли аласың?). Әле кичә генә иң укымышлы һәм көр тормышлы бабам гаиләсен туйдырыр өчен ат белән кеше ташып йөри башлый...

Шул ук истәлекләр буенча, ул ни генә күрмәгән: исәпсез тентүләр, кинәттән килеп талау-җәберләүләр (аклар тарафыннан да, кызыллар тарафыннан да. Алар арасында бернинди аерма булмый) бабамның һәм якыннарының сәламәтлеген һәм яшәү рәвешен нык какшата.

Ак бандитлардан качып, Олы Базардагы унике бүлмәле өйләренең подвалында тәүлек буе ач утырган әбием белән бер яшьлек улы Әдһәмне очраклы бер хәл генә коткарып кала...

Шуннан соң бабамның кичәге эшчеләре (бүген исә кызыллар) килеп, чираттагы тентүләрен ясап, гаиләнең соңгы кашыгына кадәр алып чыгып китәләр...

Бу тентүләр даими кабатланып тора. Үз чиратында килгән һәр җитәкче инде талап алырлык берни дә калмавына ышанмый хәтта.

Октябрь түнтәрешеннән соң хәтта 14 ел үткәч, 1931 елның 14 декабрендәге тентүнең саргаеп һәм төссезләнеп беткән соңгы беркетмәсе моңа дәлил.

Шунысы кызык: инде алырлык берни дә калмаган булса да, тентү ясаган ОГПУ хезмәткәре Гродненков беркетмәгә үзенең имзасын русча, бабам гарәпчә куя, ә пүнәтәйләр С.Умарова һәм И.Дюскалиева өчен (укый-яза белмәгәнгә күрә) район милициясе хезмәткәре: «*Грамота белмиләр, моны раслыйм, милиционер...*», – дип язып куя.

Шулай булса да тормыш дәвам итә. Бар нәрсә акрынлап җайлана, кешеләр дә яңа тәртипкә ияләнә башлый. Әдһәм дә, автобиографиясендә үзе язганча, 5 нче сыйныфны тәмамлый – совет мәктәбендә, татар телендә.

Чынлап та ул елларда татарча укытыла торган мәктәпләр хәтта үзәктән ерактагы торак пунктларда да бар иде, бу – элек төбәкләрдә яшәүче Казан татарларының күплеге, мәдәниятенең шактый югары булуы, шул замандагы хакимиятләрнең гадел милли сәясәте: беренче мәлләрдә рус телен генә түгел, башка халыклар телләрен дә үстерү юнәлешендә эшләве – барысы да һәр милләт мәнфәгатен кайгырту турында сөйли.

Дөрес, бу – вакытлыча гына булган хәл. Чөнки инде минем әтием, башка мәктәпләр булмаганлыктан, казах мәктәбендә укый. Ә безгә, аның улларына, шулай ук сайлау мөмкинлеге

булмады – без рус мәктәбендә укыдык. Шулай да мәктәптә үз ана телендә уку Әдһәмгә, татар теленнән гайре, казах (латин шрифты белән), рус һәм гарәп телләрендә иркен сөйләшергә комачауламый. Сакланып калган документлар күрсәткәнчә, бу телләрне ул яхшы белгән һәм хатлар язышкан.

Соңрак, инде үсмер булгач, ул татарча шигырьләр дә яза башлый... Әмма тормыш шундый шартлар китереп куя, шигырь язу теләге бөтенләй сүнә.

Зур гаилә, әтисе инде бу дөнья белән бәхилләшкән, гаиләдә иң өлкәннәр булып әнисенең карт туганнары Кумисбай (1854 елгы) һәм Сабира Таһировлар гына кала. Һәм ул – дүрт бала арасында иң өлкәне, шуңа күрә, татар мәктәбенең дүрт сыйныфына рус мәктәбенең биш сыйныфын өстәп, 15 яшендә хезмәт биографиясен башлап җибәрә. Бу – гадәти хәл булып санала, чөнки авыл балалары туу белән диярлек кул астына керә башлый.

Әдһәмнең хезмәт эшчәнлегенең һәр адымы эш урыныннан белешмә һәм характеристика белән ныгытылган. Вакыты да шундый: теләсә кайчан раслаучы документ таләп итүләре ихтимал – «халык дошманы» баласы бит. Утызынчы елның икенче яртысында Казахстанда репрессияләр башланып китә.

Ул чакта грамоталы кешеләр бирeдә сирәк була, шуңа күрә аңа билгеле бер вакытка кадәр тимиләр – системага кирәк булгандыр, мөгаен. Шуңа күрә ул профессиональ яктан бик тиз үсеп китә:

курьер, «Живколхозсоюз»ның эш башкаручысы;

район җир бүлеге статисты;

район элемтә бүлеге инструкторы;

1 нче балык заводының җәмәгать инспекторы (фабрика-завод пленумында сайлана);

корреспондент, Жилая Коса районының яңа гына оештырылган «Социалды аул» газетасы (хәзер «Кен Жылай» исеме белән чыга) балык бүлеге җитәкчесе.

Аның биографиясендәге бу чор – 15 яшьтән 18 яшькәчә, ягъни 1932 елдан 1936 елга кадәрге вакытны үз эченә ала.

1936 елның 10 августында 19 яшьлек Әдһәм Кәримов беренче мәртәбә эшчеләр һәм авыл хәбәрчеләренең округ киңәшмәсендә катнашу өчен Гурьев шәһәренә килә.

Бу киңәшмәгә ул шушы елларда чыгып килгән «Социалды курылыс» һәм «Прикаспийская Коммуна» өлкә газетларының җаваплы мөхәррирләре Кажахметов һәм Патрикеев (соңрак репрессияләнә) тарафыннан шәхсән чакырыла.

1936 елның ноябрендә ВЛКСМ сафларына алынгач, ул ВЛКСМның Жилая Коса райкомының эшләр идарәчесе итеп раслана.

Яңадан Гурьевка, инде ВЛКСМның округ комитеты секретаре Тулебаевка килә.

1937 елның 12 гыйнварында 1937 елда яңадан үткәрелгән Бөтенсоюз халык санын алуда исәп алып баручы сыйфатында катнаша.

Билгеле булганча, беренче мәртәбә үткәрелгән халык санын алу нәтиҗәләре Сталинны канәгатьләндерми, аны оештыручылар «халык дошманы» дип репрессияләнә.

Һәм шул чакта кемдер, көтмәгәндә, аның социаль чыгышын исенә төшерә – янәсе, пролетарлардан да, эшчеләрдән дә түгел бит ул. Шулай итеп, Кәримов Әдһәм «социаль чыгышын яшергән» өчен ВЛКСМ сафларыннан чыгарыла һәм комсомолның район комитеты аппаратыннан азат ителә.

Ул чакта аңа унсигез яшь тулып киткән була.

Ай ярым чамасы эшсез йөргәннән соң, ул бер карарга килә – ВЛКСМ сафларына кайтаруны сорап апелляция бирә һәм Көнбатыш Казахстанның финанс бүлеге оештырган салым бухгалтерлары курсында белгечлек алу өчен Уральскка китеп бара.

Курсларны тәмамлап, өенә әйләнеп кайткач, Әдһәм абый ВЛКСМ сафларына кире алуларына ирешә һәм Жилая Косаның район финанс бүлегенә өлкән салым инспекторы булып эшкә урнаша.

Монда да, тиз арада абруй казанып, яңадан җәмәгать эшенә тартыла – комсомол оештыручысы урынбасары һәм ОСОАВИАХИМ рәисе итеп сайлана.

Тиздән, егерме ике яшендә, әле шактый яшь булуына да карамастан, Жилая Косаның инде Косчагылга күчерелгән район финанс бүлеген җитәкли.

Шул яшендә ул Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенә алына, кызганыч, гаилә кормыйча кала...

Аның тормышының бу елларына кагылып, сакланып калган документларның алты дистәләп үткән ел аша яңадан теге еллар мохитенә кайтаручы саргаеп беткән битләрен актарыйк: шәхси корал – 171519 номерлы һәм җиде патрон белән браунинг йөртү хокукына махсус күрсәтмә (районның элемтә бүлеге); Сталинның «Краткий курс истории ВКП(б)» китабы, ВКП(б)ның XVIII съездында Жданов, Молотов, Андреев чыгышлары белән аерым брошюралар; балыкчылар профсоюзы, МОПР (международная организация помощи борцам революции – РКЯХО) әгъзасы билетлары һ.б.

Дәүләт хезмәткәрләре арасында бер-берсенә ышанмау, бер-берсеннән шикләнү һәм гомуми күләмдәге куркуның киң күләмдә таралганлыгын туганымның үз социаль чыгышын яшереп калу гына түгел, кунаклар чакырганда, бөтен дуслары кебек үк, тыелган темаларга әңгәмә булмаячак һәм өй хуҗасы буларак, гомуми тәртип өчен җаваплы, дигән йөкләмә алуы хакында белешмә кәгазенең булуы да раслый.

Ул чактагы тормыш менә шундый була. Кайберәүләр аны онытa, ә бик күпләр аның булуын хәтта күз алдына да китерә алмый.

Барлык документлар күчермәсенең пөхтәләп тегелеп куелуы очраклы гына түгел, билгеле.

Шуны да әйтик, Әдһәм абыемның һәр эшләгән урыныннан диярлек бирелгән характеристикаларда аңа бары тик уңай бәя (йә «яхшы», йә «бик яхшы») генә куела...

Гурьевның Степан Разин урамындагы 46 нчы йортта урнашкан округ хәрби комиссариатыннан гурьевлыларның берничә буыны – кем хәрби хезмәткә, кем турыдан-туры фронтка җибәрелә.

Әдһәм абый исә үзенең хәрби хезмәтен Казан шәһәренең 284 нче укчы полкында башлап җибәрә.

Язмыш абыема фронтка китәр алдыннан үзенең әти-әтисе туып үскән, борынгы бабалары яшәгән изге җирдә булырга насыйп итә, ни өчендер аңа бу җирләрне күрсәтеп алырга «уйлый». Бәлки, алдан барын да белептер.

Чөнки өйдәгеләр, кыска вакытлы ялга кайтып киткәннән соң, аны инде башка беркайчан да күрми. Аларга бары тик аның язган хатларын көтәргә, уңышларына шатланырга, горурланырга һәм бары яхшыга гына ышанырга кала...

Югарыда әйтелгәнчә, Каспий диңгезе ни өчендер кешеләрдән китә башлый.

Шуңа күрә кешеләр үзләре дә еллар буе яшәгән урыннарын ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Әйберләрен җыеп, зур агач өйне сүтеп һәм бар нәрсәне грузовикка төяп, Кәримовлар да Гурьев шәһәренә кузгала.

Кайчандыр үзенең район үзәге буларак көйләнгән тормышы белән яшәгән, ә аңа кадәр бай базары, диңгез балыгы промыселы, зур православие чиркәве соборы һәм мөселман мәчете белән дан тоткан Жилая Коса бушап кала...

Биредә, кайчандыр гөрләгән цивилизациянең кайнап узган тормышының бер ядкәре буларак, вакыт үтү белән җимерелгән саман һәм кирпеч йортлар, төзелешләр фонында беренче У-2 совет тракторының ташланган каркасы һәм судноның диңгез причалы урынында аунап яткан якоре бүгенге көнгә кадәр күгәреп черүен дәвам итә.

Шунда ук, даладагы маяк сыман, әллә кайдан күренеп һәм сирәк кенә килгәләп йөргән кешеләрне үзенә чакырып торучы, сәүдәгәр һәм балык промышленнигы Мөфти Кәримовның балык тозлау өчен кулланылган һәм Совет заманында балык цехында файдаланылган гаять зур багы кара тап булып аерылып тора. Аннан ерак та түгел, зур мөселман зиратында аның кабере өстенә дюралюминийдан безнең әтиебез куйган плитә, кояшта ялтырап шулай ук игътибарны җәлеп итә*...

Бу хәлләр соңрак булачак, ә хәзергә Гурьев шәһәренең Киров исемендәге мәйданында авыр тормышта яшәүче Кәримовлар Кызыл Армиядән хат-хәбәр көтә.

Ниһаять, 1940 елның 21 маенда «Прикаспийская Коммуна» газетының 115 (2006) нче санында «Кызыл Армиядән хатлар» рубрикасында рота командиры Петряков һәм политрук Миронов язган «Алга таба да уңышлар телибез» дигән мәкалә басылып чыга.

*«Хөрмәтле иптәш Маһибәдәр Кәримова, Сезнең улыгыз Әдһәм Мөфти улы, Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәндә, үзен совет халкының тугры улы итеп күрсәтте...*

*Англия-Америка империалистлары теләсә нинди юллар белән сугыш районнарын Ватаныбыз чикләренә якынайтырга тырышкан катлаулы халыкара хәлләрдә безнең армия частьлары үзебезнең күпмилләтле совет халкының бәйсезлеген һәм иреген саклауда тарихи бурычын үтәргә һәрвакыт әзер.*

*Без ышанабыз: сезнең улыгыз кебек патриотлар белән теләсә кайсы дошманны тар-мар итә алырбыз һәм аларны үзләренең территориясендә кыйнаячакбыз...*

*Сезнең улыгыз безнең подразделениедә булганда кыска вакыт эчендә командование тарафыннан, үрнәк командир буларак, берничә мәртәбә макталды.*

*Сугышчан һәм сәяси әзерлек отличнигы булды...*

*Улыгызның аңын формалаштыруда зур рольне, Маһибәдәр Кәримова, Сез уйнадыгыз, шуңа күрә безнең часть командованиесе Сезгә чын күңелдән рәхмәт белдерә һәм Сезнең нәтиҗәле хезмәтегездә зур уңышлар тели».*

Беренче карашка коры кебек тоелган бу сүзләр артында шактый зур мәгънә ята. Бигрәк тә хәзер, инде күпме еллар үткәч сизелә.

Игътибар итегез: мәкаләнең эчтәлегеннән аңлашылганча, Европаны инде Икенче бөтендөнья сугышы ялкыны чорнап алган бер вакытта Сталин җитәкчелеге СССРга төп куркынычны фашистлар Германиясеннән түгел, ә Бөекбритания белән АКШтан күрә. Инде белгәнебезчә, 1939 елда Гитлер Германиясе белән Һөҗүм итешмәү пактына өстәмә рәвештә, Европаны капма-каршы ике идеологиягә таянган Гитлер фашизмы белән Сталин коммунизмы арасында бүлгәләү турында яшерен Беркетмәгә дә кул куела.

Дөньядагы иң көчле идеология машинасы безгә Икенче бөтендөнья сугышы башлану шартларын шундый итеп китереп куйды, безнең илебез анда бер гаепсез корбан итеп күрсәтелде. Ә бит «сәхнә арты интригалары» шуны раслый: Сталин җитәкчелегенең роле бар нәрсәдә дә бөтенләй башка.

Икенче төрле әйткәндә, Россия империясенең колоньальләштерү, басып алу һәм чит территорияләрне оккупацияләү сәясәтен дәвам иткән Совет империясе бу юлы инде үзе зыян күргәннәр ролендә, ә совет халкы, һәрвакыттагыча, әлеге сәясәтнең тоткыннары, аның корбаннары булып кала...

Сугыш алдыннан, 1940 елның декабрендә, Казаннан өйгә язган бер хатында Әдһәм абый туган ягы Жилая Коса турында шигырь дә язып җибәрә...

1941 елның июлендә Самара һәм Сызрань шәһәрләрендә хәрби курслар тәмамлаганнан соң, 1941 елның ноябрендә Пенза артиллерия училищесының (1942 елның февралендә Вольск шәһәренә күчерелә) строевой бүлегенең 2 нче ранглы техник-интендант дәрәҗәсенә ирешә. Ул фашистларга каршы артиллерия белән тәэмин итү дивизиясе штабы составында көрәшә.

Сирәк һәм кыска язылган өчпочмаклы хатларында ул (бер ишесен – гарәп шрифты, икенчеләрен латин шрифты белән яза, аларда тормыш турында, сугыш турында фикерләрен шигъри юллар белән бәян итә) үзе турында бик аз мәгълүмат бирә. Борчылып һәм сагынып, күбрәк әнисенә мөрәҗәгать итә. Нәрсәдер сизенгән кебек, соңгы хатларының берсен кече энесенә, ягъни миңа – ундүрт яшьлек Әкрәмгә юллый: *«...Сугыш бетмичә, очраша алмыйбыз. Шуңа күрә дәресләреңне яхшылап өйрән, белем алырга омтыл, әнигә өй эшләрендә булышырга тырыш...*

*Мин кайтканчы, әби белән әнине сакла...*

*Бу тормышта сезне тагын бер кат күрә алсам, һәлак булсам да үкенечкә калмас иде...»*

1944 елның 7 июлендә капитан Әдһәм Мөфти улы Кәримов (фронтта дуслары аны Алексей дип йөртә) Минск янында, 14011-М гаскәри часть штабы составында Белоруссияне азат иткәндә һәлак була.

Бу 1944 елның иң зур стратегик һөҗүм операцияләренең берсе була.

«Багратион» дигән яшерен исем алган Белорус операциясе немец фашистларының «Үзәк» төркемен тар-мар итү һәм республика территориясен азат итүне максат итеп куя. Ул 23 июнь – 29 август вакыт арасында үткәрелә. Дошманны тар-мар итү өчен армия генераллары И.Баграмян, И.Черняховский, Г.Захаров һәм Советлар Союзы маршалы К.Рокоссовский җитәкчелегендәге 1 нче Балтыйк буе һәм 1 нче, 2 нче, 3 нче Белоруссия фронтлары тартыла.

Операциянең I этабында (23 июнь – 4 июль) Минск азат ителә һәм немец армиясенең 105 мең кешедән торган 4 нче һәм 9 нчы берләшмәләре чолганышка алына.

II этапның төп бурычларыннан берсе – Минскидан көнчыгыштарак дошманның нәкъ менә шул төркемен юк итү. Аны 5 июльдән 11 июль көннәрендә 3 нче Белорус фронтының 33 нче армиясе гаскәрләре һәм 2 нче Белорус фронтының 49 нчы һәм 50 нче армияләре көчләре гамәлгә ашыра. Бу сугышта дошман 70 меңнән артык солдатын югалта, 35 меңгә якыны, шул исәптән 12 генералы әсир төшә.

Совет гаскәрләре Литваны, Латвияне азат итеп, 20 июльдә Польша территориясенә килеп керә. Безнең югалтулар хәбәр ителми. Бары шунысы гына билгеле була: бу ике ай эчендә (июль-август) 400 меңнән артык (!) солдат һәм офицер орден һәм медальләр белән бүләкләнә...

*«Мин сезне белмим, бәлки, сез Алексей Кәримовның әтиседер, әнисе яки туганнарыдыр. Мин аның белән бер частьта (14011-М) хезмәт иттем, немецларга каршы сугышта бергә булдык. Нәкъ менә миңа соңгы гранатаны аңа бирергә, ә үземә икенче командирга ярдәмгә йөгерергә туры килде.*

*Мин калдырып киткәндә, аның янында әле иптәшләре дә бар иде, әмма, һөҗүмне кире кайтаргач, урман аланына кире әйләнеп кайтсам, соңгы каен астында һәлак булган капитан Кәримов ята иде.*

*Мина ярчыклары, артериясе белән бераз башын эләктереп, муенын тишкәләгән. Мин күп итеп яза алмыйм. Капитан үз бурычын үтәп һәлак булды, аның тирәсендә өч немец солдаты үлеп ята иде...*

*Аның дусты Лида Меркулова сезгә барын да җентекләп язгандыр инде...»*

*«Ул 1944 елның 7 июлендә һәлак булды. Аны шул ук кичтә җирләделәр.*

*Җирләгәндә музыка да булды, шул арада дошман һөҗүмен дә кире кайтардык. Безнең максат Минск янында немецлар төркемен өзеп чыгу иде.*

*Гафу итегез, ничек булган булса, шулай яздым. Бурычыбыз шул...»*

*«Орден һәм медальләре Л.Меркуловада, ул аларны сезгә җибәргәндер инде.».*

*** * ***

*«...Зур бәхетсезлеккә, сезгә Алексейның гитлерчыларга каршы сугышта батырларча үлеме турында хәбәр итәм.*

*Һәлак булганчы, ул бу һөҗүмдә дистәләгән немецны юк итәргә өлгерде.*

*Ярасы авыр – үлем ярасы иде.*

*Ул минем якын дустым иде, ике елга якын бергә бер подразделениедә хезмәт иттек.»*

*«...Әни, мин сезне бик яхшы аңлыйм: Алексей кебек улны югалту гаҗәп авыр. Без аны барыбыз да яраттык. Аның һәлак булуын барыбыз да авыр кичерәбез, ә мин бигрәк тә...*

*Алексейны мин Вольск шәһәреннән үк белә идем. Соңгы көненә кадәр без бергә булдык...*

*Башкалар аның егылганын күргәннәр, яраланды дип кенә уйлаганнар. Кызганыч, алай булып чыкмады. Алексейны сугыш кырыннан 25–30 чакрым ераклыкка алып китеп, офицерларга тиеш булганча, дәрәҗәләп, хөрмәтләп күмдек...»*

*** * ***

*«...Без Леша белән ике ел бергә булдык. Аны яраттым, ихтирам иттем һәм менә кинәт кенә һәлак булды.*

*Без урманда идек. Каһәр суккан фриц шайкалары бөтен урманны айкап йөри. Барыбыз да оборона тотарга әзерләнгәндә, Леша, беребез дә көтмәгәндә, каты яраланды, коткарып калырлык түгел иде: ярчыклар муенын, кан тамырын, умрау сөяген, уң җилкәсен тишкәләгән, уң кулының бөтен бармакларын чәрдәкләгән иде.*

*Канын күп югалтты – яраланган бар җиреннән бәреп акты.*

*Шулай тиз югалтырмын дип һич уйламаган идем.*

*Бу авыр көндә берьюлы иң яхшы алты солдат, офицерыбызны югалттык.*

*Әле хәзер дә аның юклыгына ышанасым килми. Шунысы бераз тынычландыра: аны, үзем дә булып, бөтен шартына туры китереп җирләдек.*

*Соңгы вакытта ул нигәдер бик боек йөрде, гел үлем турында гына сөйләде. Сөйләшүе дә теләр-теләмәс кенә иде.*

*Мин аның һәр хәрәкәтен, сөйләшүен, көлүен хәтерлим, ул һәрвакыт минем күз алдымда...*

*Аның гел өенә кайтасы, туганнары белән күрешәсе килде, тик аңа ял гына бирмәделәр.*

*Әйе, сугыш яхшы кешеләрне күпләп алып китте...»*

Бу юллар өч кешенең – Александра Акишина, Николай Черничко һәм Лидия Меркулованың 1944 елда Белорус фронтыннан ерак Гурьевка Кәримовларга язган хатларыннан өзекләр.

Бу сүзләргә ни дә булса өстәп булмый. Шулай да мин, тәвәккәлләп, берничә сүз өстәргә булдым: Гурьев шәһәре хәрби комиссариаты сугышка озаткан һәм һәлак булган 6193(!) кешенең бары берсе генә майор, ә уналтысы капитан дәрәҗәсендә була. Шулар исәбендә безнең туганыбыз Кәримов Әдһәм...

Ул чакта аңа егерме сигезенче яшь иде.

Ул Минск шәһәреннән 10–12 чакрым көньяктарак, Бабовозовщина авылыннан көнбатышка табан 500 метр ераклыкта һәлак була, Минскидан Барановичига бара торган тимер юлдан ике чакрым көнбатыштагы Самофаловичи районының Волковичи авылында күмелә.

Гурьевка хатлар аннан соң да күп килә, хәтта сугыштан соң да. Фронтташ дуслары яза. Николай Черничко исә, яраланганнан соң, хәтта үзенең хәрби пенсиясен дә җибәрә...

Бу – Кәримовларның киләчәк буыннарына туганыбызның берсе Әдһәм Мөфти улы Кәримов турында калган бөтен истәлек. Ул, чарлакта иске әйберләр арасында ята-ята, вакыт узу белән кибеп беткән күн портфельдә сакланып калган.

**СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА**

*Китеп баручы XX йөзнең соңгы язы ахырында, 1999 елда, үземнең юлдашларым белән беренче мәртәбә Жилая Коса хәрәбәләренә килгәч, ниндидер бер илаһи көч мине шундук без торган җирдән көнчыгышка таба тартып алып китте.*

*Һәм бераздан әрем даласында кояшта үзенә чакырып торучы әллә ни зур булмаган якты бер металл әйбер күренде.*

*Якынрак килсәк, бирегә кайтуның максаты булган, 1977 елда әтием тарафыннан бабасы Мифтахетдин Кәримов каберенә куелган дюралюмин плитә булып чыкты. Чынлап та, ни мин, ни минем белән кайткан юлдашларым аны шулай тиз табарбыз дип уйламаган идек. Әле аннан соң булганы безнең барыбызга да тагын да көчлерәк тәэсир итте.*

*Без, әлеге плитә нигезенә урнашып, Коръәннән дога укыганнан соң, кинәт кенә күк йөзен болытлар каплап, күңелләрне сафландыра торган язгы яңгыр әкрен генә сибәли башлады. Аның чиста тамчылары, күз яшьләре сыман, битебезне, җирне, даладагы сирәк үләнне һәм бу мизгелләрне теркәп калучы фотоаппарат объективын чылатты...*

*Ярты сәгать үтәр-үтмәс, кояш яңадан ялтырап килеп чыкты да җаныбызны шундук сүз белән аңлатып бирә алмаслык, безнең барыбызны да алда көткән Мәңгелеккә якынайтучы җиңеллек һәм тынычлык биләп алды...*

Шунысы гаҗәп: бу материалны әзерләгәндә, ачыкланасы сораулар туды исә, кайда гына булсам да – Алма-Атадамы, Атыраудамы, Мюнхен, Ессентукидамы – аерым детальләр, фактларны сорау һәм тәгаенләү өчен шундук әтиемә яки әбиемә мөрәҗәгать итү теләге импульсив рәвештә туа иде. Әйтерсең лә алар минем янда...

Сорар кеше булмаса да, бу тема җаныма тирән кереп урнашкангамы, әллә чынлап та ул миндә яшәгәнгәме, җаваплар каяндыр табыла торды. Чынлап та кемдер аларны миңа әйтеп тора кебек иде.

Эчке шикләнүләр каналы, истәлекләр, газаплар, документларны кабат тикшерүләр, очрашулар һәм әңгәмәләр, хатлар һәм бүтән архив материаллары һ.б. аша.

Әлеге теманың дәвам ителүе үзеннән-үзе соралып тора иде.

Ул булыр дип уйлыйм. Әмма аерым материал булып тупланыр. Чөнки һәр нәрсәнең нигезендә кеше тормышы ята.

Шуның өстенә һәр кеше – үз Вакытының баласы. Безнең теләсә кайсыбызның тормышы кешелек тарихының, аның билгеле бер чорының, буыннан буынга күчеп торучы чорының бер кыйпылчыгы, шуңа күрә мин әлеге материалның төгәлләнмәгән булуын күрәм.

Сүз дә юк: әлеге мин каләм алып язарга теләгән чиксез процессның төп нервысы – хәтер. Бу очракта кайсы тамыр борынгырак, болгарныкымы яки татарныкымы – әһәмиятле түгел.

Бу – иң әүвәл халкыбыз, безнең гаилә өчен әлеге мөһим мәсьәләнең асылын күпмедер дәрәҗәдә аңлатырга яки, ахыр чиктә, кагылып үтәргә тырышу гына.

Хикәятнең төп бәйләүче чарасы – әрнү.

Узганы һәм хәзергесе өчен әрнү һәм киләчәк өчен – өмет. Халкыбызның, димәк, минем гаиләмнең дә киләчәге өчен ул өмет, ышаныч.

Бәлки, әлеге материал бер яклы һәм субъектив килеп чыккандыр, әмма шулкадәр озак онытылып торулардан соң башкача була да алмас иде, мөгаен. Бу – беренчедән.

Икенчедән, соңгы инстанциядә хакыйкатькә тулысынча дәгъва кылмыйм, чөнки бу материал фәнни хезмәт түгел, публицистика дияргә була. Алтын урталыкны эзләгәндә, бәлки, кайбер төгәлсезлекләр дә киткәндер, әмма шуңа ышанам: алар тупас хата түгел, принципиаль дип тә әйтеп булмый, алдан уйлап, махсус эшләнгән дә түгел. Язма ачыктан-ачык, чын күңелдән, җыелма, күп сандагы төрле әдәбиятка (тарихи да, сәяси дә), әмма күп кешегә әле билгеле булмаган һәм тарихның болай шәрехләнүе оппонентлары арасында популяр булмаган әдәбиятка нигезләнеп тупланды.

Шул ук вакытта әбиебез авызыннан күп мәртәбәләр яңгыраган бер мәсьәлә – аның борынгы «чыганакларының» берсенең Мамай ханга барып тоташуы турындагы мәсьәлә ачык килеш, мин төбенә төшеп җитә алмаган килеш кала. Кайсына – Иделнекенәме, әллә Нугайныкынамы (тарихта бит ике Мамай була) – шулай ук белмибез.

Теориядән аермалы буларак, нәкъ менә шушы тормыш фактлары, минем уемча, Казан татарларының, димәк, Кәримовларның да болгар-кыпчак тамырын билгели.

Әбиебез югарыда телгә алынган Кәримовларны бабай туганнары (күпмедер дәрәҗәдә) дип йөртә иде, безгә, сезнең бабайларыгыз типографиясендә басылган дип, бер горурлык һәм хөрмәт белән Коръәнне күрсәтә иде.

Чынлап та, аңа шактый мөһим һәм кызыклы вакыйгалар билгеле иде. Кызганыч, безгә Кәримовлар гаиләсе тормышы гына түгел, гомумән, теге ерак заманнарда калган тормыш турында да күп нәрсә билгесез булып калды, күпме мөмкинлекләр кулдан ычкынды...

Истәлекләрдән кала, бездә берни дә калмады, чөнки ул елларның байтак документы – Совет властен урнаштырган, кулаклар белән көрәшкән елларда, Сталин репрессияләре елларында социаль чыгыш, патша режимы чорында яшәү, башка туганнар турында дөреслекне раслаган документлар, ни дә булса булмагае дип, йә табып булмастай ерак яшерелде, йә яндырылды. Вакыты шул иде.

1993 елның ахырында Германиядә «Инлингуа» халыкара лингвистика мәктәбе доценты фрау А.-Л.Эббен ярдәмендә Франциянең Кызыл Хач җәмгыятенә бирелгән Россиядән 1917 ел Октябре заманында Кәримов фамилияле эмигрантлар турындагы гарызнамә әлегә җавапсыз тора.

1996 елда Атырау шәһәрендә «Казахстан» дигән Казан җәмгыяте вәкилләре белән очрашып сөйләшүләр дә бернинди яңалык өстәмәде.

Шулай да бу материал басылып чыкканнан соң әлеге ачыкланмаган мәсьәләләр ачыкланыр, чөнки тагын да күбрәк һәм төгәлрәк мәгълүматы булган кешеләр үз фикерен әйтми калмас дип уйлыйм әле. Шулай булса, мин бик шат булыр идем.

Өченчедән, шулай килеп чыкты ки, бөтен XX йөз гамәлдә безнең өчен, Кәримовлар һәм Казан татарларының башка бик күп гаиләләре өчен, нигездә, үткән йөзьеллыкта ирекле рәвештә күчеп килгәннәр өчен, Казахстан йөзьеллыгы булды. Һәр буын үзе яшәгән һәр тарихи этапта Казахстанны торгызуда һәм үстерүдә үзенең өлешен кертә.

Бүгенге көндә исә, узган гасыр ахырында һәм яңа гасыр башында, Казан татарлары арасында кире тенденция күзәтелә – алар үзләренең тарихи Ватаннарына күпләп кайта башлады.

Ни өчен? Монысы икенче мәсьәлә. Минем уйлавымча, монда, бер яктан, кемнең дә булса гаебен эзләү дөрес булмас иде; икенче яктан, яхшыга яман белән кайтаруны да раслау кирәкмидер.

Бар да күпкә гади: минемчә, бу – табигый һәм закончалыклы процесс.

Бу теманы тәмамлап шуны да әйтәсем килә: боларның һәммәсен дә бәян итеп, мин асылда милләтебезнең киләчәк буыннарына мөрәҗәгать итәм. Иң мөһиме, минемчә, бу дөньяга килгән һәр кеше, кайда гына һәм нинди генә дәүләттә яшәмәсен, әллә нинди батырлыклар, ачышлар ясамаса да, тормышта үзенең лаеклы урынын табарга, башлангычы борынгы болгар заманыннан килүче

татарларның гореф-гадәтләрен, йолаларын тиешенчә дәвам итәргә бурычлы. Моңа минем иманым камил.

Шулай да, «тирән борынгылыкны онытмаска өндәгән» хикәятемә апелляция биреп, мин беркемне дә үткәнгә, ягъни бары тик үткән белән генә яшәргә чакырмыйм.

Үткәнне белү киләчәк өчен кирәк. Аны белмәгән килеш, лаеклы бүгенгең дә, тотрыклы киләчәгең дә юк.

Язмамда безнең нәселгә нинди дә булса кагылышы булган күренекле фамилияләрне атасам да, аларга бернинди дәгъвам да, таләбем дә юк. Икенче төрле әйткәндә, генеалогия тамырларын һәм бәйләнешләрен эзләүдән гайре, бернинди максатны күздә тотмадым.

Бу үз чиратында гаҗәп киң дөньяның ни дәрәҗәдә тар булуын, теләсә кайсы гаиләдә вакыйгалар, хәлләр һәм язмышларның ничек итеп бер-берсе белән бәйләнештә тору мөмкинлеген күрсәтә.

Шуны да онытмаска кирәк: күп-күп дип сөйләнсәк тә, дөньяда Казан татарлары әллә ни күп түгел икән бит. Өстәвенә үзебез үк киметә барабыз. Сакларга һәм арттырырга иде милләтебезне...

Соңгысы. Үз халкымның тарихына аеруча басым ясасам да, мин аны башка халыкларга, бигрәк тә рус халкына каршы куюны максат итмәдем.

Шуның өстенә Казан татарларының үзләре арасында да әлеге принципиаль фәнни мәсьәләгә, милләтнең этносәяси тарихына бәйле мәсьәләгә төрле караш яшәп килә.

Болар – аларның хокукы булса, бу очракта мин язганнар – минем хокук, бу мәсьәләне үземчә күрүем дип әйтергә була.

Әлеге мәсьәләләр хәл ителер дип ышанасы килә. Бигрәк тә XX йөз белән XXI йөз кисешендә татар халкы яңарыш чорын кичергәндә. Бу чор бөтен дөньяга чәчелгән татарның рухи көчен берләштереп, милләтебез, мәдәниятебез һәм икътисадыбызны үстерүдә яңа борылыш ясар, борынгы һәм катлаулы тарихыбызның безгә әле һаман да билгеле булмаган байтак битләрен ачар.

## Высоцкий, рок һәм футбол

*Ашыктырма әле мине, Ходам! –*
*Җырларымны җырлап бетерим.*
*Өлгерермен әле Синең янга –*
*Әүвәл монда «гөлләр» үстерим,*
*Бәгыремдә шыткан һәр «гөлемне»*
*Дусларыма илтеп җиткерим,*
*Сөйгәнемә илтеп җиткерим!*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

*Һәр буынга үзенең кабатланмас үзенчәлекләре һәм формалашуы, үсеше, аякка басуы өчен үз шартлары була.*

*Алар кешенең эчке дөньясын, холык-фигылен, әйләнә-тирә мохитне кабул итүен үзенчә формалаштыра, калыпка сала, реаль чынбарлыкка үзенең шәхси мөнәсәбәтен булдырырга мөмкинлек бирә.*

*Минем карашка, бу процесслар, хәлләр унсигез яшь тулганга кадәр бара.*

*Шәхсән минем өчен, марксизм-ленинизм классиклары сүзләре белән әйтсәк,ербөтеннең өч өлеше – Владимир Высоцкийның җыр репертуары, 60 нчы еллар азагы – 70 нче еллар башындагы рок-музыка һәм шул ук еллардагы футбол.*

*Бу җенләнүләр, мавыгулар минем тормышымда әллә ни хәлиткеч роль уйнамады; аларда мин нииндидер уңышларга, дәрәҗәләргә ирешмәдем, теләгем дә булмады, ягъни алар минем һөнәремә, профессиямә яки эшемә әйләнмәде.*

*Алар бер-берен тулыландырып, минем эчке кичерешләремә һәм уйлануларыма ияреп йөрүче, юлдаш мөһим факторларга әйләнеп, тормышымда беркайчан да югалмас тирән эз калдырдылар...*

### 1. «Ә МИНЕМ САГЫШ – МӘҢГЕЛЕК КАРДАЙ...»

Высоцкийны мин беренче мәртәбә 1969 елның көзендә кинода күрдем.

Миңа 11 яшь һәм мин Күкчәтау өлкәсендәге «Боровое» дигән балалар шифаханәсендә.

Кичен кино залында «Вертикаль» дигән фильм күрсәттеләр.

Ә аннан алдагы көндә бөтен бала, минем яшьтәшләрем, бары тик Высоцкий турында гына сөйләшеп йөрде. Ниләр генә уйлап чыгармадылар, ул чакта ук инде Высоцкий тере әкияткә әйләнгән иде. Мин дә бу кинода ниндидер бер могҗиза күрергә әзерләндем.

Тик көткәнем акланмады.

Ул – гади бер кеше; гадәти, башкалардан әллә ни аерылып тормаган патриотик җырлар башкарды.

Өстәвенә җырында җырлаган тау түбәләренә бер мәртәбә дә күтәрелмәгән радист ролен уйнады. Билгеле инде, боларның барысы да сценарийга бәйле иде, шулай булса да ул чакта без малайлар каршында күп нәрсә югалтты ул. Хәтта сакалы да ярдәм итмәде.

Мин уйга калдым. Монда нәрсәдер үз урынында түгел.

Беренчесе. Фильм рәсми, димәк, актер үзен тулысынча күрсәтә алмый.

Икенчесе. Яңадан карарга туры килсә, аның җырларына ныграк игътибар итәргә. Сөйлиләр икән, димәк, аның шигырьләрендә, җырларында нидер бар. Бу мәсьәләне әйбәт көннәр житкәнчегә кадәр дип күңелемә яшереп куйдым да үземчә хәл иттем.*

Шуннан соң, ике еллап вакыт үткәч, олы абыем Әдһәм ярдәмендә В.Высоцкий иҗаты белән танышу мөмкинлегенә генә ирешеп калмадым, Битллар, Роллинглар, Джефферсон Эйрплан, Лед Зеппелин, Шокинг Блу һәм башка күренекле рок-башкаручыларны да ишеттем.

Дөрес, ул чакта алар 9 нчы тизлектә һәм 6 нчы типтагы магнит тасмадагы, өстәвенә әллә ничә мәртәбә күчерелгән, ягъни, безнеңчә әйткәндә, «пычрак» моноязма иде. Әмма ул елларда аларның дәрәҗәсе югары, бәһасе зур иде.

Үсә төшкәч, мин Высоцкийны, ягъни аның үз җырларында ни әйтергә теләгәнен аңлый башладым.

Бу бик гади икән бит.

Ул элек булган һәм хакыйкатьтә, тормышта бүгенге көндә бара торган хәлләр турында сөйли икән ләбаса.

Без бит бөтенләй икенче дөньяда, икенче үлчәүдә яшибез: ниндидер реаль булмаган, кемдер уйлап чыгарган дөньяда. Хикмәт менә нидә. Ул без күрергә тиешле дөньяны түгел, чынлыктагы, хакыйкый дөньяны күрә икән бит.

Бу артык мөһим иде. Кайчакларда ул без уйлаган нәрсәләр турында сөйли кебек тоела иде.

Кабатланудан да курыкмыйча (бу турыда сөйләү яхшы тон булып санала) әйтә алам: Владимир Семенович *Высоцкий – минем заман кешесе*, һичшиксез, кабатланмас феномен, вакыйгаларның, дөньяда, тирә-юньдә бара торган хәлләрнең асылын берничек тә бозмыйча, икенчегә бормыйча, читкә тайпылмыйча, тәлинкә тотмыйча ачып биргән зат.

Бөтенесен һәм бар нәрсәне тоткарлап торган, комачаулаган коммунистлар идеологиясенең сәяси мәйданыннан китеп барган булса да (күргәнебезчә, сәбәп бөтенләй башкада икән), моны эшләү әле хәзер дә беркемнең дә хәленнән килми.

Шунысы гаҗәп: кешеләр дөньяны элеккечә үк бары тик кемнеңдер призмасы аша гына күрергә тели (бәлки, шулай җайлырактыр һәм файдалырактыр да) һәм бүгенге көнгә кадәр бирегә үзләренең вакытлыча гына килүенең асылына төшенә алмый.

Шуңа күрә дә безнең чынбарлыкта бүгенге көнгәчә закон көченә ия диярлек бозыклыкны, аерым алганда икейөзлелек, хөсетлек, караклык, казна басу, тәкәбберлек, көчләү, рәхимсезлек, күралмаучылык, ялган, битарафлык, кеше хисабына яшәргә тырышуны (чөнки хакимият башында бүген син) үз эченә алган проблемалар тулып ята.

Аның шәхесен идеаллаштырмыйча, үземә якын җыр репертуарыннан гына чыгып шуны әйтә алам: мин В.Высоцкий белән бер чорда яшәдем.

Бу чыннан да шулай. Әле аны бары тик кинода яки телевизорда гына күрергә туры килсә дә.

Әдһәм абый безгә – энекәшләренә караганда күпкә бәхетлерәк иде. Мәскәүдә АКШ бәйсезлегенә 200 ел тулу уңаеннан үткәрелгән күргәзмәдә һәм, Таганкадагы театрда булып, безне күреп торган кебек аны да тере килеш, янәшә торып күргән абыемны тын да алмыйча тыңлап утыруыбыз һаман да истә.

Үзе белән бер полкта хезмәт иткән һәм театрда эшләгән (ул чакта театрның баш режиссеры – Ю.Любимов) дусты В.Кондратьев ярдәмендә ул В.Высоцкий катнашындагы берничә спектакль – Дж.Рид буенча «Десять дней, которые потрясли мир»ны, Шекспирның «Гамлет»ын карый алган һәм аңа сәхнә артында, актерлар буфетында да булырга туры килгән.

Шушы мәрхәмәтле, күңелле һәм яхшы вакыт турында ядкәр булып Таганкадагы бу спектакльләрнең дүртәр тиенлек программалары, Хокуклар турында Билль һәм АКШ Бәйсезлеге Декларациясе калды.

Высоцкийның ниндидер бер тәгаен темага багышланган җырлар циклы кызыклы да, гыйбрәтле дә иде. Болар сугыш, атлар, кораблар, спорт, фән, совет обывателе, мәхәббәт һәм башка темалар, җыеп әйткәндә, тормыш, нәкъ менә безнең тормыш турындагы темалар иде.

Аның 800 дән артык җырының һәммәсенә дә шагыйрь тарафыннан гаҗәеп тирән мәгънә салынганга, байтак гыйбарәләре, өземтәләре шундук үзенә бертөрле әйтемнәргә, формулаларга, хикмәтле сүзләргә әйләнде; алар, төрле һөнәр ияләре арасында танылып, популярлашып өлгерде, бүгенге көндә дә халык теленнән төшми.

Шуларның берничәсен генә булса да искә төшерик:

«Таулардан бары тик үзең барып күрмәгән таулар гына яхшы»;

«Барыннан да кирәгрәк, иң яраткан һәм тугры хатын-кыздан кала, бар да әйләнеп кайта»;

«... Ходай янына кунак килә соңламый»;

«Дөньяда менеп җитә алмаган биеклекләр юк»;
«Мин сулыйм – димәк, яратам!
Яратам – димәк, яшим!»
яки:
«Чырайны соңрак изәрбез,
Әүвәл шәраб бирегез!» һәм башкалар.

Тик шулай да хикәятемне дәвам итәр өчен түбәндәге аңлатманы бирергә тиешмен.

Беренче: В.Высоцкий иҗаты турында сүз чыкканда, аның Сталин репрессияләре темасы белән тыгыз бәйләнгән, аваздаш булган сугыш турындагы җырлары хакында сөйләү гадәткә кергән. Бу очракта шуны әйтергә һәм танырга кирәк: чынлап та аның хәтта сугышны үткәннәр арысында да тиңе юк. Әмма бу турыда еш сөйләнгәнгә, кабатланмас өчен мин аңа тукталып тормыйм һәм аның җыр репертуарындагы башка юнәлешләр турында кыскача әйтеп китәм.

Икенче: сүз дә юк, аның җырларыннан өзекләр китереп кенә дә чикләнеп булыр иде, әмма мондый кисек-ертыклар, минем уемча, аның иҗаты белән гомумән таныш булмаган яңа укучы өчен берни дә бирмәячәк, һәм, иң мөһиме, аның җанын тою мөмкинлеге булмаячак.

Шуңа күрә, алга таба В.Высоцкийның берничә җырын тулысынча китереп, мин бары тик аның истәлегенә минем бүләгем, ихтирам билгесе булыр дип кенә уйладым.

1976 елда, әле студент чагымда, мин аның «Иске йорт» («Старый дом», 1974) җырын ишеттем. Шуннан бирле бу җыр Россия (ул чакта Советлар Союзы) образы белән ассоциацияләнә.

Минем уемча, бу тема бүген дә актуаль. «Куу» («Погоня») дигән беренче өлешендә ул атларда, урманда тирән карны ерып, бүреләрдән кача.

Нинди өй соң бу, гел төнгә чумган,
Үзәккә үткән җилләр чатында,
Бар тәрәзәсе чокырга карый,
Ә капкалары – юллар катында?
Таушалдым, ардым – атны тугардым,
Әй, кем бар анда – чык та ярдәм ит.
Беркем юк, ахры – бары шәүләләр,
Козгыны төште, эзләп сасык ит.
Өйгә атладым – әйтерсең кабак*,
Халык бер көтү – чиреге дошман.
Йөзен чөерә – көтмәгән кунак!
Почмакта тәре – янтаеп төшкән.
Китте сөйләшү, шомлы гөрләшү,
Кемдер җыр сузды, гитара кызды,
Үзчирле берәү – исәр һәм карак –
Өстәл астыннан пычагын «сузды».
«Кем әйтер миңа – бу соң нинди өй,
Чума кергәндәй, ник караңгыда?
Лампадлар* сүнде, һавасы керле –
Яши белмәгән кешеләр монда.
Ишекләр ачык, ә җаннар бикле.
Кем хуҗа? Әйдә, куй шәрабыңны!»
Җавабы килде: «Ахры, күп йөрдең:
Гел шул тормыш бит – син белмәдеңме?
Үлән ашыйбыз, көн дә – кузгалак,
Җаннар әчеде, беттек бетчәләп,
Шәрабны койдык – бугаздан чыкты,
Талау, сугышу, асу һәм ләгънәт –
Безнең бар гадәт, бездә юк әдәп».
«Атлар интекте – бүре күп иде.
Лампад яктырткан җирләр кайда соң?
Идәннәре дә авыш булмасын,
Анда һәр кеше бары җырласын,
Күңел төшереп, гел сыкранмасын».
«Андый йорт барын ишеткән дә юк –
Дөм караңгыда яшәү хас монда.
Гомергә – явыз, шомлы сердә без –
Корымга каткан тәре астында».
Хачы** кыйшайган бу чирканычтан
Чыбыркысыз да кудым атларны.
Кая булса да риза, бары тик
Кешечә җиргә илтсен башкайны.
...Күпме баттым мин, күпме чикләндем,
Язмыш күп төйде – калдым нишләптер.
Шәп җырлар сезгә миндә, шәт, әздер,
Әй кара күзләр, ап-ак эскәтер?!

«Петр Русе турында җырлар» да («Песни о петровской Руси» (или «Купола», 1975) мәңгелек сагыш һәм чынга ашмаган өметләр белән сугарылган:

Күзләрем ничек күрер дә, ничек итеп сулармын?!
Яшенле яңгыр алдыннан һава кырыс һәм үзле.
Ни хакта ишетермен мин, ни турында җырлармын?
Күрәзәче кошлар сайрый, әкияттән алып сүзне.
Сирин кош дигәне миңа шатланып «авыз ера»,
Күңелемне кинәндереп, кыстап үзенә чакыра.
Ә аның каршында исә, сагыш-моңга күмелеп,
Гаҗәеп сәер Алконост җанымны адаштыра.
Әйтерсең серле җиде кыл
Чыңлап куйды чиратлап.
Бу бит Гамаюн дигән кош –
Җырлый өметем аклап.
Манаралар тишкәләгән зәп-зәңгәр аяз күктә
Бакырдан коелган чаңнар чыңлыйдыр инде күптән –
(Әллә зур шатлык өләшә, әллә ачуы җиткән).
Чиркәү башы Россиядә сары алтын, саф алтын –
Ходай ешрак күрсен диптер үзенә табынган халкын...
Мин торам басып мәңгелек бер табышмак алдында,
Бөек һәм әкияти бер ил каршында калдым да.
Тозлы, әче, бер үк вакыт зәһәр дә, татлы да ул,
Зәңгәр күкле һәм чишмәле, ипиле, ашлы да ул.
Ябышкак һәм үзле сазны көчкә ерып
Килгән атлар өзәңгедән батып кала.
Тарта мине шешенеп беткән, җебеп төшкән,
Йокысыннан һич айнымас бу держава.
Әйтерсең лә бай җиде ай
Юлыма чыкты килеп.
Гамаюн һаман да җырлый,
Миңа ышаныч биреп.
Югалтулар адаштырган бу җанымны,
Гөрелтеләр изеп киткән бу җанымны,
Ямаулыгым үтә юка калган булса,
Алтын белән тизрәк ямап куярмын мин –
Ходай нурын инде күбрәк тоярмын дип!..

Әйе, бу – Россия. Кичәге һәм бүгенге Россия. Ә иртәгә ул нинди булыр? Кем белә...

Высоцкий һәр җырын үзе аша, үзенең мине аша үткәрә иде, һәрвакыт үз исеменнән генә сөйләде, шуңа күрә дә үз фикерләрен, үзенең шигъри образына тулысынча кереп бетеп, шулай төгәл чагылдыра алгандыр да.

«Талымлы атлар» («Кони привередливые», 1972). Шагыйрь сүзләре котылгысызлык, шул ук вакытта яшәүгә сусауны ничек итеп ачып бирә алган!..

Кеше тормышының мәңгелек алдында соңгы мизгелләренең, инде беркем дә, бернәрсә дә сиңа ярдәм итә алмый торган мизгелләрнең искитәрлек сюжеты...

Әлеге фаҗигале һәм сагышлы җырда, минем карашка, Высоцкийның шагыйрь буларак та, башкаручы буларак та, җырчы һәм актер буларак та бөтен таланты ачыла.

Бер үк вакытта Шагыйрь булу һәм тыңлаучыга үз шигырьләреңне ишеттерә белү, бу очракта – җырлау, һәркемгә дә бирелми, беркем дә аның кебек булдыра алмый, әлбәттә.

Аны тыңлаган саен, үз фикерләрен һәм хисләрен ничек болай төгәл һәм үзәккә үтәрлек итеп әйтеп бирә алды икән дип таң каласың.

Бөек һәм Мәңгелекне – гадидә, гадине Бөек һәм Мәңгелектә күрә белү, минемчә, аның көче һәм куәте нәкъ менә шунда.

Текә яр буйлап, упкын өстеннән, нәкъ кырыеннан
Ярсу атларны бик нык камчылап барам куалап.
Тыным кысыла – салкын җил эчәм, томанны йотам –
Һәм фаҗигале соклану белән сизәм – югалам.
Бетәм, югалам.
И аткайларым, акрын атлагыз!
Каеш камчыдан куркып чапмагыз!
Талымлы булды никтер атларым –
Яшәп булмады – хет җырлап калыйм.
Атларны эчерермен,
Җырымны бетерермен –
Яр кырында тик бер мизгел
мин көттерермен...
Сүнү белән мине учтан давыл очыртып китәр,
Һәм чаналар иртүк кардан шуар, җиргә орынмый.

Ашыкмыйча юыртыгыз, и яраткан атларым,
Бераз гына озайтыгыз минем соңгы юлымны!
И аткайларым, акрын атлагыз!
Камчы үзгәртмәс сезнең адымны.
Талымлы булды никтер атларым –
Яшәп булмады – хет җырлап калыйм.
Атларны эчерермен,
Җырымны бетерермен –
Яр кырында тик бер мизгел
мин көттерермен...
Өлгердек. Ходай янына кунак килә соңламый...
Нигә анда фәрештәләр матур итеп җырламый,
Әллә атлар кыңгыравы шулай өзгәләнәме,
Әллә үзем, акрын бар дип, чанага бәйләнәмме?
И аткайларым, акрын атлагыз!
Үтенәм сездән, алай чапмагыз.
Талымлы булды никтер атларым –
Яшәп булмады – хет җырлап калыйм.
Атларны эчерермен,
Җырымны бетерермен –
Яр кырында тик бер мизгел
мин көттерермен...

Владимир Высоцкий яшәп тә, җырлап та, иң мөһиме, яратып өлгермәде...

Әйбәтләрне үлем берәм-берәм ала,
Әүвәл шуны, кем кайчандыр юри генә үлеп караса...

Ул, аның иң яхшы һәм соңгы фильмнарының берсе – «Калина Красная»ны безнең исебезгә төшереп, Василий Шукшин истәлегенә багышланган җырында шулай яки шуңа охшаш сүзләр язды һәм җырлады.

Мондый рольләрне Высоцкий үзе дә уйнады. Театрда – «Гамлет», кинодагы соңгы рольләренең берсе – дон Гуан (А.Пушкинның «Каменный гость» әсәре буенча төшерелгән «Маленькие трагедии» фильмындагы монолог-спектакль).

Шундый ук рольне бервакыт «Кино» төркеме лидеры, минем карашка, совет чорының иң талантлы рок-музыканты, иҗат планында барыннан да күбрәк В.Высоцкийга якын торган Виктор Цой да уйнады.

Совет эстрадасының соры һәм төссез күгендә якты йолдыз булып балкып алды да, көтмәгәндә-уйламаганда үзенең тормыш юлын фаҗигале төстә тәмамлап та куйды.

Бу хәл шулкадәр тиз булды ки, безнең күбебез ул китеп баргач кына бу югалтуны чын-чынлап тойды...

Кеше гомере...

Без җир йөзендә безгә яшәү мөмкинлеге бирелгәнгә берәр вакыт хисап тотабызмы, үзебездә ни йөртәбез, бирелгән вакытның кадерен беләбезме?..

Сораулар... сораулар... сораулар!

Кемдер күрде җимешне – бу бит тиз пешми,
Кәүсәне селкеттеләр – килде дә төште.
Менә сезгә матур җыр – җырланмый калган,
Тавышы да бар юкса – белмәгән алдан.
Бәлки, язмышы аннан
хата тапкандыр,
Гамәлләре кайчакта
үзен саткандыр.
Нык тартылган нечкә кыл
шушы ладларга
Кимчелеген сиздерми
килеп яткандыр.
Кыюсыз гына «до» дан башлады,
Суза алмады – көйне ташлады.
Аккорд тәмамланмады,
Беркем илһам алмады.
Эт өрә торды, ә мәче
Тычкан аулады.
Көлкеме, чынлап көлкеме?..
Шаяртты, тик күпкәме?
Туйганчы шәраб эчмәде,
Иренгә дә җитмәде.
Әлегә ул бары тик бәхәсләр кора,
Ышанып та бетмичә, ашыкмый гына.
Әйтерсең лә тамчылап тир тамып тора –

Тәннең һәр ноктасыннан җан саркып чыга.
Башланып китте келәмдә
дуэль бермәлне,
Ул, көч-хәл белән булса да,
аңа иярде.
Уенга акрынлап кына
керде шул чакны –
Хөкемдары да әлегә
ачмый хисапны.
Беләсе килде аның барын да,
Тик өлгермәде «...кадәр» барырга.
Төшмәде ул тирәнгә –
Җиңел генә уйлады.
Ә үзе ялгыз берәүне
Яратып та туймады.
Көлкеме? Әйе, көлке шул...
Ашыкты – йөрәк талды.
Үзе хәл итмәгән бар да
Хәл ителмичә калды.
Бер генә сүзем дә бит ялган түгел –
Ул чынлап та булды аңа хезмәтче.
Ап-ак карга шигырь язды аңа дип,
Кызганыч, кар эри кеше күргәнче!
Ул чакта шактый күп итеп
кар яуды,
Ә ак карлар
шигырьләрдән каралды.
Зур-зур кар бөртекләре
һәм дә бозлар
Йөгергәндә иреннәрдә
таралды.
Тик ул көмеш ландода
Барып җитмәде аңа...
Качкын чапкын берничек тә
Киталмый хәлдән тайды.
Йолдызлыкта Үгезбозау
Каз юлын ялап калды.
Көлке бит, әйе, көлке!..
Вакыт китте әрәмгә.
Бер генә буын ычкынсын –
Бар да оча галәмгә.
Көлке, чынлап та көлке!..
Сез дә көләсез, мин дә...
Ат – йөгәндә, ә кош – күктә –
Гаеп кемдә, гаеп кемдә, гаеп кемдә?!

*(«Өзелгән юл» –*
*«Прерваный полет», 1973)*

Һәм соңгысы.

Аның бөтен җырлы иҗатыннан үтәли, барын да берләштергән, бәйләгән кебек бетмәс сагыш уза. Хәтта юмористик сюжетларда да, лирикасында да. Бөтен җирдә – сагыну-сагыш, котылгысызлык, һәлакәт.

Шуңа күрә Шагыйрьнең киләчәктә чыгачак шигырьләр китабына аның фильмнарының берсендә үзе җырлаган сүзләрен эпиграф итеп алыр идем мин:

Минем сагышым, мәңгелек кардай,
һич тә эреми.
Җәйге эсседә, көндез челләдә
хәтта эреми.
Мин беләм шуны (уйлар йөгерек):
Хәсрәт-сагышның тик үзем белән
бетәр гомере...

Тагын да алгарак китсәк, ул шигырьләр җыентыгымы яки Владимир Высоцкий башкаруында үз җырлары тупланган CD язмамы – гомуми исем белән «Ә минем сагыш – мәңгелек кардай» дип аталыр һәм аңа Высоцкийның үзем яраткан иң матур җырлары керер дип уйлыйм.

## 2. КҮККӘ БАСКЫЧ

Һәр чәршәмбе кичке унынчы яртыда, «Ригонда» радиоласы янына иркенләп утырып, түземсезлек белән 31,7 метрлы кыска дулкын диапазонында Билл Чейзның танылган «Open Up Wide» джаз композициясенең яңгырый башлавын көтәм.

Һәм, ниһаять: «Сәлам. Вашингтоннан «Америка авазы». Микрофон алдында – Юрий Осмоловский. Популяр музыка. Концерт-Берне башлыйбыз...» «Америка Кушма Штатлары. Вашингтон, дистрикт Колумбия, 20044 нче бокс. Концерт-Бер яки Ике»...

Радиоалгычтагы ешлык каядыр китеп югалса яки шул ешлыкта башка авазлар яңгырый башласа, тагын да игътибар белән ябышасың...

Чынлап та, гомуми һәм тотальмәгълүмати вакуум чорында җитмешенче еллардагы совет яшьләре арасында Вашингтоннан яңгыраган әлеге популяр музыкаль тапшыруны кем хәтерләми икән?.. Яисә Ирина Левитина белән Шари Бэклның һәр шимбә яңгырый торган «Бию программасы»н?..

Җитмешенче елларның беренче яртысында әлеге язмалар өчен яшел тышлы блокнотым гына булса, ә аның урталарында инде мәктәпнең «Яуза» дигән катушкалы магнитофонын, ә аннары үземнең өйдәге «Снежеть» дигәнен әзерләп куя идем.

Дөрес, музыка белән танышуның башка чыганаклары да бар, тик алар Осмоловский тапшыруларына якын да килми – аның рок-музыка өлкәсендәге барлык мәгълүматы да чын дөреслеккә туры килә, тапшырулары да оператив була иде.

Ул чактагы рәсми совет чыганаклары арасында Виктор Татарскийның ял көнге «Запишите на Ваши магнитофоны» («Магнитофоннарыгызга яздырыгыз»), Вячеслав Осокинның «На всех широтах» («Барлык киңлекләрдә») дигән радиотапшырулары, басмалардан «Новое время», «Ровесник» журналлары, полякларның «Панорама» журналы, «Кругозор»га өстәмәләр», «Мелодия» фирмасының аноним башкаручылар белән (җырның исемен атагач, гади генә итеп «вокаль-инструменталь ансамбль» дип кенә әйтелә иде) язылган күпләргә билгеле кечкенә грампластинкалар сериясе бар иде.

Алтмышынчы еллар ахыры – җитмешенче еллар башы чынлап та тетрәндергеч, чын-чынлап фантастик музыкаль шартлау, рок-музыкада бер-бер артлы төрле һәм кабатланмас юнәлешләрнең туу чоры булды.

Аларны санап чыгу гына да күп нәрсә турында сөйли. Мәсәлән, фолк-рок, кантри, блюз-рок, джаз-рок, авыр, җир асты, металл, глиттер-рок, арт-рок, панк-рок, прогрессив, рухи, симфо, техно-рок һәм башкалар; музыкаль агымнарның төрле катнашмалары да киң таралган вакыт иде ул. Алар арасында рок-операны, рок-мюзиклны күрсәтергә була. Рэггей, диско һәм яңа дулкыннарны да кертеп, нәтиҗәдә алар җитмешенче елларның финишы булды.

Шуның өстенә һәр төркемнең үз стиле, кабатланмас яңгырашы, вокал, имиджы бар иде, ахыр чиктә алар рок-музыкада тулы бер чорны тәшкил итте.

Ул еллар гаҗәп күңелле һәм кызыклы еллар иде: сине кызыксындырган төркемнең яңа язмаларын түземсезлек белән көтәсең, ә ул, чынлап та, рок-музыкада нәкъ менә бу юнәлешне үстерүдә алга таба баруы белән таң калдыруы сәбәпле, синең бу көтүеңне, ышанычыңны аклый...

Сүз дә юк, рок-музыка үсешендә 1969 елда иң зур һәм легендар фестиваль үткәрелгән Нью-Йорктан 120 чакрымдагы Вудсток дигән зур булмаган сөт фермасы бер борылыш ясады. Андагы фурор рок башкаручыларның иҗади музыкаль фикерен әле тагын ун еллап тайпылышсыз алга этәрде.

Җыеп әйткәндә, бу ниндидер сәер һәм гипнозланган кебек аңлатып бирә алмастай бер халәт иде, чөнки миллионлаган кеше әлеге музыкадан исәрләнеп йөрде...

Иң мөһиме, үзенең табигате белән төрле музыкаль стиль һәм юнәлешләрнең катнашмасы булган, төгәл ритм белән драматик вокалга нигезләнгән рок-музыка ни өчен күпмиллионлы аудиторияне тиз арада яулап ала алды. Рок-музыкантлар әлеге музыка аша үзләренең уй-фикерләрен, идея һәм хисләрен, әйләнә-тирәгә үзенең карашын белдерде, ягъни бу – яшьләрнең үзен күрсәтүдә яңа һәм үзенчәлекле чара булды.

Ул елларда безнең чагыштырмача кечкенә, барысы өчен дә ябык Гурьев шәһәрчегенә кайдандыр, ниндидер юллар белән әүвәл магнитофон язмаларының (сыйфаты әһәмиятле түгел иде), ә аннары грампластинкаларның үзләре (Beatles, Rolling Stones, Deep Purple һ.б.) күренә башлавы мине бик гаҗәпләндерә иде.

Тим Райс һәм Эндрю Ллойд Уэбберның «Иисус Христос – Суперзвезда»... рок-операсы чын-чынлап ачыш һәм өермә булды.

Ул чакта мин: килер бер көн, билгесез бер җирдә түгел, нәкъ менә милли социализм, сыра фетнәсе һәм Европаны бүлергә керешкән Мюнхен пакты ватаны Баварияның башкаласы (ул чакта безгә дошман) «Ирекле Европа» радиосы сөйләп торган, дөньяның Франц Беккенбауэр белән Герд Мюллер җитәкчелегендәге иң яхшы командасы уйнаган, Silver Convention белән Boney M һәм «Мюнхен стиле» яки диско-музыка барлыкка килгән Мюнхен шәһәрендә, музыкага кагылышлы бар нәрсә дә булган «World of Music»ка кереп, теләсә кайсы төркемнең теләсә нинди компакт-дискын, барлык башкаручылар һәм аларның бөтен дискографиясен, ягъни бөтен заман һәм буыннар музыкасын сайлап ала алырмын дип күз алдына китерә ала идемме?..

Дөрес, буең җитмәстәйгә дә үрелергә һәм рок-музыка турында, аңа кагылышлы төрле әдәбиятны файдаланып, ни билгеле булса, барын да сөйләп бирергә дә мөмкин булыр иде, әмма мин, композицияләре үз вакытында кеше җанының иң тирән почмакларына да төшеп, бүгенге көнгә кадәр

чынлап та югалмас эз калдырган төркемнәр һәм башкаручыларга гына тукталам, чөнки аларны искә алганда ул елларның идея һәм уй-фикерләрен кабат тергезү генә түгел, кайчандыр үзең дә булган шул дөньяга кире кайтырга мөмкин...

Нинди бәхет: мин әлеге фантастик музыкаль шартлауның иң бөек ноктасына җиткән вакытына туры килдем. Аны бернигә дә тиңләп булмаслык нурланышы белән галәмне балкытучы һәм бу мизгелдә әлеге бушлыкның, салкынлык, тынлык һәм караңгылыкның чиксез киңлегендә кеп-кечкенә ком бөртегендәге безнең барыбызның да бәгырен үтәли кисүче гаҗәеп якты һәм өр-яңа балкыш белән генә чагыштырырга мөмкин булыр иде...

Иманым камил, алтмышынчы еллар ахыры – җитмешенченең беренче яртысы узган һәм алдагы унъеллыкларның барысыннан да иҗади яктан өстен тора. Алар белән чагыштырып та булмый хәтта.

Бер уйлаганда, шул ук алтмышынчы белән илленче еллар җитмешенченең нигезен төзи дә инде. Алардан башка берни дә була алмас иде.

Әлеге еллар чын-чынлап бөтен XX йөз музыкаль иҗатының иң биек ноктасы булды.

*«Музыка киләчәккә юл яра...*

*Бер көн килер, пулялар истәлекләр өлкәсенә күчеп китәр.*

*Бүгенге көндә без яши торган көндәлек пычрак дөнья, рухи дөнья белән чагыштырганда, океан янындагы бер вак хәшәрәт кебек. Ә Океан – безгә билгеле булган иң зур тереклек иясе.*

*Бу дөньяга илтә торган юлларның берсе – Хакыйкатькә туры карау...*

*Рухи дөнья – бар нәрсәне чагылдырган атмосфера кебек. Бу атмосфера үзен музыка аша танып белергә, тоемларга мөмкинлек бирә, чөнки Музыка – үзенең табигате белән рухи күренеш.*

*Ул – океан дулкыннары кебек. Сез океанның бер дулкынын кисеп алып өегезгә алып кайтып куя алмыйсыз, чөнки ул – даими хәрәкәттә. Әлеге хәрәкәт җирне электр энергиясе белән кора.*

*Музыка һәм хәрәкәт – кешегә хас, кешегә бәйле нәрсәләр...*

*Музыка күктән төшә, кешеләр исә музыка белән аның сафлыгына күтәрелә. Әлеге табигый биеклектән кире төшкәндә, алар үткенрәк күрәләр, икенче төрле сиземлиләр, үзләрен борчыган нәрсәләрне, авырту-газапларны оныталар һәм башка кешеләргә дә авырту, борчулар сала алмыйлар. Шул чакта, фикереңне ничек тупларга, хаталарыңны ничек ачыкларга, аларны ничек төзәтергә дип уйлый башлыйсың...»**

Сүз дә юк: Вакыт өчен үзенең кабатланмас композицияләре булды һәм була тора. Алар, дистәләгән еллар үтү белән, нәкъ менә шул Вакытны, шул Чорны тасвирлый. Бүгенгене дә, еллар үткәч, үз «мелодияләре», дөресрәге, яшьлектәге мелодияләре аша искә алырлар.

Менә мин дә, бу дөньяда минем заманның рок-музыкасын тасвирлау өчен биш популяр төркемгә тукталасым килә.

...Бервакыт туксан өченче елның Мюнхен көзе кичендә, «World of Music»ка кергәч, инде бөтенләйгә онытылган Shoking Blue язмаларын ишетеп таң калдым.

Мин, Европа үзәгендә басып торган килеш, соңгы мәртәбә моннан егерме ел элек (!) ишеткән Голландия квартеты музыкасын тыңлыйм һәм шул мизгелдә ерактагы туган шәһәрем Гурьевны, сентябрьнең җылы көнен, Киров мәйданындагы өебез ишегалдындагы «Восход» мотоциклын, кара йөземнең өлгергән тәлгәшләрен, «Юпитер» магнитофонын, акрын гына әйләнеп торучы бабинаны, тулы составтагы гаиләбезне һәм, ул чакта миңа тоелганча, безнең барыбыз өчен дә алда торган мәңгелек тормышны күрдем...

Кыска гына, әмма төгәл тәмамланган композицияләр, беренче аккордларыннан ук бөтереп алып һәм аны эчке «Мин»нең иң тирән катламында бетмәс сагыну-сагыш белән төреп, әйтерсең лә җаныңны актарып ташлый. Бу халәткә сине Маришка Вереш вокалы төшерә...

Тыңларга гына кирәк – барын да шундук аңлап аласың.

...Әйтергә кирәк, үзләренең совет тыңлаучыларын Иске Дөнья төркемнәре белән әллә ни «иркәләмәгән», һәм бары тик Төньяк Америка башкаручыларына гына өстенлек биргән Левитина/Бэкл музыкаль программаларыннан аермалы буларак, Юрий Осмоловский, киресенчә, эфир вакытын еш кына Британия рогына, ул Вакытның алыштыргысыз лидерларына багышлый иде.

Һәм бермәлне, җитмешенче еллар башында, «Америка авазы» дулкыннарында Led Zeppelin башкаруында рок классикасына әверелгән «Immigrant Song» һәм «Black Dog», аннан соң «Свинцовый дирижабль»нең «Starwey To Heaven» дигән искиткеч композициясе яңгырады. LED ZEPPELIN – авыр блюзның ярымакустик, нервларны параличлаучы композицияләре. Роберт Плантның тора-бара психологик тирәнлеккә төшә торган вокалы белән җанны кыл кебек суырып тартып чыгаручы һәм өзгәләүче, кисәкләргә телгәләүче каты, рәхимсез хард-рокка күчә...

Бер сүз белән әйткәндә, күккә алып менә торган баскычны һәм шул баскычтан үрмәләп менүче җаныгызны күз алдына китерегез – Led Zeppelin шул була инде.

Әгәр Led Zeppelin һәм шундый ук Black Sabbath кебек төркемнәр өметсезлек, сагыш һәм котылгысызлыкка салса, the BEATLES исә, киресенчә, яхшылык, наз һәм ышаныч уята.

Ливерпульдә оешкан әлеге Бөек Квартет (Дүртлек) турында бик күп әйтелде һәм язылды, мин инде ни дә булса өстәргә батырчылык итмим.

Бу урында музыкантларның үзләре позициясеннән, кешелекнең музыка хәзинәсенә мәңгегә кереп калган әсәрләрнең авторлары позициясеннән карау мөмкинлеген биргән үз сүзләренә тукталып үтәсем килә.

Гомумән, тулы ышаныч белән шуны әйтергә мөмкин: XX йөз – атом төшен бүлү һәм атом энергиясен тудыру, кешенең космоска очуы һәм айга төшүе, электроника һәм мәгълүмати технологияләрнең үсүе, кешелекнең башка эпохаль казанышлары белән беррәттән, тормышыбызга килеп кергән «БИТЛЗ» рок-музыка төркеме кебек феноменаль күренешнең тууы белән дә танылды.

«Ак альбом»ның дөньяга чыгуына бәйле (1968, ноябрь), Джон Леннон болай дигән иде:

«*Әйбәт җырлар, әмма мөкиббән китәрлек түгел...*

*Мин үзебезнең музыкага башкалар аны артык җитди кабул иткәнгә шулай битарафтыр, мөгаен. Ошыймы – шул җиткән, әмма аны күкләргә чөеп мактауны, аннан әллә нинди бөек нәрсәләр казып чыгаруны мин аңлый алмыйм...*

*Халыкның безгә шундый мөнәсәбәте, тәэсире аркасында без үзебезне чынлап та бөекләр, әллә кемнәр дип уйлый башлыйбыз... Кешеләр: «Битлз» үзенең ни дәрәҗә икәнен, әйбәт башкаруын белә», – дип уйлый.*

*Ә без аны белмибез, бары тик үз эшебезне башкарабыз – менә шул гына...»*

Минем карашка, «битлларның» иң яхшы (һәм соңгы) «Abbey Road» («Монастырь яки аббат юлы») дигән уртак дискы чыккач, 1969 елның сентябрендә Джордж Харрисон болай дигән иде:

*«Чынлыкта без эшли дә башламадык әле. Музыкант буларак нәрсәгә сәләтле һәм нинди чикләрне үтеп китәрлек булуыбызны без әле яңа аңладык. Киләчәк безнең хыяллар артында ята».*

1974 ел ахырында, Урал елгасын боз каплагач, мин, унынчы сыйныф укучысы, абыемнар үрнәгендә, ул чакта безнең өйдән ун минутлык юлдагы елга аръягында урнашкан ДОСААФның радиотехника мәктәбенә йөри башладым.

UK70AA яки – Ульяна, Киловатт, Семерка, Ольга, Анна, Анна (ике Анна) – әлеге күмәк радиостанциянең баш хәрефләрдән җыелган позывное (чакыру сигналы) шундый иде.

Әмма, ультракыска дулкында, тавыш тембры югарылыгы буенча хөкүмәтнең югары ешлыктагы (ВЧ) телефон элемтәсе белән генә чагыштырырлык югары ешлыктагы эфирда эшләп, кайчакта Владивосток белән элемтәгә керә алсак та, без бары тик һава торышы турында гына сөйләшә ала идек. Күңелгә ятышлы бердәнбер нәрсә – ул чакларда чиксез илебезнең төрле почмакларыннан даими алына торган безнең радиосөйләшүләрнең булуын раслаучы ЩСЛ карточкалары.

Уралда боз эреп беткәч, мин, яңадан абыйларым үрнәгендә, башка дулкынга күчтем – ул чакта нигездә яңа музыка язмаларын әйләндерер өчен эфирга чыккан «радиохулиганнар» ешлыгына – СВ ешлыкка чыга башладым.

Монда инде без төрлесе турында – рок төркемнәр, радиотехникадагы яңалыклар хакында сөйләшеп, саклык белән генә очрашулар билгеле һәм, хәзергечә әйтсәк, кызыксыну буенча яңа танышлар таба идек.

Сүз уңаеннан: энекәшем Рафик, үзе җыйган тагын да көчлерәк, чын радиостанциясе аша, тиешенчә теркәлгән булганга, өйдә килеш бөтен союздагы коллегалары белән законлы рәвештә элемтәгә керә иде.

Һәм менә 1975 елның июнендә, мәктәптәге чыгарылыш кичәсеннән соң иртәнге якта гына өйгә кайтып кергәч, радиоалгычны кабыздым да соңгы мәртәбә эфирга чыктым. Һәрвакыттагыча алхәбәр (заставка) сыйфатында «Космическая фабрика» – «Гастролирующий ансамбль» альбомыннан Криденсларның ике минутлык боевигын куйдым. Аннары бер сәгать дәвамында эфирда бары тик Криденслар музыкасын гына әйләндердем – «Бег через джунгли» («Джунгли аша качу»), «Я заколдовала тебя («Мин сине сихерләдем»), «Гордая Мэри» («Горур Мэри»), «Видел ли ты дождь?» («Синең яңгырны күргәнең бармы?») һәм башкалар. Үземнең музыкаль программамны яңа, әле миңа бөтенләй таныш булмаган Sweet төркеменең «Америка авазы»ннан язып алынган «Блицкриг на танцплощадке» («Бию мәйданчыгында блицкриг») дигән хиты белән тәмамладым.

Менә шулай итеп, «Криденслар» ярдәмендә урта мәктәптә укуыма нокта куйдым һәм радиоалгычны сарайга чыгарып яшердем дә яңа тормышка аяк басарга – институтка имтиханнар бирергә әзерләнә башладым...

CREEDENCE CLEARWATER REVIVAL – беренче карашка, аның стиле югарыда телгә алынган төркемнәр белән чагыштырганда күпкә гади – кантри буларак билгеле рок-н-рол композицияләре һәркемгә аңлаешлы, җиңел истә кала торган һәм аның белән ял итүе дә рәхәт иде.

Шулай булса да, бу төркемдәге музыкантлар үзләренең осталыгы белән башкалардан калышмый иде. Алар арасында, һичшиксез, ике бертуган лидер – композитор һәм вокалистның берсе Джон Фогертиның таланты аерылып тора иде.

Алтмышынчы еллар ахырында дөньядагы әйдәп баручы рок-төркемнәр рәтенә югары сыйфатлы балладалар кушылмасында һөҗүм итү планындагы көчле хард-рок белән биш музыканттан торган инглиз төркеме бәреп диярлек килеп керде.

DEEP PURPLE төркеменең составы төрле елларда төрлечә булды.

Әгәр аның беренче язмалары бераз тыйнаграк булса, «Deep Purple in Rock», «Feridall» һәм «Machine Head» дигән альбомнары бөтен хит-парадларны шундук яулап алды. Җитмешенче елларның беренче яртысында бер ел интервал белән чыккан дисклары бу төркемнең иҗат стилен тулыландырды һәм үстерде.

Мин чынлап та аларның яңа альбомнарын көтеп ала һәм, аны тыңлаганнан соң, моңарчы аларда булмаган, хәтта башкаларда да булмаган берәр яңалыкны тотып ала торган идем.

«Диплар», дөньядагы әйдәп баручы рок-төркемнәр рәтенә көтмәгәндә килеп кереп, алар арасында мәңгегә торып калды. Һәм бүгенге көнгә кадәр аларның кайбер язмалары иң популяр музыкаль рок-композицияләр рәтенә керә.

1975 елның ноябрь аеның беренче көннәре минем хәтеремдә әле дә саклана. Ул көннәрдә Гурьевта күп итеп ап-ак чиста кар яуды. Салкын көн. Мин инде институт студенты.

Совет Армиясе сафларыннан кайтып килүче абыемны каршыларга, автобустан автобуска күчә-күчә, иске аэропортка кадәр рәттән берничә кич бардым. Кечкенә генә көтеп тору бүлмәсендә утырам, ә башымда DPның соңгы хиты – «Солдат фортуны» («Бәхет солдаты») бөтерелә...

Ул чакта да, аннан соң да аерым игътибарны җәлеп итәрлек супертөркемнәр дә, байтак кызыклы башка төркемнәр һәм башкаручылар да булды. Аларның һәркайсы рок-музыканың алга таба үсешенә үз өлешен һичшиксез кертте. Тик минем өчен алар инде дәвам итүчеләр, чираттагы этап кына иделәр.

Бу материалны минем Сан-Францисконың күренекле психологик «Jefferson Airplane» рок-төркеменең җитмешенче еллар башында өлкән абыем магнитофон тасмасына яздырып алган «Сюрреалистическая подушка» («Сюрреалистик мендәр») альбомыннан шундук һәм мәңгегә хәтеремә сеңеп калган сагышлы-моңлы «White Rabbit» композициясе белән тәмамлыйсым килә. Бу композиция башланып киткәндә «Америка авазы» музыкаль тапшыруын алып баручының: *«...җырчы Сигне Андерсон, Марти Бэйлин – вокалист һәм барабанчы Скип Спенс...»* – дигән сүзләре яңгырый иде.

Ә калган сүзләр исә хәтеремнән төшеп калган, әмма бу мелодия үзе һәм җыр авторы Грейс Сликның вокалы, әлеге текст өземтәсе кебек, башымда әле дә саклана һәм бүгенге көнгә кадәр тормышымда (инде чирек гасырдан артык) үзем белән янәшә бара.

## 3. «АЛТЫН АЛИҺӘ»

*Һәркемнең тормышында, соңыннан кем генә булмасын – коммунистмы ул, демократмы, Президентмы әллә гади бер кешеме – һәрвакыт туп була. Гап-гади бер туп...*

*Әле дә хәтеремдә: без дә, яңа йөри башлаган балалар, җепкә бәйләнгән кәгазь кисәге артыннан кечкенә мәче балалары ничек сикерсә, иркен зур бүлмә буйлап әллә ни зур булмаган, кая юнәлтсәң, шунда тәгәрәгән резин туп артыннан шуышып һәм куышып йөри идек...*

*Ә аннары безнең һәркайсыбызның үзенең зур футболы булды. Тик кайберәүләрдә ул ишегалды, мәктәп яки студент командасы белән генә чикләнеп калды, ә икенчеләрдә чын футболга әйләнде. Бу, минем карашка, иң мөһиме түгел, чөнки гаять әһәмиятлесе – аның безнең барыбызны да – җанатарларны да, уйнаучыларның үзләрен дә берләштерә, бөтереп ала торган футболның – XX йөзнең иң бөек уены булуы...*

...Алтмышынчы елларның икенче яртысы.

Танышларыбызның кысан, кечкенә «Запорожец»ында әти-әни белән шактый озак барганнан соң мин беренче мәртәбә стадионга аяк бастым. Безнең Гурьевта да стадион булган икән.

Бу ачыш туган шәһәремнең минем алда абруен тагын да күтәрде, ә инде аста, тузан каплаган футбол кырында безнең футболчылар белән СССР җыелма командасы ветераннарының йөгерешүен дә күргәч, башым күккә тиде – гаҗәпләнүемнең чиге юк иде – шундый зур һәм бөек илнең шулай ук бөек футболчылары минем янәшәмдә генә...

Ә соңрак, әти-әниләр белән Уральск шәһәренә җәйге айларга кунакка килгәч, мин телевизордан беренче мәртәбә зур футболны күрдем (ә бездә, Гурьевта, әлегә ни телевизор, ни телевидение юк иде).

*** * ***

...Бер мең тугыз йөз алтмыш җиденче ел. Хельсинки. Скандинавия – Советлар Союзы җыелма командасы (элек шундый командалар һәм шундый матчлар бар иде). Кунаклар командасында әллә ни пошынмас кебек тоелган тбилисилы Мортаза Хурцилаваның сокландыргыч голы хәтергә сеңеп калды...

...Алдагы елның җәе. Уен яңадан Скандинавиядә. Швеция – СССР.

Игътибар үзәгендә «Тре Крунур» белән уен. Мәскәү «Торпедо»сының исәпне ачкан яшь һөҗүмчесе Михаил Гершкович белән соңгы минут эчендә (бер ел элек булгандагы кебек) исәпне тигезләгән шул ук М.Хурцилава.

«Спартак» – «Динамо». Мәскәүнең Галимҗан Хөсәенов белән легендар Лев Яшин катнашындагы иң популяр ике командасының таң калдыргыч уены. Спартаклыларның шактый күтәрелгән чагы – 4:1 (!)...

...Без, үскән саен, вакытыбызның күп өлешен футболга бирәбез: ишегалды яки урам туп типкән малайлардан шау килеп тора.

Шул ук Уральскида «Авангард» стадионының ямь-яшел футбол кырына беренче мәртәбә килгәч, капкага нәкъ менә мин типкән күн туп очып кергәннән соң тойган аңлатып булмаслык соклану хисеннән, куанычтан мин озак тынычлана алмадым. Караңгы төшеп, мине өйгә алып кайтып киткәнче, шул зур һәм авыр тупны берничә сәгать буе «тибеп очырдым да очырдым»...

1969 елның бөтен язын, җәен һәм көзен Күкчәтау өлкәсенең «Боровое» шифаханәсендәге футбол кырында үткәрдем. Шул елдан үзем керткән голларның статистикасын алып бара башладым...

...1970 елның җәе. Мексика-TV аша мин күргән беренче дөнья чемпионаты һәм «Алтын Алиһә»нең соңгы чемпионаты.

Бу, һичшиксез, ике йолдызның (берсе – команда, икенчесе – уенчы): Бразилиянең Эдсон Арантес до Нассименто яки Пеле җитәкчелегендәге җыелма командасы белән Мюнхенның «Бавария»се форварды, алты уенда ун гол керткән (!) Герхард Мюллер турниры иде.

Чемпионатның иң оста уенчылары, аның бизәге булып, минем уемча, түбәндәгеләр саналды:

төркемнәр турнирында – Бразилия белән Англия җыелма командалары очрашуы;

чирекфиналда – Англия – ФРГ матчы. Бу уенда 1966 елның дөнья чемпионнары 2:0 исәбе белән барды, әмма өстәмә вакытта исәп 2:3 булды;

ярымфиналда – шул ук ФРГ командасы белән италиялеләр уены. Тик бу кискен һәм гаҗәп матур уенда Джанни Ривера командасы 4:3 исәбе белән җиңде.

Финал шулай ук хәтергә сеңеп калды – бразилиялеләрнең таң калдыргыч уены, Пеле керткән гол, исәп – 4:1 һәм Жюль Римэның легендар кубогы, Җиңү алиһәсе Ника кубогы – гади итеп әйткәндә – «Алтын Алиһә» өч мәртәбә дөнья чемпионы белән Рио-де-Жанейрога китәчәк.

Ни кызганыч: унөч елдан соң планетабызның иң популяр уенының Изге Реликвиясе «һәлак» була – алтын кисәгенә әйләнә. Киләчәк буыннарның барысы өчен дә ул буй җитмәслек хыял булып кала, хәтта музейда күрү мөмкинлегеннән дә мәхрүм ителә...

Уенчыларны сайлап алу буенча бөтен юнәлешләрдә дә тигез эш йөрткән Союз җыелма командасы бу юлы да уртача гына уйнады; чирекфиналда, тагын да йомшаграк уйнап, үзен берничек тә, хәтта эпизодларда күрсәтә алмыйча, Уругвай командасына оттырды. Бердәнбер «казанышлары» – капка сызыгыннан чыгып киткән туп безнекеләргә исәпләнде. Бу – арбитр намусында кала...

Тагын бер нәрсәне әйтмичә китә алмыйм: СССР җыелма командасы мин күргән-белгән чирек гасыр дәвамында (!) чәчрәп чыгып, гөрләтеп, бөтен җанатарларны дәррәү кузгатып уйный алмады, аның бертөрле, салынкы уйнавы, төгәлрәге, туп һәм көндәш белән көрәше беркайчан да чын комбинацияләр һәм голлар фейерверкы, ташкыны була алмады. Командада төрле елларда дөнья футболының менә дигән йолдызлары уйнаса да, менә ичмасам уен, дип әйтерлек, чөеп мактарлык уеннар аз булды...

Ул чакта бу турыда уйланылмаган инде.

Кайчан да булса, бер могҗиза туып, безнең командабыз да, хоккей командасы кебек үк, дөньяда барыбер беренче булыр әле, дип өметләнә идек. Әлеге җыелма команданың хәтергә сеңеп калган берничә матур уены да булды – Киевтан Виталий Хмельницкийның егылып барган уңайга башы белән бельгиялеләр капкасына оста һәм матур итеп гол кертүе (4:1) һәм шулай ук киевлы Анатолий Бышовецның турнир вакытында керткән дүрт тубы... шундый мизгелләрдән.

*...Уң флангтан йөгереп үтеп, мин, команданың бердәнбер һөҗүмчесе, каршыма җәйсез гына йөгереп чыккан капкачы аша тупны капканың сул як өске почмагына җиңел генә томырдым. Исәп – 1:10 һәм – Уральск шәһәрендә узучы укучылар турнирында беренче җиңү...*

Шул ук елның көзендә Мәскәүдә Мәскәү армеецларын 18 ел үткәннән соң чемпион титулына китергән Валентин Николаевның яңа җыелма командасын тәкъдим итү (презентацияләү) булды (икенче өстәмә финал матчында Ташкентта Мәскәүнең «Динамо»сына оттырып (1:3), алар очрашуның барышын борып җибәрә алдылар һәм соң мәртәбә СССР чемпионнары булдылар (4:3).

Югославия белән үткәрелгән ул матч (4:0) Совет футболының ике яңа йолдызы – Казанның «Рубин» командасыннан (соңрак дистә еллап Киев «Динамо»сында һәм Союз җыелма командасында балкыган) Виктор Колотов белән Бакуның «Нефтьчи») командасыннан (Викторданn аермалы буларак, алга таба ничектер сиздермичә генә уеннан төшеп калган) Виталий Шевченконың дебюты булды.

Әмма ул елда бу ике дебютант гаҗәеп оста старт алды – җыелма команда өчен беренче ике уенда да – югославларга да, киприотларга да берәр туп кертте (3:1).

...Җитмеш беренче елның җылы язы. Егерменче гасырның иң оста капкачысы (голкиперы) Лев Яшинның хушлашу уены. «Динамо» клублары җыелма командасы – дөньякүләм футбол йолдызлары җыелма командасы.

Йолдызларның баш тренеры Райко Митич командасында – Иво Виктор, Драган Джаич, Джацинто Факетти, Бобби Чарльтон, Г.Мюллер.

В.Хмельницкийның уругвайлы Ладислао Мазуркевич капкасына керткән мәңге истә калырлык голы, Бөек Яшинның талантлы яшь Владимир Пильчуйга капкачы эстафетасын тапшыруы һәм – 2:2...

*...Мини-футбол буенча шәһәр турниры. Көндәшләрнең штраф мәйданчыгында алар капкасына аркам белән баскан килеш һәм үз ягыма «навестан» файдаланып, көтмәгәндә һәм кинәт егылып барганда «кайчы» алымы белән үзем аша тупны капканың үземнән уң яктагы югары почмагына тибеп керттем, Исәп 3:3 булды. Биш уенда барысы тугыз гол керттек...*

...Париж. Яңа гына реставрацияләнгән, күпләргә билгеле «Парк де Прэнс» стадионы. Франция белән СССРның олимпиада җыелма командаларының сайлап алу матчы.

Икенче тайм башланды. Союз җыелма командасы һөҗүмчесе, бөтен кырны диярлек зур тизлек белән йөгереп үтеп, хуҗалар капкасына тубы белән бергә очып кереп китте. 1972 елның язында совет футболының 1 нче номерлы бомбардиры Олег Блохин футбол дөньясына менә шулай килеп керде.

Совет футболы йолдызларының күбесе кебек үк, О.Блохин да дебют матчында җыелма команда өчен «үз» голын кертте (Лахти, Финляндия, 1:1). Тик шул ук елны, Киев «Динамо»сы өчен үзенең беренче уеннарының берсендә Ростовның СКА капкасына матчтан соңгы хәлиткеч кубок пенальтиыннан тупны кертә алмаганга, киевлылар турнирдан төшеп калды...

...Бу 1972 ел ике төрле тәэсир калдырды. Бер яктан, Европа беренчелегендә илебез җыелма командасы икенче урынга чыкса, икенче яктан – йомшак, бернигә ышаныч багламаган уен һәм Мюнхен олимпиадасында бары тик өченче урын, шулай ук континентның яңа чемпионнары – ФРГ командасы белән уенда икеләтә оттыру – 1:4 һәм 0:3.

Шуның өстенә Г.Мюллер бу ике уенда да Евгений Рудаков кебек иң ышанычлы капкачы (голкипер) капкасына алты (!), ә СССР җыелма командасы белән өч уенда җиде (!) туп кертте. Мондый уенда гына түгел, хәтта аутсайдерлар белән уенда да кую гаҗәеп катлаулы булган бу рекорд турында безнең матбугатта хәтта телгә дә алынмады...

*...Бу елларда минем өчен футбол, башка бөтен нәрсәне кысрыклап чыгарып, иң мөһим вакыйгага әйләнде.*

*Елның кайсы фасылы – кышмы яки язмы, җәйме яки көзме, һава торышы нинди – яңгыр яки кармы, пычрак яки җилле көнме – бернинди аерма юк иде. Бернәрсәгә дә исебез китмичә, башка бернәрсәне дә күрмичә-сизмичә, үзебезне шушы Бөек Уенга багышлый идек, дөньябызны онытып, шунда «яши» идек. Мәктәпнең асфальт җәелгән футбол кыры дисеңме (сыйныфташлар һәм күршеләр белән), су станциясенең такта җәелгән баскетбол мәйданчыгы дисеңме, безгә барыбер иде – барысында да туп типтек. Әлеге мәйданчыкта мәктәпнең үз эчендәге төрле турнирларны үткәрә, ә кайчакларда А.Хлебников, М.Ганус, Н.Богачкин, Д.Свинтицкий, Н.Мартынов һ.б. кебек танылган ишкәкчеләр белән болай гына мәш килә идек...*

...1974 елның июне хәтергә футболда яңа юнәлеш, яңача уен стиле туган ай булып кереп калды. Бу юнәлешне Германиянең футбол кырларында танылган Йоханн Крунфор яки Кройфф җитәкчелегендәге «оча торган голландиялеләр» башлап җибәрде. Ул елда дөнья чемпионнары булып икенче мәртәбә ФРГ командасы калса да, футболның асыл җанатарларының йөрәге Голландия җыелма командасы ягында булды, чөнки иң яхшы уйнаган команда ул иде.

Дүрт елдан соң да шундыйрак хәл кабатланды: дөнья чемпионнары булып кабат беренчелек хуҗалары – бу юлы аргентинлылар калган булса да, үзләренә кирәкле исәп (6:0) белән сәер рәвештә Перуны җиңгәннән соң кайбер шикләр туа башлады, чөнки турнир барышында бер генә уенны да оттырмаган бразилиялеләр кинәт «җиңелде»...

Туп – түгәрәк, ә кыр – тип-тигез, бәхет кемгә елмая, шул көчле. Ошаса-ошамаса да, бу – футболның төп иярчен кагыйдәләренең берсенә әйләнде...

*...1974 елның «Көз Кубогы» – өч уен, һәр очрашуда өч хәлиткеч гол һәм ул чактагы шәһәрнең популяр үсмерләр турнирында җиңү. Өстәвенә икенче ел рәттән һәм яңа составта. Гурьев шәһәренең Ленин исемендәге урта мәктәбенең югары сыйныф укучылары арасында футбол шулкадәр популяр иде.*

*Шәһәрнең «Нефтяник» стадионы. Финал. Икенче тайм. Исәп 0:0. Тәнәфестән соң тупны уйнату.*

*Арбитр сыбызгысын сызгыртуга, тупны шундук үзебезнең үзәк ярымсакчы М.Доскалиевкә биреп, мин каршы як капкасына ыргылдым. Ул, бераз паузадан соң минем ыргылуны күреп, тупны җайлап кына минем юлыма чыгарды.*

*Шуннан соң инде бар да өйрәнү фильмындагы кебек булды – тупны сулъяк флангта төгәл турылап аягыма эләктереп алдым да, зур тизлектә килгән килеш ике сакчыны әйләнеп үтеп, үзәк зонага штрафнойга хәрәкәтемне дәвам иттем, аннан соң, турыдан-туры капкага чыгып һәм сактагы соңгы*

*уенчыны узып китеп, капкачының үзенә чыктым. Әле уңга, әле сулга ыргылып, каршыма килгән капкачыны адаштырып, тупны үземнән сул яктагы почмакка очырдым һәм туп унбер метрлы билгедән капка почмагына тәгәрәп керде дә ятьмәсендә торып калды – 1:0. Кырык алтынчы минутта ачылган бу җиңү исәбе ахырга кадәр үзгәрешсез калды.*

*Бу минем иң җитди уңышым булды. Миңа бары уналты гына яшь, һәм шул чакта алга таба моннан да кызыклырак сынаулар һәм, һичшиксез, казанышлар булыр кебек тоеле иде...*

*Ә безнең теге, биш милләт вәкиленнән – казах, рус, немец, чечен һәм татардан торган гаҗәп күңелле мәктәп командасы – тагын да югарырак дәрәҗәдәге үсмерләр турнирларында зур уңыш белән катнаша алган команда бүгенге көнгә кадәр минем хәтеремдә. Укытучыбыз Л.А.Плетнев туплаган бу команда Ю.Лайс, С.Сейтимов, М.Жалпаков, Е.Курманбаев, М.Кубашев, С.Рыскалиев, М.Доскалиев, С.Ненциев, О.Аланьев, Е.Агеев, Б.Есекенов, В.Катковлардан тора иде. Бүген, шул елларга кире кайтып, сагыну катыш кызгану белән шуны әйтә алам: тормыш безнең күбебезне элекке советлар иленең төрле почмакларына таратып кына калмыйча, безнең һәммәбезгә дә төрле язмышлар әзерләп куйган булып чыкты...*

Футболда капкачы керткән голлар бик сирәк була. Иң матур һәм иң әһәмиятлеләре – егылып барганда үзең аша яки «кайчы» алымы белән кертелгән, «коры яфрак» дип аталган, ягъни почмактан тибеп, капкага бөтерелеп килеп кергән, шулай ук алга таба егылганда баш белән бәреп керткән туплар.

Җитмешенче еллар уртасында шактый көчле ике динамочы – Мәскәү белән Тбилиси командалары уены шулай ук хәтергә сеңеп калды. Ул чакта техникасы гаҗәеп көчле Владимир Гуцаев мәскәүлеләрне «пыран-заран» китерде, ә капкада В.Пильгуй могҗизалар тудырды. Хуҗалар 2:1 исәбе белән отты, ә алмашка чыккан Владимир Козловның егылып барганда башы белән керткән хәлиткеч голы әлеге ачык һәм һөҗүмчән футболчыларның чын бизәге булды...

1975 елның язында киевлеләр Европа Кубоклары Кубогында үзләренең беренче уңышларына барганда, ярымфиналда чит кырда Голландиянең «Эйндховен» капкасына Леонид Буряк та егылып барган уңайга башы белән гаҗәеп матур гол кертте.

О.Блохинның зур уңышка ирешү биеклеге, һичшиксез, 1975 ел булды; аерым алганда – Чемпионнар кубогы иясе «Бавария» белән Европа Суперкубогы өчен матчлар.

Европа-75 нең иң яхшы уйнаучы бу футболчысы ике матчта исәпкә кертелгән өч тупны (1:0; 2:0) кертеп кенә калмыйча, Мюнхендагы Олимпия стадионында, араларында Франц Беккенбауэр белән Бертти Фогтс та булган дүрт көндәшен берьюлы егып салып, дөньяның тагын бер чемпионы Зепп Майер капкасына иң матур супергол кертеп, футбол дөньясын үзенең таң калдыргыч слаломы белән шаккатырды. О.Блохинның 1972 ел язында Франциянең олимпия җыелма командасы капкасына керткән тубына әйләнеп кайтсак, 1976 елда Европаның яшьләр чемпионаты финалында Владимир Федоровның шул ук рәвешле керткән тубы искә төшә. Кызганыч: бераз соңрак Ташкент «Пахтокор»ының авиаһәлакәте вакытында ул да һәлак булды...

Шуны әйтәсем килә: һәрвакыт футбол кырына чыкканда, әгәр дә син форвард икәнсең, каршы яклар капкасына туп кертү турындагы уй синең башыңда гына түгел, җаныңда да булырга тиеш.

«Гол кертергә» – һәр уен алдыннан үземә куйган шул максат даими минимум йөкләмә булып торды. Сүз дә юк, уен һәрвакытта да мин теләгәнчә барып чыкмый иде, әмма уенга, көрәшкә, туп кертүгә, җиңүгә корылган бу халәт, эчке әзерлек һичшиксез җилкендереп торды.

Әгәр дә футбол кырына бернинди максатсыз болай гына чыгасың икән, башкаларга футбол «ясарга» комачауламас өчен гомумән чыкмаска кирәк. Бу вакытта уеннарның дәрәҗәсе һәм статусы әһәмиятле түгел. Һәвәскәрләр турниры дуслар яки танышлар очрашуы гына булып кала...

*Шулай бервакыт Уральскида, көндәшләрнең бик тырышып күнегүләр ясый-ясый әзерләнүен күргәч, күңелне мондый очракта гадәттәгечә төшенкелек, нindидер үз-үзеңә ышанмау хисе түгел, ә бәлки җиңүгә омтылыш биләп алды. Өстәвенә, мин монда әллә ни билгеле уенчы булмаганга, шул якны да файдаланырга уйладым.*

*Тупны уйнату белән, көндәшемнән аны аерып алдым да, сулъяк флангтан йөгереп үтеп, капканың миңа якын сулъяк өске почмагына шундук кертеп тә җибәрдем. Аннан соң, саклануга күчеп һәм үземнең шәхси сакчымны актив уеннан чыгарып, тактиканы алыштырдым. Шуннан соң, әледән-әле көрәштә «кабынып», үз капкабыз яныннан контратака башладым. Нәтиҗәдә, менә шундый өзек-өзек, үземне һәм көндәшемне хәлдән тайдыра торган ритмны файдаланып, мин өч мәртәбә тупны гол кертерлек хәлгә китердем һәм иң соңыннан тагын бер туп керттем. Исәп 5:3 булды...*

1977 ел футбол тарихына 19 яшькәчә яшьләр арасында беренче дөнья чемпионаты һәм Африка континентында, Туниста үткәрелгән беренче турнир елы буларак кереп калды.

Ул чакта Союз командасында талантлы гына түгел, иң әүвәл чын спортчыга хас характерлы уенчылардан торган төркем барлыкка килде. Шуңа күрә дә бу яшь категориясендә алар беренче мәртәбә дөнья чемпионнары була алдылар. Киевле Владимир Бессонов һәм Ростовтан Вагиз Һидиятуллин (минем яшьтәшләр), гаҗәп оста уйнап, үзләрен беренчелекнең иң яхшы уенчылары итеп таныттылар.

Шул ук елда Мәскәүнең беренче лигада чыгыш ясаучы «Спартак» командасында К.И.Бесков үзенә бер көчле команда оештыра башлады. Аның составындагы совет футболының яңа һәм шул ук вакытта соңгы йолдызлары Ринат Дасаев, Федор Черенков, Юрий Гаврилов, Георгий Ярцев, Сергей Шавло, Сергей Радионов, шул ук В.Һидиятуллин алга таба иң көчле футболчылар булуын һәр уенда раслап тордылар.

*...Аннан соң безнең шәһәр һәм өлкә турнирларында да күп төрле матчлар һәм голлар булды. Мин Петровский исемендәге завод, techniститутның «Буревестник», химия заводының «Химик» командаларында уйнадым. Тупларны мин төрле алымнар белән – егылып барганда үзем аша да, слаломдагы кебек бөтен футбол кыры аша ыргылып, барысын да һәм капкачы янынннан да йөгереп үтеп, соңгы мизгелдә ачык калган капкага очыртып кына кертә идем.*

*Хәтердә уңышлы уеннар һәм керткән голлар гына түгел, тәндәге, биттәге күгәргән һәм кабарган җирләр, егылулар, көндәшләр зур көч белән бәргән туплардан ике мәртәбә аң югалтулар, хәлдән тайганчы һәм көзән җыера башлаганчы күнегүләр ясау, А.Джумалиев белән икәүләп Урал елгасының кар сарган яры буйлап, ишегалдында алмагачлар арасында тарттырып куелган резин жгут белән бер урында йөгерүләр дә калды. Яисә Җиңүнең 30 еллыгына Уральск шәһәрендә йөгерүдә катнашкан абыем Рафик белән даими тренинглар үткәрү. «Физика» өчен Н.Мамбетовтагы күнегүләр, спринтер дистанцияләренә йөгерү буенча, шулай ук волейбол, баскетбол, алкалы хоккей буенча җиңел атлетика турнирларында катнашулар шактый ярдәм итте. Бары тик шуннан соң гына һәр уенга үзеңнең тактикаңны планлаштырырга, көндәшләреңнең әзерлек дәрәҗәсеннән чыгып, тизлекне җиңел генә арттырырга һәм аларны, әйтерсең хәрәкәтсез калганнар, әйләнеп һәм узып китәргә мөмкинлек туа...*

*Әмма тормыш реалийлары, шартлары футболны тора-бара арткы планга чыгара башлады, хәтта, А.Ш.Әмиров чакыруы белән иң беренче составка алынган булсам да, «Прикаспиец»та ил чемпионатының икенче лигасында уйнау мөмкинлеген алды – ирекле студент еллары кире кайтмаслык булып китеп барды, ә алда бары тик эш кенә көтә иде...*

*Уйлый башласам,ниләр генә искә төшми: менә ветеран стадион «Нефтяник» – Гурьев футбол фанатларының күпме буыны үзен шул стадион белән бәйли! Байдаркаларда, каноэда ишүгә, бокс яки көрәшкә өстенлек биргән кайбер якташлардан аермалы буларак, футболчыларга нинди дә булса лаврлар алу, бүләкләргә күмелү мөмкинлеге булмады. Кайберләренә Казахстанның югарырак дәрәҗәдәге командаларына китү, дистә еллардан соң «Шагала» дигән хатын-кызлар командасы һәм аның лидеры С.Махамбетовага бөтенсоюз дәрәҗәсендә уңышка ирешү мөмкинлеге туса да, С.Даутов һәм башкалар кебек яңа талантлар мәйданга чыкса да, болар инде бөтенләй башка, аерым сөйләшүне таләп итә торган тема. Ә минем бары тик әлеге Бөек Уенга үзенең табынуы белән бу стадионны – минем мондагы елларым стадионын мәңгегә истә калдырган кешеләрне генә хәтеремә төшерәсем килә. Мин алар уенын хәтерлим, ә алар – Р.Ли, Н.Воробьев, Сабирҗанов, А.Әмиров, Б.Иргалиев, М.Медетов, Д.Үтәгәнов, һ.б. бик күпләр – бераз гына булса да минем мондагы уенымны хәтерлидер, дип уйлыйм.*

*Шәхси пролетар секторда урнашкан Ленин исемендәге мәктәпнең элекке биш укучысы – М.Покатилов, А.Турдыгулов, И.Азовский, П.Сутягин һәм Тамбовцев (әшче сыйныф балалары) шулай ук әлеге стадионда «үсте». Безнең спорт залыбыз да юк иде. Күнегүләр урамда үтте. Безнең өчен моның әһәмияте булмады, чөнки ул елларда без чынлап та бары футбол дип кенә җенләнеп йөри идек.*

*Ул еллардагы футбол фанатлары исемлеген яза башласаң, бу исемлек берничә битне тутырыр иде. Иң кызганычы шул: кызыклы һәм чын-чынлап талантлы футболчыларның күбесе Зур Футбол тарафыннан җәлеп ителми, таләп ителми калды, чөнки безнең көнбатыш регионга берниндиигътибар бирмәгән республика яшүсмерләр футболында селекция эшләрен бөтенләй алып бармый иде...*

...80 нче елларда футболга игътибар шулай ук көчле иде әле. Җыелма команда капитаны тбилисилы Александр Чивадзе иң яхшы футболчы дип танылса да (мин аның белән ел ахырында Алма-Атада таныштым), бу ел берьюлы өч җыелма командада уңышлы уйнаган һәм беренче команда өчен уеннарда тугыз уенда җиде гол (аның алтысы – рәттән) керткән Ф.Черенков елы буларак истә калды.

Ул елда ростовлы Сергей Андреев ил чемпионатында иң яхшы бомбардир булды – җыелма команда өчен үзенең дебют матчында – бер туп, ә бер сезон эчендә тугыз туп кертте. Әле тагын ул керткән янә ике туп, Ф.Черенков очрагындагы (бер гол) кебек үк, беренче җыелма уеннарының рәсми реестрына кертелмәде. Шулай итеп ул гамәлдә бер ел эчендә 11 туп кертте.

Сүз дә юк: Ф.Черенков белән С.Андреевның «Марокан»да Бразилия җыелма командасы капкасына керткән туплары иң кыйммәтлеләрдән санала.

Бу – дөньяда иң данлыклы һәм иң зур стадионның ачылуына 30 ел, бразилияләрнең IX дөнья чемпионатында җиңүенә 10 ел тулуга багышланган матч иде. СССР җыелма командасының бразилиялеләрне гомумән беренче мәртәбә җиңүе иде, әле өстәвенә аларның үз футбол кырында һәм 130 мең тамашачы (рекорд!) күз алдында.

Нәтиҗә – 2:1, ә команданың нигезен К.И.Бесков спартаклылары тәшкил итте...

...Сиксәненче еллар башында, футбол минем өчен инде үткән заманда булган елларда, халыкара яшьләр үзәкләре Югославия һәм Мәскәү янында уздырылган уеннар шактый уңышлы булды. Туплар башкортларга да, мәскәүлеләргә дә, грузиннарга да җитәрлек кертелде, шулар арасыннан югославлар капкасына гади генә булса да, бүтәннәрдән башкарылуы белән аерылып торган берсе истә калды.

*Футбол кыры уртасыннан тупны эләктереп алдым да унъяк флангка ыргылдым, берьюлы берничә уенчыны үтеп, тизлекне арттыра барып, штрафнойга килеп кердем, шунда тубым белән бергә кисәк туктап калдым – шул ук мизгелдә зур тизлек белән мине озата килүче сакчы янымнан выжлап үтеп тә китте, бу хәлне күзәтеп торган капкачының урыныннан кузгала башлаганын көттем дә тупка китереп типтем һәм ул, капкачы хәрәкәтенә туры килеп, аяклары арасыннан капкага керде дә китте. Боларның барысы да үтә тиз, берничә секунд эчендә эшләнде...*

Шуның белән бетте. 1983 елда «Алтын Алиһә», эретелеп, алтын кисәгенә әйләнгәннән соң гамәли футбол белән (һәвәскәрләр футболы булса да) кызыксынуым үтте дә китте, ничектер сиздермичә генә узганга китеп югалды.

Гамәлгә ашыра алмый калган Хыялым белән бергә китеп барды...

...Зур Футболга ясаган кыскача экскурсны тәмамлап, Бөек Уенга тиешле ихтирамымны белдереп һәм дәрәҗәсенә баш иеп, тагын берничә кызыклы вакыйганы телгә аласым килә.

1982 ел. Паоло Россинең күтәрелеп килгән чагы. Дөнья беренчелеге нәтиҗәләре буенча дөнья җыелма командасының оештыру комитеты төзегән рәсми исемлегендә беренче мәртәбә совет футболчысы – Ринат Дасаев.

1984 ел. Европа беренчелегендә Мишель Платинининың сокландыргыч уены.

1986 ел. Өченче мәртәбә Европаның иң яхшы футболчысы дигән исем (Л.Яшин белән О.Блохиннан соң) совет футболчысы – киевле Игорь Белановка бирелә.

1988 ел. СССР җыелма командасы исеме белән уйнаучы команданың соңгы уңышы: Европа чемпионатында – икенче урын, Сеулда – олимпиада алтыны, ә ел нәтиҗәләре буенча дөньяның иң яхшы, иң оста капкачысы булып Р.Дасаев танылa. Шуны да әйтеп үтик: СССР җыелма командасы өчен 97 уенда катнашкан Дасаевка халыкара «100» кубына керү мөмкинлеген бирмиләр, «өстәгеләрдән» кемдер, Иделнең Әстерхан ярларыннан килгән «чит милләт» кешесен болай да күп уңышларга ирештердек, дип уйлагандыр, мөгаен.

1994 ел. Чираттагы уңышсызлыкка да карамастан, ленинградлы Олег Саленко дөньяның бөтен чемпионнары рекордын куйды: Камерун белән уенда биш (!) туп кертте һәм, өч уенда алты туп кертеп, болгар Х.Стоичков белән бергә дөньякүләм турнирның иң оста бомбардиры булды!..

Кызганыч: бөтен совет футболының шактый талантлы уенчылары спорт тормышы тәмамланганнан соң нык катлаулы язмышка дучар булды: Всеволод Бобров, Эдуард Стрельцов, Валерий Воронин, Анатолий Банишевскийлар бу дөньядан бик тиз һәм сиздермичә генә мәңгегә китеп барды.

Әле янып торган чагында Мәскәү «Динамо»сында уйнаган Анатолий Кожемякин, Владимир Федоров һәм Ташкент «Пахтакор»ыннан Михаил Ан, Тбилисидан Виталий Дараселия фаҗигале төстә тормыштан китеп бардылар...

Ә хәзер Союз җыелма командасы белән уенда үзләрен күрсәтә алган уенчылар турында.

Рекордчы Герд Мюллер – бер уенда дүрт туп кертте. Инглиз Хейнс (0:5), швед Эдстрем (4:4) һәм ирландияле Твенс (0:3) – өчесенә дә «хет-трик»ка ирешү мөмкин булды.

1958 елның октябрендә «Уэмбли»да Томанлы Альбион футболчыларының уены иң зур җиңелү булып саналды (0:5).

Менә хәзер бетте бугай инде...

*...Җәйге җылы бер кичтә Лужникига бераз иртәрәк килдем. Үз секторыма күтәрелеп трибунага чыккан идем, таң калырлык манзара күрдем: турыпочмаклы битабигый ачык яшел, прожекторлар белән яктыртылган футбол кыры, көчле ут яктысыннан кап-караңгы күккә кадәр пар томаны күтәрелә...*

*Җанатарлар, бәхәскә кереп, җанланып сөйләшә-сөйләшә, тиз арада стадионны тутырды. Аларның дулкынланган йөрәгенең тибеше миңа бу дәрәҗәдә уйнау мөмкинлеге булмаган, ниндидер бер моңарчы күрелмәгән фантастик тамашаның башлануын хәбәр итә кебек иде...*

*Язмалар, Мюнхенда 1993 елның ноябрендә башланып,*
*1997 елның август-сентябрь айларында*
*Атырауда эшкәртелеп тәмамланды*

## Чит кырда

*Тирә-юньне курку белән каплап,*

*Аерып торган сызаларны таптап,*
*Көтү утлап йөри чит кырда –*
*Ни хикмәттер, көтү кергән саен*
*Шул җирдәге бөтен нәрсә яна:*
*Балалары яна, ятим кала,*
*Ак Әбиләр, Аксакаллар яна,*
*Хатын-кызлар яна чытырдап.*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

## ...Ә АННАРЫ НӘРСӘ, ГАЛИҖӘНАП ПРЕЗИДЕНТЛАР, ЯКИ СЕЗНЕ ТАГЫН НИЧЕК АТАРГА?..

*1993 елның 10 декабрендә «Zyddeutsche Zeitung»тан РФ Президенты администрациясе җитәкчесенә сылтама белән Россия Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрен алдагы көннәрдә Башкортостан Республикасына, Татарстан Республикасына, Тыва һәм Чечняга кертү турында хәбәр ителү уңаеннан*

*«Кеше күпме юл үтәргә тиеш,*
*Кеше дигән исем алганчы?*
*Туп ядрәсе күпме оча ала,*
*Атмаска дип тыелу алганчы?..*

*Һәр халыкка күпме яшәү кирәк,*
*Азатлыкка рөхсәт алганчы?*
*Кеше күпме читкә борыла ала,*
*Күрмәмешкә салынып арганчы..?*

*Боб Дилан,*
*«Ответ носится по ветру», 1962*

Рус халык әкиятләрендә Иванушка Дурачок яки Добрый Молодец образындагы Яхшылык күпбашлы Елан (Аждаһа) яисә Кащей Бессмертный (Үлмәс Кащей) рәвешендәге Явызлыкны җиңә. Ни өчендер, һәрвакыт Могҗиза белән генә: йә тылсымлы кылыч табып, йә нindидер энә табып, ягъни үзенең акылы һәм көченә таяна алмый, әйтерсең аларда бу сыйфатлар беркайчан да булмаган.

Нәкъ шуның кебек, рус, россия, совет бүгенге көндә яңадан Россия империясе тарихы һәрвакыт ниндидер могҗиза көтүгә, могҗизага ышануга, «бәлки»гә бәйләнгән.

«Без эчкән һәм типтергән, бер-беребезнең бугазын чәйнәгән арада, берәрсе безгә булышыр, бәлки. Булышмаса – басып алырбыз. Без – бөек халык лабаса!»

Әлеге дәүләт яшәгән бөтен гасырлар дәвамында биредә якынча менә шулай уйлаганнар һәм шулай уйлауларын дәвам итәләр.

Иң әүвәл үзләренә кенәзлек итәргә чакырган варягларга үзләрен ышанып тапшырганнар, аннан соң бөеклеген күрсәтү өчен император дип чукындырылган патша атакайга буйларын сындырганнар, ары китеп – марксизм-ленинизмга, ә хәзер бар ышаныч – имештер, Көнбатыш инвестициясенә, ялган рус демократиясенә, ә монысын инде квазидемократия дип тә атап булмый, гади генә итеп хәрби диктатура дисәң, төгәлрәк булыр, мөгаен.

Чөнки боларның барысы да халык канына манчылган, түнтәрешләр, инкыйлаблар, путчларга корылган.

Бу җирдә һәрвакыт шулай булды, бүгенге көндә дә шулай, мөгаен, шулай булыр да.

Бик тырышсалар да, алар башкача булдыра алмый.

«Ник? – диярсез сез. – Әкият ахырына кадәр шактый ерак булгангадыр, бәлки. Шуңа күрә биредә Могҗиза һаман күренми дә күренми».

Алай түгел шул. Парадокс та нәкъ менә шунда. Могҗиза һәрвакыт булды һәм һаман булып тора.

Әлеге могҗиза бу Планетада яшәүчеләрнең барысына да җитәрдер, бәлки: бер генә дәүләт тә мондагы кебек чиксез бай табигый ресурсларга ия түгел, әмма бер генә башка дәүләт тә, хәтта иң кечкенәсе дә, бу кадәр хәерче һәм кан белән нәҗес эчендә яшәми.

Кешелек башланганнан бирле җирдә яшәүче башка бер генә халыкның да шушундый тормышта яшәргә «башы җитмәс иде», мөгаен.

«Баш – патшасыз» – инде күптән үзләре турында үзләре әйткән сүз бу.

Әлеге империянең бердәнбер куәтенә ирешү юлы (аның белән еш мактанырга яраталар) – хәрби юл, анысы да бөтенләй башка халык интеллекты белән булдырылган.

Ул арада могҗизалар, нәкъ әкияттәге кебек, әледән-әле туып кына торалар, әмма кире нәтиҗә белән.

Мәсәлән, яңа пешеп чыккан Добрый Молодец, ике Ильич сәламәтлеген кайгыртып җырлап йөргән, үз вакытында шуның белән тамагын туйдырган ажгырып торган элекке коммунист, кинәт кенә үзгәрешләр кичереп, Демократ булды да куйды.

Әүвәл бу могҗизага ышаныч та белдерделәр, хуплап каршы да алдылар.

Тик юкка гына булган икән, чөнки ул аларга көтмәгәндә тискәре ягы белән ачылып китте.

Тәхеткә ул, үзеннән алдагыларның күбесе кебек үк, корбаннарга басып һәм канга батып менде.

Моны могҗиза дими, ни дисең инде?

Аңлатма биреп торуның кирәге юк – барысы да сүзсез дә аңлашыла.

Шуны гына өстәп әйтә алабыз: һәр халык үз җитәкчесенә, үз башлыгына хокуклы һәм лаеклы. Моны да истән чыгармаска кирәк.

Әлеге башлык, сүз дә юк, үз халкына лаек. Халкы нинди, үзе шундый.

Икенче төрле әйткәндә, алар бер-беренә бик тә туры килә. Үзегез дә моны яхшы беләсез.

Узган гасырның 1990 елларында гына да депутатларны зур ышаныч белдереп ике мәртәбә сайладылар: кайберләрен куып таратсалар, беришләрен башкала үзәгендә гомумән танклардан атып үтерделәр, калганнарын исә тимер рәшәткә артына яшерделәр.

Ул гына да түгел: элгәрләрен куып өлгермәделәр, шундук башкалар этешә-төртешә, абына-сөртенә, бер-берсен әллә нинди сүзләр белән кимсетә-кимсетә, төрмәдә утырганнар урынына сайланып калырга ашыктылар.

Хакимият һәм сәясәт – чынлап та пычрак һәм куркыныч нәрсә. Аңа менеп утыру өчен кешегә нинди түбәнлеккә, вәхшилеккә, нәҗеслеккә төшәргә кирәк...

Шунысы кызганыч: әлегә колониаль империянең башка халыкларына да нәкъ шул эздән барырга, нәкъ шундый пычраклыкны эшләргә туры килә.

Әгәр алардан аерылып китә алмаса. Беркайчан да кире кайтмаслык булып.

Үз вакытында, мәсәлән, поляклар, финнар һәм күптән түгел генә прибалтлар кебек, ышанычлы итеп.

Шуны аңлаган килеш, алар, Ак Йортны утка тотканнан соң, яңа рус республикалары – Себер белән Уралдан түгел, кайчандыр русның бөтән патшасы Иван Грозный атаганча, әлеге «басурманнардан» башлап, бер-берсе белән үз мөнәсәбәтләрен ачыклауны дәвам итәләр.

Аларга бит риялыкка, һавалыкка һәм икейөзлелеккә кеше кисәсенә керергә кирәк түгел, үзләре шуңа чумган.

Урта гасырны да күптән уздык югыйсә.

Шунысы да көн кебек ачык: кайчандыр җәзасыз калган яман гамәлләр бүгенге көндә шулай гына үтеп китмәячәк.

Бу инде гражданнар сугышы яки дәүләтләр сугышы гына булмыйча, ике дин сугышы булачак. Моңардан да коточкыч хәлнең булуы мөмкинме? Аның ни икәнен бары тик акылга зәгыйфь кеше генә аңламас.

Бу сугышта ни җиңүче, ни җиңелүче булмаячак. Аның очы-кырые да күренмәячәк...

Бүгенге көндә – менә шул каршылыкның башлангычы төсле. Әллә башканыкымы?

Вакыт күрсәтер...

Чынлап та бу хәл була калса, шул ук ялкын башкаларны да өтәргә мөмкин. Әгәр дә хәзерге көндә алар, гадәттәгечә, боларның берсе дә безгә кагылмый, дип уйлый икән, икенче төрле әйткәндә, дәшми кала яисә (инде ничәнче мәртәбә) үзенең өлкән туганының бар эшен хуплый икән – моны көт тә тор.

Ул вакытта инде чынлап та кан кардәшең – өлкән абыеңа таянырга кирәк булачак...

...Ә инде чират Сезгә җитсә ни эшләрсез, галиҗәнап президентлар яки Сезне тагын ничек атарга?..

*Мюнхен, декабрь, 1993*

*P.S.1. 1993 елның 12 декабрендәге сайлауларның көтелмәгән нәтиҗәләренә бәйле вакытлыча тукталып торуга да карамастан, фараз барыбер чынга ашты – һәм бер елдан соң Россиянең федераль гаскәрләре, Татарстаннан гайре, РФның барлык субъектлары һәм БДБның барлык дәүләтләренең сүзсез ризалыгы белән чеченнарның Ичкерия Республикасына кертелде.*

*Сугыш башланды. Кемгәдер бик кирәк булган сугыш бары тик әлеге дәүләтләр халкына гына кирәк түгел иде. Чөнки анда дистәләгән мең кеше гомере өзелде.*

*Грозный шәһәре, күпләгән авыллар җимерелде, халык ач-ялангач калды.*

*Россиянең бөтен тарихында иң демократик булып саналган Президенты алып барган гадәти басып алу сугышы бара...*

*август, 1995*

*P.S.2. Икенче бөтендөнья сугышының ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, Казахстанның батыр очучысы Тәлгать Якубек угълы Бегельдинов 1997 елда Чечня бәйсезлегенең алты еллыгы уңаеннан*

*парадта катнашу өчен Грозныйга барып кайткач, «Казахстанская правда» газетасына (12.09.07. №201) биргән интервьюсында түбәндәгеләрне әйткән иде: «Бөек Ватан сугышы елларында мин җимерелгән шәһәрләрне күп күрдем, әмма моның кадәр дә вәхшиләрчә җимерүне мин хәтерләмим. Бреслау шәһәреннән гайре.*

*Аңа да карамастан, Чечня башкаласы акрын-акрын гына булса да аякка басып килә...*

*Президент Мәсхадов Дудаевның шартлатылган Сарае торгызылачак урынга нигез ташы куйды. Шәһит киткәннәргә һәйкәл дә куелачак... Ә башкала исә – Ичкериянең һәлак булган беренче президенты Җохар Дудаев истәлегенә Җохар шәһәре дип йөртеләчәк. Шәһәргә керү юлында бу исем язылган гаять зур һәм мәһабәт стела куелган...»*

*декабрь, 1997*

## ПУТЧЛАРГА СОҢГЫ СҮЗ

Бүгенге Россия сәясәтчеләренең һәм хакимнәренең иң яраткан сүзе ул путч («фетнә» алай ук яңгырамый, шуңа бу сүзне тәрҗемә итмичә калдырдым. – *Ф.Т.*).

Элек – инкыйлаб иде, ә хәзер – путч.

Революционерларны һәм коммунистларны путчистлар һәм демократлар алыштырды.

Элгәрләр – революционерлар – җитмеш дүрт ел хакимлек иттеләр.

Әлегеләр – өч кенә ел.

Шулай булса да ике путч ясап өлгерделәр инде.

1991 елның августында һәм 1993 елның октябрендә.

Гамәлдә болар инкыйлабтан берни белән дә аерылмый – нәкъ үзләре.

Әмма сүзе ни тора: үзе заманча, үзе кыска. Шуңа күрә аларны ешрак ясау уңайрактыр, мөгаен.

Теләгең уяну белән. Халык та инде аңа ияләнеп килә бугай, бигрәк тә октябрьдәге ике көнлек гражданнар сугышыннан соң.

Ә алар арасында тагын бер фетнә булып алды. Пущеда. Дөрес, путч ук түгел, әмма аңа шактый охшаган. Фетнә инде.

Тәгаенләп әйтик: элеккеләр – революционерлар – бер генә инкыйлаб (революция) ясадылар. Унҗиденченең октябрендә.

Ә калган икесенә – 1905 нең гыйнварында һәм 1907 елның февралендәгеләргә күбрәк социал-демократлар, эсерлар, ач халык мөнәсәбәтле иде. Тегеләре дә, болары да октябрьдә җиңгәннәр – большевиклар тарафыннан бераз вакыттан соң атылдылар һәм төрмәләргә ташландылар.

Бүгенге көндәге кебек үк. Тик хәзерге вакытта «демократлар» тарафыннан.

Җитәр, мөгаен. Гасырлар төпкеленә чумып, чагыштырулар ясамаска тырышырбыз.

Шуны гына күзәтик: яңа эра, путчистлар эрасы күпмегә сузылыр? Ә бит берникә дә, беркемгә дә карамастан, тормыш бара, дәвам итә.

Борчак патша заманында да, коммунистлар, ә хәзер – путчистлар заманында да...

Шунысы кызык: аларга алмашка кайчан да булса берәр кеше килерме?

Нигездә, нинди аерма бар соң: барыбер шул ук диктатура һәм шул ук большевиклар белән яшәргә туры киләчәк. Бары тик «нео» дигәнен генә өстибез.

*** * ***

...Шунысы ачыкланды: хәтта XX йөздә дә азатлык белән демократия Россиягә яраклаша, яраша алмады...

*Мюнхен, декабрь, 1993*

## АРДЫМ

*– Әти, син кайчан кайтасың? Без син юклыктан ардык инде...*

*Өйдә мин берүзем генә. Артур белән әни инде ике сәгать буе ипи чиратында тора. Ике кешегә ипине күбрәк бирәләр, берничә көнгә җитә аннары...*

*– Алма? Юк, бездә алма юк.*

*Ни туры килсә, шуны алабыз. Кичә кильки бирделәр. Май белән шикәр кибеттә дә юк...*

*(Мюнхеннан Атыраудагы алты яшьлек*
*улым Ринат белән телефоннан сөйләшү,*

*декабрь, 1993)*

Соңгы вакытта миңа нидер булды.
Миңа яшәүдән ардым кебек тоела башлады. Хәтта сулаудан ардым.
Кайчакта, бүгенге кебек, тын алырга һәм бер тамчы һава йотарга да үземне мәҗбүр итәргә туры килә, хәтта мәҗбүр итү дә кыен була...
Йөри-йөри дә ардым. Хәтта уйлап ардым.
Минем ашыйсым да, эчәсем дә килми. Барысы да инерция белән генә эшләнә...
Мин ардым. Мин чыннан да ардым.
Мин бирегә килүемнән ардым.
Мин яңа мәгълүмат ташкыныннан, бу илнең икътисады, предприятиеләре турында сөйләүләрдән, әлеге укулар, өйрәнүләр уза торган шартлардан ардым.
Рекламалардан, урам, витрина, кибетләрнең балкып торуыннан, кибетләрдәге муллыктан ардым.
Пунктуальлектән, төгәллектән, мәҗбүрилектән һәм теләктәшлектән ардым.
Шалтыратулардан, сөйләшүләрдән һәм сәфәрләрдән ардым.
Факслардан, төрле проспектлардан, чагыштырулар, валюта курсларыннан, яңа технологияләрдән һәм моңарчы миңа билгеле булмаган җиһазлардан, җайланмалардан ардым.
Безнең бу укып йөрүләр үзебездә, тегендә, кемгә дә булса кирәк булыр микән, кайчан да булса эшкә ярар микән... дип уйлаудан да ардым.
Мин сәясәттән, анализлар, фаразлар һәм көтүләрдән ардым.
Мин Германиянең бердәмлеге, аның яңача төзелеше, хәл ителәсе мәсьәләләре, уңышлары турында мәгълүмат җыю, өйрәнү һәм язудан ардым.
Россия, бездәге һәм мондагы, Германия вакыйгаларыннан ардым.
Борчылып ардым.
Кичерешләрдән ардым.
Биредә бар нәрсә дә, һәркемгә дә булудан ардым.
Мин үзебездә шулай хәерче яшәвебездән ардым.
Әлеге бернинди файдасыз әңгәмәләрдән, бәхәсләрдән, очрашулардан, утырышлардан һәм тыңлаулардан ардым.
Кайчакларда мондагы кешеләрне аңламаудан, аларның мине аңламауларыннан ардым.
Үз халкым, ата-анам, балаларым өчен гарьләнүдән ардым.
Йокысыз төннәрдән ардым, һәм кайчакларда, кинәт кенә уянып, төне буе сәясәт, балачак, мәхшәрләр, тарих, әле яңа гына булып узган төрле вакыйгалар, кем өчендер аларның тәфсилле аңлатмасы турында язасың, язасың, язасың – шулардан да ардым.
Миңа безнең ни өчен шулай яшәвебезнең серен беләм кебек тоелудан да ардым.
Укудан, эшсезлектән, акча һәм вакыт җитмәүдән ардым.
Үземнән, үз тәкъдимнәремнән ардым.
Монда килер алдыннан һәм монда үземә йөкләгән йөкләмәләрдән ардым.
Бездә кайчан барысы да үзгәрер икән дип көтүдән, аны белмәүдән ардым...
Чит гаиләдән, чит илдән ардым.
Үз гаиләмнән башка ардым.
Хәләлемнең анда безнең хәл ителмәгән мәсьәләләрдән аруыннан ардым...
Бездә беркемнең дә үзен читтән торып күрәсе килмәүдән, шуңа күрә ничек яшәвебез турында берни белмәүдән, бары тик булганына разый булып яши бирүеннән ардым.
Барысыннан да ардым...
Ардым, нык ардым...

*** * ***

Гаиләмә, өемә бик кайтасым килә. Үземә кайтасым килә.
Үз музыкамны тыңлыйсым килә.
Нәрсә уйлыйм, шул турыда сөйлисем килә.
Үземә кирәкле һәм үзем ошаткан нәрсәләрне эшлисем килә.
Барыбызның да бер-берләрен аңлавын теләр идем...

Әйе, без барыбыз да нык ардык...

*Нюренберг – Мюнхен автобанындагы*
*уйланулардан.*

*13 декабрь, 1993*

## ЧИТ КЫРДА

*Үзем булып калыр өчен бөтен көчемне куеп тырыштым. Тик барысы да минем үзләре кебек булуымны телиләр.*
*Алар миңа, син кол кебек җырларга тиешсең, диләр, ә мине кол булу туйдырды...*

*Боб Дилан, «Ферма Магги»*

Спортта, чит кырда уйнау, дигән төшенчә бар.
Нәкъ менә төшенчә, башка берни түгел.
Чит кырда уйнау бигрәк тә футболда нык сизелә. Чөнки бу очракта уенның сыйфаты түгел, нәкъ менә чит кырда уйнау хәлиткеч булып санала.
Бу вакытта җанатарлар гына түгел, хәтта (иң мөһиме) судья да сиңа каршы, чөнки ул – кагыйдә буларак, бер капкага – кунаклар капкасына гына хөкемдар.
Оттырмас өчен генә дә (җиңү турында сүз дә юк) кунакларга хуҗалар белән тигез дәрәҗәдә уйнау гына җитми, күпкә өстенлек белән, бер башка югары торып, тагын да көчлерәк, беренчедән – судьяга, икенчедән, көндәшкә бернинди шанс калдырмаслык итеп уйнарга кирәк.
Югыйсә беттең, син төшеп каласың.
Хуҗаларга исә әллә ни тир түгәргә, ягъни «җигелеп эшләргә» кирәк тә түгел.
Еш кына бар да алдан ук билгеләнгән була.
Рольләр бүленгән, сценарийдан читкә китү гамәлдә рөхсәт ителми.
Бу – нормаль хәл дип санала, кагыйдә буенча рөхсәт ителгәннәргә кирә, дисәк тә була.
Чөнки бар очракта да матч нәтиҗәсе үз көчендә кала.
Дәгъва белдерәсеңме – юкмы, файдасы да, аермасы да юк.
Белдерә калсаң, үз нервыларыңны гына бетерәсең, әле өстәп түлисең дә.
Гаделсезлек булганда да судьяны гына сүгәргә мөмкин, ә син аны сүксәң-сүкмәсәң дә барыбер оттырдың инде, кабат уйнату булмаячак, хуҗалардан судья күптән инде гельд* алып куйган.

*** * ***

Әлеге мәсьәлә шактый катлаулы, беренче карашка гына гади булып тоела.
Монда эш – чит кырда гына түгел, «чит кыр турында» нигезләмәнең үзенең ясалма булуында, ул судья артында торучылар, ягъни әлеге система хуҗалары тарафыннан оештырыла да инде.
Аның бер буыны икенчесен алыштыра – шигарьләре, элмә күрсәткечләре, исемнәре генә үзгәрә, ә асылы шул ук кала.
Чөнки боларның барысы да аларның канында, ә законнар биредә алар тарафыннан һәм үзләре өчен генә язылган.
Шуңа күрә бөтен җирдә дә алар өчен «яшел ут» – ачык юл, барлык ишекләр дә үзләре ачыла, һәм алар моңа шулкадәр күнеккән, хәтта бүтәнчә мөмкин булуын күз алдына да китермиләр.
Бу җирдә беркайчан да башкача була алмады, алмас та, мөгаен.
Бүгенге система хуҗаларының беренче буыны большевиклар шигарьләре белән үзләреннән мәдәниятлерәк, укымышлырак булганнарны юкка чыгарды; ә икенче буыны исә, инде коммунистлар шигарьләренә таянып, могҗиза белән котылып калганнарны үтереп бетереп, беренчеләрнең «изге эшләрен» дәвам итте; өченчеләре – үзләренең махсус фатирларында һәм дачаларында оҗмах тормышы ясап, аннан соң аларны улларына, кияүләренә һәм туганнарының балаларына мирас итеп калдырып, бу җиңүгә мәдхия җырлады.
Ә хәзер инде болар – әүвәл коммунистлар, аннан социалистлар, алга таба центристлар, бүгенге көндә партиясез реформаторлар һәм базарчылар, чынлыкта исә – яңа большевиклар бар нәрсәне, ни икәнен дә аермый, үзара бүлешәләр, саталар: хакимият структураларындагы вазифалар, бизнестагы йогынты өлкәсе, инвестиция проектлары, кредитлар, табигый байлыклар һәм берничә буын барлыкка китергән дәүләт мөлкәте – барысы да сатыла, әйтерсең лә болар тик аларныкы гына, бары тик алар гына хуҗа.
Бу гамәлләрнең бер ишесе хосусыйлаштыру дип аталса, икенчеләре инвестицияләр җәлеп итеп эшләнә.
Кем тарафыннан кая һәм кемгә? – монысы инде аерым сорау, аерым мәсьәлә...
Гамәлдә исә ни дәүләткә, ни халыкка берни дә калмады, шуңа күрә бюджетта да һәрвакыт кара бушлык һәм кытлык кына ыржаеп тора.

Безне яңа буяулар һәм бизәкләр, исемнәр белән ничек кенә адаштырырга тырышмасыннар, моның схемасы бик гади.

Сиксән ел элек корбаннар һәм кан елгасы белән хакимияткә килгәннәр алга таба губкомнарда, фабзавкомнарда, райкомнарда, шәһәр комитетларында, өлкә комитетларында, башкарма комитетларда, президиум, сессия, пленум, бюро һәм политбюроларда, бүгенге көндә коллегияләрдә, һәр төрле киңәшмәләрдә, ассамблеяләрдә урын алдылар. Үз тормышлары, яшәү рәвешләре белән нык канәгать бу затларның беркайчан да эшкә генә түгел, дөрес күрсәтми торган линзалы күзлекләрен салып: «Бу дөньяда башкалар ничек яши икән?» – дип кызыксынырга да вакытлары булмады.

«Халык безне аңламас», «Без әлегә моңа әзер түгел», «Безгә әле моңа иртәрәк», «Безгә бу кирәк түгел» һәм башка шундый фикерләр һәм гамәлләр барлык уңай эшләрне тоткарлап торды.

Һәрвакыт шулай булды – тегеләре, болары һәм хәзергеләрендә дә.

Алар һәрвакыт башкалар, калганнар өчен барысын да хәл итте һәм бүгенге көндә дә хәл итә.

Ә шул ук вакытта аларга кайчандыр репрессияләнгәннәрнең һәм һәлак ителгәннәрнең балалары, оныклары, шулай ук авыр, фаҗигале язмышлары белән инде килешкән, кыска гомерләрен дәшмитынмый гына узып баручылар хезмәт күрсәтте.

Шунысы гаҗәп: җитештерүчеләр, хезмәт итүчеләрнең саны утырышчылар санынннан күпкә аз булып чыкты. Җитмәсә, хуҗаларның интеллекты колларның кул хезмәтен оештырудан башкасына җитмәде, нәтиҗәдә аларга Вакыт һәм цивилизацияле дөнья белән бергә атлау мөмкинлеге тумады.

Шулай итеп, бүгенге һәлакәткә килеп тә җиттек.

Әмма бу система бүген дә гамәлдә. Тик ашыгып кына трансформацияләнеп, шул нигездә яңа, бернигә дә ярамаган, вакытлыча гына булган формаларны кабул итеп яшәргә тырыша.

Бәлки, шуңадыр да биредә бер урында таптанган закон чыгаручылар хакимияте төпләнә алмыйдыр. Бер яктан, аның кирәге дә юк, икенче яктан, әлеге системада чиратлап, алыштыргысыз булып утырышкан бер үк бәндәләрдән ни көтәсең?

Хакимият хуҗаларына бер генә нәрсә ошамасын, шундук – Советларны, Парламентны тарату, яңа сайлаулар, кабат сайлаулар, референдумнар.

Пенсия белән хезмәт хакы түләүгә акча җитми, ә менә саны һәм чиге булмаган туйлар, юбилейлар, киңәшмә, исем үзгәртү, сайлау, кабат сайлаулар, референдумнар, күченеп йөрүләр һәм башка мәҗлесләр өчен миллионлаган, миллиардлаган сумнар сарыф итү берни түгел. Мәрхабә, баш өсте, күпме кирәк?!

Обывательнең башын әйләндерү, миен болгату – әлеге сәясәттә төп эшләрнең берсе...

Яңа дәүләтчелекне төзүчеләр, ялган реформаторлар үз икътисадларының бөтен куәтен бары тик бернәрсәдә – гади халыкны, үз халкын, яңадан бер әйберсез калдырып, үзләренә тиз арада, хәтта бик тиз генә, бөтен нәрсәне минималь бәядән сатуда, үзләштерүдә күрәләр.

Бүтәне «кулларыннан килми», бүтәннәргә таратуга күңелләре ятмый. Ничек инде үз нәсел-нәсәбеңә калдырмыйча, башкага бирәсең?!

Йөзләрен яшерү өчен, өлкә комитетлары һәм өлкә башкарма комитетлары дигән атамаларны тиз генә «администрацияләр» дип үзгәртеп куйдылар: ә «мәгариф бүлеге» кебек җәмәгать урыннарын департаментлар иттеләр. Ә җитәкчеләре – шулар ук: кичә – коммунизм, бүген капитализм төзүчеләр.

Сәер мантыйк (логика) – әйтерсең яңа исемнәр, юнәлешләр биреп кенә асылда нидер үзгәрә?

Шуның өстенә, хәтердән кичәгене сызып ташлап, элекке кебек үк бүгенге белән генә яшәү – узган гомерсез, димәк, киләчәксез калу дигән сүз.

Бары тик үзең турында гына уйлау, бүгенге катлаулы һәм болгавыр заманда, калганнар ярымач һәм тораксыз яшәгән көннәрдә күбрәк үзеңә каерып алырга тырышу яки хакимнәрне ашатып торучыларны кешегә санамау, яисә яшь дәүләт мәнфәгатьләрендә бүгенге көндә шулай кирәк дип уйлау һәм шуның өчен калган бар нәрсәгә дә битарафлык күрсәтеп тыныч карау – рөхсәт ителмәслек байлык, зиннәтлелек түгел, ә зур җинаять.

Үз дәүләтең, халкың, киләчәк буыннар алдында җинаять.

Ә аның ахыры көтелмәгән хәлләр белән бетәргә мөмкин.

Боларның үзләре өчен дә, дәүләт һәм халык өчен дә.

* * *

Алга таба да футболда кулланыла торган әлеге терминга таянсак, минем кечкенә балаларыма, ягъни безнең дүртенче буынга биредә һәрвакыт чит кырда «уйнарга» туры килә.

Шулай булса да, миндә моңа карата артык берниндиә дә хисси реакция юк, амбициозлыкны әйтмим дә инде.

Чынбарлыкка система хуҗаларыныкына охшамаган башка караш кына бар. Дөньяны да ничек бар, шулай күрәм мин. Беркемнең дә призмасы аша карамыйм. Башкалар мәнфәгатен яклаган үзгәртүләрсез, бозып күрсәтүләрсез кабул итәм.

Ә моннан инде система һәм аның хата-кимчелекләреннән канәгатьсезлек хисе туа. Берәүләрнең җиңел кулыннан бередә алар закон статусы алуны дәвам итә һәм, минем уемча – кимчелекле, бозык булып (ә алар күзлегеннән нормаль булып) тоелган системада билгеләүче юнәлеш була һәм шуңа күрә алар тарафыннан аклана һәм яклана да.

Ана сөте белән үк үз кырының өстенлеген сеңдерә барып һәм үзләренең командасында үзен судья итеп таныганга, аларга, ни өчен син моңа кадәр әлеге уен кагыйдәләренә буйсынмыйсың һәм син нигә, нәрсәдән канәгать түгел, дигән нәрсәне аңлау бик авыр, хәтта мөмкин түгел. Чөнки – «Эш бирделәр бит инде, сиңа тагын нәрсә кирәк?»тән ары китә алмыйлар.

Әмма сиңа ачыктан-ачык каршы судья белән даими рәвештә бер үк капкага уйнау еллар узган саен үз-үзеңне яклау һәм мондый хөкемдарлык белән килешмәү, канәгатьсезлек, җавап рәвешендә контратакага күчеп, капканы һичшиксез яулап алу белән тәмамланырга тиеш дигән хисне көчәйтә генә.

Гади бер гол кертеп кенә түгел, бу гол үзен мул сулы бөек елга дип хис итүче, аның ярында яшәүчеләрне туендырып торучы дип уйлаучы, үз-үзеннән канәгать ярымйокылы Баткаклыкны уятучы булырга тиеш.

Әгәр шулай булса...

Әгәр инде гол кертә алмыйсың икән, җанатарлар сине бер мизгел эчендә, хәтта алар баткаклыгында, юкка чыгарып атачак...

Бу уенның кагыйдәләре шундый.

* * *

Әлеге системаның яшәеше, аның кимчелекләре, бозыклыкларының үсә һәм тирәнәя баруы минем күз алдымда гына да инде чирек гасыр дәвам итә.

Бернинди үзгәрешсез.

Һәм бер мәлне миңа мондый уй килде: «Әгәр бернинди дә ачылып китү, яктылык күренми һәм бу системадагы уен кагыйдәләрен, үзеңне тоту кагыйдәләрен яхшы беләм икән, бәлки, хуҗалар командасына күчәргә кирәктер? Өстәвенә күчү кагыйдәләре дә билгеле».

Әмма бу системаның (перспективасызлыгы һәм бетүгә юл тотуы белән) парадоксы менә шунда күренә дә инде.

Мин әйткән кагыйдәләр бар да төсле, икенче караганда, юк та кебек.

Чөнки алар хуҗаларга гына яраклы.

Ә безгә, ягъни башкаларга, аның өчен яңадан туарга, ягъни физиологик, принципиаль, тулаем үзгәрешләр кичерергә кирәк булачак.

Шулай итеп, бу җәмгыять озак еллар дәвамында, имештер, сыйныфларга гына бүленде. Ә гамәлдә исә ул, бүгенге көндәге кебек, һәрвакыт төгәл һәм катгый рәвештә кешенең милләте, яше, элемтәләре, нәселе һәм туганлык җепләре, социаль хәле, чыгышы һ.б. буенча социаль төркемнәргә бүленде.

Һәм бу – узган (элекке) һәм хәзерге системаның варислыгын раслаучы төп сыйфатларның берсе.

Берәүләрнең хокук, мөмкинлекләре башкаларныкына караганда күпкә артык.

Ә бит боларның барысы да закон кысаларында эшләнә.

Игътибар үзәгендә кеше, гражданин һәм аның хокуклары түгел, бары тик – кем ул? кайдан? ни өчен? кемнән? һ.б.

Билгеле, барысына да кул селтәп, бөтенесе белән дә килешергә, образлы итеп әйткәндә, хуҗалар командасында дубль булырга, аларның затлы мәҗлесләреннән, өстәлләреннән килгән сынык-санак белән генә дә канәгатьләнергә мөмкин.

Китеп барырга да була. Барын ташлап. Еракларак. Күз күрмәгән, колак ишетмәгән җиргә.

Тик бит әле эш миндә генә түгел, әлеге система хуҗалары командасына кермәгәннәрнең барысына да кагыла бу нәрсә.

* * *

Халык әйтсә, белеп әйтә: «Коега төкермә, суын үзең эчәрсең», – ди.

Әйе, бу чынлап та шулай.

Әгәр кое бер генә булса.

Ә инде биредәге кебек аларның саны шактый булса?

Өстәвенә алар төрле-төрле дә бит әле: зурлары һәм кечкенәләре, тирәннәре һәм сайлары, чиста, саф сулы һәм пычрак сулылары бар.

Алардан һәрвакыт кемлегенә карап эчәләр.

Һәркемнең үз коесы.

Нәрсәдән эчә башлаган булсаң, үлгәнче шуннан эчәчәксең.

Шуңа күрә бер дә борчылмагыз, әфәнделәр, – миңа сезнең коедан эчү насыйп түгел. Сезгә бит кешенең үзе түгел, ә аның артында торган нәрсәләр әһәмиятле.

«Өлешләп демократия», яңа «апартеид», трайбализм, дәүләт һәм базар структураларын кушып үстерү, ришвәтчелек, протекционизм, крими, мафия – әлеге система шуларга гына сәләтле.

Әйе, тормыш нәҗестә уза.

Әлегә башкача була да алмый.

Билгеле булганча, нәҗес батмый, һәрвакыт йөзеп йөри, – гел өстә, каплап тора, шулай булгач, аннан астагыларның тормышы нинди булырга мөмкин?

Элмә такталар, шигарьләр, партияләр үзгәреп бетте, ә алар шул ук калды.

Аларның китәселәре дә юк, китсәләр дә аларны янә үз вәкилләре, үз кешеләре алыштырачак.

Алда ни? Моннан чыгу юлы бармы?

Минем карашка, әлеге системаны, димәк, биредә яшәгән безнең барыбызны да ныграк җимерелүдән, һәлакәттән коткарып калырдай бердәнбер нәрсә: хөкемдарны, әйтеп кителгән кырдагы гадәтләрне үзирек алыштырып, яңа капка – чын капка куярга һәм уенны да нульдән башлап, бар кешегә дә тигез булган яңа кагыйдәләр буенча уйный башларга кирәк.

Икенче төрле әйткәндә, законнарыбызны яңабаштан язу, аларда өстенлекле булып берсүзсез демократия белән ирек, законлылык һәм хокук тәртибе тору (димәк, һәр граждан ирегe һәм хокукы), ә аннан соң аларны үтәү зарур.

Югыйсә тарих спираленең яңа әйләнеш ясавы – элекке хуҗаларны шундый ук яңа хуҗаларга алыштыруы мөмкин.

Моны аңламый һәм эшләми торып, без барысын да югалтачакбыз.

*Мюнхен, ноябрь, 1993*

## ЯҢГЫР

*Һәм барысы да өемнәргә һәм дулкыннарга әйләнде.*

*Ибн-әл-Әсир*

Яңгыр сибәли.

Акрын гына.

Күңелгә моң, сагыш салып.

Һәрвакыттагыча – чиксез ямансу.

Бераз вакыт үтүгә ул, сибәләүдән туктап, шундый көчле итеп ява башлады ки, әйтерсең лә әлеге соры, эрегән пычрак карлы җиргә, төссез, караңгы корылмаларга, сирәк агачларга һәм йөгерешеп йөргән кечкенә, ач һәм хәерче кешеләргә берьюлы тизрәк ишелеп төшсен дип өстә кемдер шудырманы ачып җибәрде...

Шул кешеләрнең берсе, энәсеннән җебенә кадәр чыланып һәм туңудан калтырап, табигатьнең бу котыруын ышыкта үткәреп җибәрү уе белән, бер читтә ялгыз торган йортның подъездына кереп качты.

Зур көч белән бәреп яуган бу яңгыр, кемгәдер катгый итеп нидер аңлатырга теләгәндәй, подъезд тәрәзәсенең ватык пыяласын дер селкетеп туктаусыз шакылдап тора иде. Ә аннары, аның гозерен беркем дә ишетмәгәнгә ачуы килгәндәй, яңгыр ташкыны күпкатлы йортның подвалына агып төшә башлады һәм аны тиз арада тутырып та куйды. Бу мескен корылманың нигезен шул рәвешле юдыртып, ишеп, кемнәндер үч ала кебек тоела иде.

Юеш киемен кагып, дымлы һавадан һәм суыктан бөрешеп калган, чит йортның, шәһәрнең, илнең, бөтенләй белмәгән чит һәм аңлаешсыз дөньяның әлеге подъездында ни кыш түгел, ни яз түгел бер вакытта баштанаяк чыланып бетеп япа-ялгыз басып торган бу кеше уйга калды...

*Әллә тоелды, әллә чынлап та шулай булды: ул кинәт кенә үзен кабаттан теге тыныч, кояшлы һәм һәрчак сагынып көтеп алган шәһәрдә, аның үзәкне өзәрлек якын һәм таныш урамнарында, бакча һәм мәйданнарында йөргән кебек хис итте. Гадәттәгечә, Сендлингер-Тор метросыннан чыгып, Зонненштрасседан өскә таба китеп Штахуска кадәр килгәннән соң, фонтан янында бераз хәл алгач, кайчандыр яшәгән кебек тоелган теге мәхшәр дөнья турындагы уйлардан, ниһаять, арынып калгач, бәйрәм итеп йөрүче туристлар һәм юкны-бушка аударып йөрүчеләрнең шау-шулы һәм күңелле*

*төркеменә кушылып Карс капкасыннан үткәннән соң, ашыкмыйча гына Мариенплатцка таба юнәлде...*

Шул арада подвалдагы су, минут саен арта барып, бөтен ярыкларны, төрле-төрле бушлыкны тутырды. Әүвәл аска гына аккан булса, җыела-җыела, подъездның үзенә үк күтәрелде.

Яңгырның туктарга исәбе юк иде.

Алай гына да түгел: тагын да көчлерәк ява башлады. Үзенең көче, ташкыны белән кешеләр яши торган бу бистәне җир йөзеннән юып төшерергә тырыша кебек иде.

Бу күренештә – куәтле су ташкынында, күңелгә ятышсыз квадрат корылмаларда һәм кешеләрнең тавышсыз-тынсыз гына ары-бире йөргәндә ниндидер явыз, куркыныч көч бар иде.

*Ә Мариенплатцта һәрвакыттагыча – рәхәт һәм җанлану хөкем сөрә.*

*Йөзләреннән елмаю китмәгән ял итеп йөрүчеләр, кибет витриналары, Хугендубель, Кауфхоф, метродан чыгу юлы янында җыелышып, яңа-иске Ратхаусның готик ратушасындагы бавариялеләрнең катып калган гүзәл курчак сыннарыннан күзләрен ала алмый торалар.*

*Бернидә дә гаме булмаган үсмерләр мәйданның үзендә, фонтан белән шпиль янына утырышканнар да ялкау гына кыздырып торган кояш астында эшсезлектән ни турындадыр бәхәсләшәләр.*

*Шулкадәр тыныч һәм рәхәт, хәтта йокы бабай үзенә тарта башлады...*

Ә монда исә табигатьнең болай котыруын берничек тә аңлатып булмый иде: яңгырмы соң бу, әллә чынлап та «өске катта» коточкыч берәр хәл булганмы – өстән аска тоташ агып торучы су ташкыны шашты бугай, туктар нияте бөтенләй юк.

Сап-салкын су подвалны күмеп китте һәм беренче баскыч биеклегенә күтәрелде.

Һәм аның белән бергә подвалдагы дистәләгән еллар җыелып яткан бөтен чүп-чар, шакшы күтәрелә башлады.

Баксаң, әлеге подвал гадәти йомышларны үти һәм җыен әләмә-сәләмәне ташлый торган урын булып чыкты...

Ул инде тынычланып һәм салкын кан белән, ниндидер өметсез битарафлык белән бу галәмәтне күзәтеп тора башлады. Ул бер генә нәрсәне аңлый һәм исенә төшерә алмады – ничек һәм ни өчен бирегә килгән соң ул?..

Өндәме, төштәме соң бу? Моның кайсы өн дә кайсы төш: шакшы суның янартау кебек атылуымы, әллә теге – кояшлы, тыныч шәһәр мәйданымы?..

*Фонтан янына чыпчыклар очып килеп төште, башларын боргалый-боргалый, томшыкларын тиз-тиз хәрәкәтләндереп, су эчәргә кереште.*

*Кызык, чыпчыклар бар җирдә дә бертөсле икән – соры һәм хәрәкәтчән, куркаклар һәм җәһәтләр...*

Су ташкыны бөтен шәһәрне басты. Шулай булса да, бу хәл беркемне дә борчуга салмады, исен китәрмәде – бернинди кызу хәрәкәт, бернинди куркып калу яки йөгерешә-йөгерешә качу юк иде. Боларның барысы да – бар нәрсәне дә үтә кискән өметсезлек, шыксызлык, бетүгә баруны чагылдыра иде.

Мөгаен, бирелә моның ише хәлләргә инде күптән күнеккәннәрдер, барысы белән дә килешкәннәрдер. Диңгезнең басып керүе дә, кыш көне ярты елга диярлек сузылган һәм менә инде бу ишеп яуган яңгыр аркасындагы юлсызлык та беркемне дә борчымый...

*Фонтаннан бәреп чыккан нечкә су агынтыларының йомшак тавышы кайчакларда туристлар белән әкрен генә килеп туктаган автобуслар, беркем дә игътибар итмәгән полиция машиналары тавышы белән бераз күмелеп китә.*

*Көтмәгәндә, Мариенплатц җанланып, соклану, гаҗәпләнү авазлары белән гөжләп куйды һәм меңләгән халык Ратхаусның үзәк шпиленә күзен төбәде: музыка авазлары яңгырый башлады һәм шул арада курчак сыннар төрле хәрәкәтләр ясап биергә керештеләр.*

*Төрле яклап фотоаапаратлар балкып-балкып алды, видеокамералар текелди башлады...*

Ә биредә суның быгыр-быгыр килеп кайнап агуы күңелләргә шом сала: тирә-якта тоташ кара су коймасы һәм тимербетоннан төзелгән караңгы йортлар чынлап та ниндидер кыргый һәм булуы мөмкин булмаган бер сәер һәм куркыныч күренешне ача иде.

Ул бары тик шул мизгелдә генә тирә-юнендәге бөтен нәрсәнең тоташ караңгылыкта булуын абайлады һәм эңгер-меңгер, үзен сиздермәскә тырышып, тиз арада барлык реаль һәм тоемланган нәрсәне камап алды.

Һәм шул караңгылыкта ул яңадан дым белән юешлекнең подъездында үзе басып торган корылманы җебетеп «ашый», акрынлап җимерә башлавын әллә күрде, әллә инде күңеле белән сизде. Беренче карашка, бу корылма тимербетоннан булса да, ә гамәлдә гадәти бер ишелеп һәм коелып торучы ком кебек тотрыксыз, ышанычсыз һәм вакытлыча гына булып чыкты...

*Бу гүзәллекне соңгы мәртәбә күргән сизенгәндәй, ул, читтән караганда, бар нәрсәдән ваз кичкән кебек бөтенләй башка дөньядан һәм вакыттан күчкән кеше сыман, яңгыр һәм суның тыгыз пәрдәсе*

*аша гөрләп торган мәйданга һәм бәхетле кешеләргә ниндидер хушлашу сагышы белән карап тора иде...*

Кинәт аның аңында боларның барысы да – чынбарлыкта булганы-булмаганы да – кайдандыр ыргылып кергән коточкыч тимер шыкырдавы һәм кешеләрнең җаночеткеч ачы кычкырулары белән өзелде дә китте: нигезе юылып торган әлеге бина үзенең авырлыгы басымында янтая башлады, авыр блоклар читкә шуышты һәм берничә секунд эчендә, бу хәерче һәм фәкыйрь цивилизацияне, аның бәхетсез кешеләрен үз астында калдырып, тотрыксыз кәгазь өй сыман җимерелде дә төште.

«Ниһаять, бар да бетте» дигән соңгы уй йөгереп үтте аның башыннан, ниндидер бер канәгатьләнү биреп, әмма ул, ташкын булып агып кергән су һәм тимербетон белән бер мизгелдә юылып, ажгырып торган әлеге упкынга йотылды...

...Иртәнге якта бар да тынычланган иде.

Яңгыр, туктамаган булса да, инде шактый акрынайган һәм тынычлана төшкән, әле кичә генә шәһәр торган урында меңьеллардан соң үз урынына кайткан диңгез дулкыннары гына йөгерешә иде.

*Атырау, март, 1994*

## ЛИФТ

...Максатчан юнәлеш алган, кырыс һәм барган уңайга йокысыннан айнып килүче халык шәһәрнең иң биек һәм дәрәҗәле бинасының түрәләр йөри торган ишеге төбенә агыла; аннары, ике юнәлеш буенча – уңга һәм сулга таралып, тар коридорлардан җирле хакимиятнең кечкенә һәм тынчу кабинетларына кереп тула башлады.

...Халык ташкыны, әйтерсең күптән иялэнгән команда белән һәм акрынайтылып төшерелгән фильмдагы кебек, үзенең боек-интенсив агымын тоткарларга кереште: подъезд төбенә акрын гына автомобиль килеп туктады.

Машинадан чыккан берәү, беркемне һәм бернәрсәне дә күрмичә, инде күптән ияләнгән гадәте буенча як-ягына баш кагып, ниндидер мөһим мәсьәлә турында авыр уйларга чумгандай, ашыкмыйча гына ачык ишекләргә турылап китте.

Куркудан катып калган, керфекләрен селкетергә дә кыймыйча, аңа мөкиббән китеп карап торучы, аның берни дә аңлатмый торган пыяла карашын тотып алырга һәм шулай итеп аның күзенә күренеп калырга тырышучы кешеләр коридоры аша үтте ул.

Җыелган бу халыкка аның әллә ни исе китмәде – ул аннан күптән чыккан, күптән аерылган, шуңа үзен һәрвакыт аннан өстен санады. Хәзер инде халык төркеме аның өчен әһәмиятсез бернәрсә иде.

Ул ни өчендер уйга буйсынмаган ниндидер бер фикере турында уйларга тырышып караса да, барып чыкмады: әйтерсең баш миендә тоткарлаучы тормоз тора – уйлары ары китә алмыйча туктап калды...

Аякларын көчкә атлатып, ел һәм көн саен кабатланып торган һәм шуңа күрә автоматизмга җиткерелгән гадәтенчә ашыкмыйча гына сулга борылып, лифт янына килеп туктады.

Лифтны чакыру төймәсен, һәрвакыттагыча, инде кемдер яндырып куйган иде.

Бар да гадәткә кергәнчә.

Бер генә нәрсә дә шик тудырырлык, сагаерга мәҗбүр итәрлек түгел иде.

Бары кинәт туган бер генә сорау – инде җавабын беркайчан да белә алмаячак, шулай да көн саен аңа лифтны кем чакырта икән дигән сорау гына бераз сагайта-сагайтуын.

Ярымйокылы хәленнән лифтны гадәттәгедән озаграк көтүе генә түгел, үзе турында әле генә ни өчендер үткән заманда уйлавы да чыгара алмады...

Ниһаять, кайдадыр бина эчендә сузылган канатларын шыкырдата-шыкырдата, «күктән төшкән» лифтның ишеге ачылып китте.

Бары тик аның артыннан ябылган ишекнең сәер тавышыннан гына ул, озак еллар гипноз тәэсирендә булганнан соң айнып киткәндәй, гаҗәпләнеп һәм каушап, саннар язылган квадрат төймәләргә текәлде.

Аңа әлеге сәер тартмага беренче мәртәбә утырган кебек булып китте – кая, ничәнче катка менәсен дә онытты...

Һәм шул мәлдә, әйтерсең үзе түгел, кемдер икенче бер кеше, ышаныч белән иң югары катка менгерә торган төймәгә басты. Лифт, старт алдыннан «сискәнеп» китеп, салмак кына тизлекне арттыра башлады. Кабинадагы бердәнбер неон лампасы, еш-еш «күз кысып», нәрсәдәндер курыккандай яктылыгын киметте һәм аны ярымкараңгылыкта калдырды.

Гаҗәеп зур тизлек белән югары катка менеп китүче лифтта коты алынып бөрешеп калган әлеге адәми зат күкрәк читлегендә, йөрәге янында ук, ниндидер сәер һәм күңелкайтаргыч суык һәм курку хисе тойды – аның миеннән үтәли, электр тогы суккандай, бу коточкыч әрҗәдән инде беркайчан да чыга алмаячакмын, дигән уй узды...

Бер мәл тын да алмыйча торды. Шул мизгелдә кечкенә, яклаусыз һәм бөтенләй бернәрсәгә яраксыз кешегә әйләнде дә куйды. Мондый хәлдә үзен күптән хис иткәне юк иде. Бар нәрсә – вазыйфалары,

акчасы, титул һәм элемтәләре турында онытып, коты очып, үз катын инде күптән узып киткән саннардан күзен алмый карап тора башлады. Кинәт аңа лифт менгән уңайга бина түбәсен тишеп чыгар да үзе белән бергә каядыр югарыга очып китәр төсле тоелды һәм ...нәкъ менә шул мизгелдә чакыру төймәсенең пистолеттан аткандай чиртләп атылып чыккан тавышы аны чын мәгънәсендә аяктан екты – чиктән тыш киеренке торган йөрәге ярылып, җансыз гәүдәсе идәнгә барып төште...

Аның белән бергә, юлында тотрыклылык биреп саклап йөртүче инде күгәреп беткән пружинасын өзеп, үзенең шәхси лифты да шахта упкынына очып чәлпәрәмә килде. Шулай итеп, әлеге ак, ә чынлыкта исә соры һәм шомлы бинаның тирән чоңгылында бу түрә дә, аны йөртүче шәхси лифты да үзенең соңгы сыеныр урынын тапты...

*Атырау, июнь-октябрь, 1995*

*Хәтерем дулкыны буйлап*
*Киттем үткәннәрне уйлап.*
*Истә чакта язып калыйм,*
*Сөю, мәхәббәтне зурлап.*

*Кайнар хисләр, назларыма*
*Юлны ачкан ялкын бит ул.*
*Шул ялкыннан аваз салды*
*Гүзәл бер кыз һәм ике ул.*

*(Ф.Тарханова, 2008)*

## ХӘТЕРЕМ ДУЛКЫНЫ БУЙЛАП...

*1993 елның 30 мае. Мюнхен. TVдан, SAT-1 каналы аша Френк Синатр турында фильм бара. Матур һәм хисләрне кузгата торган нәфис музыка яңгырый. Мин еракта калган хатыным, балаларым турында уйлыйм. Һәм үзебезнең беренче очрашуларыбызны, ничек кушылуыбыз һәм язмышларыбызның бергә бәйләнеп китүен исемә төшерәм...*

1985 елның яз башы.

Илебезнең үзгәрешләр көтеп яшәгән чагы.

Кремльдә хакимиятнең чираттагы алышынуы язга туры килде, шуңа күрә аны якты фал дип уйларга җирлек туды.

Чынлап та, апрельдә саф һава китергән җилләр исә башлады, шул нигездә тормышыбызда уңай үзгәрешләр булыр дигән өмет уянды.

Икенче төрле әйткәндә, яз килде һәм барыбызның да бары тик яхшылыкны, матурлыкны гына күреп яшисе килә иде.

Шулай да минем хикәятем үзгәртеп корулар турында түгел, ә мәхәббәт турында.

Ул вакытта инде мин – тәмам җитлеккән, егерме җиде яшен тутырган ир-егет.

Язгы яңарыш, уяну үзе белән һәрвакыт яңа тормыш дәрте һәм яшьлек дәрманы алып килә.

Ә менә ул вакытта башкачарак булды, хәлләр гадәттәгедән күпкә өстен иде. Яшәү шатлыгы аеруча нык сизелеп, һәр нәрсә бәйрәм, тантана һәм кабатланмас бәхет булып кабул ителә иде.

Минем белән булганы да, әйләнә-тирәмдә барганы да.

Хәтта безнең кечкенә генә һәм килбәтсез шәһәрчегебез һавасында ниндидер гадәти булмаган, сүз белән аңлатып бирә алмый торган бернәрсә очып йөри кебек иде.

Тышкы яктан үзгәрешсез калсам да, эчтәге җаным бөтенләй башка дөньяда яши иде: күңел күтәренке һәм һушны алырлык очрашу көтеп йөри...

Ул очрашу озак көттермәде.

Шул ук апрельнең егермеләре тирәсе иде.

Эш көне. Мин, гадәттәгечә, дүртенче каттагы кабинетымда утырам.

Кинәт тирә-юнемдәге ниндидер сәер, гадәти булмаган тынлыкка игътибар иттем. Ни өчендер янымда ни хезмәттәшләрем, ни гозер белән килүчеләр юк. Бар да каядыр киткән.

Берни аңламыйча, бернәрсә турында да уйламыйча, беренче катка төшеп киттем.

Бөтен җирдә тынлык, бәлки, миңа шулай тоелгандыр гына. Ни өчендер астагы катның бер буш кабинетына кердем, тиешле вакытны җиткергәндәй, бераз басып тордым да ишекне ачып җибәрдем һәм ...Аны күрдем.

Янәшәмнән тиз-тиз атлап, гаҗәп сөйкемле һәм зифа буйлы бер кыз ишеккә юнәлде. Нәкъ төштәге кебек, мин аңа иярдем. Тәрәзә янында туктап, язгы-көзге пальто кигән бу кызыйның үкчәләре белән

җиңел генә шакылдатып ничек итеп асфальттан үтүен һәм автобуска утырып китүен тын гына карап калдым.

Тәрәзә янында басып торган килеш сәер бер хискә биреЛдем.

Мин аның йөзен дә күрми калдым юкса, ә үземә аны күптәннән беләм кебек тоелды.

Боларның барысы да бер мизгелгә сыйды. Хәтеремне ничек кенә җиксәм дә, аның йөзен күз алдыма китерә алмадым.

Җанымны җылы хис һәм наз биләп алды. Горур сыны, зифа гәүдәсе күз алдымнан китмәде.

Зур бина тынлыгында тирә-юнемдәгеләр йотылып, әһәмиятен югалтты.

Бөтен галәмнең асылы минем өчен менә бу билгесез кызыйның мөлаем образында тупланды...

Берничә көн узып китте.

Май бәйрәме җитте. Элек бездә андый бәйрәм дә бар иде.

Хәтеремдә – элеккечә теге кызның бары тик томанлы образы.

Әмма җанымда туган наз аны шул дәрәҗәгә җиткерде ки: бернинди шик калмады – нәкъ менә бу көннәрдә, бернигә дә карамастан, мин аны яңадан күрәчәкмен һәм таныячакмын.

Бер караганда, гаҗәп тә инде: төштә генә күргән кебек тоелган кешене назлы хисләр буенча гына ничек танырга була, мин бит аны юньләп күрмәдем дә.

Шулай да йөрәгем тыныч иде, гүя Аны мин үзем танырмын һәм Аның кайда икәнен үзем күрсәтермен, дия иде...

Беренче май көннәре, беренче сентябрь көннәре күк, бездә елның иң матур, иң күңелле чагы.

Җил дә юк, тузан да, яңгыр да, димәк, пычрак та юк, дигән сүз. Озынборыннар да күренми, бөркүлек һәм үтәли яндыра торган кояш нурлары да борчымый – бар да әле алда.

Ә ул көнне, Беренче Май бәйрәме көнне, иртә салкынча һәм кояшлы иде. Кояш мәйдан өстенә күтәрелгәч, көн бераз җылынды.

Урал тауларыннан иртәнге саф һава таралды, ә күк йөзе, зәңгәрсу төскә кереп, тормышның үзе кебек иксез-чиксез булып тоела башлады...

Бәйрәмгә дип җыелышкан каршыдагы төркем эченнән мин Аны күреп алдым. Шулай тиз табуыма гаҗәпләнмәдем дә хәтта.

Әйе, бу – ул иде.

Гәүдәсенә сыланып торган куе көрән күлмәге аның зифа буеның һәр ноктасын күрсәтеп тора.

Тирә-ягымда басып торган кешеләр ни турындадыр сөйләшә. Мин исә барысын да оныттым, Аннан гайре бернәрсәне дә, беркемне дә күрмим.

Әйләнә-тирәм каядыр тынлыкка күчте, бары тик бернинди әһәмияте булмаган образлар гына торып калды...

Минем бөтен игътибарым Аңарда гына.

Мин аны беренче тапкыр күрдем.

Аның матур, саф һәм яшь йөзенә, назлы көрән күзләренә, җитди иреннәренә, йомшак искән җилдә бераз дулкынланып торган куе каштан төсендәге озын чәчләренә, нечкә нәфис биленә игътибар иттем...

Шул мизгелдә ул кемгәдер елмайды, моны күргәч, минем йөрәгем кысылып куйды – аның елмаюы һуштан яздырырлык иде.

Ул күзгә күренеп үзгәрде: әйтерсең кояш тагын да яктырак яна башлады – бу мөлаем кызый тирә-юненә шулкадәр дә күп наз өләшә иде...

Мин аңа сихерләнеп карап тора башладым. Миңа яңадан аны күптән беләм кебек тоелды.

Бу күзләр, иреннәр, елмаюы, тәненең төсе һәм чәчләр әллә кайчан таныш сыман.

Ул гына да түгел: мин аны үтәли күрәм кебек иде.

Кайчандыр кочагыма алып, бу нәфис иреннәрне, күзләрне үпкән төсле булып китте.

Әгәр юк икән – һичшиксез булачак...

Кинәт күзләребез очрашты. Ул моңа бөтенләй әһәмият бирмәде. Соңрак минем тарафка гаҗәпләнеп бер караш ташлады да, нәрсәгәдер көлемсерәп, демонстрантлар арасына кереп югалды.

Әлеге берничә минут мәңгелек булып тоелды.

Янәшәмдә бар да элеккечә. Мин инде кем беләндер ни турындадыр сөйләшәм. Тик берни дә ишетмим – уемда бары Ул гына.

Әйе, мин Аны күрдем. Хәзер инде аны гомерлеккә табуыма иманым камил иде. Әйтерсең, бар да күптән билгеле булып, алдан хәл ителеп куелган.

Бары тик назлы һәм җиңелчә сагыш кына җанымны бөтереп алды, йөрәгем исә аның белән очрашу мизгелен кабат кичерә иде.

Аның турында уйлавымны дәвам итеп, миңа гаҗәеп бер уй килде.

Башыма Д.Тухмановның моннан дистә еллап элек яңгыраган «Хәтерем дулкыны буйлап» («По волне моей памяти») дигән җыры килеп керде. Анда алтынсу төстәге тәнле, нечкә үкчәле туфлидән,

кара ефәк чәчле, балаларныкы кебек нәфис иреннәренә матур елмаю кунган, камыштай төз буйлы, хәтер дулкынында бер килеп, бер китеп йөрүче мулат кыз турында сүз бара...

Мин танышымның образын ирексездән әлеге җырдагы кыз образы белән чагыштырдым: бераз кучкыл тәнле, яшь һәм камыш кебек җиңел гәүдәле, балаларныкы кебек матур иреннәрендә нәфис елмаю...

Әле яңа гына ачылып килүче, беркем кулы тимәгән матур бер чәчкә.

Өйгә кайткач, мин Куба шагыйре Николас Гильенның сайланма шигырьләр җыентыгын табып алдым да югарыда әйтелгән җырның сүзләрен («Хатирәләр диңгезе буйлап») элек куелган кыстыргыч буенча бик тиз эзләп таптым.

Билгеле, мин моның әле башы гына икәнен бик яхшы аңлыйм.

Сораулар бихисап, ә шикләнүләргә бернинди урын юк.

Мин язмышка, хисләргә һәм үземнең эчке рухыма (әбием әйткәнчә, үземнең җаныма) ышаныч багладым...

Күпме генә тырышсам да, беренче өч очрашуда танышырга омтылуым нәтиҗәсез калды.

Шунысы гаҗәп, моңа кадәр минем аны шәһәрдә күргәнем булмады, ә хәзер очраклылык безне әле монда, әле тегендә очраштыра да тора, күрештерә дә тора.

Ә менә бу көнне ул миңа беренче мәртәбә игътибар итте. Бу хәл – шул көннең иң мөһим вакыйгасы иде. Аның миңа зур коңгырт кара күзләрен тутырып каравы хәтеремә мәңгегә сеңеп калды, шуңа күрә бүген дә күз алдымда тора...

Әлеге көтелмәгән очрашулардан мин отмасам да, ышанычымны, өметемне җуймадым. Дөрес, ямансулап, сагышланып кала һәм яңадан күрешү көтеп, аны эзләп йөри идем. Безнең шәһәр әллә ни зур булмаганга, аның кайда эшләвен белү миңа авыр булмады. Чираттагы бу тырышлыгым да нәтиҗә бирмәде, шулай да бозның кузгалуын тойдым.

Исемен дә белеп өлгердем – Әминә икән. Бу исемне моңарчы әллә ничә кат ишеткән булсам да, ә хәзер ул бөтенләй икенче мәгънәдә яңгырый иде. Ниндидер матурлык, гадәти булмаган үзенчәлек, серлелек һәм үзенә җәлеп итү көче бар иде бу исемдә. Шул ук вакытта буй җитмәс биек тә иде...

Бөтен уемда ул гына...

Бәйрәмнәр үтеп китте.

Чираттагы бәйрәмне көтеп утырырлык түгел идем инде: аны эзләп чыгып киттем. Барлык мәдәният учреждениеләре буйлап.

Безнең шәһәрдә алар күп түгел-түгелен, шулай да бар.

Китапханәләрнең берсендә таптым мин аны.

Соңгы очрашудан соң узган берничә көн эчендә (минем соклануымның иге-чиге юк иде) ул тагын да матурайган, нәфисләнгән – табигать, яз һәм яшьлек үз эшен эшләгән иде.

Без сөйләшеп туймадык...

Мин эштән соң очрашачагыбызга ышандым да, ышанмадым да.

Һәм без чынлап та шул ук көнне кичен очраштык.

Күрешүләребез көн саен кабатлана башлады. Мин аннан башка бер генә көн дә яши алмый идем: иртән һәм көндез эшенә шылтыратам, ә кичен, нинди генә көн булмасын, нинди генә хәл булмасын, күпер аша аны каршыларга йөгерәм...

Тын алырга да куркып, аңа карыйм, аның өчен бөтен нәрсәне эшләргә дә риза.

Кайчакларда төнгә кадәр, хәтта таң атканчы да бер-беребездән аерылып китә алмый йөрибез.

Шулай берөзлексез. Көндез дә, кичен дә.

Безгә инде бер-беребезне бик күптән беләбез һәм яратабыз кебек тоела башлады. Шуны гына аңламый идек: моңарчы бер-беребездән башка ничек яшәгәнбез?..

Аның ягымлы елмаюы күпме наз һәм җылылык бирә иде. Хәл ителмәгән берәр мәсьәлә булса, тиз генә хәл ителә дә куя, елмайсын гына.

Мин бер-беребез тормышына шулай тиз кереп китәрбез дип һич уйламаган һәм хәтта башыма да килмәгән иде...

Беренче очрашудан соң нәкъ бер ай үткәч, без загска гариза керттек.

Ә аннан алда, әти-әниләребез хозурына барып, ниятебезне белдердек. Мөгаен, безнең хисләр, шатлык йөзләребезгә язылган булгандыр: алар, зирәк кеше буларак, безне шундук аңлап һәм барын да күреп, хәтта берни дә сораштырмыйча, фатихаларын бирделәр һәм бары тик бәхет кенә теләделәр...

Бу минутлар чынлап та кабатланмас һәм сүз белән әйтеп бирә алмаслык кыйммәткә ия.

Сөю һәм наз, сагыш һәм бәхет, горурлык һәм дулкынлану белән без яңа тормышка аяк бастык...

Һәр кеше тормышында сихри һәм кабатланмас төш булып истә калган көннәр була. Аны искә төшергәндә, әүвәл аның үтеп киткәненә уфтансаң да, аннары, ярый әле язмышымда шушындый матур вакытлар булган, дип шатланасың...

Безнең тарихта да кызыклы һәм гаҗәпләндерерлек вакыйгалар күп булды.

Без аларга, әллә ни зур игътибар юнәлтмичә, шулай булырга тиешле хәлләр итеп кенә карадык.

Кайчакларда, Хак Тәгалә үзе һәм бар дөнья безгә йөзе белән борылып, бер-беребезне табарга ярдәм итә кебек тоела иде.

Бу хәлләр әллә кайчан булса да, әле кичә генә үткән төсле. Вакыйгаларның һәр бөртеге хәтергә уелып калды.

Ул чакларда кичергән хисләр дә нәкъ шулай – бөтен нечкәлекләренә кадәр хәтердә...

Һәм менә 1985 елның 17 августы – безнең туй көне.

Без бергә – хәзер инде мәңгегә.

Бөтен сөюбезне, барлык матур хисләребезне балаларыбызга күчерәчәкбез.

Без ышанабыз: боларның барысы да алар тормышында да кирәк булачак һәм ярдәм итәчәк.

Бөтен теләгебез шул!

*Мюнхен, июнь, 1993*

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН КЫСКАЧА ЯЗМАЛАР

### КӨЗГЕ КАРШЫНДА – ҮЗ-ҮЗЕМӘ

Бүген мин бик арыган кыяфәттә.

Төнлә йокладыммы соң? Белмим.

Төн эчендә мин һаман арыйм.

Йокым һич туймый. Моны авыр кичерәм – һаман йокым килә.

Тынычлап бер йоклар идем, бернинди куркыныч төшләрсез.

Яту белән йокыга китеп, берничә көн рәттән йоклый алсаң иде ул.

Берни турында да уйламыйча. Уянып, йоклап китә алмый газапланмыйча һәм бернәрсәдән дә сискәнмичә.

Дөресен әйтим: бар да туйдырды.

### ИРТӘН

Фатир хуҗалары каядыр киткән.

Өйдә берүзем.

Йокыдан уяндым, торып аягыма бастым, гадәттәгечә кухняга төштем. Электр плитәсен кабыздым да чәйнеккә су салып, кайнарга куйдым.

Аш бүлмәсенә үттем. «Beyern-3» дулкында музыка тоттым. «Zүddeutsche Zeitung»ны кулыма алып караштыра башладым.

Мориц дигән ата мәче аяк астында чуала башлады. Ашарга сорый.

Аның белән яңадан кухняга кереп киттем.

Савытына «Kite-Kat» салдым.

Үземә бер йомырка пешердем дә, ике кисәк сыр, колбаса, ипи алып, ашарга утырдым. Ашыкмыйча гына ашадым. Бер шешә «Edel-stoss» сырасын ачып куйдым.

Диванга барып утырдым. Музыка тыңлый-тыңлый (ул туктаганда – нахрихтен), сыра эчеп, газета укып, яңалыклар белән таныштым.

Авызын ялый-ялый Мориц килеп керде. Инде тамагы тук, барыннан да канәгать.

Мине хуҗасы итеп таныгандай, рәхмәтен белдереп, аякларыма сырпаланды да сузылып ятты.

Икәүләп ял итәбез. Ул идәнгә сузылган, мин кәнәфигә җәелгән. Рәхәт...

Шул мизгелдә сәгатькә күз төште – бәрәч, соңга калам икән ич!

Сикереп тордым – хәтта мәче дә читкә ыргылды. Моны көтмәгән иде. Барысын да сүндердем дә, «әһ» дигәнче киенеп, 83 нче автобус тукталышына чыгып чаптым...

...Вәт шул.

Хуҗа булып кыландым, имеш.

Кичен бар да өйдә иде инде.

*Мюнхен, 2 гыйнвар, 1994*

### ФАКТ

Теләсә нинди хәлләрдән чыгуның ике варианты бар. Берсе – ишекне каты ябып чыгып китү, икенчесе – инглизләрчә, саубулашмый китү.

Аларның кайсы әйбәт – тәгаен ситуациядән һәм мөмкин булачак нәтиҗәләрдән яки әлеге гамәлнең ни-нәрсәгә китерү мөмкинлегеннән тора.

Минем өчен алар бертигез.

Чөнки мин үзем сайлаган юлның дөреслегенә ышанам, интуициямә таянам.
Ә авыр хәлдән чыгу юлы һәрвакыт бар – котыла алмаслык хәлләр булмый. Таба белергә генә кирәк.
Ә менә – китү мәсьәләсе... икенчерәк.
Китеп барганда ни өчен? ни сәбәпле? дигәннәре мөһим роль уйный.
Беренчедән – ару, арыганлык.
Икенчедән, ситуациядән коры чыгарга яратучы, үзләреннән канәгать һәм бүсенгән ватандашларымның кабахәтлеге һәм бозыклыгының күңелне кайтаруы.
Өченчедән, аларның үзгәрүен аңламыйм да, мин моңа риза да түгел.
Һәр очракта да үзең булып кала белергә кирәк.
Кем белән, кайда гына, кайчан гына һәм кем генә булсаң да.
Төрләнүне кабул итмим.
Булган әйбәт мөнәсәбәтләрнең кадерен белергә, кыйммәтен аңларга кирәк.
Бигрәк тә озак еллар буе ныгыган мөнәсәбәтләрнең.
Аны бернинди акчага да сатып алып яисә алыштырып булмый.
Югыйсә бу мөнәсәбәт кире юнәлеш алачак.
Тормыш раслаганча, дуслыкның битарафлыкка, ахыр чиктә дошманлыкка күчүе беркемгә дә беркайчан да бәхет китергәнә юк әле.
Электән килгән, озак елларга сузылган дуслык бәйләнеше – иң ышанычлы бәйләнеш.
Мин моңа берничә мәртәбә инандым, ни өчендер тегеләр генә моны аңлап җиткерә алмый – бу факт.
*5 гыйнвар, 1994*

**«ТӘКЪДИРИ КӨННӘР ҺӘМ САННАР ТУРЫНДА»**

*В.Высоцкийдан*

Үзенең билгеле һәм еш кабатлануы белән сәер саннар тормыш юлыбызда һаман эзәрлекләп тора, дисәк тә була.
Безне нindидер кысалардан чыгармаска тырыша яки бездән көчлерәк, югарырак торган илаһи нәрсә турында исебезгә төшереп тора сыман.
Мөгаен, моңа тыныч кына, юрамаларга буйсындырмыйча гына карарга кирәктер, бары тик аның бар икәнен генә онытмаска кирәк. Чөнки без бар нәрсәне үзебез дә белмичә, кайчакларда сизмичә барлыкка китерәбез, шул ук вакытта аның хакимлегендә, аңа буйсынып яши бирәбез...
Иң әүвәл – җитди нәрсә турында.
Әтиемнең абыйсы егерме сигезенче яшендә фронтта һәлак була.
Мин дөньяга килгәндә, әтиемә егерме сигез яшь була.
Төп-төгәл егерме сигез елдан соң минем улым – әтиемнең оныгы туа.
Миңа егерме сигез яшь тулгач, әтием үлеп китә.
Кызык хәл бит: вакыйгаларны сәер 28 саны берләштерә...
Тормыш дәвам итә. «Шулай булсын», – дип җырлады Д.Леннон да кайчандыр.
Әйе, булсын шулай.
Ә хәзер җиңелрәк нәрсә турында.
«Тугыз ай – әле ел түгел», – монысы инде Высоцкийныкы. Чынлап та шулай.
Чөнки һәр кешенең гомер башы шул айларда һәм кеше тормышында бу сан иң саф, иң пакь сан.
Үзегез фикер йөртеп карагыз әле. Мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында уку елы да нәкъ менә шул тугыз ай кысаларында үтә.
Үземнең беренче мәктәп һәм студент елларын бергә кушканнан соң унҗиде саны килеп чыкты.
Алга таба – тагын да кызыклырак.
Тормышымда бу тугыз ай, шайтан вәсвәсәсе кебек, тагын сигез мәртәбә очрады!
Бала чагымда «Боровое» шифаханәсендә дәваланганда, аннары төрле елларда алты (!) вазыйфаи урында эшләгәндә, Германиядә стажировка үткәндә – барысында да тугыз ай хөкем сөрде...
Җәмгысе – 25 мәртәбә. Гаҗәпләнмәслек тә түгел. Асылда моңа игътибар итмәскә дә була булуын, әмма...
Курс – Гиннесның рекордлар китабы.
*Мюнхен, гыйнвар, 2009*

**СССРНЫ ТАРКАТУГА БЕР КАРАШ**

Өч борынга керергә уйладылар.

Керделәр дә. Элекке өч ата коммунист.

Берочтан илне дә таркаттылар. Дөресрәге, халыкларны.

Өчәүләп.

Әллә Бучу Пущасында, әллә путч булды шунда, әлегә кадәр моны юридик яктан, Конституциягә туры китереп атый, аның ни икәнен аңлата алган кеше юк.

Һәм элекке союздаш республикаларга яңа, урысның өч хәрефеннән торган – БДБ дигән исем куштылар.

Барысының да тарих ясыйсы килә. Бер караганда, бу аңлашыла да. Әмма аны, ни өчендер, һәркайсы нульдән башлап язарга тырыша. Әйтерсең аларга кадәр беркем дә, бернәрсә дә булмаган.

Беренче булу дәрәҗәлерәк шул. Ә алар һәрвакыт беренче булды – өлкә комитетлары, шәһәр комитетлары, Үзәк Комитет секретарьлары.

Гадәт һәм варислык, күчемлелек – большевикларның үлмәс эше. Шуңа күрә таркату принцибының да Ленинчасын сакладылар – бу җир кайчандыр үз белдеге белән җирләрне халыкларга бүлгән кебек бүленде (яшәсеннәр шунда), иң мөһиме – шул ук статуста.

*«Әгәр дә Ильич сиңа союздаш республика дигән кушамат таккан икән, димәк, син бәйсез дәүләт, әгәр инде автономия генә икәнсең – безнең указлар, өлкәннәр указы сиңа кагылмый – борын астың кипмәгән, үсәсең бар әле...*

*Ә демократия дигән нәрсәне без сезгә бирербез, тик үзегез ала алган кадәр генә, әмма сез аны барыбер бездән ала алмаячаксыз...*

*Шулай булгач, россияле кече туганнар, Ильичка хезмәт күрсәтү – икенче мәсьәлә, ә хәзер, гафу итегез, сезнең барыгызны да иреккә җибәрә башласак, үзебезгә берни калмаячак...»*

Европа интеграцияләнә. Глобаль гомумкешелек мәсьәләләрен бергәләп хәл итү юлларын эзли. Безнең игътибарны исә ул җәлеп итми, хәтта кешенең, гражданның, закон, демократия һәм ирекнең өстенлекле булуы да кызыксындырмый – безгә алар кирәк түгел. Бары бер генә нәрсә борчый – безгә һәрвакыт кем беләндер көрәшергә, сугышырга гына кирәк. Контрреволюция белән, кулаклар, руханилар, капитализм, империализм белән, ә бүгенге көндә инде коммунизм һ.б. белән көрәшер чират җитте.

Хәтта нинди дә булса эшләр башкарганда да көрәшәбез – коллективлаштыру, индустрияләштерү, уңыш өчен, эчкечелек һәм алкоголизмга каршы. Үзебезгә үзебез каршылык ясыйбыз да аннан соң аңа каршы (яки белән) көрәшәбез.

Бүгенге заманда, шөкер, халык дошманнары да, чит илдәге дошманнар да юк. Юк икән, булдырабыз, үзебездән үк – милли нигездә.

Алма-Ата, Ферганә, Яңа Үзән, Ош, Карабах, Тбилиси, Вильнюс, Баку, Мәскәү, Абхазия, Грузия ... – шуның дәлиле түгелмени?

Бу коточкыч исемлектә чираттагысы кем?..

**ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ**

*** * ***

Мюнхенда «Француз кухнясы» дигән ресторан бар. Штахус белән Мариенплатц арасында. «Марше» дип атала. Көннәрдән беркөнне монда озын чәчле латиноамериканец килеп керә. Биредә официант булып эшләп йөргән таныш французын очрата. Көлешә-көлешә гәпләшәләр болар. Французның эше күп – озак тормый, китә.

Шулчак тагын берәү (монысы – кара тәнле) килеп керә. Тагын көлешәләр болар.

Латиноамериканец, француз, кара тәнле – боларда милләтне аеру юк. Бар да бертигез. Тән төсенә карап та аерымланмыйлар.

Кызыл тәнле, ак һәм кара тәнле.

Уртак, аралашу телләре – немец теле.

*** * ***

Бервакыт кич белән Мюнхен метросында кара тәнлеләр төркемен күреп алдым һәм алар русча (?!) сөйләшәләр иде.

Әллә инде шулай булуын үзем теләдемме?..

*** * ***

Телефон шылтырады.

Килеп җитә алмадым.

– Мориц (теге ата мәче), син ник төрепкәне алмыйсың?

– Мин сөйләшә беләммени?

– ?!

*Мюнхен, 5 гыйнвар, 1994*

**«БЕВЕРЛИ-ХИЛЛЗ»**

*(Шул исемдәге фильм карагач)*

«Беверли-Хиллз»...

Минем дә «Беверли-Хиллз»ым бар идеме? Билгеле, бар иде. Моңсу булып китте. Чөнки – бар иде, ягъни үткән заманда калды. Бит әлеге вакыт – тормыштагы иң күңелле, иң әйбәт чор. 16 дан 20 яшькәчә. Мәктәп, аннары институт.

Дуслар, очрашулар. Дуслар артып, очрашулар яңарып тора. Өмет, яшьлек, көч, уңышлар һәм ышанычлар еллары. Мөмкинлекләр еллары да. Бар дөнья – синең аяк астында. Күпме кирәк – ал. Тик бик аз алына, соңыннан үкенәсең-үкенүен... Бәлки, шулай булырга тиештәдер. Кешегә һәрвакыт җитми, һәрвакыт аз тоела. Анысы соңыннан, ә бу вакытта...

Шулай да, дөнья матур. Шуңа да матур – барыбер дә минем «Беверли-Хиллз»ым булды.

**МАҢКА**

Немецлар гаиләсендә беренче иртәнге ашым.

Хуҗам, минем яшьтәшем, ашый башлаганчы, кесәсеннән кәгазь салфетка чыгарды да рәхәтләнеп сеңгерде...

*«Ходам,.. моннан соң ничек ашарга инде?»*

Әмма моңа игътибар итүче булмады. Бер-беренә «тәмле булсын» дип теләделәр дә ашый да башладылар.

Шуннан китте...

Бөтен җирдә, һәр адымда.

Автобуста, метрода, электричкада, трамвайда.

Уңда да, сулда да, алда да, артта да – сеңгерү, сеңгерү, сеңгерү...

«*Бу нинди халык? Без андый түгел бит».*

Гадәтләребезне искә төшердем генә, сискәнеп киттем...

Бигрәк тиз оныткнмын икән!

Әйе, бездә маңка сеңгереп йөрмиләр, лач итеп төкерәләр йә... какыралар.

Кинода һәм театрда, автобуста, урамда һәм бөтен җирдә.

Хәтта үтеп баручының йөзенә дә, әгәр ул ошап бетмәсә...

*«Бу нинди халык?»*

**БЕРВАКЫТ ВИКТУАЛИЕН-МАРКТТА...**

Бервакыт Виктуалиен-марктта (Мюнхенның тарихи өлешендәге борынгы, яшел чирәмле базар), хеллес-биер эчеп, әле генә карап чыккан Пикассо картиналары күргәзмәсе, геометрик фигуралар, кубизм турында сөйләшеп утырабыз.

Башта әңгәмәгә катнашсам да, бераздан үз уйларыма кереп киттем... Һәм кинәт минем башка Казахстаннан әле яңа гына алынгандай бер мәгълүмат килеп керде.

Кызганыч, мин бу мәгълүматка үзем дә ышанмадым, шуңа күрә аңа әллә ни әһәмият тә бирмәдем.

Гадәттә мондый уй-фикерләрне хәтеремә язып куя торган идем, бу юлы анысын да эшләмәдем.

Бары тик шул ук көннең кичендә генә бу турыда уйлап алдым. Хәтеремне күпме генә җиксәм дә, әлеге мәгълүматның нидән тууы турында детальләп искә төшерә алмадым.

Шуны гына әйтә алам: минем Атыраудагы якын танышымда миңа моңарчы билгеле булмаган ниндидер мөһим һәм кирәкле нәрсә барлыкка килгән.

Мин хәтта үземнән кызыксыну белән, бу мөмкин хәлме? дип сорадым.

Бит мин аны үз күзләрем белән күргәндәй булдым, дөресрәге, боларның барысын да күз алдыма китердем...

(Бәлки, моны үзем теләгәнмендер? Шулай булуы да мөмкин, чөнки миңа элек билгеле булган мәгълүматлар суммасы шул мизгелдә үк вакыйгалар үсешенең алга таба объектив хәрәкәтен күрсәткән булуы мөмкин.)

Әгәр шулай булса, минем карашка, мөмкинлекләр, сизеп алып, ни турындадыр ерак аралардан белү принцибы үзе әһәмиятле, бу очрактагы факт түгел.

Минем үземә куйган соравым шул: чынлап та мөмкинме бу хәл?..

*Мюнхен, 1 июнь, 1993*

**КИЧЕКТЕРЕЛГӘН ӨМЕТ**

Йоханнес Леопольд Майер, Мюнхен кичләренең берсендә Анне-Лоре Эббен тәрҗемәсендә минем берничә әсәремне («Яфрак», «Кадаклар», «Чит кырда» һ.б.) ишетеп, аларның берсенә – «Киләчәкне искә төшереп, яки Исеңдәме, бу ничек булачак?..» дигәненә музыка язу турында көтелмәгән идея белдерде.

Вена симфоник оркестры дирижерының бу кызыклы тәкъдимен мин ул чакта кичектереп, җайлырак чакка калдырып торган идем.

Дөрес эшләмәгәнмен...

Соңыннан гына аңладым.

**ЯҢГЫРДАН СОҢ**

*(Ессентукида беренче җәйге көн уртасы,*
*1977 елның июле)*

*Җанга рәхәт җиләс саф һава.*
*Әйтерсең «Ан-24» тә очып килү дә,*
*«Газ-53» кузовында селкенеп бару да булмаган.*

Тирә-юнь яшеллеккә чумган.
Яшел агачлар һәм үләннәрдән,
Су тамып торган агачлар
һәм үләннәрдән
Җанга рәхәт җиләс саф һава...

Әле яңа гына явып үткән
Яңгырга чыланган агачлардан
Һәм дә үләннәрдән
Җанга рәхәт җиләс саф һава...

Яфраклардан тамган тамчылардан
Һәм аяк астындагы дымнан
Кабарган җирдән
Җанга рәхәт җиләс саф һава...

Гаҗәп чиста,
үтә күренмәле,
озон белән туендырылган
Җиләс, саф һава.
Бар нәрсәдә дә шундый ук
сафлык
һәм җиләслек.

*Ессентуки, 31 июль, 1995*

**КАКТУС**

*Кей Максвэллга, Майкл Пальмбах, Шерон Хэкман, Боб Браатон, Джерри Гэри һәм Халидә Крыкбаевага, яки – Экспертларның халыкара Корпусына, АКШның Санта-Круз институтына һәм Мәгълүматлар агентлыгына.*

Аризона өстендә, көйдереп һәм бөтен нәрсәне яндырып, ут чәчеп торган кояш эленеп тора.

Бөтен җан иясе – кешеләр, хайваннар, кошлар, сөйрәлүчеләр, әлеге сусыз якта яшәүчеләрнең барысы да кояш ялкынынннан кем кая өлгергән, шунда кереп качкан. Чүлнең хайваннар дөньясы һәм дүрт йөз меңлек Туссон шәһәре әйтерсең үлеп беткән – тереклек итүчеләрнең берниндие хәрәкәте күренми.

Бары тик кактус кына – штатның символы – Фаренгейт буенча йөз дә ун градуска җиткән кызуга горур гына һәм сабырлык белән түзеп тора...

Чүлләрнең, Прерий һәм Тауларның сүзсез генә көеп утырган дөньясында бар да сәер булып күренә:

әлеге берничә метр биеклеккә күтәрелгән бинибая зур йөз меңләгән ялгызак кактуслар да;

гел буш, җансыз булып тоелган, пыяла белән бетоннан гына торган күккә ашкан шыксыз биналар да;

яр буе ныгытмалары белән сусыз Санта-Круз елгасы да – бер тамчы суы булмаган бу коры елга (хәтта елгалар да монда җир астыннан ага) яңгыр сезоны вакытында шәһәргә генә түгел, бөтен Пима графлыгына да коточкыч су басу куркынычы сала;

бер-беренә бөтенләй охшамаган бер үк исемдәге ике Ногалес шәһәрчеге дә (аның берсе – дәүләт чигенең Америка ягыннан, икенчесе – Мексика ягыннан)...

Боларның барысы да чынлап та бик сәер һәм гадәти булмаганча күренә. Безнең җирдәге кебек тә түгел, әйтерсең башка планетада яки уйлап чыгарылган фантастик фильмдагы төсле.

Әмма бу – бары беренче карашка гына шулай. Чынлыкта исә, кояш көйдереп торса да, Туссон тәүлек буе тулы канлы тормыш белән яши – ни төн, ни иртә таң, ни кызу көн аңа комачау түгел: машиналар агымы шәһәрдә генә түгел, аның тирәсендәге автобанда да хәрәкәтен туктатып тормый.

Биналар эчендә – барлык уку йортларында, спорт, хастаханә үзәкләрендә һәм офисларда салкынча һавада һәм фонтаннарның салмак кына челтерәгән тавышы астында төрле төстәге күпмеңләгән халыкның җанлы хезмәте бара.

Ә бернинди болыт әсәре күренмәгән ачык күк йөзе астында шулай ук ялгыз-ялгыз һәм дәшмитынмый гына, мондагы барлык нәрсәне көл итәргә әзер кояш радиациясенең бөтен куәтен үзенә сеңдереп торучы төрле төрдәге күпләгән гаять зур һәм кечкенә кактуслар тезелешеп тора.

*Туссон, июнь, 1997*

**КАРГА**

«Нива» машинасы сәгатенә 110 км тизлек белән трасса буйлап чаба.

Көтмәгәндә, нәкъ юл уртасында, егерме метрлап алда бер карга пәйда булды.

Машинабыз тизлекне киметмичә чабуын дәвам итә. Карганың берничә минуттан машина тәгәрмәчләре астында калу ихтималы зур.

Мин, бу хәлне көтеп, ихтиярсыз бөрешеп калдым һәм шул мизгелдә йөрәгемне кинәт авырту чәнчеп алды: миңа юлда карга түгел, мин үзем торам, машина минем өскә килә кебек тоелды...

Шул ук мәлдә карга, авырлык белән булса да юлдан күтәрелеп, читкә китеп өлгерде һәм исән калды...

Бар да ике-өч секунд эчендә булды.

Әмма минем хәлем, каты авырудан яки авыр стресстан соң булган кебек, арып, авыраеп калды, ә йөрәк турысындагы авырту, аның ешайган тибешеннән көчәеп, күкрәгемнең бөтен өске сул ягын камап алды...

*Атырау – Уральск – Самара –*
*Ульян – Чабаксар – Түбән Новгород,*
*июль, 1977*

**ҖАВАПСЫЗ СОРАУЛАР**

**Беренче.**

...Киләчәк юк.

Узган булмаган кебек.

Һәрвакыт бүгенге генә, ягъни хәзерге генә бар – ягъни кичә, бүген һәм иртәгә.

Һәрвакыт хәзер булган нәрсә генә бар.

Ул беткәч – бар да бетә.

**Икенче.**

...Бу планетада кеше, бөтен халык –ербөтеннең – югары аңның бер кисәге.

Туры мәгънәсендә түгел, әлбәттә.

Кеше, аның түбәнрәк стадиясе вәкиле буларак – әлеге югары аң өчен кирәкле энергия чыганагы гына.

Безнең миебез, безнең, минем аң – кайдадыр тупланган Югары Аңның микроскопик үрнәк өлгесе (прообразы).

Безнең энергия (биологик һ.б.), миебез яки җаныбыз, бер караганда, тышкы дөньяга бәйле булмаса да, безнең өчен буй җитмәслек Югары Аңы белән турыдан-туры багланышта тора, әмма шул ук вакытта, бүленеп чыгып һәм нурланып, аның кечкенә генә бер кисәген тәшкил итә.

Һәм боларның барысы да кайдадыр бергә туплана.

Әмма без моны беркайчан да аңлый алмаячакбыз.

Чөнки бу нәрсә безнең акылыбызга сыймый һәм ул, боларның барысыннан да – бер үк вакытта бөек тә, кыркыныч та булган, бездән, безнең дөньядан, безнең акылдан һәм безнең зиһеннән тыш гамәлдә йөргән нәрсәдән акылдан язмыйча, моны кабул итәргә, төшенергә сәләтле түгел...

**Өченче.**

...Кеше, бер мизгелдә үзенә шул чакта кирәкле бөтен мәгълүматны тотып алып, якты дөньяга аваз сала.

Кеше тормышында кирәкле бөтен Мәгълүмат инде тупланган, каядыр салынган (бәлки, аның үзенәдер дә) һәм ул аны әйтерсең кемнәндер (бәлки, шулайдыр да) һәр тормыш баскычында кирәкле һәм тәгаен үлчәнгән өлешләр, дозалар белән ала – бер тамчы артык та түгел, ким дә түгел, бар да чамалы; шул ук вакытта моңа ул үзе яки бөтен кирәкле нәрсәне узган буыннардан файдаланып һәм кабул итеп ирешә кебек тоела, әмма бар да кем тарафыннандыр инде күптән билгеләп куелган...

Без кемнәндер бары тик безгә тиеш булганын гына алабыз һәм беләбез, артыгы бирелми...

**Дүртенче.**

Соңгы өч ел эчендә Вакыт төшенчәсе, дөресрәге, аның агым тизлеге, сизелерлек артып, кинәт үзгәрде.

Бар да элеккечә кебек, тик гасырлар күчеше барыбер үз ролен уйныйдыр, мөгаен – көннәр, атналар, еллар, нәрсәгәдер, ниндидер очып китү ноктасына магниттай тартылып, арта барган тизлек белән үтәләр...

Аңа җитүгә, спираль буйлап тыныч кына, ашыкмыйча гына яңадан тәгәри башлыйлар.

**Бишенче.**

...Төш – безнең икенче параллель дөньябыз кебек: без анда үтеп керәбез, йөрибез, яшибез, борчылабыз.

Аларда булган хәлләрне ничек тә күзәтүдә тотарга йә булмаса истә калдырырга кирәк, шул чакта күп нәрсә ачылачак...

Бүген (төшемдә) ниндидер вакыйгалар һәм гамәлләрдән соң мин тәгаен заттан: «Менә син хәзер бирелә, иртәгә син өндә, монда булган һәм күргән хәлләрне исеңә төшерә алыр идеңме? – дип сорадым. – Гомумән, монда булганыңны белерсеңме, бу бит төш кенә – өстәвенә мин генә күрә торган төш?»

Кызганыч, көндез без төнлә йөргән җирләрне (бигрәк тә төштә) бик тиз онытабыз.

Ә бу төштәге вакыйгалар чынлап та нәкъ өндәгечә иде.

Яңа панель йортлар, буялган тәрәзә кашагалары, бишкатлы ике йортның ишегалды, әле китеп өлгермәгән төзүчеләрнең вагончыклары яки вакытлыча ярдәмче корылмалары, гравий, урыны-урыны белән җәелгән асфальт, бөтен җирдә чисталык, неон фонарьлар, эңгер-меңгер, әмма бу вакыт төш өчен генә – анда кояш юк.

Бөтен нәрсә ап-ачык күренеп тора. Караңгылык та, яктылык та юк кебек, әмма барлык объектлар да төгәл аерылып һәм ерактан үк күренеп тора. Күләмнәре әллә ни зур булмаса да.

Кайдадыр янәшәдә генә бер урыннан икенчесенә күчену мөмкинлеге чиге. Бар гамәл – павильонга охшаш төгәл чикләнгән әлеге киңлектә бара: аның диварлары урынына акрын гына күчеп бара торган караңгылык, аның артында бернәрсә дә юк, һәм без ни бар, шуны гына күрә алабыз. Шул ук вакытта бүлмәдән чыгу, баскычтан төшү мөмкинлеге дә бар. Подъезд ап-ачык күренеп тора, бөтен үзенчәлекләре белән. Аннары, берәрсе белән сөйләшә-сөйләшә, күрше йортка да керергә мөмкин...

Тәгаен затлар. Бар да моның икенче дөнья икәнен белеп яши. Бөтенесе дә безнең өчен реаль тормыштан кебек.

Мин бу сорауны биргәндә, үземнең аңсыз аңым белән алардан моның ни икәнен сораштырам, алар килешәләр дә сыман – әйе, бу төш кенә, әмма барыбер тормыш кебек, монда шулай ук һәркемнең үз дөньясы, үз эше, проблемалары (тегендәге кебек дөньякүләм түгел, билгеле), үзләренеке генә, янәшәдәгеләр белән генә.

Иң мөһиме, анда да шундый ук кешеләр, өннән күчкән. Мин тормышта күрмәгәннәре дә бар, алар да кайдадыр яши. Билгеле, инде тормыштан киткәннәр белән дә очрашкалыйсың...

Бервакыт мин төштә чынбарлык тормышта миңа шактый бурычлы кешене (исемен атап тормыйм) күрдем һәм кинәт ни өчендер ул барысын да киресенчә, мин бурычлы итеп китереп чыгарды. Шуннан соң мин аның иңенә төшәчәк проблемаларны күрдем һәм алар аңа төште дә...

Мондый очраклар күп булды...

**Алтынчы.**

Мәгълүмати технологияләр, кичә генә үзгәрмәс булып тоелган күп нәрсәне кысырыклап чыгарып, көндәлек тормышка зур тизлек белән кереп баралар.

Мөгаен, якын киләчәктә кешеләрнең гади генә аралашуы да Интернет кебек элемтә аша гына башкарылыр һәм ул нормаль булып саналыр. Шулай итеп, китап уку, газет-журналлар, кино-театрлар, концерт-кичәләр, очрашу-әңгәмәләр онытылачак. Бүлмәдән чыкмыйча гына укырга, имтихан бирергә, шахмат уйнарга, офиска бармыйча гына эшләргә һ.б. мөмкин булачак, ә телевизор белән телевидение, өй компьютерының мәгълүмати каналларының берсе булып, үткән заманда калачак.

Әмма үтәр еллар һәм кеше зур бер сусау белән китапка ябышачак, тере театрны торгызачак, табигатькә, яшел бакчаларга чыгачак, андагы эскәмияләргә утырып газет укыячак, шахмат уйнаячак, тере кешеләр белән тере аралашуны эзли башлаячак, әгәр инде соңга калмаса, соң булмаса...

**Җиденче.**

Шәһәрләргә исем очраклы гына кушылмый.

Исемнәрендә аларның язмышы, тәкъдире.

Кеше, үзе дә белмәстән, аңа бу язмышны, мәгънәне сала, кайчакларда ниндидер көч моңа мәҗбүр итә.

Күп мисал китереп тормыйм, бары тик Чернобыльны гына атыйсым килә. Монда фаҗига булды инде, әле ниндие. Бүгенге көндә күпме шәһәр һәм торак пункт үз сәгатен көтеп ята...

Әллә бу бары сүзләр уены гынамы яисә аннан туган ассоциацияме; ә булган фаҗигале вакыйгалар, хәлләр безне моңа ышанырга мәҗбүр итә...

**Сигезенче.**

Кешелекнең киләчәге – Дөнья Океанында, бу гаять зур тере организмда.

Дөресрәге, XXI гасыр Океанны ачу гасыры булачак.

Югарыга, күккә һәм йолдызларга күзләрне төбәп, безнең җирне актарып ташлавыбыз мөмкин. Язмыш шул ук вакытта безнең янәшәбездә генә булган гаҗәеп зур киңлекләргә җәелгән суны күз уңыннан җибәрүне, ягъни тынычлыкта калдыруыбызны хуп күргән.

Никтер без аның чиксез су киңлекләре генә булмыйча, Җир дип аталган Планетабызда тормышның башланып китүе дә шуннан икәнен бик тиз онытып җибәргәнбез.

Океаннар эчендәге серне без һаман да белеп бетермибез әле.

Ахыр чиктә, без үзебез дә нигездә шул Судан торабыз лабаса: без аның балалары, ул тудырган җан ияләре. Шуңа күрә җир йөзендә без үзебез җимергән балансны шул Су белән тергезеп карарга кирәктер, бәлки.

Әмма шунысы билгесез: бу юлы Океан, кайчандыр безгә тормыш биргән Океан, коткарып кала алырмы яки, киресенчә, һәлакәткә илтерме...

## XXI ЙӨЗ БУСАГАСЫНДА

Кая карама, кая гына барма – бөтен җир: урамнар, базарлар, вокзаллар, подъездлар, кибет ишеге төпләре ач-ялангач, хәер сорашып торган кешеләр һәм, ни кызганыч, балалар белән тулды.

Дәүләтнең, дөресрәге, җирле хакимиятләрнең бу хәлдә җаваплылыгы нинди?

Үз-үзеннән канәгать, тук кыяфәтле, бөтен нәрсәне – кредитларны, ссуда, ресурслар, квартирлар, инвестицияле проектлар, хакимлек итүче структураларда җитәкче урыннарын, бюджет сатып-алуларын һәм башкаларны элеккечә гел үзләре арасында гына бүлгәләүчеләрнең җаваплылыгы бармы?

Шуның өстенә хезмәт хакына, пособиеләр түләүдә миллиардлаган бурыч, йөз меңләгән эшсез, коррупциягә каршы обывательгә йөз тоткан ялган көрәш...

* * *

Кулны күкрәккә куеп әйткәндә, Президентны вакытыннан алда сайлауда бернинди дә фаҗига юк.

Тәгаен хәлләр шуны таләп итә – сайлап алырга кирәк.

Әмма шунысы бар – сайлап алу мөмкинлеге тудыручы кешеләре юк, ягъни бүгенге көндә бездә сайлап алу мөмкинлеге юк – бер караганда, бу әйбәт тә.

Чөнки безгә, сайлаучыларга, кемне сайлыйм икән, дип баш ватасы да булмый.

Ә алдан сайлау яки ашыгып сайлау, аны билгеләү безне, имештер, коткарырга теләгән таркалу, җимерелү процессын тизләтәчәк кенә.

Чөнки безне кая гына кертеп җибәрсәләр дә – аның гаебе юк.

Җитәкчеләребезнең, хакимнәребезнең бөтен зирәклеге менә шунда.

Гаепле һәрвакыт Президент үзе билгеләп куйган хөкүмәт булачак.

Бүгенге хөкүмәтебез, персональ составы бары тик ирония һәм көлке тудыра торган (моны күзлексез дә күреп торабыз) безнең хөкүмәт нәрсәгә сәләтле, дөресрәге, нәрсәгә сәләтле түгел?

Бу җыенга игътибар беләнрәк карагыз әле...

* * *

Хәзерге вакытта кулында хакимлек булганнарның һәрберсенең авторитар режим урнаштыруда үз урыны бар.

Тарихка алар нәкъ менә шул яктылыкта кереп калдылар.

Сүзнең кем турында булуын алар бик тиз төшенәчәкләр.

Шулай булса да, бу – аерым бер кешенең гамәлдәге режимда шәхси хакимлеге мәңгелек, дигән сүз түгел.

Чөнки бераз вакыттан соң шул ук, кайчандыр дәшми-тынмый гына, оят бер нәрсәдән котылган кебек коммунизмнан, аннан демократиядән ваз кичкән кешеләр авторитаризмнан да, үзенең юлбашчысыннан да, миллион сәбәп табып, күзгә карап ваз кичәчәкләр.

Һәрвакыттагыча кебек, акланырлар да. Үрнәк алыр, иярер мисаллар шактый...

*Гыйнвар, 1999*

**ЧИР**

Тирә-юнегезгә игътибарлырак булыгыз әле. Алга да, артка да борылып карагыз. Сезнең янәшәдә кемнәр?

Кемнәр белән янәшә яшисез, кемнәр белән бергә эшлисез, җитәкчегез кем, авыл, шәһәр, бистәгез белән кем җитәкчелек итә һ.б. – мөһим мәсьәлә.

Игътибар белән күзәтсәгез, иманым камил, аларның барысында да, хәтта үзегездә дә аңлатып бирә алмастай ниндидер сәерлекне күрерсез. Бу – гади генә әйткәндә, чир, авыру билгеләре. Әхлакый һәм рухи чир билгеләре.

Безнең һәрберебез ни белән булса да чирли, димәк, җәмгыятебез дә чирле.

Дәваламасаң, чир тарала, үз җәмгыятендәге һәр кешене зарарлый, алманы корт ашаган кебек, бөтен почмакларга үтеп керә.

Чир таралдымы, «корт» кердеме, инде җәмгыять акрын-акрын, әмма тәгаен, чери, җимерелә һәм таркала башлый...

Үзегез уйлап карагыз: кичәге үрнәк һәм кристалл кебек чиста ҮК аппаратчысы, провинциягә килеп төштеме, кинәт үзгәрә дә куя – җирле әһәмияттәге акулага әйләнә; заманында безгә партбилетлар биргән элекке райком секретарьлары нишләде? – сөйләргә тел әйләнми хәтта...

Боларның барысыннан соң, тиздән тормышыбыз матураеп, илебез чәчәк атачак, дигән башкатыргыч сүзләренә үзләре генә түгел, бер генә кеше дә, хәтта бала да ышанмый инде...

Әлеге картаеп беткән чирле кешеләргә ничек ышанырга кирәк?

Яңалары да элекке җитәкчеләреннән ким куймый: узган буыннар ничәмә еллар, гасырлар төзегән, булдырган бөтен нәрсәне тураклап бетерделәр.

Өстәгеләрне бар да күрми. Ерак бармыйча гына, янәшәдәгеләрегезгә күз салыгыз.

Күршеләрегезнең берсе, төн кергәч, подъезд ишеген салдырып, тәрәзә пыяласын алып, кайдан урларга була, шуны өенә ташый, ә иртә белән, адәм рәтле, намуслы кеше кебек, сезнең белән баш иеп исәнләшә.

Өлкәннәр мисалында балалар үсә: мәктәптә бер-беренең дәфтәрен, ручкасын, аяк киемен, хәтта өс киемен урлый.

Инде болар турында, борчый, дип кенә әйтеп булмый, бу чирле җәмгыятьтә яшәве куркыныч.

Әлеге чир, ахыр килеп, безнең барыбызны да таркатачак көн әллә ни ерак та түгел кебек тоела.

*Атырау, февраль, 2000*

* * *

Көннәрдән бер көнне, 1973–1974 елның апрель-май айлары булса кирәк, ике туган абыем Шакир белән Гурьев шәһәре буйлап атлыйбыз һәм, гәпләшә торгач, «Һәр кеше үзенең фани дөньядан китәсе көнен белсә, кешелек өчен яхшырак булмас иде микән?» дигән сорауга килеп төртелдек.

Бу турыда сөйләшү озакка бармады, нигезле дә түгел иде; ашыкмыйча гына фикер алыштык та, тәгаен бер нәтиҗәгә килмичә, башка темага күчтек...

Әмма, берничә ел үткәч, Шакир туганым, безне тирән хәсрәткә салып, әлеге мәсьәләне үзенчә хәл итте – бу дөньядан үз теләге белән китеп барды.

Һәрберебез хәтеренә көчле һәм йомшак күңелле, игелекле кеше булып кереп калды...

**ВИТЬКА КОРОБКИН ҺӘМ ЧЫПЧЫК**

*Балаларга. Германиядән өйгә кайтып китәр алдыннан, кичен язылды*

Витька Коробкин көн саен
Камчаткада «котыра».
Ә бүген тәрәзгә карап,
Борын казып утыра.

Кинәт тәрәз кәрнизенә
Килде кунды бер Чыпчык.
Тирә-якка каранды да
Тәрәзне куйды чукып.

Шулчак күзләре очрашты –
Витька бик тиз җанланды.
Түгәрәк борынына тыккан

Бармагын тартып алды.

Бер-беренә карап торды
Бу ике «җен орчыгы» –
Бишенче «В»дан Коробкин
Һәм күрше йорт Чыпчыгы.

Таныштылар тиз арада,
Башларын бора-бора.
Чыпчык та гайрәтле икән,
Бер дә курыкмый тора.

Карый-карый арыгачтын,
Һич тиктормас бу Чыпчык.
Пыяланы чукып алды –
Әйдә, имеш, син дә чык.

Шулчак тәрәз ачылып китте,
Тавышсыз-тынсыз гына.
Коробкин Витя, шаккатып,
Авызын ябалмый тора.

Күзләр түм-түгәрәк булды,
Ярый класс сизмәде.
Шунда Чыпчык телгә килде –
Сүзен әйтми түзмәде.

«Җитте сиңа утырырга,
Әйдә, оч минем арттан!»
Витька җавабында әйтте;
«Мин очалмыйм бит, братан!»

«Оча алмыйсың шул, балбес,
Сугышырга beləсең.
Рогаткадан безгә атсаң,
Чукырбыз баш түбәсен», –

Дигән генә иде Чыпчык,
Кыңгырау шалтырады.
Витьканың каты тавыштан
Куллары калтырады.

Очып төшә язды шулчак
Утырган урыныннан.
Караса, әлеге Чыпчык
Шул мизгелдә юк булган.

...Камчаткасында Коробкин
Уйлый-уйлый интеккән:
Төшме соң бу? Әллә өнме? –
Һич аңлый алмый икән.

*Мюнхен, гыйнвар, 1994*

## АРАХНОИДИТ*

*...Минем чигәләремне ышкыйлар. Нидер әйтәләр. Лекцияләрдән кайтарып җибәрәләр.*
*Лифтта төшеп, Мюнхендагы «Инлингуа» дигән халыкара лингвистика мәктәбе ишегалдына чыгам.*
*Эскәмиягә килеп утырам, күзләремне йомам. Уйларымны туплыйм.*
*Бар да моннан ун еллап элек Гурьевта булганча...*

Үтәли сызлап авырту чигәләремне кыса.

Кашлар, күз кабаклары, керфекләр күтәреп булмастай авыр. Күзләрдә кечкенә генә ак таплар, нокталар пәйда була, үтәли тишеп чыккан кебек – бушлыкка, чиксезлеккә китеп югалалар.

Чигәләрдәге, күз өстендәге авырту басымында аң китә башлый. Бу борчулы мизгелдә яшәү мәгънәсе генә игътибар үзәгендә кала – тизрәк өйгә кайтырга, караңгы бүлмәмә чумарга, май белән шикәрле кайнар чәй эчәргә һәм ятып торырга. Түзәргә, түзәргә, ничек тә үткәреп җибәрергә...

Тик иң куркынычы әле башлана гына. Сул күз, дөресрәге, баш мие капкачының сул ягы акрынлап сүнә, күз күрми башлый. Әйләнә-тирә ап-ак, күзләрне, аңны кисә торган кискенлек, чигәләрдә, башта авырту көчәя.

Бераздан шул ук хәл уң күзгә күчә.

Әйләнә-тирә дөньяның күләмлеге тулысынча юкка чыга, бары тик янәшәдәге объектларның чагылышы гына кайдалыкны белдерә.

Төсләр дә юкка чыга, күз алдымда бары тик ак нурлар, шәүләләр генә биешә.

Чигәләрдәге авыртуга түзеп булмый, ниндидер тимер, металл белән кыскандай, баш үтереп чатный.

Моның белән дә бетми әле.

Кризис көчәя бара.

Инде тел, битнең уң ягы берни сизми башлый, яңак сөякләре авыр хәрәкәтләнә. Яшәү мәгънәсе юкка чыга...

Кемдер кабинетыма кереп, нидер сорый.

Мин аны ишетәм дә, ишетмим дә, сүзләренең мәгънәсен аңламыйм. Оеп бара торган агач телемне көчкә әйләндереп нидер әйтәм, инде үз сүзләремнең мәгънәсен аңламыйм. Гадәти сүз миңа бик сәер булып тоела, әйтерсең мин аларны беренче ишетәм. Ни әйткәнемне аңларга тырышам – булмый.

Тирә-ягымда бары тик ак, аңымны җибәрә торган нурлар гына.

Кинәт бар да тынып кала.

Куркыныч тынлык. Янәшәдә беркем дә, берни дә юк сыман.

Симптомнары – баш сөяге эчендә басым арта, озакка сузылган баш авыртуы, күз күреме начарая, баш әйләнә, ишетү сәләте кими, тигезлек, тотрыклылык югала.

Мин торып басам. Баш авыртуы көчәя.

Һәр адым чигәләргә авырту булып суга. Бары тик сул ягым белән генә, баш миенең сульяк ярымшары белән генә ориентлашам, уңъяк берни сизми, берни күрми. Тоташ ап-ак пәрдә...

Куллар, баш – боз кебек.

Туңам. Нык туңам. Кулларымны, битемне җылытмакчы булып ышкыйм. Ярдәм итми.

Ап-ак караңгылыкта капшап кына пальтомны, шарф, бүрегемне табып алам. Киенәм. Башта уй: «Киемнәремне онытмыйм тагын, урамда – февраль...»

Көч-хәл белән урындыкка барып утырам, электр утын кабызам, күзләремне йомам. Ярымкараңгыда шактый утырам – хәлем яхшырмый: бер үк хәлдә.

Иң мөһиме – начараймый.

Аңымда. Бары тик тирә-юнем аңлаешсыз, бу дөньяда, яшәештә мәгънә юк. Шулай да Мин әлегә биредә, Мин – бар.

Кайдалыгымны, кемлегемне аңламасам да.

Башымда коткарыр төсле бер генә уй – тизрәк китәргә. Утырган урынымнан торам да ишеккә юнәләм.

Телем тәмам ойый – әйләнми. Җиңелчә генә кычыту һәм калтырау. Бер сүз дә әйтә алмыйм.

Һава җитми. Тын алуы авыр. Артериаль басым төшә. Йөрәк турысында авырту барлыкка килә.

Шул мизгелдә, баш әйләнеп, ишек яңагына килеп бәреләм...

Бу – әле юлның башы гына.

Коридор буйлап утыз метр чамасы юл үтәргә, баскычтан төшәргә кирәк. «Иң мөһиме: кеше игътибар итмәсен өчен гадәттәгечә тигез адымнар белән барырга кирәк, һәрвакыттагыча – эш белән чыгып барам, янәсе».

Үч иткәндәй, коридорда неон лампаларының барысы да балкып яна. Алар мине тулысынча сукырайталар. Туры сызыктан барырга тырышам, кайчакларда стена ярдәмгә килә, ярый әле коридорда кеше юк, тып-тыныч...

Элеккечә чигәләр чатный.

Коридорны үтәм. Караңгы баскычтан төшеп барам. Биредә җайлырак – караңгы, күз күремен яхшыртырга мөмкин.

Чыгу ишеген ачам – күзгә яңадан яктылык китереп бәрә, бу юлы инде нурлар чәчеп торган кояштан.

Баш әйләнә, ак таплар, ак нурлар...

Пальтомның якасын күтәреп куям, аска – аяк астына карыйм, барыбер абынам, эрегән карда таям, баруымны дәвам итәм. Баш элеккечә үк әйләнә, хәзер саф һавадан булса кирәк. Кабат тыным кысыла башлый.

Барып булмый, елга яры буйлап сузылган култыксаларга кадәр юлның чиге юк төсле...

Һиһаять, алдымда – бары тик Урал елгасы.

Шундук башыма уй килә: быел, язның иртә килүе сәбәпле, кар башка еллардагыга караганда иртәрәк эри башлады, елгада да иртүк әллә никадәр майна, балык тотучыларның кечкенә бәкеләре иде, көне буена алар тагын да арткандыр инде.

Урал аша боз өстеннән өйгә якынрак, күпер аша әйләнеп кайтсам – кайтып җитә алмам.

Пирс култыксаларына таянып торам – елгада ни хәлләр бар икән – шуны күзлим, тик берни күрмим.

Башымдагы һәм чигәләрдәге көчле авыртуга да карамастан, хәлем бераз яхшыра башлый, аңым кайта, текәлебрәк карасаң, предметларны да аерып була.

Шулай да алдагы әйберләр күзгә күренми, күзне томалаган ак пәрдә аркасында елгада балыкчыларның бармы-юкмы икәнен дә белеп булмый. Мөгаен, бардыр. Алар боз кузгалганчы утыра анда.

Ул-бу була калса, алар миңа да ярдәм итәрләр әле, дигән ышанычым да бар...

Кинәт минем уйларымны һәм каушавымны, икенче үлчәмдәге дөньядан килгәндәй, әллә кайдан ишетелгән тавышлар бүлә; минем яннан целлофан пакет тоткан (монысын мин тәгаен күрдем) ниндидер бер үсмер егет мине бәреп ега язып йөгереп үтә.

Баскычтан тиз-тиз төшүен ишетеп, аның артыннан китмәкче булам.

Мин акрын гына төшеп җиткәнче, ул минем күз күрememнән югала. Елга буенда берүзем басып калам. Боз өстенә су күтәрелгән.

Кире китүдә мәгънә юк, барыбер алга барырга кирәк, су ерып булса да, бәлки, бар да җайланыр. Боз өстендәге суда яткан һәм яр белән бозны тоташтыручы ташлар һәм такталарга басам, бераз талпынып, боз өстенә килеп керәм.

Әле дә ярый җиңелчә генә чыгып киткәнмен, сумкамны алмаганмын, боз, җебегән шикәр кебек, бик көпшәк, уалучан. Берничә адым ясаган идем – майнага килеп төртелдем – андагы боз кебек салкын су кояш нурларында җемелдәп тора.

Инде хәзер иң куркынычы башлана – балыкчылар бәкесенә яки агым белән юылган майнага эләкмәсәм ярар иде.

Алда – майна, артта – су, аннары гына яр.

Кире китеп булмый бит инде. Бөтен көчемне җыеп, бар игътибарымны туплап, акрын-акрын гына каршы ярга таба китәм.

Борчылмыйча, тыныч кына барган уңайга әллә кайдан килеп чыккан балыкчыларның сизелер-сизелмәс контурларын шәйләп алам.

Тик кар белән кояш тагын күзне чагылдыра. Туктап калам.

Күзләрне яңадан ак пәрдә каплый. Тынлык. Тавышлар урынына – резонанс кебек дерелдәп торучы авырту.

Объектларның күләмлеге, тирәнлеге бөтенләй юкка чыга. Ара ераклыгын да күз алдына китерә алмыйм.

Күзем күргән кайбер нәрсәләр – кәгазьдә генә кебек, бернинди үлчәме юк.

...Кинәт каяндыр кычкырган тавышлар ишетелә.

Як-ягыма каранам. Берни күрмим.

Нәрсәдер булган.

Бу кычкыруларның мәгънәсенә төшенмәкче булам – кемгә кычкыралар? Ни дип? Берни аңлашылмый.

Нәрсә эшләргә? Бәлки, минем алда башка боз юктыр, бәлки, алар миңа кычкырадыр?

Бөтен тәнем белән дерелдәп куям. Ярларның ни монысын, ни тегесен күрмим. Боз өстендә озаклап хәрәкәтсез басып тору да куркыныч – боз шактый көпшәк, ышанычсыз. Тик кая барырга? Кайчан да булса теге ярга чыгып җитәрменме?

Шулай да интуиция белән алга баруымны дәвам итәм.

Әле һаман кемдер кайдадыр кычкыра. Инде якында гына ишетелә.

Шулчак нәкъ минем алда әле бая гына мине узып киткән теге үсмерне суында әйләндереп торучы зур майнаны күреп алдым.

Тартып чыгарырга кирәк бит инде моны. Тик ничек итеп?

Як-ягыма каранып, янәшәдә тагын кем дә булса бар микән, дип ачыкларга тырышам. Балыкчылар шәүләсен күрәм, тик алар еракта.

Алга таба бар да үзеннән-үзе, нәкъ автопилоттагы кебек эшләнә. Андый төгәл, тиз һәм тәвәккәл гамәлләрне мин үзем дә көтмәгән идем.

Бүгенге көн дәвамында инде ничәнче мәртәбә, бар көчемне туплап, бары тик сиземләү буенча гына гамәлләр кылам. Әйтерсең бу хәлләр минем белән булмаган яки минем бу гамәлләрне беренче генә башкаруым түгел: боз өстенә сузылып ятам да тыпырчынып торган үсмергә якынрак шуышып киләм, сүзсез генә үземнең озын шарфымны муенымнан алып, бер очын үсмергә сузам. Ул, шулай ук сүзсез генә, аны шундук тотып ала.

Шуннан соң акрын гына тарта башлыйм һәм, ниһаять, аны судан тартып чыгарам.

Мин яткан җиремнән торып та өлгермим, үсмер, куркуыннан күзләрен шарландырып, юеш пальтосында, акыра-акыра кирегә, ярга таба җан-фәрманга йөгереп китә.

Мин шунда гына аңыма киләм. Балыкчыларның кычкыруы (араларында, миннән ерак та түгел, бер күршемне танып алам) көлүгә әйләнә. Бераз аптырап торганнан соң, мөмкин булган кадәр тиз адымнар белән алга атлыйм.

Боз өстеннән үткән калган юлны хәтерләмим...

Өйдә беркем дә юк.

Утны кабызмыйча гына, шикәр белән берничә чынаяк кара чәй эчәм дә, башымны яулык белән каты итеп кысып бәйләп, залга үтәм. Тәрәзә пәрдәләрен ябып куям, диванга ятам да күзләремне йомам. Көч җыярга, хәлләнергә кирәк...

...Әйе, ул чакта Гурьевта нәкъ менә шулай булган иде.

Хәзер, менә бу минутта да шул ук хәл – бернинди каршылыксыз, тизрәк фатирга кайтып җитү. Эскәмиядән торып, акрын гына (нәкъ төштәге кебек) метрога керәм, эскалаторда түбән төшеп, поездга утырам.

Беркем дә миңа игътибар итми. Тышкы яктан берни дә сизелми булса кирәк. Шулай да үземнең юл йөрү билетымны (проездноемны) барлап куям – анда минем Мюнхендагы адресым язылган. «Роткройцплатц». Өскә күтәреләм. Автобус көтәм. Хәлем авыр. Башым әйләнә. Өстәвенә кояш көчле яктырта, тирә-юнемдә яңадан ак таплар. Җитмәсә автобуста да кеше күп. Бөркү. Һава җитми, тын алуы авырлаша, күңел болгана, берни күрмим. Артык бөркү булганга, буылам һәм беренче тукталышта ук кем беләндер бергә автобустан төшеп калам.

Эскәмиягә килеп бәреләм. Утырам. Башым әйләнә, ничек тә түзәргә кирәк. Күзләремне йомам. Йөрәк клапанының ярсып эшләвеннән чигәләрдә авырту. Беттем.

Берни ишетмим, берни күрмим – бары тик тынлык, үтергеч тынлык.

Бераз вакыттан соң, үземдә көч табып, тагын автобуска утырам. Башым шартларга җитешеп авыртканга юлның очы-кырые юк шикелле тоела.

Ниһаять, «Гнейзенауштрассе». Автобустан чыгам.

Абына-сөртенә, берни күрмәгән хәлдә өйгә керәм, югарыга, үз бүлмәмә күтәреләм. Каешымны салып, башымны кысып тарттырып куям. Артык тартылуга чыдамыйча, каешым шартлап өзелә.

Аңкып торган исле бәлзәмне чигәләремә сөртәм дә, калтыранган кулларым белән су эчеп, барып ятам.

Авырту акрын гына китә. Күзләрем дә күрә башлый. Телем дә үз хәленә кайта. Озак авырып яткандагы кебек, хәлсезлек, арыганлык...

*Мюнхен, 15 ноябрь, 1993*

## СЮРРЕАЛИСТИК ОЧЫШЛАР

### МӘЧЕ БАЛАСЫ

...төнге ярымкараңгылыкта ниндидер тонык ак нур белән яктыртылып торган рәт-рәт тезелгән агач куаклары, биек булмаган агачларның чайкалып торган аерым ботаклары – барысы да куе яшел (яшь, яңа ачылган яшеллек) төстә (чыршыны хәтерләтәләр), көтмәгәндә ни өчендер көрән төскә керде һәм кинәт алар, минем теләгем буенча, бер мизгелдә бергә җыелдылар да бу көрән төстәге тәпиләрдән, өлешләп-өлешләп, мәче баласы җыелды. Ул шундук йөгереп китте, аллеяның асфальтланган сукмагында уйнап йөри башлады. Бу – Мурзик түгел, икенче бер мәче баласы иде...

### КӨРӘШ

...бүлмәмдәге диванга килеп яттым, әмма ниндидер куркыныч тоеп, сикереп тордым да миңа һөҗүм итүчеләргә якынайдым, тик аларны тота алмадым – каядыр китеп югалалар иде. Аннары аларның кая кереп качуын аңлап алдым: бүлмәмдә иң кыйммәтле әйбер – телевизор, шуңа күрә пычак алдым да экранның нәкъ уртасына төбәп җибәрдем, ул аңа майга кергән кебек шома гына, йомшак кына кереп китте. Аннан сары шар килеп чыкты. Аны очып килгән шәпкә тотып алган идем, майлы булып чыкты. Үзе зур да түгел, теннис тубы хәтле генә. Мин аны тоттым да сыттым, эченнән нәрсәдер агып чыкты. Шуннан соң бу гамәлләрне өч мәртәбә кабатларга туры килде – ватылмый торган экранга пычак ыргытырга, майлы тышчалы сары массаны сытарга...

Аңыма килсәм, үзем һаман яткан хәлдә. Кемдер әйтте кебек: «Тәнең гел ятып торды, ә җаның көрәште, нәрсәнедер куды». Мин моны алар халәтенә кергәнгә эшли алганмын икән, алар булып, тәнсез, үтә күренмәле булып, әмма ләкин шул ук вакытта кеше кыяфәтендә, сурәтендә калып...

### КАРАШ

...мин икенче катта тәрәзә янында басып торам, шул ук вакытта үземне аста, бу йорт янында күрәм. Карашымны аска күчерәм. Хәзер мин өй каршында, таш түшәлгән юлда басып торам, шул ук вакытта

икенче катта тәрәзә янында басып, миңа, ягъни үземә карап торган үземне күрәм. Ике очракта да янәшәмдә кемдер (әллә шәүләме) басып торганын сизәм. Бәлки, ул бер үк вакытта астан да, өстән дә миңа карап торучы һәм күчеп йөрүче мин үзем булганмындыр...

**КЫЧКЫРУ**

...кемнеңдер кара куллары (үзләре хатын-кызныкына да охшаган – җиңел, йомшак, әмма тыгыз), йон шарф төсле, арттан һәм өстән көчле итеп бугазымны, битемне, кулларымны томалый. Аңыма килә башлап, хәрәкәтләним дисәм, шунда гына аңладым – мине кемдер буа, каршылык күрсәтергә тырышам, кычкырырга, ычкынып китәргә, тик боларның барысы да кайдадыр эчтә бара, шуңа күрә бернинди аваз да, кычкыру да миннән чыкмый. Минем кычкыру кайдадыр тирәндә йотылып кала. Бәлки, кычкырырга маташуым миңа шулай тоелган гынадыр, ә гамәлдә – инде берни дә эшләп булмый иде...

**ВЕРТОЛЕТ**

...кояшлы салкын бер көндә мин, башкалар кебек үк, боз белән капланган елга, күл яки диңгез өстендә басып торам һәм вертолетның очып китүен күзәтәм. Мондый нык салкын көндә ни өчендер ул артык кинәт күтәрелде кебек тоелды – бер-бер хәл булмагае дип, шикләнеп уйлап куйдым. Тиз генә күтәрелеп, үз биеклегенә менде дә боз өстеннән очып китте, нәкъ шул мизгелдә һавада шарт иткән тавыш яңгырады – вертолет салкыннан әллә ярылды, әллә шартлады: ян тышлыгында тишек барлыкка килде һәм ул, янтаеп, боз өстенә барып төште, шундук боз ярылып, салкын суга чумды; башка тагын уй килде: эчендәге кешеләре шартлаганда үлгәннәрме яки әле хәзер генә, вертолетлары белән бергә суга баткач, бозлы суда һәлак булганнардырмы – аларга инде барыбердер...

**КӨЗГЕ**

...төнге ярымкараңгылыкта йокы бүлмәсенең бер почмагында торган ялгыз көзге серле нурлар белән балкып китте.

Һәм бары бер мизгел элек кенә кап-кара һәм хәрәкәтсез бу көзге караңгылыгында эчтән яктырып торган кечерәк кенә тонык тукыма кисәге күренде.

Әүвәл хәрәкәтсез эленеп торды да аннары акрын гына көзгедән йөзеп чыга башлады, әйтерсең болар (бүлмә белән көзге эче) – бер үк пространство, бер үк киңлек.

Тонык кына нурланып торучы бу тукыма кисәге көзгедән чыга башлагач, очкын чәчеп торган балкышның җиңелчә чатырдавы ишетелде, һәм көзге эчендә аның икенче сурәте пәйда булды, әмма ул, көзгене дә, бүлмәне дә яңадан караңгылыкка күмеп, шундук юкка чыкты.

Белмим кайдан килеп чыккан бу тукыма, инде реаль, чын әйбергә әйләнеп, шуңа күрә әйләнә-тирәдәгеләргә сагаеп карап алгач, бүлмә уртасында эленеп калды.

Аннары хәрәкәтсез караңгылыкта җиңелчә генә җилфердәп һәм ниндидер фантастик, күзләрне чагылдыра торган тонык яктылык белән яктыртып, кинәт миңа таба очып килә башлады...

**ОЧЫП БАРГАНДА**

...җиңелчә баш әйләнүне һәм арткы яктан калак сөякләренә иңгән калтырауны сизеп, терсәкләремдә күтәрелеп һәм идәннән бераз этелеп, мин иркенләп һәм салмак кына очып киттем... Як-ягыма каранып алганнан соң, кулларымны алга суздым да һавада, нәкъ судагы шикелле, җәелеп китеп, бүлмә буйлап бик җиңел, үземнең авырлыгымны бөтенләй сизмәгән хәлдә очып йөри башладым. Тезләрем белән этелгәндәй хәрәкәтләр ясап, түшәмгә кадәр менеп җиттем. Кемдер астан миңа карап тора. Әмма ул яки алар минем кебек оча алмыйлар, моны тәгаен хәтерлим. Миңа рәхәт, җиңел, иркен, бернәрсәгә дә бәйле түгел... шунда уйлап куйдым: әгәр идәнгә төшсәм, кабат очып китә алырмын микән? Сынап карадым – барып чыкты. Тик беренче мәртәбәсендәге кебек җиңел булмады – акрын гына, сантиметрлап кына, аяк астына карап кына – шулай да күтәрелдем. Нәкъ менә күтәрелдем – очып китмәдем, бер үк вакытта идәнгә вертикаль рәвештә алга таба хәрәкәтләнүемне дәвам иттем...

**ВАКЫТНЫҢ КИРЕ ЮНӘЛЕШЕНДӘ СУ ӨСТЕННӘН ОЧУ**

...төн уртасы, үземнең эшкә кия торган пиджагымны җилкә аша аркама салдым да шәһәрнең үзәк урамыннан атлыйм. Кинәт, минем якка ыргылып, зур бер эт килеп чыкты. Үзенең галәмәт зур авызындагы үткен тешләре белән, чиратлап, минем уң аягымның табанын һәм сул кулымның чугын эләктереп алды. Батырып тешләгәнче бераз тукталып торуын күреп, мин, этнең игътибарын алу өчен, кесәсендәге кабинет ачкычлары белән бергә пиджагымны юлга, эттән шактый алга ыргыттым. Эт шунда чабып китте, пиджакны иснәп карады да әллә кайдан килеп чыккан хуҗасына ияреп юк булды. Пиджак яткан урынга килсәм, берни тапмадым – пиджак юкка чыккан. Аны эзләп бу урамның башыннан ахырынача йөреп чыкканнан соң, төн уртасында кемнеңдер катер-очкычына утырдым. Ул, тизлеген арттырып, елга дулкыннарын яра-яра башка катерларны һәм көймәләрне узып китеп, салмак кына судан аерылып, елга өстеннән оча башлады. Бу судно капитанына югалган пиджагым турында

әйткән идем, ул, хәзер табабыз аны, дип, артка бирде дә, тасманы кире чорнаган кебек, без артка таба очып киттек – вакыт кирегә ага башлады. Шунда мин үзебезнең теге эт пәйда булган урынга килеп чыгачагыбызны, мин аңа кадәр пиджагымны киячәгемне, аны ыргытмас өчен этккә карата да, аның хуҗасына карата да ниндидер гамәл табып өлгерәчәгемне, ягъни бу сюжетны тулаем үзгәртә алачагымны аңлап алдым. Кире табан очканда һәм капитан белән сөйләшкәндә тавышым, яңгыраш биргән кебек, калтырап, бераз үзгәреп чыкты, тембры да үзгәрде. Аста, кире юнәлештә без кабат теге катерлар, көймәләр өстеннән очтык, дулкыннарны да кире юнәлештә ярып уздык...

**БЕРНИ ДӘ**

...әрнеп авырту йөрәкне китереп кысты – тын алу авырлашты, аң акрын гына томалана башлады, куллар салынып төште... сәер, битараф, арыган һәм берни дә аңлатмый торган халәт – абсолют берни дә, хәтта яшисе килми...

**КУУ**

...судан көч-хәл белән чыгып, текә ярның ташлы битләве буенча өскә күтәрелгән генә идем, мине тотып алырга ашыккан мылтыклы ике кешене күрдем дә шундук кире суга ташландым. Маска белән аквалангны да киеп өлгердем. Мине чын-чынлап эзәрлеклиләр иде – шул арада әлеге мылтыклы ике кеше утырган әллә очкыч, әллә ниндидер бер судно килеп чыкты да су өстендә асылынып калып, мин чумган җиргә туры китереп суга ата башлады. Беренче ату тавышы янәшәмдә генә яңгырады, мин уйлап куйдым: эх, скафандрны кимәскә булган икән, үземнән бераз алда күрсәтеп алып, тегеләрне ялган юлга керткән булыр идем: хәзер инде бөтен эчке куәтемне туплап (авыр хәлләрдән чыгу юлы һәрвакыт бар), елга ләменә күмелдем дә шактый озак тегеләрнең киткәнен көтеп яттым, шуннан соң гына алардан котылдым кебек...

**АЯКЛАР**

...япманы бераз ачып карасам, аякларым һәм аяк мускуллары урынына бары тик сөякләр һәм сеңерләрне генә күрдем; баш миеннән килгән теләсә кайсы боерыкны шарнирларда гына хәрәкәткә китерәләр – бу коточкыч иде...

**СУГЫШ**

...илдәге икътисади хәлне, коточкыч авыр кризисны һәм өметсезлекне исәпкә алып һәм халыкны соңгы чиккә җиткерүдән, эчке сәяси шартлаудан куркып, инде сөйләшүләрнең мөмкин булган һәм мөмкин булмаган законлы һәм законсыз бөтен вариантларын кулланып һәм хәтта янауларга кадәр җитеп, күрше бердәмлек дәүләтләренең ике лидеры, бер-бере белән килешеп, бер үк көнне (беренчесе бераз иртәрәк тә) т...га сугыш игълан иттеләр; үзләренең бөтен бәласен шулардан гына күреп, шул юл белән үз халкын дөньяви мәшәкатьләрдән читләштерергә тырыштылар, әмма хакимиятне саклауның бу соңгы чик варианты да барып чыкмады – беренче көнне үк ил буйлап качаклар һәм чигенүче хәрбиләр ташкыны агылды.

**О'БРАЙЕНН ЛОС-РИОС**

...бәйге яки җиңел атлетика буенча йөгереш, финиш дистанциясе артындагы участок, стадионның йөгерү юлы кырыенда ике-өч рәт булып тезелешеп баскан күпләгән тамашачы – җанатарлар. Тәненә сыланып торган спорт костюмындагы җиңүчегә котлаулар, һәм кинәт тамаша кылучы хатын-кызларның берсе, салкын кан белән, җиңүченең аркасына ниндидер сыекча сибә һәм шундук ут төртә – халык төркеме, гипнозланган кебек, дәшми-тынмый, коты чыгып һәм шул ук вакытта кызыксыну белән күз алдында О'Брайенн Лос-Риосның гөлт итеп кабынып янып беткәнен карап тора...

**РАЙОННЫҢ ҖИР АСТЫ КАРТАСЫ**

...үзара кушылмый торган ике җир асты елгасы ...кара төстәге ике зур күл – болары нефть күлләредер инде ...биредә алтын яки шуңа охшаш бер-бер нәрсә дә булырга тиеш ...бар да кем тарафыннандыр районның әлеге җир асты картасына бик төгәл итеп төшерелгән, ягъни җир астында нинди табигый байлыклар барлыгы тәгаенләп күрсәтелгән...

*1996–1999*

## ЭПИЛОГ УРЫНЫНА

*Беләсең бит – очрашабыз әле,*
*Хәтерең сине ташлап китмәсә.*
*Утлы тәгәрмәчем юлдан түбән төшә,*
*Шуны җиткер якын туганнарга –*

*Ул шартларга тиеш, җитмәсә.*

*Боб Дилан,*
*«Утлы тәгәрмәч»*

**АВТОР ТУРЫНДА**

Тәүфикъ Әкрәм улы Кәримов 1958 елның 1 февралендә Казахстан СССРның Гурьев шәһәрендә туган. Милләте буенча Казан татары. Тарих укытучысы, сәясәт белеме, тау инженеры-геолог белгечлекләре буенча өч югары белемгә ия.

Училищеда укытучы, комсомолның өлкә комитетында инструктор, бүлекчә мөдире, бүлек мөдире булып эшли. Аннан соң нефть-газ эзләү экспедициясендә инженер, партия эшендә инструктор, шәһәр комитетында бүлек мөдире урынбасары, партиянең өлкә комитетында җаваплы оештыручы, уртак Совет-Германия предприятиесендә төп белгеч, өлкә администрациясендә бүлек мөдире урынбасары, тышкы икътисад компаниясендә эксперт, өлкә икътисад комитеты хезмәткәре, «Тенгизмунайгаз» акционерлар җәмгыятендә төп инженер. Соңгы унбер елда (1994 елның октябреннән) – Казахстан Республикасының Атырау өлкәсе акимы (башлыгы) аппараты җитәкчесе.

1993 елның тугыз ае дәвамында Германиянең Мюнхен шәһәрендәге «Linde AG» концернында стажировка үтә. 1996 елда Россиядә Президент сайлауларында халыкара күзәтче була.

1997 елда АКШның Вашингтон һәм Туссон шәһәрләрендә Казахстанның югары дәүләт хезмәткәрләре өчен оештырылган бер айлык укуларда белемен арттыра.

Гаиләле, өч бала – бер кыз, ике угыл тәрбияләп үстерә.

«Төсләр балкышы» – китап язуда беренче тәҗрибәсе.

Бу китаптан соң ул Казахстанда һәм Татарстанда рус, казах һәм инглиз телләрендә янә биш китап бастырып чыгара. «Төсләр балкышы» – татарчага тәрҗемә ителеп басылган беренче китабы.

ЭЧТӘЛЕК

Сүз башы урынына ......................................................................................................
Евразияле – мәңьеллыклар кисешендә ..............................................................
**Төсләр балкышы**
Төсләр балкышы .........................................................................................................
«Макабка бабай» ..........................................................................................................
Өрәңге яфрагының көзге регтаймы, яки Гади генә әйткәндә – Яфрак .....
Бала чак рәсемнәре ....................................................................................................
Төнге сызгыру ..............................................................................................................
Исәнме, газиз йортым!.. .........................................................................................
Нимфенбургер каналында .......................................................................................
**Башлану**
Башлану. Бу ничек булды? .......................................................................................
Сиңа һаман вакыт җитми ..........................................................................................
Киләчәкне искә алып, яки «хәтерлисеңме син, бу ничек булачак?» .........
Дерелдек ..........................................................................................................................
Мин – ?.. ..........................................................................................................................
**Katnarsis (чистарыну)**
I. Үз аңың тирәнлегенә үтеп керү
Кадаклар ...........................................................................................................................
Уяндым .............................................................................................................................
Төн. Трамвайда ..............................................................................................................
Шыксыз шәһәрдә ..........................................................................................................
II. Мәңгелек һәм чиксезлекнең акылга сыймаслыгы
Кайту ..................................................................................................................................
Танып-белү .......................................................................................................................
III. Вакыйгаларның (хәлләрнең) вакытлыча гына булуы
Уяну ...................................................................................................................................
Беренче көн иртәсе .....................................................................................................
Көн ......................................................................................................................................
Төн ......................................................................................................................................
Төнге юлаучылар ..........................................................................................................
Төнге сагыш .....................................................................................................................
Кешеләр ............................................................................................................................
Музыка ..............................................................................................................................
IV. Котылгысызлыкны һәм һәлакәткә таба баруны аңлау
Челлә ..................................................................................................................................
«Ч» вакыты ......................................................................................................................
Тынычлану .......................................................................................................................
**Хәтер сандыгыннан**

Кереш сүз урынына .....................................................................................................
I. «Татар-болгар – бертөрле»
1. Төрки болгарларның башлангыч тарихыннан .............................................
2. Идел Болгариясе .......................................................................................................
3. Руслар турындагы мәсьәләгә якын килеп ...................................................
4. Болгарлар һәм Киев Русе ..................................................................................
5. Бөек Болгар иле монголларга кадәрге чорда ..............................................
6. Монголларның Болгар иленә басып керүе ..................................................
7. Болгар иле һәм Алтын Урда ............................................................................
8. Алтын Урданың таркалуы һәм Казан дәүләтенең төзелүе ....................
9. Казан ханлыгы белән Мәскәү Русе каршылыгы .......................................
10. Казан ханлыгының җимерелүе .......................................................................
11. Болгарларның Руська китүе ............................................................................
12. Мәскәү Кремле сугышлары һәм территорияләрне яулап алу ..............
13. Идел-Урал – Русь, Россия һәм Совет хакимиятенең колониаль режимына каршы көрәштә .....................................................................................
14. Идел болгарларының юкка чыгуы ......................................................
15. Төрки телле Чулман һәм Идел болгарлары – казанлыларга мөнәсәбәттә «татарлар» этнонимының килеп чыгуы ...........................................
16. «Татар-монгол золымы», Куликово сугышы һәм Россия тарихы хәтереннән төшеп калган кайбер башка фактлар турында. Ахыр чиктә бу Казан татарлары кемнәр соң?
Соңгы сүз .........................................................................................................................
Файдаланылган әдәбият исемлеге ........................................................................
II. Кәримовлар
1. Каспий буе төбәге тарихыннан .........................................................................
2. Жилая Коса ...............................................................................................................
3. Кәримов Мифтахетдин ........................................................................................
4. Унҗиденең Бөек Октябреннән кырык бишнең Бөек Җиңүенә кадәр ..........................................................................................................................
5. «Әкрәм Кәримов хыялы» ....................................................................................
III. Әдһәм Мөфти (Мифтахетдин) улы Кәримов
Соңгы сүз урынына .....................................................................................
**Высоцкий, рок һәм футбол**
1. «Ә минем сагыш – мәңгелек кардай...» ........................................................
2. Күккә баскыч ...........................................................................................................
3. «Алтын Алиһә» ........................................................................................................
**Чит кырда**
...Ә аннары нәрсә, Галиҗәнап президентлар, яки Сезне тагын ничек атарга?.. ......................................................................................................................
Путчларга соңгы сүз ......................................................................................................
Ардым .................................................................................................................................
Чит кырда ............................................................................................................................
Яңгыр ....................................................................................................................................
Лифт .......................................................................................................................................
**Хәтерем дулкыны буйлап...**
Хәтерем дулкыны буйлап... ..........................................................................................
Төрле еллардан кыскача язмалар .............................................................................
Арахноидит ........................................................................................................................
Сюрреалистик очышлар ..............................................................................................
**Эпилог урынына**

Автор турында .......................................................

Литературно-художественное издание

***Каримов*** *Тауфик Акрямович*

**И ВСЕ ЦВЕТА РАДУГИ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Кәримов*** *Тәүфикъ Әкрәм улы*

ТӨСЛӘР БАЛКЫШЫ

Мөхәррирләре *Ф.М.Сафин, Ф.М.Хафизов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Э.Р.Миңнуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 19.10.2009.
Форматы $84 \times 108^{1}/_{32}$. Шартлы басма табагы 14,28.

Тиражы 1000 экз. Заказ В-1541.

Татарстан китап нәшрияты ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru  E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.

420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.